# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Ком бураны. *Поэма.* ....................3
Равил САБЫР. Фәхрине үтереп ташладылар. *Роман.* ....................11
Рифә РАХМАН. Идел буе – минем йортым ул. *Шигырьләр.* ....................56
Алмаз ХӘМЗИН. Кабул итәсезме?.. *Роман-фарс.* ....................61
Фәүзия СОЛТАН. Сал хәсрәтең тирән дәрьяга... *Шигырьләр.* ....................108

«МӘЙДАН – БАТЫРЛАР ӨЧЕН!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Ландыш ӘБҮДӘРОВА. Кара каплан. *Хикәя.* ....................112
Атлас ГАФИЯТОВ. Чуен аю. *Документаль хикәя.* ....................121

*Яңа исемнәр:* Ландыш РАВИЛОВА. Балакошлар инде белми хөрлек төсен. *Шигырьләр.* ...125

*Кардәш халыклар әдәбияты:* Венер ИСХАКОВ. Дуслар. *Хикәя.* ....................128

ЕРАКТАГЫ УТЛАР

Рафис КОРБАН. Таныш булыгыз: Нижгар шагыйрьләре. ....................132
Ришат РАМАЗАНОВ. Хәтер буйлап кайтам егет чакка. *Шигырьләр.* ....................133
Хәйдәр БӘДРЕТДИНОВ. Кер син миңа төннең уртасында... *Шигырьләр.* *(Рафис Корбан тәрҗемәләре).* ....................134

*Юбилейлар:* Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА. «Чорләр туа үз җырчысы белән». ....................136

*Миллият:* Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Күренекле мәгърифәтченең җан авазы. ....................140

ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЛАР ҺӘМ ЗАМАН

Шәүкәт КУНТАЙ. Бер заманнар юллары Анадолудан кичкән татар хатыннары... ....................145
Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА. Айнелхәят һәм аның хатирәләре. ....................149
Рәҗаи САНАЙ. Кызыл Россиядә бер төрек хатыны. *Романнан өзекләр.* ....................152

*Китап күзәтү:* Марсель ИБРАҺИМОВ. «Һичбер вакыт бездән «татар» дигән сүз алына алмас». ....................161

*Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы:* Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. XVI гасырның икенче яртысы – XVIII йөзнең уртасында Идел-Урал төбәгендә ислам дине. ....................164

*Замандашыбыз*: Ландыш НӘСЫЙХОВА. Олы юлның... узылганы. ....................176

*Газиз тавышлар:* Ул кабызган утлар сүнмәс алар... *(Кәрим Тинчуринның тууына – 135 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....................178

*«Ак җилкән»:* Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ. Бәләкәй Риман. ....................180

*Шаян сәхифә:* Зиннур МАНСУРОВ. Уены-чыны бергә. ....................183

*Печән базары:* Илдар ХӘЙРУЛЛИН. Юмористик хикәяләр. ....................188

«Казан утлары» архивыннан. ....................174
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....................190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 9 (1199) 2022*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 26.08.2022, график буенча 26.08.2022, басылып чыгу вакыты 01.09.2022
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-2542. Тираж 7627.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2022 ел



Флёра
Гыйззәтуллина

# КОМ БУРАНЫ

ПОЭМА

**1**

*Һәр гасырның моңы, сагышы бар,*
*Ташка язылып калган тарихы бар.*
*Һәр гашыйкның сөю җилкәне бар,*
*Сөю серен ачкан Коръәне бар.*

...Кулда – тарих!..
Өстәлемдә – Коръән!..
«Бисмилла...» дип сыйпыйм Коръәнне.
Тәңрем язган сөю нигъмәтендә
Мин соң дөрес фикер йөртәмме?

Тиешенчә аңлый аламмы мин
Милләтемнең сихри җыр-моңын?..
...Борынгы моң, чорлар аръягында
Талгын гына тибрәлдереп ала
Моң агышын көмеш быргының.

Быргы моңы сайрый хәтерләтеп
Чишмәләрнең челтерәп акканын,
Кияү белән кәләш туйлап килгән
Ак атларның тояк какканын.

Тарих сөйли: дөнья имин торса,
Шатлык чәчеп йөзләр балкыган...
Ә Иленең иминлеге китсә –
Көрәшкән дә татар кан койган.

Җан каурыен чор канына манып,
Язган ташка сөю дастанын –
Хәрәкәттә, бәрәкәттә күргән
Хыялының чынга ашканын.

Көрәш кырында да азан әйтеп
Каршылаган таңны, иртәне...
«Чишмә җыры» төшләренә кергән,
Үзе белән йөргән Коръәне.

Коръән сүзе туры юл күрсәтә
Ил-гавамга биргән антыңа.
Ирек көрәшендә ант үтәлсә,
Күңел мәхәббәткә тартыла.

---

Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА (1931) – *шагыйрә; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова, Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Йөрәгемдә шаулый карурман», «Күз нурларым», «Башкаемда дөнья исәпләре» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

**2**

*Ихлас мәхәббәткә табынып мин,*
*Зөләйхадай сөеп сызланам.*
*Сөембикә кебек сөелеп тә...*
*Сөрген киткәннәрне кызганам.*

Коръән сүзе белән тарих айкап,
Мәхәббәткә фаллар ачканда,
Мин тап булам Йосыф, Зөләйхага
Һәм меңьеллык шигъри дастанга.

Мең ел аша мәшһүр Кол Галинең
Котылганын күрәм коллыктан.
Татарстан бүген меңьеллыкка
Хәзерләнеп ята шунлыктан.

Шул меңьеллык, шул дастаннар буйлап
Сөембикә кайта ак атта... –
«Ханбикәм!» дип ярат аны, халкым,
Күзләреңә туры карат та!

Күкрәгеңә ирек иңәр, халкым,
Кулың куйсаң Коръән өстенә.
Әлегә бит татар тарихында
Коръән – калын, ирек – кечкенә!

Шул кечкенә генә ирек өчен
Күпме изге эшләр эшләнгән!
Мәхәббәттән йөрәк ярылганда,
Тик иреннәр генә тешләнгән.

Иреннәрдән, иреннәрдән генә
Бүген җиргә тып-тып кан тама.
Җанлана күк дүрт-биш гасыр элек
Шаһгалиләр корган тантана.

Ак канаты белән кан кайнаткан
Идел дулкыннарын акшарлап:
«Китәсең бит!.. Сау бул, Ханбикә!» дип,
Үкси кебек бала акчарлак.

Хыянәт һәм сөрген беркайчан да
Була алмый Идел бизәге...
Ханбикәнең сагыну-сагышыдыр –
Акчарлакның канат изәве.

Шул чорлардан бер ядкарьдер миңа –
Хәтер атлы канлы кашагам[1].
Каш ясыйм дип күз чыгарган дәвер
Ханбикәсен тотып ашаган!

Йортын, Илен утка салган аның,
Халкын кылыч аша үткәргән...
...Гаҗәпмени безнең җан авазы
Күкрәп ишетелсә күкләрдән?

**3**

*Аңым туплап, Күкләр кодрәтендә*
*Ил тәкъдирен фалдан багамын,*
*Йоласына тугры калыр өчен*
*Ил тергезгән ата-бабамның.*

...Күкләр күкри дәвер «аһ»ын ташып...
Киеремачык күңел тәрәзәм.
Тәрәзәмнән өй эченә агыла
Гүрдән кубарылган шәҗәрәм.

Күмерләнгән йөзләр. Өзгән телләр
Ни сөйләр дип фикер йөртәмен,
Шул фикеремнән кинәт «дертләп» куя
Өстәлемдә яткан Коръәнем.

Һәм шуннан соң фалым ачыклана,
Сабыр гына күзлим барысын:
Йөзләрендә үз төсмерем күрәм,
Күзләрендә тарих сагышын.

Шулай сагышланып торалар да,
Тукталалар Коръән турында.
Әрвахларга хәер-дога кирәк,
Балку кирәк иман нурында.

...Ишетә беләм: Коръән төпкелендә
Мәңге-бакыйлашкан Аң ята...
Үзебез аңламагач, дөнья хәлен
Гүрдәгеләр кайтып аңлата.

Җирдәгеләр, Күктәгеләр белән
Фани дөнья, ахры, бербөтен!
Күкләр аша ишетәм бер Тәңремнең:
«Доганы кыл!..» дигән үгетен.

[1] Өй түренә элә торган чыбылдыкның бер төре.

Бөек Тәңре безнең тәкъдирләрне
Эшкәрткәнгә алдан «кызулап»...
Чыккан җаннар җиргә кайта икән,
Җиде катлы күкне йөз урап.

Йөз урап та ләкин якынаймый
Коръән белән тарих арасы.
...Гаҗизләнеп шушы аралыкта
Бәргәләнә адәм баласы.

Адәми зат алдый, хәрәмләшә,
Дошман күреп, дуска ут ача.
Сөймәсә дә: «Сөям!.. Яратам!..» дип,
Антлар эчеп, күккә тоташа.

Ялган колы белеп торсын өчен
Хәрам антның кая тартасын,
Изге Коръән һәрбер аятендә
Ачып биргән тарих хатасын.

Йосыф, Зөләйхадан калган сөю
Безнең антны ләкин ишләгән...
...Биргән антын хыянәткә сылтап,
Кан тамырын татар кисмәгән.

Тумышыннан канын чиста тоткан,
Чиста тоткан нәсел орлыгын.
Җиде ятка туйлап кыз бирмәгән,
Бирнә итеп салып җыр-моңын.

Татар моңы һәрчак тартылган ул
Җиңү таңнарына сөрмәгә...

...Борынгы таң әнә нурын сирпи
Яшь бикәчләр торган тирмәгә.

Сөрмәле таң, шиксез, бик уяу ул!..
Уяуларның алда – чираты.
Бикәч куенында йоклап ятмый,
Ат иярли таңнан ир заты.

Күпне күргән бөркет күзе белән
Ирек күзли ир-ат таң аша.
Мин дә бүген җанга ирек ачып,
Шул таңнарны кылам тамаша.

Аң таләбем үтәп алга үтәм,
Саный-саный чорлар кәрванын.
Соңгы кәрван башы хәбәр итә
Европада сугыш барганын.

Соңгы кәрван башы – минем Әткәй!
Ул да ат өстендә иярдә!..
Озакламый күздән югалыр ул:
«Сау булы-гыз!!! Кит-ә-әм!!!» – дияр дә.

Артыннан тик ишетелеп калыр
Тупырдаган тояк тавышы.
Ут өстенә тупырдатып сала
Ирнең яуга китү сагышы.

Шушы сагыш бар дөньяны били,
Ятимнәрнең җанын яралап...
Яши ятим, җирдә үз иманын
Сагыш мәхшәреннән аралап.

**4**

*Кодрәтленең, куәтленең төсен*
*Сөю хисе ача.*
*Сагышлының, нужалының эчен*
*Выжан[2] күче баса.*

...Китте Әткәй... Сугыш «выжаннар»ы
Дәррәү күтәрелде күкләргә.
Кем әҗәле башлап язылгандыр
Алар төяп йөргән йөкләрдә?

Сугыш башлануга күңел күгем
Әверелде күк кара ярага.
...Җәелде ут-мәхшәр, илем җиргә
Чабатасын каккан арада.

Шул мәхшәргә томырылды яулар
Дөньякүләм кайгы сайратып.

Ватан чакырганда татар халкы
Китми калды соң ул кай вакыт?!

Герман явы утлы өермәдән
Өлгеррәк булды ул чакта.
Язмыш каршысына чыгып бастык
Без дә, сабый гына булсак та.

Язмышыбыз – утта өч чатлыдыр:
Без Әткәйдән калдык өч бала!
«Ул китте бит!.. Ник калдыгыз?» диеп,
Өч баладан үгием үч ала.

[2] Выжан – төклетура, бомба төягән очкычларны да без «выжан»нар дип атый идек.

Шул үч адым саен чага безне,
Үгилек ул – тәкъдир «выжан»ы!
Ил өстендә ирләр калмаганда,
Толлар тарта бөтен нужаны.

Көне-төне кырда арыш урып,
Толлар саргайганда кайгыда,
Ятим җиргә нурлы сукмак сабып,
Моңайгандыр бары ай гына...

Кызгангандыр Кояш ятимнәрен –
Вакытында калкып чыгалса...
Кояш булып Кояш һушын җуя –
Күз яшенә ятим чыланса!

**5**

*«Уф Аллам!» – дип, яшь түгүдән башка*
*Ни кала соң ятим балага?!*
*Нәселеңне корыта бит ул сугыш,*
*Ватаныңны тартып ала да!*

...Ил өстендә елап тетрәнүдә
Ай-Кояшка чыгып тиңдәшкә... –
«Ай урагым» көен җырлый-җырлый,
Кулга урак алдым ун яшьтә.

Ай-Кояшлар сүнә, бала чактан
Ут камаса өмет нурларын.
Утка тоташ... Урак очы белән
Ай нурына язган җырларым.

Язмыш яраларым тоташ минем
Үгиемнең ачу-үченә.
Ачу-үчләр ком бураны сыман
Чордан чорга үрчеп күченә.

Имансызга утлы офык ача –
Дуска үч кайтару максаты.
Гитлер, Геббельс куйган шушы максат
Бөтен Европаны аксатты.

Ничәмә ил төп әсире булды
Герман явы кылган хатаның.
Көн тудисә салым, хәер җыйды
Көчен, төсен җуйган Ватаным.

Мин дә җуйдым әткәм күзе төсле
Зәңгәрләрдән-зәңгәр һаваны...
Безнең эчтә Герман уты булып
Дүрт ел янды сугыш дәвамы.

Дүрт ел буе безнең авыл аша
Җырлап үтте күрше авыллар.
Кайгы капкан тояк эзләреннән
Күтәрелде җырлы давыллар.

Юл буенча җырладылар яшьләр:
«Мондый давыл дөньякүләм... – дип, –
Герман җиркәйләре яшел үлән:
Әллә кайтам, әллә үләм...» дип.

Без дә риза идек шушы моңлы
Җыр артыннан китеп үләргә.
Әмма мичкә ягу өчен кинәт
Утын бетеп китте өйләрдә.

...Утын бетте... барыр урман ерак,
Хәер, безгә, әнә, кыр якын.
Кышын кырга чыгып, әрем урдык,
Саклап калыр өчен җыр хакын.

Авыл өстен шундук каплап алды
Әче төтен – әрем төтене.
Мондый хәлдә авыл баласының
Еламыйча узмый бер көне.

Бала чакның яшьле куагында
Дөрләде дә әрем, дөрләде.
Әткәй үргән чабаталар тузды,
Ә яңасын үгием үрмәде.

Төтен иснәп кичен исерсәк тә,
Әрем кыры истән чыкмады.
Чөнки шунда бәйләп тотты безне
Айдан төшкән өмет сукмагы.

Көн артыннан көннәр үтте, әйе... –
Тик ул төтен күздән китмәде.
Карын казып, әрем урган өчен
Язмыш безне гафу итмәде.

Язмыш безне – тере ятимнәрен
Төпсез чабатага тиңләде.
Чабатадан ком каккандай какты,
Әмма горурлыкны җиңмәде.

**6**

*Себер сөрелгәндә, Тәңре безне*
*Озаткандыр өмет егәрләп.*
*Без бит анда эшелонлап киттек,*
*Киттек йөзләп түгел, меңәрләп...*

...Кан-тамырдан аккан бу горурлык
Тотылмасын өчен сарыфка,
Гомер итеп булыр иде, бәлки,
Соң чиккәчә Илдә калып та.

Сөрсәң, гөлләр чәчеп булыр иде
Әрем үскән кырлар түренә.
Өмет бит ул ятим балага да
Гөл бакчасы булып күренә.

Тик калдырып авыл кырында мин
Бар өметен, гөлен гомернең,
Сабыйлыктан чыгып «меңнәр» белән
Себер сөргененә сөрелдем.

Тайга гизеп анда урман кистем,
Шахтасына төштем күмернең.
Билдән су эчендә вагон этеп,
Язмышымнан алда йөгердем.

Йөгереп җиңүчеләр арасында
Әти-әнилеләр булмады.
Сугыш тынгач, алар вузга китте,
Яшьлек җырын шунда җырлады.

Аларның да җыры матур иде –
Бер сүз әйтәсем юк яманлап.
Ләкин вакладылар ул җырларны
Базар бәясенә таманлап.

Алар алган аң-белемне исә
Килеләргә салып төйделәр;
Төеп, ком таулары өйделәр дә:
«Җилгәрелер әле...» – диделәр.

Тауга карап, айлар, еллар санап,
Тау булмады Илдә беркем дә,
Җилләре дә каршы яктан исә
Эшсез калган ярлы төркемгә.

Белем армиясе бетеп килә,
Төркемнәргә, әйе, таркалып.
Комсызлардан нидер өмет итеп,
Базар карап йөри бар халык.

Мин дә шул базарда йөри идем,
Эшсезлектән сагыш кизүләп...

«Үз комыңны син дә илә!» диеп,
Язмыш сузды миңа җиз иләк.

Шулчак янәшәмдә пәйда булды
Замандашым, бергә укыган:
«Мин дә хәзер чыктым пенсиягә,
Иләк көтеп комда утырам.

Беләсеңме, акча әйбәт төшә
Комны әйбәт иләүчеләргә.
Кыш өсте бит... Ком күп кирәк була
Базар урамына сибәргә.»

Ялганмы бу? Әллә ярашумы,
Яулар өчен базар шәлләрен...
Чуклы шәл бөркәнгән замандашны
Үләр чиккә җитеп жәлләдем.

...Ком иләүче булган! Кайчан гына
«Доктор» диләр иде аларга.
Совет чоры күп докторлар бирде
Фәндә ачыш эзләп янарга.

Ул чорларда: «Комың илә!..» диеп
Әйтүче юк иде миңа да.
Язмыш, Язмыш! Зинһар, ач күзеңне!
Шагыйреңә чыкма җеназа!

Мең алтынлык горурлыгым талап,
Ком иләрлек хәлгә төшермә!..
Мин болай да шигъри моңнарымда
Адашканым күрәм төшемдә.

Шул моңнарым ком бураны булып
Өннәремә кайта кайвакыт, –
Яшим сөю тулы йөрәгемне
Нәфрәт утларында кайнатып.

«Йа бер Ходам, ярлыкагыл!» димен,
Күз салуга базар эченә.
Күлмәк киеп карар өчен анда,
Халык шәрә калып чишенә.

Товарларга бәя очсыз булгач,
Оят кача, ахры, халыкта.
Чит-ят күзләр карап кала арттан,
Тиңләгәндәй кара сарыкка!

...Мин үзем дә кара халыктан ич!..
«Сарык» сүзе шактый эләкте.
Тик мин җиде ятка ялынмадым,
Үзем җөйләп кидем кулмәкне.

Ни кызганыч!.. Чордашларым менә
Әверелгән чүпрәк колына.
Ә Ватаным оят җуймас өчен
Башын тыккан гасыр комына.

Чүпрәк кенәме соң!.. Җырлардан да
Коела бүген базар талкышы.
Ком һәм җил кузгалган һәр ноктада
Тетрәп тора татар язмышы.

Җыр ярасы, җир ярасы кебек,
Хәтерләргә тирән уела.
Милләт эзе кинәт җуелса да,
Дөнья бетәр кебек тоела.

**7**

*Ком бураны... ком бураны куба –*
*Ил иләгән иләк җиленнән...*
*«Ком бураны» көе баштан үткән*
*Һәр кайгыма каеп чигелгән.*

...Бетү аянычы үзебездә!..
Ватан таянычы кемдәдер?
Тойгыларым әгәр хата булса,
Җиңел сулар идем мин дә бер.

Юк шул әле, җиңеләеп булмый,
Базар кануннары бик коры.
«Себер шахталары ябылды!» дип
Сөйли әнә Себер дикторы.

Эшсез империя җирлегендә
Бармы ябылудан күп нәрсә?..
Ябылган җир – яла ягылган җир,
Ярый үзен-үзе күтәрсә.

Ярый: «Яңа шахта ачабыз!» дип,
Бер шарлатан сөрән салмаса!
Шарлатан ул Җир хуҗасы белән
Кара күзлек киеп аңлаша.

Ком иләүче теге «доктор» да бит,
Киеп күзлегенең калынын,
Миңа үзенең диплом эшен сөйли,
Сөйли шуны яклау алымын.

Һәм «шәп бит!» дип, ботын чабып куя:
Һичбер гаеп-хата кермәгән... –
Илдән сөрелсә дә, анда татар
Сыер җигеп, сабан сөрмәгән.

Ул шахтага төшеп, күмер урган,
Корыч комбайнга утырып.
Аракының бары агын салган,
Акча алган учын тутырып.

Тайга гизеп, татар ауга йөргән,
Күңел ачып, аю биеткән.
Үзенә дә аю жаны кергән,
Караган ул җиргә биектән.

Андый данга, андый биеклеккә
Әле һичкем аяк басмаган.
Алтын, алмаз, гранит шахталарын
Елгыр эшкуарлар ачмаган.

...Тайга тулы кыргый ат көтүе!..
Тотып ал да ауга, иярлә...
Төлке, тиен мыжлап тора, әгәр
Тун кирәксә кышын кияргә...

***

Ачышлары караңгыда калган
Хәрам хезмәт, диләр, җан ала.
Шуңа микән кара битлек кию
Мода булып хәзер санала.

...Нәрсә әйтим? – ярлыкасын Ходай!
Бар да «бодай» сукыр күз өчен...
Шушы диплом эше вакытында
Эшләгәндер үзенең «төп эше»н.

Илебездә «сөрген дипломнары»н
Якламыйлар аны тикмәгә...
Матур ялган, акча, мал артыннан
Татар кая гына китмәгән!

Тарих сөйли: борын-борынгыдан
Татар башын сөрген ашаган.
Гадел канун тудырмыйча торып,
Ил дә чыга алмас хафадан.

Татарстан дигән Ил эчендә
Баш сабалмас татар иреге!
Һәр чат саен әләм кадый әнә
Төрекмәне, әрмән, төреге...

Әләм тотып килгән килмешәкләр
Бездә хәзер йөзләп, меңәрләп...
«Безнең чатка элмә чүпрәгеңне!
Килмә!» диеп кара син әрләп.

Җилкә тамырыңа нинди хәнҗәр
Төбәлгәне шундук шәйләнер.
Чүпрәк белән күзләр бәйләнер дә,
Дөнья албастыга әйләнер!

Баш очыңа калкыр «выжан» күче:
Бомба арты бомба ярылыр.
«Теракт» дигән заман үләтенең
Яманаты безгә тагылыр.

Бөек Ватан сугышлары кичкән
Бөек тарих моны кичермәс!..
Киләчәккә кул селтәгән буын
«Теракт албастысы»н тикшермәс.

Ә буыны комга суырылгач,
Гаеп ташлар ул да татарга:
«Кирәк иде күптән богау салып,
Дөнья базарында сатарга!»...

**8**

*Һай айкала тарих!.. Һай чайкала!*
*Тарталмыйча гөнаһ-хаталарын.*
*Янып көл булганнар чиратында*
*Мин Әткәем исемен атамадым.*

...Тарих айкап, татарымны барлыйм,
Елап барлыйм чорлар кәрванын...
Кәрван башы – Әткәй! – күрәм аның
Ут эченә кереп барганын.

Күрәм... күрә-күрә күтәреләм
Күмер шахталары төбеннән –
Меңәрләгән татар кешесенең
Киләчәге шунда күмелгән.

Ә йотылган ут-кайгылар исә
Илгә кайткан моңга төялеп...
Мин дә шушы моң ташкыны буйлап
Йөрим Әткәемә ияреп.

Җиңү даны артык зур булганга
Мин дә ат өстендә – иярдә!
Комлык ачкан ипсез, иләмсезгә
Исәбем юк башым ияргә.

Теләгем юк мөлкәт тупларга да,
Рәхәтенә чумып, кинәнеп...
Минем инде байлык төйни торган
Төенчекләр беткән төйнәлеп.

Минем мәңгеләшер чагым җиткән:
Күрәсезме, әнә таң ата.
Ирек өчен милләт җан атканга
Таң нурларын җиргә тарата.

Һәм тарата дөнья яңа хәбәр:
«Татар арта, кайта иманга!!!
Кыйбласызлар, йортсыз, илсезләр юк,
Хәер эстәүчеләр юк анда!

Байлары да яңа – үз байлары!..
Майлары да чиста – сары май!
Шәһри Казан тоткан меңьеллыкның
Маңгаенда балкый ярымай...

Һәм өметләр ярым-йорты түгел,
Кыш та түгел – инде яз анда.
Үзәк өзгеч бураннардан арынып,
Күтәрелә татар намаздан!..»

**9**

*Азан моңын без дә ишетәбез:*
*Уята ул тирән хәтерне.*
*Әмма дөнья шундый мәкерле бит,*
*Сөенечен ихлас әйтерме?..*

...Бирсен Ходай! Бу хәбәрләр берүк
Югалтмасын көчен үзенең.
Язмыш җиз иләктән үткәргәндә
Милләтемнең рухи түземен.

Җырлап чәч чаларткан шагыйрьләрен
Онытмасын газиз Ватан да...
Без дә «үз» бит шәфәкъ аръягыннан
Сызылып кына аткан ал таңга.

Шигырь, җыр шахтасы йөрәктә бит –
Ябыла ул да, йөрәк ярылса...
...Илнең аяк асты таймас иде,
Йөрәкләргә сукмак сабылса.

Үз ireген тапса, татарымны
Тотмас иде нәфрәт тулгагы.
Гомер узды, җан да тузды, әмма
Нәфрәтләрдән айнып булмады.

Халыкларның нәфрәт давылында
Империя ауды, ишелде.
Җан тамыры төптән кубарылды,
Кан тамыры өстән киселде.

Инде шушы кансыз, шома токым
Парламентта тотып шобага:
«Халык мәнфәгатен яклыйбыз!» – дип,
Ант биетә «утлы таба»да.

...Бу табалар татар ирегенең
Дәверләрдән күчкән макеты!
Бу макетны киңәйтергә һаман
Россиянең җитми вакыты.

Россиядә Татарстан өчен
Хак хөррият һәрчак тар калды.
Таба ялап, телләр кутырлады,
Хәтер калды, өмет таркалды.

Зур Ватаннан калды кече Ватан!..
Гөнаһ йокмый «кече бала»га... –
Шушы гыйбарәдән файдаланып,
Күпләр сала салды калага.

Каласызлар, саласызлар – эшсез!..
Моннан соң да алар ком иләр...
Ни сөйләсә, нәрсә иләсә дә,
Башы иелгәнгә тимиләр.

Һәм шулай ук татар ирегенә
Бирмиләр дә татар ыстанын...
Син бит Бөек! Затсыз чорсызларга
Башың имә, Татарстаным!

Чорлар буе җыйган аң-зиһенең
Комбасарга биреп иләтмә?!
Заман ваклыгыннан аралану
Бик кыйммәткә төшә милләткә.

Татар аңы, татар халкы хәзер
Урый танып бөтен Җир шарын.
Ә кем әйтсен безгә: «Җир шарының
Әйләнүдән көт, – дип, – бушарын...»

Җир шарының һәрбер әйләнеше –
Безгә ирек юллап ташыр моң!
...Безнең буын – суырылган буын, –
Күз-яше ул узган гасырның.

Киләчәкнең күзе-колагы ул,
Туктап моңаюы баешта!..
Бу баешны җуймас газиз Ватан –
Юлы ялганса да кай очка.

Ә онытa калса ут-мәхшәрле
Гасыр «аһ»ын, юкка чыгарып.
Ил өстендә Кояш иртә батар,
Таңнар атар бераз соңарып.

Мондый хәтәрлекне Илгә түгел,
Кан дошманыма да теләмәм.
«Аһ»ын җаным белән түләсәм дә,
Коллык комын, юк, юк, иләмәм!

Соң чиккәчә Коръән кыйблам булыр,
Баш – югары, гәүдәм төз булыр.
Табанымда канлы эз булса да,
Үз каным бит! – сөрткәч тиз корыр.

Мең әҗәлне җиңгән газиз Ватан
Бу комлыктан чыгар баш алып...
Аңарчы күк җиргә ишелмәсә,
Саклык озоннары ашалып.

...Бөек Тәңрем генә батырмыйча
Саклар безнең Язмыш көймәсен.
Бакыйлыкның сөю фәрештәсе
Кара битлек кенә кимәсен!

Онытмасын татар канга сеңгән
Каралыктан чыгу чарасын,
Җир тирәли очар бөркет булып,
Тарихларга кереп каласын.



Равил
Сабыр

# ФӘХРИНЕ ҮТЕРЕП ТАШЛАДЫЛАР

РОМАН*

*Без түбәннән, тормышның*
*төбеннән күтәрелдек.*
Галимҗан Ибраһимов

*Гомерем берзаман азагына килеп*
*җитәр дип куркырга кирәкми,*
*аның, гомумән, башланып китә*
*алмавыннан куркырга кирәк.*
Джон Генри Ньюмен

## 1. Ошамый әле миңа бу кәмит

– Әнигә әйтмәгез, үтерә ул мине!

Өчесе дә шул сүзләрне искә төшерде чакыру хаты алгач. Теге кичтә булган хәлләр секундның йөздән бер өлешендә һәрберсенең күз алдыннан ялт иттереп кенә узып китте, ә менә бер мизгел кинодагы стоп-кадр кебек эленеп калды...

Каннан кызарган карда еш-еш сулап, бер егет ыңгырашып ята. Чыгып кына килә торган сирәк мыегы ап-ак – бәсләнгән. Авызыннан әледән-әле пар бөркелә. Куллары белән кендек тирәсен кысып каплаган, тик бармаклары арасыннан барыбер кан саркый.

– Скорый чакырыгыз! – диде шунда кемдер, илереп.

Егет соңгы көчләрен җыеп, башын күтәрә төште, тавыш килгән якка күз ташлады. Җаны күккә ашарга бер мизгел кала: «Әнигә әйтмәгез, үтерә ул мине!» – диде һәм нишләптер елмайды. Киләсе мизгелдә аның башы хәлсезләнеп, карга төште, куллары да аска шуышты, бите өстендә пәйда булган пар болытчыгы – соңгы сулышы – салкын һавада эреп югалды...

* Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан үткәрелгән конкурсның «Роман» номинациясендә 3 урынны алган әсәр.

Равил САБЫР (1974) – *язучы, драматург, журналист. Туфан Миңнуллин исемендәге премия лауреаты. «Ак әби» китабы, «Абага алмасы ачы була», «Кирәкле кишер яфрагы» һ.б. пьесалар авторы. Әлмәт шәһәрендә яши.*

Әйе, хат алгач, һәммәсе дә шушы мизгелләрне искә төшерде. Очрашуга килми кала алмый иде өчесе дә. Беренче булып Галимҗан килде.

Очрашу урыны итеп N шәһәренең иң кәттә кунакханәсендәге иң шәп люкс-номер билгеләнгән иде. Галимҗан башта шөлләп кенә, ишеккә кагып карады. Ә юк, әле шакыганчы ул бу имән ишеккә, аның матурлыгына, уеп-сырлап ясалган бизәкләренә исе китеп торды. Бигрәк тә арыслан башларының сыннары сихерләгәндәй итте аны. Дүртесе дүрт төрле иде: берсе усал, икенчесе акыллы, өченчесе хәйләкәр елмая, дүртенчесе йоклый иде. Хәйран гына шул бизәкләрне өйрәнеп торгач, Галимҗан берзаман айнып киткәндәй булды һәм шунда гына ишеккә шакыды. Башта куркып, шикләнеп кенә, аннары тагын бер мәртәбә – бу юлы ныграк, монда икәнен, ниһаять, белгертәсе килеп какты ул ишекне.

Ачучы булмагач, тотканы әкрен генә аска төшерде һәм җилкәсе белән җиңелчә генә ишекне этеп җибәрде. Зур биек ишек бик авырдыр кебек тоелган иде, тик ни гаҗәп, ул бер тавыш та чыгармыйча тыңлаучан гына ачылып китте. Галимҗанның аяк-куллары калтырый башлады, тик алай да ул эчкә узды.

Болын хәтле бүлмә уртасында аш өстәле тора иде. Аның өч ягына урындык, бер ягына затлы кәнәфи куелган. Кәнәфидә ап-актан киенгән 35-40 яшьләр тирәсендәге ир иягенә таянып, бер ноктага төбәлеп, мәрткә киткән бер кыяфәттә утыра иде. Күрәсең, ул үз уйларына шулкадәр нык бирелгән иде ки, хәтта Галимҗанның кергәнен ишетми-сизми дә калды.

– Кхым-кхым,– дип тамак кырып алды Галимҗан. – Ялгыш кердем, ахрысы.

– Исәнмесез!

Ак костюм кигән ир шундук кәнәфидән сикереп торды, ул анда утырганына үзен ничектер гаепле итеп хис итә иде бугай. «Официант, ахрысы, бу», – дип уйлады Галимҗан.

– Исәнмесез... Тик ялгыш кердем бугай мин.

– Ник алай дисез? – Аптыраудан официантның кашлары сикереп куйды.

– Миңа... Хат килгән иде... Монда чакырып, – диде Галимҗан, пиджак төймәсен бөтереп. – Тик...

– Тик нәрсә? – Официантның күзләре хәйләкәр ялтырый башлады.

– Бигрәк затлы бүлмә бит бу! Әнә нинди шәп өстәл әзерләнгән. Минем үз гомеремдә мондый нәрсә күргәнем юк иде, гап-гади укытучы бит мин.

– Сезнең исемегез ничек? – дип сорады официант, кесәсеннән ниндидер кәгазь чыгарып.

– Галимҗан.

– Фамилиягез?

– Гыйлемҗанов.

– Алайса, бернинди ялгышлык та юк, сез дөрес кергәнсез! – диде официант, сүзләренә нык инанып һәм тимер тавыш белән. Аннары бераз йомшаграк итеп: – Тик... Гафу итегез... Сезнең пиджакта... Сез аның этикеткасын салдырырга оныткансыз, – дип өстәде.

– Һай Аллам, үләм икән! – Галимҗан артына каерыла-каерыла карап, этикетканы эзләде. – Яңа гына сатып алган идем бу костюмны. Кайчы юкмы సездә?

– Кайчы юк, менә өстәлдә пычак бар.

Галимҗан кулына пычак алып, яшел камин өстендә эленеп торган галәмәт зур көзге каршына килеп басты. Шуңа карана-карана пиджак ярлыгының җебен кискәч, Галимҗан кире өстәлгә таба китмәкче иде, тик күз чите белән генә көзгедә нindидер ир-ат чагылышын искәргәндәй булды. Бу ир-ат аңа көлеп карап торган сыман тоелды. Исәнгерәп, ул башын күтәреп, көзгегә ныклабрак карады, тик анда үз чагылышыннан тыш берни күрмәде. Бераз тынычланып, инде китәм генә дигәндә, Галимҗанга көзгедә тагын бер сурәт пәйда булгандай тоелды: каннан кызарган карда еш-еш сулап, бер егет ыңгырашып ята иде кебек. Көзгегә тагын бер борылып карагач, Галимҗан янә үзен генә күрде.

– Ә кем чакырды соң мине монда? – дип сорады Галимҗан официанттан, пычакны кире өстәлгә илтеп куйгач.

– Ә сез белмисезме?

– Юк.

– Сәер. Кем чакырганын да, ник чакырганын да белмәгәч, алайса ник килдегез? – Официант бу сүзләрне үзе генә белгән ниндидер рольгә кереп, аякларен күтәрә төшеп әйтте.

– Чакыру хаты бик оста язылган иде, – диде Галимҗан, ишетелер-ишетелмәс кенә үзалдына мыгырданып.

– Һе! Кызык!

– Сезгә кызыктыр да, ошамый әле миңа бу кәмит... Бу номерны кем сатып алды соң? Өстәлгә заказны кем бирде? – диде Галимҗан, бу сорауларга җавап алмасын белсә дә.

– Белмим.

– Ничек инде, белмисез? Сез официантмы соң?

– Официант.

– Үз хуҗагызны белмисезме? – диде Галимҗан шаккатып, аның хәтта авызы да ачык килеш калды.

– Хуҗамны беләм, әлбәттә! Ул – ресторан директоры. Монда мине өстәл әзерләргә һәм клиентларны шәпләп кунак итәргә дип җибәрде. Ә заказны кем ясаганын белмим. Беләсем дә килми, миңа ник кирәк соң ул?

– Өстәл дүрт кешегә әзерләнгән, – дип куйды Галимҗан һәм чалбар кесәсеннән кулъяулык чыгарып, шуның белән маңгаена бүртеп чыккан тир тамчыларын сөртеп алды.

– Әйе, заказда дүрт кеше булачак, диелгән.

– Димәк, тагын өч кеше килергә тиеш? Сезнең исемлектә тагын кемнәр бар? – дип, Галимҗан официант янына килмәкче булды.

– Ашыкмагыз! – Официант кулы белән ишарәләп, Галимҗанны туктатты. – Тиздән килеп җитәрләр, үзегез күрерсез. Менә, теләсәгез, өстәл янына килеп утырыгыз. Берәр нәрсә салып биримме: су, сок, шәраб, аракы, коньяк, виски?

Галимҗан карашын никтер өстәлдәге эчемлекләргә түгел, официантка юнәлтте. Аның каршында уртача буйлы – хәтта аннан бераз тәбәнәгрәк – буй-сыны гимнастларныкын хәтерләткән, һәр мускулы үз урынында булып, йомраеп калкып торган ир уртасы басып тора иде. Өстенә ап-ак костюм кисә дә, моны чамалау авыр түгел иде. «Буең да булса, Камыр

батыр диярләр иде», диде Галимҗан күңеленнән генә официантка. Бик төгәл билгеләмә иде бу. Чыннан да әвәләп ясалган кебек йомры гәүдәле, хәтта кыска бармаклары да калын, әйтерсең лә, камырдан тәгәрәткән сыман иде. Дегет кебек кап-кара чәчләре кыска итеп киселгән, биек булмаган маңгаенда берничә җыерчык бар, куе кара кашлары арасында тагын бер тирән җыерчык – күрәсең, еш кына усалланып кашларын җыерадыр. Моңсу кара күзләре исә ничектер өчпочмак формалы иде, чит-читтән күз кабаклары кабарыбрак чыгып торгангадыр инде. Сул күзе астында тирән яра эзе бар, борынын да кайчандыр сындырган булганнар, хәер, бик текәлеп карамасаң, анысын сизмәскә дә мөмкин. Галимҗан официантның калын иреннәрен, чокырлы ияген, гомумән аның йөзен шулай дикъкать белән өстән аска кадәр өйрәнеп-тикшереп чыккач, кечкенә чагында әнисе өйрәткән табышмакны искә төшерде: олы урман, кече урман, ялтыравык, мышнавык, шапылтавык, йомры тавык.

Ә официант табышмак түгел, әкият искә төшерде һәм Галимҗан турында: «Картайган Буратино», – дип уйлап куйды. Чыннан да беренче булып килгән кунак икенде күләгәсе кебек озын, үзе пәри табагачыдай какча, чандыр иде. Әйтерсең лә, аны кәлчәк балыгыдай бауга элеп киптергәннәр, эче эчкә ябышкан, кулларындагы бүртеп торган куе зәңгәр кан тамырлары картага төшерелгән елгаларны хәтерләтә иде. Коры сөяк инде кыскасы, авызын ачса, үпкәсе күренер! Озын очлы борыны гына тырпаеп тора. Шул борында – калын пыялалы күзлек. Ул Галимҗанның зәңгәр күзләрен зурайтыбрак күрсәтә, аңардан ниндидер бер карикатур образ ясый иде. Өстенә кигән сыек көрән төстәге костюмы да кимендә ике үлчәмгә зур булып, бу көлкеле образны тагын да көчәйтеп җибәрә иде. Ничектер, манекенга элеп куйган сыман утыра иде бу костюм Галимҗанда, ә менә официантка ак пинҗәк-чалбар, ак күлмәк – барысы да бик килешеп торалар иде.

– Берәр нәрсә салып биримме? – дип кабатлады официант.

– Юк, юк, рәхмәт! Миңа берни дә кирәкми! Менә шушында гына утырып торам, – дип мыгырданып, Галимҗан диван читенә килеп урнашты. – Бер дә ошамый әле миңа бу кәмит...

– Мин – күрше бүлмәдә генә, кирәк булсам, чакырырсыз, – дип, официант чыгып китте.

Галимҗан башын күтәреп, өскә карады. Кергәч тә, иң беренче аның күзе бүлмә уртасында эленеп торган гаять зур люстрага төшкән иде, хәзер ул шуны җентекләбрәк өйрәнергә кереште. Галимҗан, әлбәттә, аның Венеция пыяласыннан ясалганын белә алмый иде, тик шулай да ялык-йолык килеп торган, боз сөңгеләрен хәтерләткән асылмалы бизәкләре, чын шәмгә охшаган нечкә озын лампалары, готик стильдә эшләнеше – җыеп әйткәндә, барысы да бу яктырткычның бик затлы һәм кыйбатлы булуы турында сөйли иде. Тагын шунысы да шаккатырды – түшәмнең люстра эленгән өлеше гөмбәз булып эчкә кергән, дөресрәге, өскә менгән, һәм анда алсу буяу белән төрле-төрле чәчәкләр ясалган иде.

Мондый түшәмне беренче күрүе Галимҗанның. Гөмбәзле булудан тыш ул әле тагын катлы-катлы, кирегә әйләндергән баскыч кебек. Почмакларда теге ишектәге арысланнарга ике тамчы су кебек охшаш сын-консольләр тора – әйтерсең лә, хайваннар патшасы булган җәнлек нәселеннән дүрт

бертуган түшәмне башлары белән терәп торалар. Шулай ук бу түшәмгә искитмәле матур калку бизәкләр сылап ясалган: чәчәкләр, күбәләкләр, төрле җәнлекләр – барысы да берәр генә, ике бертөрлене тапмады Галимҗан.

«Патша сарайлары шушындый була торгандыр инде», – дип уйлады ул, искиткеч матур, чәчәкле-чуклы пәрдә-челтәрләргә, куе яшел мәрмәр каминга, аның бизәкле тимер рәшәткәсенә, диварлардагы кызыл агачны уеп ясалган зиннәтле, нәзакәтле панельләргә карап. Камин өстендәге галәмәт зур көзгенең дә шулай ук кызыл агач рамга төрледән-төрле матур чәчәкләр уелган иде. Шуларга хозурланып торганда, Галимҗан көзгедә бер мизгелгә генә ике хатын-кызны күреп алды. Болар Әлфия Авзалова белән Шэрон Стоун – зур самавыр куелган өстәл янында авыл ипиенә сөт өсте ягып, бал сылап, тәмләп чәй эчеп утыралар иде. Галимҗан гаҗәпләнүеннән берничә мәртәбә күзен ачып йомды, башын селкетеп алды, якынрак килеп тагын бер кат дикъкать белән көзгегә карады – бу юлы бары үзенең кайтарылышы гына күренде.

Тагын камин өстендә, көзгенең ике ягында, фарфор вазалар, ә алар уртасында ике сын тора иде. Берсе гадел хөкем алиһәсе – ап-ак мәрмәрдән ясалган Фемида, икенчесе кап-кара Анубис – эт башлы кеше кыяфәтендәге үлем иләһесе. Җыеп әйткәндә, бүлмәдә тантаналы вәкарьлек хөкем сөрә иде.

Шунда гына Галимҗан өстәл янында торган кәнәфигә һәм урындыкларга игътибар итте. Кәнәфи карага манылган күн белән тышланган булса, урындыкларга ачык көрән төстәге гобелен тарттырып куелган. Ләкин иң мөһиме – урындыклар бу бүлмә бизәлеше мантыйгына бик туры килеп торсалар, кәнәфи соңгы мизгелдә генә каяндыр алып кертеп куелган чит-ят бер җиһаз сыман күренә иде. Әйтик, кәнәфи астына кечкенә тәгәрмәчләр беркетелгән, ә урындык аякларының очында Галимҗан тагын арыслан башларын күреп гаҗәпләнде: «Карале, монда да уеп куйганнар икән!» Ул ирексездән карашын ишеккә юнәлтте...

## 2. Әллә сиңа да хат килдеме?

Шунда ишек ачылып китте, үз өенә кайткан хуҗа кыяфәтендә икенче кунак килеп керде. Мондый бәндә ишек шакып тормый инде, арыслан башларына да исе китми. Күрде микән әле ул аларны, гомумән? Галимҗан курсташы Хамисны шундук таныса да, тегесе аның ягына борылып та карамады, туп-туры өстәл янына килеп, кәнәфигә җәелеп утырды.

Аяк тавышларын ишеткәндер, күрәсең, бүлмәгә официант кереп, Хамис янына килеп басты.

– Су сал! – дип ырылдады яңа кунак.

– Гафу итегез, сез кем буласыз? – диде официант, итагатьлек сакларга тырышып.

– Су сал, диләр сиңа, аңгыра! Мине монда кунакка чакырдылар!

– Мин сезнең өчен бик шат. Тик мине дә дөрес аңлавыгызны үтенәм, минем үз эшем – беренче чиратта, сезнең бирегә чыннан да чакырулы икәнен тәгаенләргә тиешмен, – диде официант, таләпчәнрәк тонга күчеп.

– Хамис Халитович! Устраивает?

– Шәрәфуллинмы? – дип, аныклык кертергә теләде аның әңгәмәдәше, кесәсеннән кәгазь чыгарып.

– Әйе!

– Хуш килдегез, Хамис Халитович! Тик урындыкка күчеп утырсагыз иде, кәнәфи башка кунак өчен әзерләнгән.

Хамис шикләнеп, ак костюмлы иргә карап куйды да, теләмичә генә урындыкка күчеп утырды. Уртачадан аз гына югарырак буйлы, пеләш башлы (чебен кунса, таеп егылыр кебек!), бәрәңге борынлы, яшел күзле бер ир уртасы иде ул. Өстендә – соңгы арада бөтен ирләр дә киеп йөри торган модалы зәңгәр костюм һәм саргылт күлмәк. Аны башкалардан аерып торган төп билгесе – ничектер әрсез рәвештә алга чыгып торган, квадрат формалы зур ияге иде.

– Тагын бер мәртәбә мине кичерүегезне үтенәм. Сезгә газлы су кирәкме, газсызмы?

– Газсыз.

Официант су салган арада, Хамис бүлмәгә күз йөртеп чыкты. Ниһаять, Галимҗанны да күреп алды, тик тегесе аңа арты белән борылып утырган иде.

– Элек тә сансыз идең, хәзер бигрәк пырдымсыз мәхлукка әйләнгәнсең, – диде Галимҗан борылмыйча, һаман арты белән утырган килеш.

Хамис күз ачып йомганчы очып килеп, аның якасына ябышты:

– Син нәрсә лыгырдыйсың, маңка борын?!

– Сансыз! Нишлисең?! Мин бит бу, Галимҗан!

Хамис торaташ катып, Галимҗанга текәлеп карап тора башлады.

– Буржуй Галимҗан! Әбҗәлилдәге бишенче тулай торакның 374 нче бүлмәсен исеңә төшер, – диде беренче кунак, елмаеп.

– Буржуй?! – Хамис, шатланып, дустын кочып алды. – Син нишләп йөрисең монда, Буржуй?!

– Кунакка чакырып, хат алган идем, килдем менә.

– Әллә сиңа да хат килде?

– Әйе.

– Кемнән? – дип сорады Хамис өмет тулы тавыш белән.

– Белмим.

– Ничек инде белмисең, Буржуй?!

– Менә шулай, белмим. Сине кем чакырды соң?

– Мин дә белмим шул, – дип авыр сулады Хамис.

– Бер дә ошамый әле миңа бу кәмит, – дип тәкрарлады Галимҗан.

– Әй, карале, кем?! – Хамис ялт-йолт як-ягына каранды. – Официант! Синең исемең ничек?

– Официант.

– Исемең ничек дим мин сиңа!

– Официант, – дип кабатлады тегесе тагын бер мәртәбә тыныч кына. Шул ук вакытта аның тавышында кисәткеч тон да чагылып китте кебек.

– Ну, ладно, чурт с тобой! Кем чакырды безне монда, официант, ә?!

– Белми ул бернәрсә дә, Хамис, бәйләнмә аңа, – диде Галимҗан зур җәзага хөкем ителгән кешедәй.

– Яздан тора дәвам, яздан тора...

Официант үз бүлмәсенә чыгып китешли ишетелер-ишетелмәс кенә шул сүзләрне кабатлады.

– Ни мыгырданасың син анда? – дип җикеренде аңа Хамис.

– Илгә кайтып, безнең табигатьтә яши алыр киек каздан тора – дәвам яздан тора.

– Ни мыгырданасың дим?!

– Гафу итегез, мин мыгырданмыйм, мин шигырь сөйлим. Мөдәррис Әгъләм шигыре. Ошый миңа аның шигырьләре! Төрмәдә ялгыш кына кулга бер китабы килеп кергән иде, шуннан бирле яратып калдым, – диде дә официант җавап көтеп тә тормыйча чыгып китте.

Галимҗанның тагын авызы ачылып калса да, Хамисның бала йоны да селкенмәде:

– Шулай дисәң генә... Кем эше булыр бу шулай да, ә? Кем чакырды икән безне монда?

– Кем чакырганын да белмәгәч, ник килдең соң, Сансыз? – дип сорады Галимҗан, үзе ирен чите белән генә елмаеп куйды.

– Бик выгодный коммерческий предложение бар, дигәннәр иде абзыеңа! Килми калалмадым.

– Ә-ә-ә, син эшмәкәрмени?

– Крупный компаниянең генеральный директоры абзаң!

Галимҗан Хамиска тагын бер карады да: «Шул ук Сансыз инде, әллә ни үзгәрмәгән, чәче коелып беткән дә, бүксәсе генә үскән», – дип уйлап куйды.

– Кем эше булыр бу? – Хамис шулай дип кабатлагач, диванның икесе ике ягына утырып, үз уйларына чумып тынып калдылар.

## 3. Аз гына артык

Бу вакытта ишекнең теге ягында өченче кунак басып тора иде. Алманиядән кайткан Илгизәр иде анысы. Ул да ишекне ачканчы арыслан башларына игътибар итте. «Карале, малай, ә! Көнбатыштан ясатып алып кайтканнардыр инде бу ишекне, Рәсәйдә болай ясый алмаслар иде», дип уйлады ул.

Йоклый торган арысланны күргәч, Илгизәр үзенең кумиры Черчилльне искә төшерде. II Бөтендөнья сугышы вакытында Бөекбританиянең Премьер-министры Кырымга килә, 1945 елның февралендә Ялта конференциясендә катнаша. Хикмәт шунда ки, Ливадия сараеның көньяк терассасын ак мәрмәрдән ясалган берничә арыслан сыны «саклый». Аларны Италиянең Каррара дигән төбәгендә Винценто Боннани остаханәсендә махсус заказ буенча ясыйлар. Шуларның берсе, йоклый торганы, Черчилльнең күңеленә бик хуш килә. Имеш, ул Сталиннан бу сынны бүләк итүен дә сораган, ди.

– Ни өчен нәкъ менә йоклый торганы кирәк? – дип кызыксынган Сталин.

– Соң, сез аңа карагыз! Ул бит нәкъ минем төсле, сигарасы гына җитми, – дигән, имеш, Черчилль.

– Халык милке белән сату итмим, – дип җавап кайтарган янәсе Советлар иле юлбашчысы.

Илгизәр сарказм белән генә елмаеп куйды, аннары тирән итеп бер сулыш алды да, тәвәккәлләп, ишекне ачты. Бүлмәгә кергәч, ул туп-туры Хамис белән Галимҗан янына килеп басты.

– Сәлам, егетләр! Ни хәлләр бар? – диде ул, Көнбатыштагыча ясалма елмаеп. Үзе күрешергә дип, кулын Хамиска сузды.

– Бар, чыгып яңадан кер! – диде аңа тегесе, мыскыллы елмаеп. Ул диваннан арт санын күтәрергә уйламый да иде.

– Ә? – Галимҗан сикереп торды да тагын авызын ачып катып калды.

– Яп авызыңны, чебен очып кермәсен! Ә син чыгып яңадан кер, дим! Чукрак ыштули син?!

– Юк, чукрак түгел, – дип югалып калды Илгизәр. – Ә нигә яңадан керергә, аңламадым?

– Ну, егерме ел күрешмәгән яшьлек дусларына болай сәлам бирмиләр бит инде! Керде дә, сәлам, егетләр, ни хәлләр бар, ди. Әйтерсең лә, биш минутка гына чыгып торган!

Шунда гына Галимҗан дустын танып алды:

– Илгизәр! Син түгелме соң бу? Хамис, Илгизәр бит бу!

– Илгизәргә әйләнергә тырышып карады ул, әйе, тик барыбер шул элеккеге Штирлиц булып калган.

– Каян килеп чыктың син монда, Илгизәр? Сине бит Алманиядә дигәннәр иде? – дип, Галимҗан сорулар яудыра башлады.

– Әйе, Алманиядән кайттым, туп-туры аэропорттан килдем.

– Ни хәлләрең бар соң, Илгизәр? – дип сорады Галимҗан ниндидер бер самимилек белән.

– О’кей, рәхмәт!

– Моның о’кей инде! О’кей булмый, әйбәт булмас бит инде! – диде Хамис, ямьсез көлеп. – Ә нишләп алайса бер дә кәефең юк?

– Ерак юл ардырды бераз, – дип, авыр сулады Илгизәр.

– Шул о’кей буламы? – диде Хамис, үзе һаман гыргылдап көлде.

Бу уңайсыз хәлне ничектер җайларга тырышып, Галимҗан тагын Илгизәргә сорау бирде:

– Мин башта, Хамис килеп кергәч, бу өстәлне ул заказать иткәндер дип уйлаган идем... Алайса, Илгизәр, син инде бу табынның хуҗасы?

– Юк, мин хуҗа түгел монда, кунак кына.

– Бәрәч икән?! Алайса бу кәнәфи кемгә икән соң? – дип аптырады Галимҗан. Ихлас әйткән кебек тоелды.

– Ә сез белмисезме? – диде Илгизәр, читкә карап торган җиреннән дуслары ягына кисәк борылып.

– Син беләсең ыштули? – Хамис көлүеннән туктаса да, һаман мыскыллы елмая иде әле.

– Юк, мин дә белмим. – Илгизәрнең бу сүзләре ничектер кыюсыз яңгырады, ышандырмады.

– Ник килдең соң алайса? – дип сорады Хамис, авызын җыя төшеп.

– Бар инде сәбәпләре...

Минор тоннардагы бу күңелсез сөйләшүне официант бүлдерде. Үзенең бүлмәсеннән май кояшы кебек балкып чыкты да:

– Исәнмесез! – диде ул һәркем ишетерлек итеп.

– Исән булмый, чурт булсынмыни безгә! – диде Хамис, ачуы чыгып. – Син нәрсә? Хәзер шулай биш минут саен исәнләшеп йөрисеңме инде безнең белән?

– Мин яңа килгән әфәндемне сәламләдем. Ялгышмасам, сез Илгизәр буласыз?

– Әйе, Илгизәр. Исәнмесез!

«Аз гына артык», дип уйлап куйды официант, яңа кунакны өстән акса күзләп чыккач. Уртачадан аз гына артык буй; ирләр өчен таман булганнан аз гына артык озын чәч; төз, ләкин аз гына артык зур борын; аз гына артык тырпаеп торган колаклар, аз гына артык озын куллар. «Шул «аз гына артыклар» булмаса, кызлар көтүләре белән муенына асылыныр иде моның», – дип нәтиҗә чыгарды официант.

– Сез бер дә читенсенмәгез! – диде ул кунакларга. – Әйдәгез, өстәлгә якынрак килегез, утырышыгыз. Кемгә нинди эчемлек салырга?

– Мин «Хеннесси» коньягы гына эчәм! – дип, Хамис беренче булып килеп утырды.

– Миңа, мөмкин булса, сок, – диде Илгизәр тыйнак кына.

– Ә миңа аракы! – дип ярып салды Галимҗан.

Официант кунакларга эчемлекләр салганда ишетелер-ишетелмәс кенә борын төбенә нидер мыгырданды:

– Көчтән тора дәвам, көчтән тора! Үткән белән бүген җитәкләшеп...

– Карале, бырат! – дип дәште аңа Хамис. – Сиңа врачка күренергә кирәк, по-моему! Нинди җитәкләшү турында сөйлисең син?

– Гафу итегез, бераз онытылып киткәнмен. Әйткән идем бит инде, шигырьләр яратам дип...

– Безнең янга чыккач мыгырданып йөрмә бүтән, үз бүлмәңдә чакта сөйлә шигырьләреңне, аңладыңмы?!

– Ярар, аңладым. Гафу итегез...

– Әйдә, сок белән авыз пычратып утырма инде син, Штирлиц! Яшьлек дусларың белән егерме елга бер күрешеп, – дип, Хамис кабат Илгизәргә бәйләнә башлады.

Ул арада официант тәрәзә пәрдәләрен ябып куйды, арысланлы ишекне бикләп, ачкычны кесәсенә тыкты. Үзара сөйләшү белән мавыгып, дуслар моңа артык игътибар бирмәде, бары Илгизәр генә официантны күз чите белән күзәтеп утырды. Хәер, бу эшкә Хамис бик нык комачаулый иде, гел кымтрыклап кына торды үзен.

– Штирлиц, дим! Кая, бир инде рюмкаңны, «Хеннесси» салып бирәм.

– Нәрсә соң син баядан бирле Штирлиц та Штирлиц, дисең! Каян исеңә төште ул?

– Әнә Галимҗан искә төшерде – башта минем Сансыз икәнне, аннан үзенең Буржуй икәнен.

– Танымыйсың бит! Сансыз дими, ни дисең инде сиңа тагын? – дип акланасы итте Галимҗан.

– Карагыз әле, нигә сез миңа шулай да Сансыз дип кушамат тактыгыз?

– Сансыз булгач?! – Галимҗанның тагын авызы ачылып калды. – Әдәпле һәм тәрбияле дип булмый бит инде сине?!

– Син, Буржуй, үзеңне бел, яме!

– Ә Галимҗанның ничек Буржуй булып киткәнен хәтерлисеңме? – дип күз кысты Илгизәр Хамиска.

– Ник, баштан ук Буржуй бугай иде инде ул?!

– Юк ла инде-е-е! – дип сузды Илгизәр кәефе китеп, шуны да хәтерләмисеңме инде, дигәндәй. – Исеңә төшер әле, беренче курста укыганда, кыш башлангач, ул киң җилкәле, озын итәкле, зур якалы пәлтә киеп килгән иде. Суйган да каплаган буржуй инде менә!

– Тучны, тучны! Искә төште хәзер! Ха-ха-ха, Буржуй! – Хамис тагын ямьсез итеп көлә башлады, үзе имән бармагы белән Галимҗанның күзенә үк диярлек төртте.

– Менә моны Сансыз дими, кем дисең инде тагын? – диде Галимҗан, кулларын җәеп.

– Штирлиц! Ә син соң нигә Штирлиц безнең? – дип сорады Хамис Илгизәрдән. Аннары сүзләренә серлелек өстәп, пышылдабрак дәвам итте. – Ну, мин аңлыйм, хәзер сиңа бу кушамат килешеп тора, ә студент чакта?

Илгизәр башта Хамиска усал караш ташлады, тик бик тиз арада аның йөзендә тагын ясалма елмаю пәйда булды.

– Чапай, Штирлиц турында анекдотлар сөйләргә ярата идем бит мин, шуннан тагылып калды инде.

– Әйдәгез әле, ирләрчә чәкештереп тотып куйыйк әле берне очрашу хөрмәтенә! – Хамис рюмкасын күтәреп торып басты.

– Өстәлнең хуҗасы килмәде ич әле, көтик инде бераз, – диде Илгизәр, як-ягына каранып. Әйтерсең лә, хуҗа кайсыдыр бер почмактан килеп чыгарга тиешле кебек иде.

– Соң бөтен кеше җыелып беткәнче качып эчкәне иң тәмлесе бит инде аның! – дип гыргылдады Хамис.

– Сансыз! – диде дә Галимҗан, бераз икеләнеп торганнан соң, рюмкасын кире өстәлгә куйды. Аннан күреп, Хамис та шулай итте.

Илгизәр ашыкмый гына, әз-әзләп, сөзеп кенә сок эчә иде, ниндидер бик җитди әйберләр турында уйлануы әллә каян күренеп тора. Бераздан, шул уйлардан качарга теләгәндәй, Илгизәр кисәк кенә телгә килде:

– Ничек яшисез соң, егетләр? Сөйләп бирегез әле тәфсилләп. Йөз ел күрешкән юк бит инде, мин бит сезнең турыда берни дә белмим...

– Акылың алтын икән! Сөйлә дә бир аңа, имеш! – дип ризасызлык белдерде Хамис. – Ә нишләп без сиңа сөйләргә тиеш әле?! Син сөйлә башта, нинди җилләр Алманиягә илтеп атканын!

– Нинди җилләр дип... Башта немецлар белән уртак предприятиедә эшләдем ике ел, аннан Алманиягә эшкә чакырдылар да, киттем инде.

– Ник? – Галимҗан бу соравын никтер ачу белән әйтте. Нәфрәт белән хәтта.

– Ничек инде, ник?! – Илгизәр сорауны аңламады.

– Туктале син, Галимҗан! – дип кысылды Хамис. – Үзеңнең артык акыллы сорауларыңны соңрак бирерсең.

– Кырык яшькә җитәм инде, тәки аңламадым, ничек була икән ул «артык» акыл?!

– Туктап тор әле, дим! – диде аңа Хамис, кулын селтәп. – Илгизәр, син менә миңа әйт әле, ни өчен безнең башка беребезне дә чакырмады немесләр, ә синсез эшләре бармый, имеш?

– Сез немес дигән саен ачуымнан бала йоннарым кабарып чыга! – дип,

Галимҗан урыныннан торып китте. Өч-дүрт адым атлагач, кире яңадан үз урынына килеп утырды.

– Нәрсә соң сез килеп кермәс борын икәүләп миңа ябырылдыгыз?! Ни начарлык кылдым мин сезгә? – дип, борын тишекләрен кабартты Илгизәр.

## 4. Кем боера безгә, кем?!

Бераздан ул тынычлана төште:

– Әйдәгез әле матур итеп, дусларча сөйләшик әле, егетләр! Чыннан да, сөйләгез әле үзегез турында, ә? Галимҗан! Син кайда эшлисең, кайда яшисең, гаиләң, балаларың бармы?

– Гаиләм дә бар, балалар да үстерәбез, Аллага шөкер.

– Малайлармы, кызлармы?

– Берсе малай, кечесе – кыз.

– Кайда эшлисең?

– Кайда дип, мәктәптә инде без.

– Нинди фән укытасың?

– Тарих.

– Эшеңнән, тормышыңнан канәгатьме соң?

– Зарланмыйм болай үзе...

– Ә син, Хамис? – Илгизәр Хамиска таба борылды.

Сансыз тагын имән бармагы белән Галимҗанга төртеп күрсәтте:

– Абзаң моның ише бюджетник кына түгел инде, генеральный директор! Менә өстәлдәге җимешләрне күрәсеңме? Мин кайтарттым боларны!

– Ничек? Син әзерләдең мәллә шулай да бу өстәлне? – Галимҗанның зәңгәр күзләре атылып чыга язды.

– Юк ла инде, тыңлап бетер! Минем компания...

– Ширкәт! – диде Галимҗан имән бармагын Хамиска төртеп.

– Нинди Ширкәт тагын?! Кем ул Ширкәт?! Кайсы Ширкәт?! – дип, сораулар яудыра башлады Хамис.

– Компания татарча ширкәт була, Сансыз! – дип искәртте Галимҗан, һаман да бармагын төртеп.

– Минем компания Төркиядән, Африкадан, Европадан, Көньяк Америкадан, Көньяк-Көнчыгыш Азиядән – кыскасы, бөтен дөньядан җиләк-җимеш сатып алып, шушы регионда сату белән шөгыльләнә. Глобализация, малай! Менә бу өстәлдәге виноград, әфлисун-мандариннар да, хәтта алмалар да миннән сатып алынган! Ха-ха-ха! – Хамис тагын гыргылдый башлады.

– Синең дә гаиләң бардыр инде? – дип тыныч кына сорап куйды Илгизәр.

– Әбәзәтелни! Барысы да кешенекечә! Син үзең өйләндеңме соң? Таптыңмы анда үзеңә берәр Эльза?

– Таптым... Тик ул Эльза исемле түгел.

– Кем исемле соң? – дип мыскыллы елмайды Хамис.

– Хелена.

– Немкамы ул?

– Юк, фин кызы.

– Балаларыгыз да бармы? – дип кушылды сораштыруга Галимҗан.

– Малай.

– Ничә яшь инде аңа?

– Унике.

– Фриц исемлеме инде ул... – Галимҗан бу юлы сорамады, ничектер шулай икәненә инанып әйтте.

– Юк.

– Кем исемле соң?

– Ральф.

– Ральф?! – Галимҗан гаҗәпләнүеннән тагын сикереп торды.

– Мин Ралиф дим, анасы Ральф дип эндәшә, – дип, тыныч кына аңлата бирде Илгизәр.

– Татарча берәр сүз беләме соң улың? – Галимҗанның тавышында бу сорауга җавап аның өчен үтә дә мөһим икәне ярылып ята иде.

– Белә инде бераз...

– Белми, димәк! – дип, Галимҗан бер учы белән икенчесенә китереп сукты. – Ә синекеләр беләме, Хамис?

– Нишләп белмәсен ди?! – Хамисның мин-минлеге уянды. – Мәктәптә татар теле укыйлар бит алар. Минем өч баламның өчесе дә круглый отличник! «Бишле»лек беләләр!

– Карале, балалар димәктән, өйгә шалтыратыйм әле мин, нишләп яталар икән, – дип, Галимҗан кесә телефонын тартып чыгарды. – Кая йөри икән соң инде бу өстәлнең хуҗасы?! Бер дә ошамый әле миңа бу кәмит...

Галимҗан төймәләргә күпме генә баскаласа да, телефон эшләми иде.

– Сансыз, телефоныңны биреп тор әле, минеке эшләми нигәдер.

– Мә, бюджетник буржуй! Җүнле телефон алырга хәлеңнән килми ыштули, хәерче?!

Галимҗан Хамисның телефонын да эшләтә алмады.

– Синеке дә эшләми бит!

– Юкны сөйләмә! Кая бир әле монда! Минем телефон һәрвакыт эшли, чөнки ул ике симкалы! – диде Хамис төймәләргә үзе баскалап. – Ышту за чорт?! Кара, берсе дә эшләми! Штирлиц, синеке эшлиме?

– Юк, – диде Илгизәр тыныч кына, искитәрлек берни булмаган кебек.

– Официант! Әй, кая китеп югалдың син анда? Официант! – дип акырды Хамис.

Ак костюмлы ир тагын борын астына нидер мыгырданып керде.

– Көчтән тора дәвам, көчтән тора! Үткән белән бүген җитәкләшеп бара торган үзгәрештән тора – дәвам эштән тора.

– Тагын абракадабраңны мыгырданасың! – дип ачуланды Хамис. – Безнең янда сөйләмә шигырьләреңне, дидем бит инде мин сиңа!

– Гафу итегез, онытылып киткәнмен. Ул минем ничектер үзеннән-үзе әйтелә.

– Нишләп монда беребезнең дә телефоны эшләми? Мин бик важный кеше! – диде Хамис официантка терәлеп үк басып, күзгә-күз карап. Аларның борын очлары бер-берсенә менә тиям, менә тиям дип тора иде. – Миңа сәгать саен биш-алты кеше ысручный эш буенча шалтыратып тора!

– Тагын бер кат гафу итүегезне үтенәм, гаеп миндә. Мин сезгә, килгәч үк, бу турыда әйтергә тиеш идем, онытканмын. Кунакханәнең бу номерында

шәһәр телефоны юк, ә кесә телефоннары эшләми, чөнки биредә махсус аппарат куелган, ул иярчен элемтәсен томалый.

– Нигә? – дип, Галимҗанның авызы ачылды.

– Бу номерны сатып алган әфәндем шулай теләгән. Аннан соң аның тагын бер боерыгы бар...

– Боерыгы?! – Хамис кулларын йодрыклады.

– Ул килеп җитмичә, сезнең берегез дә биредән китәргә тиеш түгел, – диде официант, хөкем чыгаргандай итеп.

– Ничек инде?! – Галимҗанның бу юлы хәтта күзлеге дә сикереп куйды бугай.

– Башкасын белмим, – диде официант тимер тавыш белән. – Миңа шулай дип әйтергә кушылган иде, мин әйттем, эшем бетте.

– Без нәрсә, монда төрмәдәге кебек бикләп куелган ыштули?! Это же низакунны! – дип, Хамис ишекне тартып карады, тик ул ачылмады. – Кем боера безгә, кем?

– Мин башка берни дә белмим, – дип кабатлады официант, үз бүлмәсенә таба атлап.

– Туктале! – Хамис официантның якасына ябышты. – Бир ачкычны яхшы чакта!

Актан киенгән ир сизелер-сизелмәс кенә кискен бер хәрәкәт ясап, Хамисның эченә китереп сукты, тегесе шундук бөгелеп төште, авыртудан ыңгырашып, идәнгә чүгәләде. Илгизәр белән Галимҗан урыннарыннан сикереп торганнар иде, официант аларны кулы белән ишарәләп туктатты. Тик кенә утырыгыз, янәсе. Тегеләргә исә шул да җитте, алар баскан килеш катып калдылар.

– Гафу итегез, кисәтергә онытканмын: миңа кул белән кагылырга ярамый. Андый-мондый нәрсә турында уйлап та карамагыз, өч кешене генә бөгеп салу миңа берни тормый, – диде дә официант, Хамиска карап өстәп куйды: – Бераз түзегез, эчегез авыртуы тиздән бетәр.

Шулай дигәч, ул кабаланмый гына юлын дәвам итте:

– Сүздән тора дәвам, сүздән тора! Кеше заты синең сүзең белән...

– Бер дә ошамый әле миңа бу кәмит, – дип, авыр сулады Галимҗан.

– Башыгызны дуракка салып утырмагыз! – Илгизәр дә чыгырыннан чыкты. – Барыбыз да белә безне монда кем җыйганын – Кадыйр!

– Кадыйр исемле кеше юк исемлектә. – Официант үз бүлмәсенең ишеген ачкан иде инде.

– Юк, әлбәттә, ул аны үзе төзегән бит, – диде Илгизәр.

– Ә менә Диләрә исемле ханым бар, – диде дә официант Илгизәргә борылып карады.

– Диләрә?! – диделәр Илгизәр, Галимҗан, Хамис өчесе дә берьюлы.

– Тиздән килеп җитәр дип уйлыйм. Хатын-кызлар шундый инде алар, көттерергә яраталар, – дип елмайды официант. – Сүздән тора дәвам, сүздән тора, – дигән булып, ул аннары ишек артына кереп югалды.

## 5. Кызыктан кызганычка – бер адым

Барысы да янәдән теге сүзләрне искә төшерде:

– Әнигә әйтмәгез, үтерә ул мине!

Каннан кызарган карда еш-еш сулап ыңгырашып яткан егетнең соңгы сулышы күзалларына килде...

Бу трагедия челпәрәмә китергән дуслык ике ел алдарак кызык эзләп йөрүдән, төгәлрәге, «Шаяннар һәм тапкырлар клубы»ннан башланды. Әйтәләр бит, уеннан уймак чыга дип. Французларда исә бу мәкаль бераз бүтәнчәрәк яңгырый: кызыктан кызганычка – бер адым.

Укырга яңа кергән студентлар белән тулыландырылган университет командасы Татар лигасында чыгыш ясарга тиеш иде. Тәүге уенда зал ярым буш калса, күңелсез булыр дип, һәр факультетка беренче курс студентларын – авылдан килгән, татарча яхшы белә торганнарын – җыеп алып килүне йөкләделәр. Шул мәҗбүриләп китерелгән тамашачылар арасында татфактан Галимҗан белән Илгизәр һәм химфактан Хамис белән Кадыйр да бар иде.

Дүртесе дә – хәер, алар гына түгел, залдагы егетләрнең барысы да диярлек – шул кичтә сәхнә тоткан Диләрәгә гашыйк булдылар. Уен ахырында алып баручы аңардан кыска гына интервью да алды. Журфакның беренче курсында укый икән, киләчәктә телевидение йолдызы булырга хыяллана. Булдырачак та ул аны, бөтен җире килгән, бер кашык су белән йотарлык инде менә!

Бер чыгышы аеруча ошады тамашачыларга. Диләрә шул бер номерда гына катнашкан булса да, барыбер бөтен залның мәхәббәтен яулап алган булыр иде, мөгаен. Имеш тә кино төшерәләр икән. Голливудта! «Асыл инстинкт» фильмының римейкын ясарга американнар татар режиссёрын яллаган, янәсе, ә ул төп рольгә Шерон Стоунны түгел, Әлфия Авзалованы чакырган. Мәшһүр җырчы ролен сәхнәдә Диләрә уйнады.

– Әлфия апа, менә моннан кереп, урындыкка утырасың, – дип аңлата режиссёр. – Синнән сорарлар: «Сез ни өчен адвокаттан баш тарттыгыз, мисс Трамелл?» – диярләр. «Мин адвокат артына яшеренергә теләмим, минем яшерер нәрсәм юк», – дип әйтерсең. Сүзләрен бутый күрмә берүк! Менә монда язылган алар, төшерә башлаганчы ятла, пажалысты, кабатла берничә тапкыр! Сүгенеп җибәрә күрмә тагын ялгыш! – дип, режиссёр Диләрәгә бер бит кәгазь тоттыра.

Аннары режиссёр камера каршындагы урындыкка үзе утыра да сул тезе өстенә уң аягын сала.

– Фильмның иң мөһим, иң кирәкле өзеге бу, Әлфия апа! – ди режиссёр. – Менә шушылай, минем кебек иттереп, утырасың башта. Аннары: «Минем яшерер нәрсәм юк», – дигәч, аякларыңны менә шушылай минем кебек мөмки-и-ин кадәр югарырак күтәреп, ботларыңны мөмки-и-н кадәр ныграк аерып аякларыңны алыштырасың. Аңладыңмы? Сул аягыңны уң тезеңә куясың. Аңладыңмы? – дип, режиссёр нәрсәне ничек эшләргә икәнен өйрәтә. – Тиздән төшерә башлыйбыз, сүзләреңне ятлый тор, Әлфия апа!

Әлфия-Диләрә кәгазьдә язылганнарны ятлый-ятлый тегендә-монда йөренә башлый, режиссёр исә операторларга, ут куючыларга ниндидер эшләр куша. Ниһаять: «Башлыйбыз!» – дигән команда яңгырый.

– Туктагыз әле, зинһар, туктап торыгыз! – ди Әлфия-Диләрә.

– Ни булды, Әлфия апа? – дип сорый режиссёр.

– Бу хәтле сүзне каян ятлап бетерим мин сезгә бер минутта?! – дип капризлана Әлфия-Диләрә.

– Ике җөмлә, биш сүз инде анда! – ди режиссёр.

– Юк, сез нәрсә, көләсезме әллә?! Әйтә алмыйм мин моны, бутап

бетерәм. Иң яхшысы – әйдәгез, бу кәгазьне минем аяк астына ташлыйк, барыбер беркем күрми аны анда. Онытсам, тиз генә карап алырмын.

– Ну, ярар! Синеңчә булсын. Прожекторлар нишләп һаман кушылмаган? – дип психлана башлый режиссёр.

Камера артындагы зур-зур прожекторларны кушып җибәрәләр.

– Уф, үләм икән! – дип чәрелдәп җибәрә Әлфия-Диләрә. – Пешәм бит мин бу ут астында! Маңгаема тир бәреп чыкты шундук! Күземдәге тушем агып төшсә, чыраем кап-кара була хәзер! Ачыгыз, ачыгыз тәрәзәләрне!

Шунда камера артында йөрүче кешеләрдән икесе ике яктагы тәрәзәләрне ачалар. Сквозняк чыгып, кәгазьне очыртып алып китә, ә рольнең тексты шунда язылган бит!

– Игътибар! Өч, ике, бер, ноль! Башлыйбыз! Мотор! – дип, команда бирә режиссёр.

Әлфия-Диләрә кәгазь ятасы урынга карап-карап тора да:

– Менә хәзер ни дип әйтергә дә белмим инде мин! – ди.

– Стоп! Стоп! Әлфия апа, ни сөйлисең син?! – дип сикереп тора режиссёр.

Бу номер шулкадәр кызык килеп чыкты ки, залдагы халык егыла-егыла, эчләрен тота-тота рәхәтләнеп көлде генә инде.

Уенга нәтиҗәләр ясагач, – ә Диләрә командасы беренче урынны яулап алды! – «Шаяннар һәм тапкырлар клубы» җитәкчесе беренче курс студентларын ШТК хәрәкәтенә кушылырга чакырды. Егетләрнең дүртесе дә – Галимҗан да, Илгизәр дә, Хамис та, Кадыйр да – ул өндәмәсә дә, университет командасына язылырга кирәк, дигән ныклы карарга килгәннәр иде инде. ШТКны ошатканга, сәхнәдә чыгыш ясыйсы килгәнгә түгел, Диләрәгә якынрак булыр өчен, аны ешрак күрү мөмкинлеге ачылыр дип, алар бер-берсе белән килешмичә бер үк карарга килгәннәр иде.

Тик бераздан, төгәлрәге бик тиздән, егетләрнең өчесе шуны аңлап алды: Кадыйр булган җирдә башкалар көндәшлек күрсәтә алмый икән. Ул бик чибәр егет булу өстенә, тагын ачык, юмор сөючән, чая, шул ук вакытта куркусыз, тәвәккәл һәм хәтта дуамал иде. «Миңа калса, сират күпере аша чыкканда, рәхәт кенә чигәрсең син!» – дигән иде аңа берсендә Илгизәр.

Әлбәттә инде, Диләрәне, «Шаяннар һәм тапкырлар клубы»ның иң сылу кызын, Кадыйр үзенеке итте. Башкача була алмый иде. Шул ук вакытта ул егетләрне дә үзеннән ерак җибәрмәде, бергә туплап торды – дус була белә иде ул. Шулай итеп, дүрт егет һәм бер кыздан торган тату компания оешты. Карап торышка бик бердәм, бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнгән иде алар, беркайчан да аерылмаслар кебек иде.

Ике елдан соң бу бишәү ШТК командасының төп уенчыларына, алыштыргысыз артистларына әйләнделәр. Шулай бервакыт ДКда чираттагы репетиция тәмамлангач, кайтырга дип, урамга чыктылар. Бик матур айлы кышкы төн иде, артык салкын да түгел, саф һава – кыскасы, тулай торакка җәяү кайтырга уйладылар. Репетициядә туган һәвәсләнү суынып бетмәгән иде әле, тагын нинди яңа номерлар күрсәтеп булганлыгы турында бәхәсләшә башладылар болар.

– Егетләр! Эшләтегез инде бераз башыгызны! Эченә аракы салыр өчен генә түгел бит инде баш! – дип үрти-үрти, Кадыйр дусларында иҗат дәртен ныграк яндырырга тырышты.

– Эврика! – дип кычкырып җибәрде шунда Хамис.

– Яле, яле, Хамис! Ни уйлап таптың?

– Егет белән кыз дискотекада билгә бил тотышып, акрын гына бииләр. Егет кызга әйтә: «Әйдә миңа!» Тегесе: «Әйдә!»

– Әбәү, бик тиз булмыймы соң бу? – дип куйды Диләрә.

– Ну, ладно, это же просто номер! – дип акланды Хамис.

– Бу Сансызның башына тагын ни килсен инде?! – дип мыгырданды Галимҗан.

– Син, Буржуй, тыңлап бетер башта! Короче, «Әйдә!», – ди кыз, әйеме? Шуннан ут сүнә, типа, монда күпмедер вакыт үтә. Ут янганда, болар янәшә утырып, кылтыр-кылтыр электричкада баралар. Кызның ваапще кәефе юк инде! «Матурым, сиңа ни булды?» – дип сорый егет. Кыз әйтә: «Син нигә башта ук миңа Актанышта торганыңны әйтмәдең?!» – Хамис соңгы сүзләрен әйтү белән буыла-буыла, гыргылдый-гыргылдый көлә башлады.

Башкаларга да кызык кебек тоелды. Бары тик Галимҗан гына:

– Сансыз! Казаннан Актанышка электричка йөрми, Кукмара түгел бит ул сиңа, – дип куйды.

– Һай, Аллам! Аптырагансың икән! Ну, ярар, электричкада түгел, автобуста кайтсыннар алайса, – дип акланды Хамис.

– Кайту димәктән, бәлки авылга кайту турында берәр нәрсә уйлап табаргадыр? – дип тәкъдим итте Галимҗан.

– Ой, бигрәк банально! Гел совсем тапталып беткән тема ич инде бу-у-у! – дип сузды Диләрә.

– Алайса телевидение турындадыр, бәлки? – дип Галимҗан «гаебен» йолып алырга тырышты.

– Өстенә бастың! – дип, күкерт кебек дөрт итеп кабынып китте Кадыйр. – Телевидение журналисты авылга килә!

– Шуннан? Нәрсәсе кызык инде моның? – диде Диләрә, күзләрен челт-челт йомып.

– Менә хәзер үстерергә кирәк фикерне, кызыгын табарга кирәк. Егетләр, йә?! Кемдә нинди фикер бар? – дип Кадыйр тагын дусларына дәште.

– Ну, нинди фикер булсын инде монда? – диде Илгизәр. – Журналист, оператор, колхоз персидәтеле йөриләр авылны карап.

– Каршыларына кемдер чыга! – диде Хамис, зур ачыш ясагандай.

– Тракторчы! – диде Галимҗан, азартка кереп.

– Габделбәр! – дип исем тапты Хамис.

– Ни өчен нәкъ менә Габделбәр? – дип аптырады Кадыйр.

– Ну, белмим, – диде Хамис, җилкәләрен җыерып. – Безнең авылның иң знаменитый трактористы Габделбәр исемле. Вечно исерек! – диде дә тагын гыргылдый башлады.

– Ни ташый соң ул тракторы белән? – дип төпченде Кадыйр.

– Хет ни ташый! Сенаж, тирес, салам – бөтенесен дә! – дип аңлатты Хамис.

– Ну, ярар. Әйдәгез, күз алдына китерик, – диде Кадыйр. – Журналист, оператор, колхоз персидәтеле урам буйлап баралар, болар каршына килә Габделбәр.

– Әйе, исерек Габделбәр! – дип, төгәллек кертте Хамис. – Көчкә атлый,

алпан-тилпән килә. Үзе бугаз ертып җырлый: «Онытa алмыйм, онытмыйм авылым урамнарын!»

– Ну, ярар, шулай да булсын, ди. Очраштылар болар. Шуннан? – Кадыйр иҗади процесс белән идарә итүне ныклап үз кулына алды.

– Ну, персидәтел таныштыра торгандыр инде журналистны тракторист белән, – диде Хамис арт чүмечен кашып. – «Менә таныш булыгыз, бу безнең калхузның иң алдынгa тракторчысы Габделбәр. Ул бу айда фәлән тонна салам ташыды», – ди.

– Журналист нинди сорау бирә Габделбәргә? – дип Кадыйр Диләрәдән сорады.

– Сорау тупой булырга тиеш! – диде дә кыз, микрофон тоткан булып кыланып, Хамис янына килеп басты: – Сез тракторчы Габделбәр буласыз инде алайса?

– Әйе, – диде Хамис, тракторчы роленә кереп.

– Басудан салам алып кайтасыз, димәк?

– Әйе! Апкайтам да, салам, апкайтам да салам!

Хамис-Габделбәр шулай дип әйтү белән бөтенесе шыр-шыр көләргә тотынды.

– Тә-ә-әк! Монысы әйбәт! – диде Кадыйр, бераз тынычлана төшкәч. – Болар тагын кемне очрата ала?

– Фермадан берәр кешене инде. Ну, белмим, каравылчыны яки ветеринарны.

– Ветеринарга ни ди журналист? – Кадыйр тагын Диләрәгә сораулы караш ташлады.

Кыз, микрофон тоткан булып кыланып, Илгизәр янына килеп басты:

– Сез калхузда ветеринар булып эшлисез инде алайса?

– Әйе, ветеринар булып эшлим.

– Казанда институт бетереп эшләргә кайткансыздыр инде авылга?

– Әйе, өч айда укып кайттым мин.

– Ничек өч айда? Шулай тиз укып бетереп буламы анда?

– Персидәтел җибәргән иде мине укырга. Өч айдан шалтыратты, тизрәк кайт, маллар үлеп бетә, диде.

– Ничек соң эшләр, барамы?

– Бара инде, зарланырлык түгел. Түлке персидәтел Казанга куа хәзер.

– Ник?

– Укуыңны бетереп кайт, ату маллар үлеп бетә, ди.

Бу экспромпт та шәп килеп чыкты, барысына да ошады, Кадыйр Илгизәргә баш бармагын күтәреп күрсәтте.

– Тәк-тәк! Алга таба киттек! – диде ул, тагын Диләрәгә карап. – Каравылчыга нинди сораулар бирәсең инде?

Кыз һаман да шулай телерепортёр ролендә Галимҗан янына килеп басты:

– Бабай, сез монда фермада каравылчы булып эшлисез инде алайса?

– Әйе, кызым, каравылчы инде без.

– Авыр түгелме соң?

– Юк, кызым, бер дә авыр түгел. Йокларга иренмәсәң, эшләргә була.

– Ә төннәрен курыкмыйсызмы соң?

– Курыкмыйм, кызым! Кемнән куркыйм? Монда бит төне буе кеше гел йөреп кенә тора.

– Точно! Бөтен авыл урлаша! Үтердең, Галимҗан! Гел үтердең генә син! – дип бөгелә-бөгелә көлде Кадыйр. Башкалар да аңардан кимен куймады.

– Кайчаннан бирле шыр-шыр киләбез, хәерлегә булсын, – диде Диләрә, шаркылдап көлүдән атылып чыккан күз яшьләрен сөрткәләп.

– Отставить предрассудки! – диде Кадыйр. Шаярып әйтсә дә, ике төрле уйларга урын калдырмый иде бу сүзләр. – Болар барысы да бик шәп, бик кызык, канишны, тик берәр тормышчанрак, актуальрәк, берәр социаль теманы күтәрергә иде.

– Миндә бер идея бар – бик актуаль! – диде Илгизәр.

– Нинди? Яле, сөйлә!

– Бу ел бит президент указы белән хәйриячелек елы дип игълан ителгән иде. Һәрбер чаттан шуны сөйлиләр. Үтүкне кушсаң, хәтта ул да хәйриячелек дип кычкыра башлар кебек. Актуальме? Актуаль!

– Ну, шуннан?

– Кыскасы, мондый юмор: Минзәлә төрмәсендә утыручы җинаятьчеләрнең һәрберсенә тагын берешәр ел өстәделәр. Хәйриячелек елы, дуслар, хәйриячелек елы! – дип, кулларын җәйде Илгизәр.

– Шәп! Гениально! – диештеләр барысы да.

Шулай шаяра-шаяра алар камалышта калуларын абайламадылар да. Җир астыннан калкып чыктылар, диярсең, бер көтү малай-шалай уратып алды боларны. Берсе, башлыкларыдыр күрәсең, Кадыйр каршына килеп басты. Тәмәке сорады башта. Аннары, сез кем, нишләп йөрисез, кебегрәк сораулар яудыра башлады. Кадыйр тыныч кына җавап кайтара торды, студентлар без, ДКда репетициядә булган идек, хәзер тулай торакка кайтабыз, диде.

Ярый әле Кадыйр вакытында, андый-мондый хәл чыкса дип, егетләрне өйрәтеп куйган иде. Алар Диләрәне уртада калдырып, бер-берсенә аркалары белән дүртесе дүрт якка карап бастылар. Тик шәһәр шпанасы сан ягыннан күпкә артыграк иде, өстәвенә караңгылык эченнән бер-бер артлы чыгып кына тордылар. Кимендә егермеләп гопникны исәпләде Кадыйр.

Кайсы тулай торактан, кайсы институтта укыйсыз кебегрәк сораулар яңгырады аннары. Бу көтелмәгән очрашу тыныч кына, татулык, дуслашу белән бетәрдәй булса, көн кире ягы белән туар иде. Ә инде теге шпаналар башлыгы: «А тёлка вроде ничёшная у тебя», – дип, Кадыйрның җилкәсе аркылы Диләрәгә кулын сузгач, егет бүтән түзеп тора алмады, әрсез чыраена берне сылады тегенең.

Шуннан китте сугыш, дөмбәсләшү, акырыш-бакырыш! Студент егетләрнең һәрберсенә каршы биш-алты шпана туры килә иде. Сан ягыннан күп булсалар да, батырлык ягыннан бирешәләр иде гопниклар, чын сугышудан бигрәк кычкыру-янаулар күбрәк ишетелә иде алардан. Студент егетләр дә бирешергә җыенмады: аяктан егылмаска, гопникларның һөҗүмнәрен кире кайтарырга тырыштылар.

Шушы хаоста берзаман җан өшеткеч акыру ишетелде. Аның артыннан ук кемдер:

– Братва! Кипиша закололи! – дип кычкырды.

Шунда барысы да сугышудан туктап, тавыш килгән якка борылдылар.

Каннан кызарган карда еш-еш сулап, бер егет ыңгырашып ята иде. Чыгып кына килә торган сирәк мыегы ап-ак – бәсләнгән. Авызыннан әледән-әле пар бөркелә. Куллары белән кендек тирәсен кысып каплаган, тик бармаклары арасыннан барыбер кан саркый.

– Скорый чакырыгыз! – диде шунда кемдер, илереп.

Егет соңгы көчләрен җыеп, башын күтәрә төште, тавыш килгән якка күз ташлады. Җаны күккә ашырга бер мизгел кала: «Әнигә әйтмәгез, үтерә ул мине!» – диде һәм нишләптер елмайды. Киләсе мизгелдә аның башы хәлсезләнеп карга төште, куллары да аска шуышты, бите өстендә пәйда булган пар болытчыгы – соңгы сулышы – салкын һавада эреп югалды...

Барысы да катып калды, күпмедер вакытка үле тынлык урнашты. Беренче булып, Кадыйр аңына килде. Хәер, аның алга таба кылган гамәлләре, аңга килү түгел, һаман да шок хәлендә булуы турында сөйли бугай. Чөнки ул Кипишьның үле гәүдәсе янына йөгереп килде, калтыраган куллары белән ашыга-ашыга аның курткасының изүен ачты, йөрәгенә массаж, авызга авыз куеп, ясалма сулыш ясый башлады.

– Братан! Сула, братан! Үлмә, братан! – дип кычкырды Кадыйр.

Ләкин соң иде инде – Кипишь җан биргән иде. Шуны аңлагач, аңа берничек тә булыша алмаганына инангач, Кадыйр торып басты һәм аны шаккатып күзәтеп торган шпаналарга һәм дусларына сөзеп карады. Аннары ул карда яткан канлы пычакны күреп алды. Шуны кулына алгач:

– Кайсыгызның эше бу?! Ул бит кеше! Ул бит әле бала гына! – дип акырды.

Шунда сиреналарын акыртып, милиция белән «Скорая помощь» килеп җитте. Шпаналар кайсы кая качып бетте. Кадыйрны, Хамисны, Илгизәрне, Галимҗанны, Диләрәне ОВДга алып киттеләр. Икенче көнне Кадыйрдан кала башкаларны җибәрделәр. Тикшерү эше елдан артык барды. Судта Кадыйрны Кипишьны үтерүдә гаепле дип таныдылар. Пычакта да бары тик Кадыйрның гына бармак эзләре табылган, өстәвенә аның кулында мәетнең кан эзләре калган иде. Аңа 12 ел бирделәр.

## 6. Ә мин аның белән үбештем!

Илгизәр кесәсеннән телефонын чыгарды, ниндидер фотоны табып ачты:

– Диләрә дә килә, димәк...

– Без барыбыз да аңа гашыйк идек, – дип, авыр сулады Галимҗан. Аннары ул Илгизәр ачкан фотоны күреп алды һәм аның янына килеп, игътибар белән портретка карады. – Ничәнче курс икән бу, Илгизәр?

– Ни күрдегез анда? – диде Хамис артык исе китмичә.

– Сансыз! Син чукракмы әллә?! Диләрә килә, диделәр бит сиңа! Диләрә!

– Шуның фотосын карыйсызмыни? Кая күрсәтегез, сыразы әйтеп бирәм! – дип, Хамис та болар янына килде. – Икенче курс бу! Финал уенынннан соң төшкән идек.

– Универның йолдызы иде бит ул Диләрә, калганнар аның янында соры масса кебек кенә иде, – диде Илгизәр, хатирәләренә бирелеп.

– Кадыйр да шул соры массага керә идеме синеңчә? – диде Хамис, авызын кыйшайтып.

Илгизәр белән Галимҗан бу сүзләрне ишетмәмешкә салыштылар.

– Дааа, аппетитный иде инде, заразы! – дип, Хамис корсак астында чалбарын ышкып-рәтләштергәләп куйды. – Кияүдә микән ул?

– Тфү, сансыз! – дип төкеренде Галимҗан. – Күзләре майланды тегенең гел!

– Әллә бүгенгә ният-планнар корасыңмы, Хамис? – дип елмайды Илгизәр. – Селәгәйләреңне сөртеп ал! Син соң кая үреләсең, отец-героин?

– Син дә өйләнгән инде! – диде Хамис, үпкәләбрәк.

– Хәзер дә шундый чибәр микән? – диде Галимҗан хыялыйрак бер тавыш белән.

– Монысы да нидер өмет итә бугай әле! – дип гыргылдады Хамис. – Ә мин, дөресен генә әйткәндә, Диләрә килеп кергәч, үз-үземне тыя алмыйча көлеп җибәрермен дип куркам. Ржака булыр кебек.

– Ник? Нинди ржака тагын? – Галимҗанның озын борынындагы калын күзлеге тагын сикереп куйды.

– Ник, ник! Чөнки 20 ел узды уже безнең күрешмәгәнгә!

– 20 ел бик күп ул хатын-кыз өчен. Егерме елда ул анасыннан туып җитлеккән кыз булып өлгерә, – диде уйга батып утырган Илгизәр.

– Әнә, тыңла акыллы кеше нәрсә ди! – Хамис шулай Галимҗанга эндәште. – Ә җитлеккән кыз 20 ел эчендә әбигә әйләнә.

– Аның иң кызганычы анда түгел, ә кайчандыр яшь-чибәр булган хатынның үзен һаман да шундый дип уйлап ялгышуында. Яшь булып калырга, чибәр булып күренергә бөтен җаны-тәне белән тырышкан картайган хатыннан да кызганыч кеше юктыр ул бу дөньяда, – дип, авыр сулады Илгизәр.

– Диләрәнең күз тирәләрендә җыерчыклар чыккандыр инде. Маңгаен, муенын сырлар баскандыр, – дип гыргылдады Хамис.

– Кешнәмә, Сансыз, тайларны куркытырсың! – диде Галимҗан.

Хамис тагын бер рюмка коньяк салып эчеп куйды, дусларына тәкъдим итү турындагы уй башына ялгышып та кереп карамады.

– Диләрә миңа шундый нык ошый иде, шундый ярата идем мин аны, – диде Илгизәр, романтикага бирелеп. – Мин курка идем аның күзләренә карарга. Карасам, минем оятсыз уйларымны белеп алыр кебек иде. Ә аңа карагач, тере егеттә башка төрле уйлар туа да алмый – бары оятсызлары гына! Лекция башында үземчә ныклы карарга килә торган идем: бүген бары тик лекторга гына карап утырам! Кая ул?! Баш үзеннән-үзе аның ягына борыла. Аңа борылып карыйсың да дөньяларыңны онытып сокланып карап утырасың. Ә ул бик сизгер! Никадәр генә тырышып, лекция язып утырмасын, синең карашыңны бик тиз тоеп ала, сиңа үзенең көйдергеч карашын ташлый. Син шундук лекторга борылып утырасың. Имеш тә, юк, мин лекция тыңлыйм...

– Диләрәнең исен хәтерлим мин һаман да! – дип күтәреп алды Галимҗан. – Башка кызлардан төрледән-төрле хушбуй исләре килә иде. Кайберләреннән – тәмле, хуш исле, кайберләренеке ошамый иде. Ул да берәр төрле импортный духи сөртенгәндер инде, тик аның үз исе иде – шундый башка беркемнеке белән дә бутап булмый торган аромат бар иде аңарда. Сафлык та сизелә иде анда, яңгыр явып киткәннән соң саф һаваны

куа торган җил дә бар иде кебек, җиңеллек тә, беленер-беленмәс кенә тагын әллә нинди төсмерләр шунда...

– Ә минем аның белән үбешкәнем бар! – дип ярып салды Хамис. Дуслары шундук «айнып» китте.

– Алдашма! – диде Галимҗан.

– Кайчан ул? – диде Илгизәр.

– Кадыйрның туган көнендәме? – диде Галимҗан үзенең сиземләнүеннән үзе дә курыккандай.

– Әйе! Ә син каян беләсең, Буржуй?!

– Тәгаен белми идем инде моңа кадәр, гөманлый гына идем.

– Нидән чыгып?

– Син, Сансыз, әйдә, сөйлә башта, аннары әйтермен.

– Әйе, ничек булды ул? – диде Илгизәр, әле һаман да бик ышанып бетмичә.

– Хәтерлисезме, аракы бетте? – дип сөйли башлады Хамис.

– Әйе, – диде Илгизәр.

– Кадыйр миңа акча тоттырды да: «Оч кибеткә!» – диде. Ну, мин очтым. Өч ярты тиде ул биргән акчага. Кайтканда да ашыктым инде, чаптым дурак сыман. И канишны абынып егылдым, заразы! Шешәләр чәлпәрәмә килде.

– Шуннан нишләдең инде? – диде Галимҗан, Хамисны кызганып, гәрчә аның белән булган бәла-каза егерме ел элек булса да.

– Нишлим инде? Торып, өсләрне кактым да әкрен генә общагага кайттым. Иелгән башны кылыч кисмәс әле, минәйтәм.

– Туктале! – диде Илгизәр. – Мин бик яхшы хәтерлим ул көнне! Син бит аракы күтәреп кайттың, алдашма!

– Алдашмыйм мин! – диде Хамис, ачуы чыгып. – Тыңлап бетерегез! Ну, вот, короче. Кайттым общагага, безнең этажга мендем, ишек янына килдем дә, ачарга куркып басып торам. Шунда күрше бүлмәдән калаклар тотып, Диләрә килеп чыкты. «Нишләп торасың монда, ник кермисең?» – ди. Үзе елмая, кәефе шәп, шампанский башына киткән моның әйбәтләп кенә! Шулай-шулай мин әйтәм, Кадыйр акча тоттырып, аракыга җибәргән иде, абынып егылдым, ашыгып бәреп ваттым шешәләрне, дим. «Шулкадәр борчылма инде, шуның өчен генә, Хамисик!» – ди бу миңа. Шунда кочаклап та алды мине! Минем бөтен тән калтырый башлады. «Чү-чү, тынычлан», – диде Диләрә. «Ты же мужик! Кил әле, мин сине бер үбәм!» – диде дә иреннән суырып-суырып үбә башлады. Ну, мин бит в натуре мужик! Үзе куенга кереп торганда этеп җибәрим ыштули?

– Шуннан? – дип сорады Илгизәр, җавап бирәсе урынга.

– Ну, баш китте инде минем сыразы! – диде Хамис. – Куллар автоматически билдән аскарак шуыша башладылар.

– Сансыз! – Галимҗанның күзлеге парланган иде.

– Нәрсә Сансыз тагын? Мин бит тере кеше! Әйтәм бит, үзе килеп асылынды муенга! – диде Хамис, ачуы чыгып. – Алдашасым килми, куллар тик тормый башлагач, Диләрә үбешүдән туктап, мине үзеннән читкә этеп куйды. Решительно так, ике уйламаслык итеп. Аннары кесәсеннән чыгарып, өч яртылык акча тоттырды. «Җаең булгач, бер кайтарырсың. Бу юлы чапма

инде», – дип елмайды да бүлмәгә кереп китте. Мин кибеттән аракы алдым да тужы бүлмәгә кайттым.

– Әйе, кайттың да туган көн беткәнче майлы күзләреңне Диләрәдән алмыйча, аңа текәлеп карап утырдың. Диләрә моны тоемласа да, синең якка бер мәртәбә дә борылып карамады. Кадыйр сизенмәсен дип тырышкандыр инде, – диде Галимҗан, кулъяулыгы белән маңгай тирен сөртеп.

– Штирлиц, карале бу Буржуйга! – Хамис, Илгизәргә эндәшеп, Галимҗанга бармагы белән төртеп күрсәтте. – Без сине Штирлиц дип йөрибез, менә кем икән бит ул Штирлиц! Кем кемгә караган, кем карамаган – всё фиксировал, гад!

– Үзең син гад! – дип торып басты Галимҗан. – Минем күңелгә шик керде ул көнне нигәдер.

– Ничек инде нигәдер? – дип сорады Хамис.

– Чөнки мин бик яхшы хәтерлим, Диләрә чыгып китәр алдыннан бик озаклап, иреннәрен буяп утырды. Кире кергәндә, помадасы юк иде диярлек...

– Ну, правильно! Мин ашап бетергәч, – дип гыргылдады Хамис.

– Кергәч, кечкенә көзгесен чыгарып, тагын озаклап ирен буяды. Помада кая киткән соң шул арада, дигән сорау туа. Берәрсе белән үбешеп керде микәнни, дип уйлый башладым мин. Юк, минәйтәм, булмас! Ә булса?! Кем белән? Диләрә чыгып торган арада безнең компаниядән бүлмәдә син генә юк идең, Сансыз. Өстәвенә, кайткач Диләрәдән күзеңне алмадың. Хәер, мин боларны шул кичтә уйлап утырдым да оныттым, – дип аңлатты Галимҗан.

– Ә мин онытмадым, – Илгизәр бу сүзләрне ничектер күңеленнән генә әйтмәкче иде, тик ул аларны дуслары ишетелерлек итеп әйтеп куйды.

– Кемне онытмадың? – дип сорады Галимҗан.

– Кемне дисеңме? – Илгизәр бераз югалып калды, сорауны аңлап бетермәгәнгә сабышты. – Кемне булсын инде... Ни... Беренче мәхәббәтемне. Малай чакта фантазияләреңдә күз алдына китерергә тырышасың бит инде кызлар белән үбешүнең ничек рәхәт икәнен. Ә чынлыкта беренче мәртәбә үбешкәч, син уйлаганга караганда, күпкә ләззәтлерәк икәнен аңлыйсың. Андый рәхәтлекне минем бүтән беркайчан да тойганым юк! Аяклар ничектер хәлсезләнә, баш әйләнә башлый, ә үзең каядыр очып китәсең... Мин аның белән гомерем буе очарга риза идем...

– Ник очмадың соң? – диде Хамис, чираттагы рюмка коньякны йотып.

– Булмады шул, барып чыкмады, – дип авыр сулады Илгизәр.

– Тормыш – анаңны ормыш! – дип, тантаналы төстә игълан итте никтер Хамис. – Хәзер алай үбешә белмиләр кызлар!

– Ә син каян беләсең кызларның ничек үбешкәнен? – Галимҗан бу юлы күзлеген сөртеп утыра иде, шунлыктан ул Хамиска ничектер сәеррәк караган сыман тоелды.

– Менә бу соңгы танышканын алыйк, например, – дип, кулларын җәеп, тәмләп сөйли башлады Хамис. – Карап торышка нормальный кебек инде үзе, бик нежный күренә. Үбешә башлаган идек, как включила свой моющий пылесос!

– Пылесос? Өй җыештыра идемени? – дип, авызын ачты Галимҗан.

– Нинди өй җыештырсын?! Образно әйтәм мин, Буржуй, образно! –

дип, Хамис кулларын җилпеде. – Үзенең метр ярымлы телен менә болай иттереп бөтерә-бөтерә, бораулый-бораулый минем авызыма китереп тыкты. Бер чыгара, бер кертә, швейный машинка урынына эшли тегенең теле мин сиңа әйтим! Маташа торгач, телнең керешен ертты, авыздан каннар чыкты!

– Шул кирәк сиңа! Йөрмәссең теләсә кем белән үбешеп! Сансыз! – дип, Галимҗан икенче якка борылып утырды.

Ишеккә карады.

## 7. Пенсиядәге фахишә

– Диләрә килде бугай! – диде Галимҗан калтыравык тавыш белән.

Илгизәр белән Хамис икәүләшеп, көзге янына килеп бастылар, чалбарларын тарткалап куйдылар, якаларын тигезләделәр, чәчләрен төзәткәләделәр.

– Йә, ничек? Шәп күренәмме? – дип сорады Илгизәр, Хамисның көзгедәге чагылышына күз кысып.

– Сельпо! – дип гыргылдады Хамис!

– Син үзең калхузник! – Илгизәр этәчләнеп, ияген өскә күтәрде.

– Бала-чага булмагыз инде, егетләр! – диде Галимҗан, чыраен сытып. – Официант! Официант, дим! Тагын бер кунак килде, ахрысы.

Официант үз бүлмәсеннән чыгып, арысланлы ишеккә таба юнәлде:

– Сүздән тора дәвам, сүздән тора! Кеше заты синең сүзең белән китеп бәхет тапкан эздән тора – дәвам бездән тора, – дип декламацияләде үзе.

Өч дус аның артыннан ияреп, шулай ук ишеккә таба юнәлгәннәр иде:

– Сезгә өстәл янына барып утырсагыз, яхшырак булыр, – диде официант.

– Курыкмагыз, без качарга җыенмыйбыз, – Галимҗан шулай дисә дә, үзенең сүзләрендә шөлләү ноталары сизелде.

– Мин курыкмыйм, куркасын куркып бетергән инде мин, – диде официант тыныч кына. – Ышаныгыз, зинһар, мин әйткәнгә, тыңлагыз сүземне. Мин сезгә караганда яхшырак беләм кайбер нәрсәләрне. Әйтәм бит, өстәл янына барып утырсагыз, үзегезгә яхшырак булачак. Чынлап!

Илгизәр, Галимҗан, Хамис урындыкларга барып утырдылар. Шуннан соң гына официант кесәсеннән ачкыч чыгарып, ишек йозагын ача башлады.

Галимҗан янәдән көзгегә карап куйды. Анда бик купшы итеп бизәлгән, ялык-йолык килгән сәхнә уртасында Диләрә басып тора иде. Өстендә киеме юк, коенмалык кына. Сул ягында нәкъ шундый ук шәрә диярлек һинд кызы, уң ягында кытай кызы елмаеп торалар иде. Сәхнә артыннан авызын ерып, үзе утырган инвалид коляскасының тәгәрмәчләрен әйләндерә-әйләндерә Рузвельт килеп чыкты, Диләрәнең җилкәсенә «Miss Universe» дип язылган тасма элде, башына таҗ кигертте. Шунда сәхнә артыннан кечкенә генә малай килеп чыкты да Диләрәгә таба йөгерә башлады. Дөнья чибәре, малайны күргәч, елмаеп аңа каршы барды, очрашкач кочып күтәреп алды, битен үпте. Аннары Диләрә әллә каян гына себерке тартып чыгарды да шуңа менеп атланып очты да китте. Малай елап калды...

Официант ишекне ачып җибәрде. Киләсе мизгелдә ачылган күренеш өч дусның хәтта иң куркыныч төшләренә дә керә алмас иде мөгаен. Бусагада Диләрә тора иде. Дөресрәге утыра иде. Инвалид коляскасында. Кайчандыр

университетның беренче йолдызы булган кыз хәзер бик таушалган, картайган, әби төсләре керә башлаган хатынга әверелгән иде. Коляска тәгәрмәчләрен куллары белән көч-хәлгә әйләндереп Диләрә өстәл янына килеп туктады. Ул арада официант ишекне бикләп, ачкычын кесәсенә салып куйды.

Уңайсыз тынлык урнашты – кем дә ни дә булса да әйтергә белмәде. Диләрә үзе беренче булып телгә килде:

– Шулай тораташтай катып торабызмы хәзер?

Өч ир-ат шаккаткан күзләрен Диләрәдән аерып, бер-берсенә карашып алдылар, тик әле һаман берсе дә үзеннән бер сүз дә кысып чыгара алмады.

– Бәлки салып бирерсез? – дип сорап куйды Диләрә.

Хамис урыныннан сикереп торды:

– Нәрсә салыйм, Диләрә?

– Шәраб.

– Кызылнымы, акнымы?

– Кызыл.

– Син эчәсең әллә, Диләрә? – дип сорады Галимҗан һәм тамагын кырып куйды.

– Ә син әллә беренче тапкыр күрәсеңме минем эчкәнне?

Илгизәр белән Хамис, Галимҗанга күзләренең агы белән генә карап, аның бик акыллы булмаган, урынсыз сүз әйтүен аңлатырга тырыштылар.

– Ә нигә сез миңа шулай итеп карыйсыз? – диде Галимҗан аларга. – Рульдә түгелмени син, дигән мәгънәдә әйткән идем мин.

Илгизәр, кулларын җәеп, Галимҗанга күзләрен акайтып карады.

– Ник? Нәрсә булган соң шулкадәр? – дип акланды Галимҗан. – Инвалидлар йөри торган машиналар да була бит! Аларда газ-тормозларны кулга көйләп куялар, махсус билгесе дә бар әле шундый – сары квадрат эчендә коляскада кеше утыра. Синең кулларың эшли бугай бит, Диләрә?

– Юк, мин рульдә түгел, – диде Диләрә.

– Гафу ит, Диләрә, мин артык дулкынланудан буталдым азрак, – диде Галимҗан. – Минем ни дип әйтәсем килгән иде...

– Син үз сүзеңне әйттең инде, Буржуй! – дип бүлдерде Хамис.

– Сансыз!

– Хәзер минем чират. Ә минем безнең очрашу хөрмәтенә, бигрәк тә Диләрә хөрмәтенә, аның исәнлеге...

– Хамис, әйдә яхшырагы мин әйтим әле тостны, яме, – дип, сүзгә кушылды Илгизәр. – Диләрә! Син әле һаман да шундый ук... Диләрә, син тамчы да үзгәрмәгәнсең... Диләрә, дөрес аңла мине, зинһар!

– Егетләр, әйдәгез эчеп куйыйк инде, – диде Диләрә.

– Булды, җитте, Илгизәр! Ату тагын берәр нәрсә әйтерсең, җә! Очрашу хөрмәтенә, дуслар! – диде дә Хамис, һәркем белән рюмкасын чәкештереп чыкканнан соң, коньягын йотып куйды. Аның артыннан – башкалар да.

– Егетләр, гафу итегез, – диде Диләрә. – Монда дамский туалет бармы? Миңа үземне бераз тәртипкә китерергә кирәк. Сезнең янга кунакка керәсемне белмәдем ич мин.

– Әйдәгез, мин сезне ишеккә кадәр илтеп куям, – дип, сүзгә кушылды официант. Ул һаман да тыйнак кына арысланлы ишек янында басып тора

иде. Официант Диләрәнең коляскасын арттан этеп, ишекләрнең берсенә таба юнәлде. – Хистән тора дәвам, хистән тора...

Коляска ишеккә көчкә сыйды. Диләрәне озаткач, официант үз бүлмәсенә кереп китте. Алар күздән югалгач, Илгизәр телгә килде:

– Егетләр, сез нәрсә инде?! Авызыгызны чамалабрак ачыгыз инде, арышыгызны урыйм! Әйтмәсәм дә булмады!

– Үзеңне бел! Үзең ни дидең соң? Диләрә, син әле һаман да шундый ук, имеш! Син тамчы да үзгәрмәгәнсең! Дебил! – дип психлана башлады Хамис.

– Син дә шәбрәк әйтмәдең инде, Сансыз! – диде Галимҗан.

– Егетләр, әйдәгез, бүтән андый җүләр сүз сөйләмик инде, – диде Илгизәр ялварган сыман.

– Нинди була соң ул – җүләр сүз? – дип сорады Хамис.

– Син әйткәннәр барысы да шундый, Сансыз, – дип кыстырды Галимҗан.

– Юк, берәр нәрсә турында сөйләшергә кирәк бит инде Диләрә белән хәзер. Әйтегез алайса, ни турында ярый сөйләшергә, ни турында ярамый? – диде Хамис, үпкәләгәндәй.

– Тәк, беренчедән аяклары турында бер сүз дә әйтергә ярамый! Коляска турында да, – диде Илгизәр, Хамисның борын төбендә имән бармагын болгап.

– Бию турында да сөйләшергә кирәкми, Сансыз! – диде Галимҗан нәсихәт биргән тонда. – Билсәпит тә ябык тема, аның яшь чакта нинди чибәр булганы да ябык!

– Ни турында сөйләшергә ярый соң вапшы? – дип аптырады Хамис.

– Син хатын-кыз белән ятак-матак турында гына сөйләшә беләсең шул! – диде Галимҗан, ачуы чыгып.

– Шунысы бик җиткән инде, артыгы кирәкми, – дип гыргылдады Хамис.

Диләрә кире чыкты. Бизәнгәндер инде ул үзенчә, тырышкандыр, тик кыяфәтендә күзгә бәрелеп торган үзгәреш әллә ни сизелми иде.

– Диләрә, без... – дип, Илгизәр сүз башламакчы иде, хатын аны бүлдерде:

– Аңлыйм мин сезне, малайлар. Миңа да уңайсыз булыр иде, мин дә ни әйтергә дә белмәс идем, әгәр дә, әйтик, мин монда бүген үз аякларым белән килеп керсәм, ә, мәсәлән, Хамисның кулы булмаса.

Хамис шундук ирексездән үзен-үзе кочып алды, учлары белән беләкләрен каплады:

– А що сыразы Хамис то?!

– Ну, мин болай гына әйттем, Хамисик! Гафу ит, теләсә кемнеке булса да инде... Миңа бик уңайсыз булыр иде, әгәр минем бар җирем дә исән булып, башка берәүнең аягы яки кулы булмаса. Мин кайчагында көзгегә каранам да: «Ну, нәрсә инде бу?! – дим, – Ярамый бит инде болай!» – дим... Әйдәгез, тагын бер мәртәбә миңа карагыз әле! Таныш булыгыз: бу мин – Диләрә. Ә менә бу – мин утырып йөри торган коляска. Бусы тәгәрмәчләре, бусы аяк куя торган урыны. Ә бусы – мин. Мин хәзер шундый.

– Нишләп без сине оныткандбыз икән соң, Диләрә? Нигә без шундый битараф? – диде Галимҗан, авыр сулап.

– Кая инде ул чакта кеше кайгысы идеме?! Үзебезнең дә хәлебез хәл иде шул! – дип куйды Хамис.

– Саллы дәлил! – дип төрттерде Илгизәр.

– Бүген ничек яшисең соң, Диләрә? Кем булып эшлисең? Гаиләң, балаларың бармы? Сөйләле, әйдә! – диде Галимҗан күзләрен мөлдерәтеп.

– Юк сөйләр нәрсә! – диде Диләрә, кистереп һәм тирән итеп сулап куйды. – Ничектер бер мәгънәсез үтте дә китте гомер.

– Ты шту?! – диде Хамис. – Иртә әле безгә гомер үтеп китте дип уфтанырга! Ярты гомер алда әле!

– Сез, ирләр, бәлки алай дип әйтергә хаклыдыр, тик мин...

– Хаклы, канишны! – дип гыргылдады Хамис. – Мужик кеше хатын-кыз белән сөйләшкәндә, һәрвакыт хаклы!

– Бүлдермә инде, Сансыз! Сөйләсен инде! – диде Галимҗан, гаҗизләнеп.

– Ярар, без капчыкта ятмас барыбер, – диде Диләрә, ныклы бер карарга килгәндәй. – Хәер, мин аннан оялмыйм, мин – карт, пенсиядәге фахишә!

– Ниче-е-ек?! – дип сузды Галимҗан. – Аңлатыбрак сөйләле, Диләрә!

– Сез аңлатыгыз башта! Ничек монда җыеласы иттегез?

– Ну, без важный эш булганга җыелдык, менә син нишләп йөрисең? – диде дә Хамис, иреннең бер читен кыйшайтып, Диләрәгә хәйләкәр караш ташлады.

– Мин монда эшлим.

– Кем булып? – Галимҗан тиздән елап җибәрер кебек иде.

– Кем дип инде... Администратор дисәң дә ярый...

– Син кунакханәдә администратор булып эшлисең? Синме соң бу чыннан да, Диләрә? – дип, Галимҗан чәчләрен артка сыпырып куйды.

– Юк, мин күптәннән башка Диләрә инде.

– Ә бит без барыбыз да сиңа гашыйк идек! – Галимҗан нигәдер түшәмгә карап утыра иде, чын Диләрәне эзләдеме соң шулай?..

– Тик син Кадыйрны сайладың, – диде Илгизәр үкенечле тонда.

– Хатын-кыз вай-фай кебек бит ул – бөтенесен дә күрә, тик иң көчлесенә тартыла! – дип шаркылдап көлде Хамис.

– Тфү, Сансыз тәре! – диде Галимҗан.

– Ә, минемчә, Хамис хаклы – хатын-кыз һәрвакыт көчлерәкләр янына сыеша, – диде Илгизәр. Аңардан мондый сүз чыгар дип, Галимҗан бер дә көтмәгән иде.

– Бәхәсләшәсем килми, күрәсең, сез хаклыдыр, – диде Диләрә, килешкәндәй. – Тик көч тә төрле була бит: акыл көче, мәсәлән, яки талант көче...

– Чын дөресен әйтеп сөйләшкәндә, хатын-кыз нинди генә вазгыятькә эләксә дә, – диде дә, Илгизәр тынып калды. Бераз уйлап торгач, дәвам итте: – Прагматизм шулкадәр көчле хатын-кызда, нинди генә хәлгә тарыса да, ул үзенең югалтулары мөмкин кадәр азрак булсын дип тырыша. Песи кебек гел дүрт тәпиенә төшә хатын-кыз.

– Ә менә монысы дөрес түгел инде! – дип килешмәде Диләрә. – Хатын-кыз табигатенә җиргә якынрак булу хас, ул тормышчанрак – анысы хак, тик тормыш үзе дә бик зәгыйфь нәрсә бит.

– Ә ник соң алайса ир-ат хатын-кызны ташлап киткәндә, үзен гаепле итеп хис итә, ә хатын-кыз китсә, ир-атны гаепле дип саный? – Илгизәр җавап көтеп, гәүдәсен Диләрәгә авыштырды.

– Монысы да дөрес түгел! Мин дүрт тәпигә төшмәдем һәм гаепле дип үземне саныйм, – диде Диләрә. – Дөресен генә әйткәндә, Илгизәр, монда бәхәсләшер урын да юк. Күптән исбатланган: хатын-кызлар гаепле булуларын тирәнрәк һәм авыррак кичерә. Минем әле дә һәр көнем Кадыйр турында уйлап уза.

– Ләкин бит Кадыйрның язмышы шундый булуда синең бер гаебең дә юк? – дип Галимҗан томаланган борынын тартып куйды.

– Бар.

– Юк! – диде Илгизәр, катгый итеп. – Мин беренче курстан ук егетләргә дә, Кадыйрның үзенә дә, чынлап та, шаярып та әйтә килдем – характерыңны үзгәртмәсәң, башың төрмәдән чыкмый синең, дидем!

– Аллаһы Тәгалә биргән характерны үзгәртеп буламы? Тышаулап буламы аны?! – Соравы түгел иде бу Диләрәнең, инанып әйтүе иде.

– Алда котылгысыз һәлакәт көткәнен белә торып, юлын үзгәртмәгән кеше кем була? – дип кызып китте Илгизәр. – Әйе, аңа неформаль юлбашчы булу, үзен башкалардан өстен итеп хис итү, алар белән идарә итү бик ошый иде. Әнә күрәсезме? Безнең өчен урындыклар, ә үзенә затлы кәнәфи әзерләгән! Әйе, ул куркусыз, чая, тәвәккәл егет иде. Шул ук вакытта аның күп кенә гамәлләре акылсыз, дуамал иде шул. Шуңа күрә, Диләрә, син үзеңне юкка камчылыйсың.

– Әллә нинди абракадабра сөйли башладыгыз әле сез! Берни аңлашылмый! – дип, һәрвакыттагыча, бик «вакытында» сүзгә кысылды Хамис. – Теге официантның чире йокты ыштули?

– Диләрә, син пенсиядәге фахишә мин, дисең... Ничек шулай килеп чыкты соң ул? – диде Галимҗан, үтә дә нык читенсенеп.

– Ни белән булса да шөгыльләнергә кирәк бит инде, – дип, авыр сулады тагын Диләрә. – Ир-атларның ач карашларын тою да туйдырып бетерде. Кыскасы, уңга-сулга типтерә башладым мин.

– Нигә?! – дип ачынды Галимҗан.

– Акылдан язмас өчен онытылырга, баштагы уйлар өермәсен тынычландырырга бер ысул табарга кирәк иде. Аракы эчә алмыйм, наркотиклардан курыктым, – диде Диләрә бернинди хиссез.

– Ә мин общий наркоздан куркам! – дип, тагын кысылды Хамис. – Операция ясаганда, аяк-кулларны бәйләп, уколны көчкә кададылар врачлар. Йоклап китәрмен дә уянмам кебек!

– Ә минем общий наркоздан күптән чыкканым юк бугай инде. Яшәү дә мөмкин түгел, үлеп тә булмый, бернине дә кире кайтара алмыйсың, – диде Диләрә үзенең күзләре ничектер пыялага әйләнгән кебек иде.

– Шуннан, Диләрә? – диде Илгизәр. Аның йөз-кыяфәтенә карасаң, кайсыдыр бер төше бик нык авыртадыр дип уйларлык иде.

– Бәлаләрне онытырга гына дип башланган бу шөгыль аннары һөнәргә әйләнде. Коляскага утырып йөрүгә калгач, ир-атлар ничек карасын инде?! Пенсиягә чыгарга туры килде, – диде Диләрә, елмаерга тырышып.

– Ә нишләп коляскага калдың, Диләрә? Авария-мазар булдымыни? – диде Галимҗан, хатынны кызганудан кашларын җыерып.

– Әйе, авария, катастрофа! – диде Диләрә. – Эчсә, башы китә торган бер клиент бар иде. Депутат үзе! Ул кичне эчү өстенә үлән дә тартты ул, гел

ычкынды шуннан соң, күзенә әллә ниләр күренә башлады. Пычак күтәреп, мине куып йөри башлады. Качалмадым, куып тотты да кул-аякларымны пычагы белән кадап-кисеп бетерде, типкәләде аңымны югалтканчы. Шул умыртка сөяге сынгач аңымны югалтканмындыр инде мин.

– Диләрә-ә-ә! – Галимҗан елый иде.

– Акча бирдеме соң хет? – дип сорады Хамис.

– Бирер, тот! Куып тотар да тагын берне бирер! Депутат ул дип торам бит мин сиңа! – диде Диләрә, ачуы чыгып.

– Күптән булган хәлме инде бу? – дип сорады Илгизәр.

– Шактый вакыт узды инде, – дип, Диләрә күңеленнән елларны саный башлады. – Сигез ел элек. Бүгенге эшем менә шундый – кунакханәгә урнашкан ирләргә кызлар тәкъдим итеп йөрим.

Диләрә сумкасыннан чыгарып, Хамиска фотоальбом сузды:

– Важный эш буенча җыелдык, дигән идең, шушыдыр инде сезнең важный эшегез! Мә, тот, сезгә бирергә куштылар, сайлап алсыннар, диделәр.

– Анаңның бәтинкәсе! – дип куйды Хамис, альбомны ачып карагач. – Малайлар, карагыз әле юри генә! Син боларның мамочкалары ыштули?!

Галимҗан да альбомга күз төшерде:

– Яп-яланаяк!

– Нәрсә, Буржуй? Әллә беренче тапкыр шәрә кызлар күрәсеңме? – дип көлде Хамис. – Син ничәне аласың?

– Кит әле моннан! – дип, Галимҗан Хамисны читкә этте.

– И-и-и, карагыз әле моның кыланышына?! Әйтерсең лә, нецелованный малай! – дип гыргылдады Хамис.

– Мин бит син түгел!

– Ярар, әкият сөйләгән бул инде, әйдә! Штирлиц! Син кайсын аласың? – дип, Хамис Илгизәргә эндәште.

– Кая, бир әле, карыйм, – дип, тегесе фотоальбомны сорап алды. Тик, аны ачып та тормыйча, үзенең рюкзагына салып куйды.

– Әй! Нишлисең?! Бир әле монда кире! – дип, Хамис Илгизәр каршына килеп басты.

– Булды! Монда цирк түгел! – диде Илгизәр, Хамиска усал карап. Аннары Диләрәгә эндәште. – Без өчебез дә Кадыйрны соңгы мәртәбә егерме ел элек суд залында күрдек. Аңлавымча, син дә?

## 8. Ул шикләнә иде

– Юк, мин аның белән әле судтан соң тагын ике мәртәбә очраштым, – диде Диләрә. Ниндидер масаю-эреләнү кебек төсмер бар иде аның бу сүзләрендә, карашы да өстән аска юнәлгән иде.

– Кайда? – дип сорады беркатлы Галимҗан.

– Кайда булсын инде, төрмәдә!

– Син Кадыйр янына төрмәгә бардыңмыни? – Хамисның шаян кәефе бер мизгелдә эреп югалды.

– Ә нигә син моңа шулкадәр гаҗәпләнәсең?

– Ничек керттеләр соң сине анда? – дип, Хамис Диләрәгә якынрак килеп утырды.

– Сөйли китсәң, бик озак була инде ул, – диде Диләрә.

– Ә без бүген беркая да ашыкмыйбыз, – диде Илгизәр, аның тавышында салкын канлылык ярылып ята иде.

– Суд булып, Кадыйрга унике ел биргәч, минем өчен тормыш туктады. Мин тулай торак бүлмәсендәге караватымда җиде көн тора алмыйча яттым. Аннары дус кызлар җилтерәтеп торгыздылар. Үзләре белән лекцияләргә алып бардылар, алып кайттылар, үзләре ашаганда утыртып ашаттылар. Ай ярым чамасы узгач, беркая да бармыйм дип карышсам да, авылга, бер таныш кызларының туена алып кайтып киттеләр. Туй мәҗлесендә минем каршыга чәчләре яртылаш чаларган абзый туры килде. Тора-бара аның төрмә нәчәлнигы булуы беленде. Кадыйр утыра торган төрмәнең. Кызлар барып ялварганнар моңа, Диләрәне егете белән күрештерегез әле дип, ничектер күндергәннәр. Ул мине чакырып китерде дә, шимбә көнне килерсең, тик очрашу минем кабинетта, минем күз алдында була, диде. Мин бардым, кердем моның кабинетына, Кадыйрны да шунда китерделәр...

– Ничек иде соң Кадыйрның хәлләре? – дип сорап куйды Илгизәр. Ул уйларында үзенчә ниндидер бик тирән анализ ясый иде, ахрысы.

– Ә нигә син моны егерме ел узгач кына сорыйсың? Ник теге вакытта кызыксынмадың? – диде, гаепләп, Диләрә.

– Хәзер генә түгел, ул чакта да кызыксына идем! Мин аңа берничә хат язып карадым, тик ул җавап бирмәде, – диде тыныч кына Илгизәр.

– Мин дә язган идем бер-ике хат, миңа да җавап килмәде шул. – Галимҗан тагын түшәмдәге рәсемнәрне күзәтүгә күчкән иде.

– Миңа да! – диде Хамис.

– Алдашма, син хат язмадың, – Диләрә Хамисның борын төбендә имән бармагын чайкады.

– Ә син каян беләсең?

– Кадыйр әйтте.

– Кайчан?

– Икенче очрашуда.

– Туктале, Диләрә, син беренче очрашу турында сөйләп бетермәдең бит әле, – диде Галимҗан үпкәләгәндәй. –Ниләр сөйләштегез инде Кадыйр белән?

– Төрмә нәчәлнигы карап-тыңлап утырганда, ни сөйләшәсең инде? «Сәлам. – Сәлам». «Ни хәлләрең бар? – Әйбәт». «Сиңа ниләр кирәк, посылка белән ни салыйм? – Кирәкми бер әйбер дә, монда бөтен нәрсә дә бар...»

– Икенче очрашуга ничек күндерә алдың төрмә нәчәлнигын? – дип сорады Илгизәр. Ул уйга батып, иягенә таянып утыра иде.

– Кадыйр белән очрашудан соң минем хәлләрем тагын да авырайды. Аның белән янәшә булу, аның назларын тою теләге чыдый алмаслык итеп йөрәгемне кимерде. Аңа кадәр җаным гына сызласа, аннан соң бөтен тәнем авырта, ничектер бөтен нервыларым тартыла башлады. Рәхмәт төшкере, төрмә нәчәлнигы кабинетында зонтигым онытылып калган икән. Шалтыраттым мин моңа. Килеп ал зонтигыңны, ди. Бардым, свидание сорадым 24 сәгатьлек. Ярамый бит, ди. Тик шулай да бер шартымны үтәсәң, булдырып булыр, ди...

– Нинди шарт? – дип куркып сорады Галимҗан.

– Ә син белмисең как будто бы! – диде Хамис, мыскыллы елмаеп.

– Әй, чукынып китсен дөньялары, дидем дә үтәдем мин ул шартны! Кадыйр белән булу теләге шулкадәр көчле иде, гомереңне бир дисәләр дә, ике дә уйламыйча бирә идем мин ул вакытта! – Диләрә туктап калды, яңакларыннан аккан күз яшьләрен сөртте. – Свиданиеләр өчен махсус ясалган бүлмәдә Кадыйр белән без икәү бер тәүлек үткәрдек. Төрмәдә уздырылган булса да, ул минем гомеремдә иң бәхетле көн...

– Ни өчен безнең хатларга җавап бирмәгән инде Кадыйр?

– Ә ул шикләнә иде, – дип Диләрә өч дусның өчесенә дә күз йөртеп чыкты, әйтерсең лә һәрберсен бәяли иде.

– Ничек инде? – Хамисның кашлары тагын өскә менеп китте.

– Аңламасаң, Кадыйрның сүзләрен кабатлый алам.

– Кабатла.

– «Мин үтермәдем ул егетне, Диләрә! Ну, өчесе арасыннан кайсыдыр бер сука өчен унике елга тыгып куйдылар, ләкин мин барыбер бер кайтырмын – әзерләнеп торсын, хәсис!» – диде.

– Менә кайткан инде Кадыйр, димәк, – диде Илгизәр һаман да шул ук уйчан кыяфәттә. Аннары кисәк кенә Диләрәгә күтәрелеп карады: – Мин шуңа аптырап утырам әле, Диләрә! Син боларны безгә нигә сөйләдең?

– Бәй, сорадыгыз бит?!

– Без сорамаган булсак та, син барыбер сөйләр идең, шулаймы? Ничектер алдан репетициясен ясап куйган концертка охшап тора бит әле бу, ә?

– Миңа да бер дә ошамый бу кәмит, – диясе итте Галимҗан.

– Миңа калса, Кадыйр безнең белән нindидер уен уйный, кагыйдәләрен дә ул үзе уйлап тапкан, – дип дәвам итте Илгизәр. – Диләрә, сине Кадыйр җибәрде бит, әйеме?

– И-и-их, җибәрсен иде мине монда Кадыйр! – диде Диләрә җан ачысы белән. – Миннән дә бәхетле кеше булмас иде! Тик гафу итмәде ул мине...

– Гафу итмәде? Нәрсә өчен? – Галимҗан Диләрәнең кулын учына салды. Тегесе шундук кулын кире тартып алды:

– Төрмәдә Кадыйр белән уздырган тәүлек тәэсирендә озак хыялланып йөрдем әле мин, – диде ул, ничектер кискен генә, Галимҗанга ачуланды, ахрысы. – Аннан соң авырга узуымны белдем. И, шатланганнарым! Йөрәгем астында бала йөрткәндә, миннән дә бәхетле кеше юк иде бу дөньяда! Чөнки мин ул баланың Кадыйрның дәвамы булуына инанган идем. Бары тик тугач кына улымның атасы төрмә нәчәлнигы икәнен аңладым – шул ук йөз, шул ук күзләр, шул ук куллар, хәтта тырнак формаларына кадәр охшаган иде...

– Диләрә-ә-ә, – дип сузды Галимҗан.

– Ә Кадыйр бу турыда каян белде соң? – Илгизәр уйларында һаман нindидер төеннәр чишәргә азаплана иде.

– Кадыйр ул бар нәрсәне дә белә, аннан нидер яшерү – мәгънәсез. Мин аңа гафу үтенеп, хат яздым, безнең төрмәдә уздырган әкияти көнебез ни бәрабәренә алынганын аңлаттым. Ә ул аны мин әйтмәсәм дә, белә иде инде. Шуның белән вәссәлам! Кадыйр, күрәсең, мине үз тормышыннан сызып ташлады...

– Алайса, малаең белән икегез яшисез инде? Ничә яшь аңа? Унтугызмы? – дип сораулар яудыра башлады Галимҗан.

– Белмим... Исән булса, унтугыздыр, әйе, – диде Диләрә салкын гына.

– Ничек инде исән булса? – Галимҗанның үз колаклары ишеткәнгә ышанасы килми иде.

– Кабул итә алмадым мин ул баланы... Ярата алмадым...

– Кайда соң ул хәзер?

– Белмим.

– Ничек инде белмисең?

– Шулай инде, белмим. Роддомда калдырдым мин аны.

– Диләрә-ә-ә! – дип суздры Галимҗан.

Берара тынып тордылар. Аннары Илгизәр телгә килде:

– Ә Кадыйр? Сез бүтән очрашмадыгызмы аның белән?

– Юк. Дөрес, мин аның исәнлеге, ничек яшәве турында төрле юллар белән белеп торырга тырыштым. Төрмәдән ул тугыз елдан чыкты. Аннан соң әле тагын ике мәртәбә утырды. Сөйләүләренә караганда, ул инде элеккеге Кадыйр түгел, ә ата каракка әйләнгән. Өч ел чамасы элек шундый хәбәр килеп иреште – имеш, аны кайсыдыр төнге клубта атып үтергәннәр. Мин барып, үз күзләрем белән хәтта аның каберен күреп кайттым, тик үлгәненә барыбер ышанмыйм! Ул исән, Кадыйр исән! – диде дә Диләрә үксеп-үксеп еларга тотынды. – Аны сезнең өчегезнең берегез кабергә тыгып куйды! Кайсыгыз үтерде ул егетне?! Кайсыгыз аркасында Кадыйр төрмәгә эләкте?! Кем безнең бәхетне челпәрәмә китерде?! Әйтегез хәзер үк!

Диләрәнең әче тавышын ишетеп, официант чыкты:

– Гафу итегез... Сезгә ашлар кертергәме соң?

– Ыслушай, малай! Нинди кеше син, ә?! – дип җикеренде аңа Хамис. – Таптың ашау турында сөйләшер вакыт! Ник кирәкмәгән җиргә кысылып йөрисең? Мин синең директорыңа иртәгә үк шалтыратам, ысчитай, ышту син уволен!

– Аңладым. Тагын бер мәртәбә түбәнчелек белән гафу үтенәм! – диде официант һәм кире үз бүлмәсенә китте. – Хистән тора дәвам, хистән тора – туган телең дигән Ана йортка җыелып килә алыр күчтән тора...

Диләрәдә истерика башланды. Ул умырткасыз җанвар кебек ничектер идәнгә шуышып төште, шунда сузылып ятып үкси-үкси елады. Илгизәр белән Галимҗан аны күтәреп, кире коляскасына утыртып куйдылар, тынычландырырга тырыштылар. Тик Диләрә аның саен ныграк ярсый гына барды. Ахыр чиктә Хамис түзмәде:

– Җитте сиңа, Диләрә! Булды, тынычлан! – диде. – Ычкына язгансың бит инде Кадыйр дип. Үзе исән, ди, үзе каберен күрдем, ди, үзе сез тыгып куйдыгыз кабергә, ди. Берни аңларлык түгел! Компетентный органнар эшне тикшерде, суд булды. Вина доказана, диделәр. Үлгән дигән хәбәре бар, кабере бар, кансы кансоф! Ни кирәк инде тагын? Всё! Эшкә нокта куелды, дело закрыто и отправлено в архив...

– Хами-и-ис! – дип, башын күтәрде Диләрә. – Нишләп шундый аңгыра соң син?! Әйтеп тора бит сиңа Илгизәр, ниндидер уен уйный Кадыйр дип! Ул җыйган бит безне монда. Мин сизәм аның исән икәнен!

– Ә кабере?

– Инсценировка ул, аңлыйсыңмы?! Спектакль!

– Туктагыз әле, туктагыз! Монда хискә бирелүнең, артык эмоцияләрнең

файдасы юк, аек акыл белән эш итәргә кирәк безгә бүген, – диде Илгизәр. – Егерме елга кире кайтырга кирәк, теге каһәр суккан төнгә.

– Ә минем барасым килмәгән иде ул көнне ДКга! Исегездәме, берүзең генә калмыйсың инде дип, өстерәп алып киткән идегез мине? – диде Галимҗан, ничектер акланып.

– Синең кайчан үз теләгең белән берәр җиргә барганың булды соң? Без кеше арасына керттек инде син авыл сарыгын! – диде Хамис ачулы тавыш белән.

– Сансыз тәре!

– Карагыз әле, тулай торакка кайтканда очраган егетләр көтүеннән берәрсе булса да дискотекада очрамадымы соң безгә? – дип сорады Илгизәр.

– Юк ла инде! Теге чакта следовательләр йөз кат тикшерде бит инде моны! Ул бандитлар бит гел икенче яктан киләләр иде, безгә каршы очрадылар! – диде Хамис, хаклыгына нык ышанып.

– Шулай да исегезгә төшереп карагыз әле тагын бер кат?

– Иртә белән нәрсә ашадың дип сора! – Галимҗанның җавабы шул булды.

– Төшерәсе-нитәсе юк инде монда! Туйдым мин сезнең белән юкны бушка аударып! – дип, кул селтәде Хамис.

– Туйсаң, бар кайтып кит! Кем тота сине? – дип ырылдады Илгизәр.

– Китәрмен дә шул! – Хамис зур-зур атлап, чыгу ягына таба киткән иде, тик ике-өч адым ясау белән туктап калды.

– Ник китмисең? – дип сорады Хамистан Илгизәр, күзләрен кыса төшеп.

– Ну-у-у, – дип сузды Хамис. – Матур түгел бит инде сезне бу хәлдә ташлап китеп бару.

– Кайчаннан матурлык турында уйлый башладың соң әле син, Сансыз?! – дип сорап куйды Галимҗан.

– Әллә хат искә килеп төштеме? – диде Илгизәр.

– Ә син каян беләсең? – Хамисның да авызы ачылып калды.

– Мин дә хат алдым, – диде Илгизәр ниндидер бер өметсезлек белән.

– Сиңа да выгодный коммерческий предложение ясадылармыни?

– Юк, миңа коммерческий түгел, миңа рухи тәкъдим ясадылар, – дип җавап бирде Илгизәр. – Галимҗан да монда хат алганга килгән дип беләм. Шулаймы, Галимҗан?

– Әйе, минекен дә рухи тәкъдим дип атасаң ярый.

– Хамис, тыңлале игътибар белән. Кадыйр да әнә Диләрәгә үзенең гаепле түгеллеген әйткән, – дип, Илгизәр нидер аңлата гына башлаган иде, Хамис аны бүлдерде:

– Ул аны Диләрә каршында чистенький калу өчен генә әйткән!

– Ай-һай! Ә нигә алайса ул бездән шикләнгән? – дип сорау куеп, Илгизәр Хамисны да уйланырга мәҗбүр итмәкче булып тырышты. – Син күз алдыңа китерәсеңме, ничәмә-ничә еллар буена ул төрмәдә утырганда, көн саен шул кичтә булган вакыйгаларны уйларында яңарткан, гаепле кешене эзләгән. Һәм, ахыр чиктә, ул аны тапкан!

– Ә син каян беләсең? – Хамисның бирешәсе килми иде.

– Тапмаса, ул безне бергә җыймас иде. Аңлагыз инде, безнең барыбызның да тормышында иң мөһим көн бүген! Кадыйр кемнәндер үч алырга, аны хөкем итәргә җыена! – диде Илгизәр, ачынып.

– Кемнәндер түгел, безнең барыбыздан да үч алырга, – дип тәгаенләде Галимҗан.

– Безгә аның килүенә ничектер әзерләнергә кирәк! – диде Илгизәр.

– Без Кадыйрдан яхшырак итеп әзерләнә алмабыз шул. Ул бездән бер адым, юк алай гына түгел, дүрт-биш адым алданрак бара, ә соңга калганга – сумала, – диде Галимҗан, авыр сулап.

– Син ни тәкъдим итәсең соң? Аңгыра сарык кебек, Кадыйр килеп, безне манчыганын көтеп утырыйкмы? – дип кычкырды Илгизәр.

Шунда үз бүлмәсеннән тагын официант килеп чыкты.

– Туган телең дигән Ана йортка җыелып килә алыр күчтән тора. Ә чын язмыш үзең язган гына, аздан тора дәвам, аздан гына, – дип сөйләнә-сөйләнә кәнәфигә барып утырды. Хуҗаларча аягын аякка салды, кулларын күкрәк алдына җыеп куйды. Барысы да берни аңламыйча башта аңа, аннары бер-берсенә караштылар.

– Әнигә әйтмәгез, үтерә ул мине, – диде официант.

– Нәрсә дидең си-и-ин? – дип сузды Хамис. Официант дәшмәгәч, башкалардан сорады: – Ни ди ул?

– Кадыйрдан сәлам, ди, – Илгизәр башын түбән иеп, идәндәге бер ноктага карап катты.

## 9. Кешенең күзенә кара да елмай

– Финита ля комедия! – диде официант, аннары Илгизәргә текәлеп карады: – Майор.

Тегесе идәннән күзен алмыйча гына, әйе, беләм, аңладым, дигәндәй килешеп, әкрен генә башын селкеде.

– Нинди сәер кеше син шулай да?! – диде официантка Хамис, тагын кабынып китеп. – Беркем аңламый торган абракадабра мыгырданып, тик йөрисең шунда! Сыразы әйтеп булмыймы турыга ни кирәгән?

– Контракт, – дип җавап бирде аңа официант. Хамис, нидер аңлап, шундук тынып калды. Аннары официант Галимҗанга борылды:

– Практикантка.

Галимҗанның коты алынды, куркуыннан маңгаенда тир бәреп чыкты, куллары калтырый башлады.

– Сезне Кадыйр җибәрдеме? Сез беләсезме аны? Сөйләгез, зинһар, безгә аның турында. Кадыйр исән бит, әйеме?! – дип өмет тулы сораулар яудыра башлады Диләрә официантка.

– Юк, исән түгел. Бүген ул үлгәнгә нәкъ бер ел тулды. Рухы шат булсын...

Диләрәнең, әйтерсең лә бу тормыш, бу дөнья белән бәйләп торучы кылдан нечкә нинидер бер җебе өзелгәндәй булды. Юк, ул җан ачысы белән колаклар ярылырлык итеп кычкырмады, дөресрәге, бу кычкыру аның күңелендә генә яңгырады, аны беркем ишетмәде. Тыштан исә аның эчендә барган хис-тойгылар давылы берничек тә чагылмады. Бары гәүдәсе, тавышсыз елаганын белгертеп, калтырый-дерелди, тагын ихтыярсыз гына идәнгә шуышып төште.

Ирләр дәшми утырдылар. Аларның күңелләрен нинди уйлар айкады икән?..

Галимҗан көзгедә сәер сурәтләр күрүдән курыкса да, кызыксынучанлыгы, шул якка борылып карау теләге гел күңелен кытыклап, ымсындырып торды. Ахыр чиктә ул карашын көзгегә ташламыйча булдыра алмады. Ә анда Кадыйр рингта кем беләндер бокс уйнарга җыена иде. Бокс бияләйләрен, шлемнарын киеп куйган, бер урында сикергәләп, кулын кулга бәргәләп тора. Икенче почмактагы боксчы башта арты белән баскан иде, менә ул да алды белән борылды. Әмма кеше түгел, эт башлы үлем алиһәсе Анубис иде бу. Галимҗан күзләрен бер мизгелгә йомып торды. Ачса, көзгедә Ялтаның диңгез буе урамы чагыла иде. Шул урам буйлап ашыкмый гына граф Монте-Кристо һәм язучы Галимҗан Ибраһимов сөйләшеп баралар. Алар өстендә зур ап-ак оча торган шар эленеп тора. Икенче мизгелдә болар икесе инде казинода, ә крупье – Кадыйр. Аның башында – түбәтәй, ә өстендә френчны хәтерләткән татар милли костюмы иде. Рулетка урынында – яңа гына пешкән, парлары чыгып торган бәлеш. Әллә Галимҗан күзен йомып алды, әллә көзге бер мизгелгә кап-карага әйләнде, тик яңадан пәйда булган күренеш мондый иде: төрмә сәкесендә Галимҗан Ибраһимов ята, үзе бертуктаусыз кан төкерә-төкерә, буыла-буыла ютәлли. Аның каршында ак халат, ак башлык кигән бер ир утыра иде. Галимҗан аны табиб дип уйларга да өлгермәде, ир йөзе белән аңа борылды һәм аның доктор түгел, Анубис икәне ачыкланды...

Бераздан Хамис торып басты, үзенә генә бер рюмка коньяк салып эчте, аннары килеп Диләрәне күтәреп, коляскасына утыртып куйды. Галимҗан аңына килгәндәй булып, ярдәм итмәкче иде, Хамис аның касыгына терсәге белән китереп төртте, комачаулап йөрмәле, янәсе.

Ул арада официант үз бүлмәсенә барып, ниндидер китап күтәреп килде. Тышында исеме әллә каян кычкырып тора иде. Зур хәрефләр белән «Фәхрине үтереп ташладылар» дип язылган иде анда.

– Менә монда Кадыйрның бөтен тормыш юлы язылган, – диде официант. – Сезнең киләчәктә бу китапны укып чыгарга вакытыгыз җитәрлек булачак әле. Хәтта берничә мәртәбә укып чыгарга. Кадыйр аны махсус заказ белән Императорның үзеннән яздырды.

– Император? Кем соң ул? Мин андый язучыны бер дә белмим нишләптер? Әллә берәр яшь каләм тибрәтүче үзенә шундый псевдоним алганмы? – диде Галимҗан.

– Язучылар союзында эшли ул. Аларда да бездәге кебек тәртипләр булып чыкты, – диде официант, елмаеп. – Ну, почти бездәге кебек инде. Кушамат тагалар бер-берсенә мәсәлән. Такмасалар, үзләренә үзләре уйлап чыгаралар хәтта!

– Ә ни өчен китап яздырырга булган Кадыйр? – диде Илгизәр. Ул һаман башын түбән иеп, идәндәге бер ноктага текәлеп утыра бирә иде.

– Укырсыз үзегез. Анда язылган барысы да. Тик бераз соңрак, яме? – диде официант. – Хәер, мин сезгә хәзер ул китапның кыскача эчтәлеген болай да сөйләп бирәм инде.

– Сез кем буласыз соң? Кадыйрны күптәннән беләсезме? – дип, башын күтәрде Илгизәр.

– Дүртне алып килдем, – диде официант, китапка карап. – Киткәндә, берәрне алырсыз.

Аннары ул китапны кире үз бүлмәсенә илтеп куйды. Кире килгәч, бүлмәдәгеләргә тагын бер кат күз йөртеп чыкты.

– Сез бер дә үзгәрмәгәнсез, бар да нәкъ Кадыйр сөйләгәнчә, – диде ул, ирен чите белән генә елмаеп. – Үзем белән таныштырырга вакыт җиткәндер. Санчо булам мин, Кадыйрның дусты. Кәефе яхшырак чакта ул мине Санчо Панса дип атый иде.

– Санчо? Үз исемең шундыймы? – дип, Галимҗан борын очына шуып төшкән күзлеген күтәреп куйды.

– Нишләп үз исеме булсын инде? Буржуй үз исемең ыштули? – диде Хамис, бераз җанланып.

– Татарда теләсә нинди исем булырга мөмкин, – диде Галимҗан. – Карбюратор да, Альянс та, Даздраперма да, Организация да, хәтта Оргазм Мәхмүтович дигән бер кешене беләм мин!

– Зөлмәт минем исемем, – диде официант.

– Кем? Зөлфәт диденме? – дип, төгәллек кертмәкче булды Хамис.

– Юк, Зөлфәт түгел, Зөлмәт! – диде официант ачулы тимер тавыш белән. Күрәсең, бу сорауны ул меңенче мәртәбә ишеткәндер инде. – Зөлмәт Сәгыйрев. Кадыйр белән танышкан вакытымны белгән булсагыз, сез мине хәзер танымас идегез. Җен баласы белән бер идем мин ул чакта! Сугышудан башы чыкмаган бер калай әтәч идем. Үзсүзле, бәйләнчек, тешләк, чәнечкеле, җор малай идем яшьрәк чакта. Кибет басып, 158 нче статья белән ике елга утыргач – чираттагысы! – Пановка төрмәсендә таныштык без Профессор белән.

– Кайсы профессор ул? – дип сорап куйды Галимҗан.

– Ә-ә-ә, сез белмисездер әле, – дип елмайды Зөлмәт. – Кадыйрның кушаматы бит ул – Профессор. Университетта укыган җирдән утыртып куйганнар бит аны. Бер гаепсезгә! Хәер, төрмәдә бөтенесе дә бер гаепсез утыра инде...

– Ничек? – дип, күзлеген төзәткәләп куйды Галимҗан.

– Төрмәдә беркем дә сиңа, мине дөрес утыртып куйдылар, дип әйтмәс! – дип аңлата башлады Зөлмәт. – Мин яшь кызны көчләп, 131 нче статья белән утырдым, мин кеше үтереп 105 нче статья белән монда эләктем, дип сөйләшеп утырмыйлар анда – барысы да гаепсез! Ну, яки абсолют күпчелеге дип әйтик инде. Шуңа күрә Профессор, бер гаепсезгә утырам, дигәч, мин моңа башта әллә ни зур игътибар да бирмәдем. Ләкин берсендә...

– Гафу итегез бүлдергәнгә, – диде Илгизәр һәм уң кулын йодрыклап, сул учына чалт итеп сугып куйды. – Диләрә бүген Кадыйр турында сөйләгәндә, ата каракка әйләнгән диде. Дөресме бу?

– Кем соң ул ата карак?

– Ну-у-у, – дип сузды Илгизәр, ничек аңлатырга белмичә. – Ягъни бу кыек юлга белеп җиткермәве белән түгел, ә аңлап-уйлап, үз аңы, үз башы белән, инанып кереп киткән кеше, димәк. Нишләгәнен, ниләр кылганын белеп эшли торган кеше.

– Аңлап бетермәдем, – диде Зөлмәт.

– Китапта да җавап юкмы бу сорауга?

– Яхшылап эзләп карасаң, җавабы булмаса да, шуңа юлны күрсәтә

торган ишарәләр бардыр, бәлки. Ә болай Кадыйр беркайчан да вор в законе булмады, ул положенец иде.

– Анысы кем тагын? – диде Галимҗан авызын ачып.

– Шактый зур кеше, аннан да өстәрәк вор в законе гына, – дип аңлатты Зөлмәт.

– Ничек алай була икән ул? – диде Илгизәр. Ул иягенә таянып, уйларына чумып утыра иде. – Менә ничек шулай мәктәптә әйбәт кенә укып, университетка укырга кереп, ШТКларда катнашып йөргән малай, ир булып җитешкәч, ата карак була да куя?!

– Ну, ул бит төрмәгә эләкте! – диде Хамис, шундый гади әйберне дә аңламыйсың дигәндәй.

– Төрмәгә меңнәрчә, миллионнарча кеше эләгә. Барысы да каракка әйләнми бит. Үз вакытын утырып кайткач, яңадан җәмгыятьнең нормаль кешеләре булып яшәүчеләр күп.

– Алары бит мужиклар, – дип куйды Зөлмәт.

– Ә менә Кадыйр...

– Мин бу турыда сезгә караганда бераз күбрәк беләмдер, Илгизәр, – дип, сүзгә кушылып китте Диләрә. Ул бераз хәлгә килгән иде инде. – Апасы Израильгә киткәч, нык үзгәрде ул. Бик ярата, якын итә иде бит ул апасын. Аны ташлап киткәнчегә кадәр. Беләсез бит инде, алар икесе генә ятим калганнар.

– Минем хәзер истә дә түгел инде, – диде Хамис. – Аның әти-әнисе нишләп үлгән әле?

– Бик укымышлы нәселдән ул үзе, – дип дәвам итте Диләрә. – Бабалары муллалар булган, әтисе – үзләренең эшчеләр посёлогында мәктәп директоры. Тарих укыткан, туган як тарихын бик яхшы белгән, Себер татарлары турында мәкаләләр яза торган булган гәзит-журналларга, мәктәптә музей да оештырган. Тик нишләтәсең, йөрәк... Әтисе шулай яшьли үлеп китмәсә, кем белә, бәлки Кадыйр...

– Ничә яшь булган Кадыйрга әтисе үлгәндә? – дип сорады Илгизәр.

– Дүрт. Апасына – унбер, – дип дәвам итте Диләрә. – Әниләре – көнетөне эштә. Совхоз вакытында завхоз булып эшләгән, көн саен диярлек тегендә-монда командировкага чапкан. Төзелеш материаллары алып кайту дисеңме, техникага запчастьләрме, яңа сортлы орлыкларны – барысы да аның өстендә булган. Кадыйр урамда үскән инде ул. Бары тик шул апасының тырышлыгы белән, аның таләпчәнлеге аркасында гына китаплар укый башлаган. Кулга китап тоттырып, ишекне бикләп куя иде, ул кыстыргыч куйган биткә кадәр укымыйча, чыгармый иде урамга, дип сөйли торган иде Кадыйр апасы турында. Шулай мәҗбүриләп укыта башлаган китаплар аннары аңа ошап киткән, ул үзе дә укуга тартыла башлаган. Дөрес, урамдагы иптәшләре дә беркая да китмәгән.

– Әнисе нишләп үлгән? – дип сорады Галимҗан.

– Кадыйрга ул вакытта ничә яшь булган? – дип өстәде Илгизәр.

– Унбиш. Рак еккан әнисен, – дип авыр сулап куйды Диләрә. – Җир җимертеп йөргән җирдән шартлап егылды да ике айда кибеп бетте, дип сөйләгән иде Кадыйр. Апасы иң якын кешесе иде шул. Аннары бик каты эгоист та бит ул Кадыйр. Апасын башта гел бөтенләй кияүгә чыкмаска үгетләгән, ник кирәк

ул сиңа ир, дия торган булган. Ә ул бит яһүдкә чыккан әле тагын җитмәсә. Апасы татар кешесе белән гомерен бәйләмәгәнгә бик нык үртәлә иде Кадыйр. Ә инде Израильгә күченеп киткәч, бөтенләй кичерә алмас булды.

– Ә нишләп бер гаиләдәге ике баланың берсе шундый ялкынлы, чын күңелдән инанган милләтче булып үскән, ә икенчесенә кемгә кияүгә чыкса да барыбер булган? – дип сорау куйды Илгизәр?

– Яраткандыр инде апасы теге яһүдне. Любовь зла, диләр бит.

– Артык гади аңлатма булыр иде бу, – дип, тагын уйга чумды Илгизәр. – Бәлки, ул... Ну, ничектер... Ну, мин белмим... Бәлки, кечкенәдән чит илләр турында хыяллангандыр ул кыз?

– Белмим инде, анысын үзеннән сорарга кирәк, – дип куйды Диләрә.

– Димәк, синең фикереңчә, апасы Израильгә киткәнгә, Кадыйр төрмәгә эләккән? – диде Илгизәр кыланчык-катгый тавыш белән.

– Мин алай дип әйтмәдем! – диде Диләрә, ачуы чыгып. – Урамда үскән ул, дидем. Ә апасы киткәч, бик нык үзгәрде, усалланды, дидем.

– Кадыйр төрмәгә ялгыш эләкмәгән ул, – диде Галимҗан. Аңардан мондый сүзне беркем дә көтмәгән иде. – Аның язмышына алдан ук язып куелган булган ул төрмә. Кадыйр, киресенчә, университетка ялгышып кына килеп кергән. Үзең әйтәсең бит, Илгизәр, гел кисәтеп тордым, характерыңны үзгәртмәсәң, башың төрмәдән чыкмый синең, дип әйттем аңа, дисең. Ә ул ничек үзгәртә алсын характерын? Ул үзе булдырган, ничектер әвәләгән характер түгел бит анда, Аллаһ биргән характер.

– Аллаһ андыйны бирмидер инде, яхшыны бирәдер, шайтан котыртып, шундыйга әйләнәдер инде ул, – дип куйды Илгизәр.

– Ә ни өчен берсе мондый, икенчесе тегенди дигәнгә җавап бик гади, минемчә, – диде Галимҗан. – Игътибар иткәнегез бардыр, Татарстаннан читтә туган, читтә яшәгән татарлар бездәге милләтчеләргә караганда кискенрәк, усалрак булалар, аларның милли мәсьәләләргә карашлары да күпкә радикальрәк. Чөнки алар кечкенәдән дошман әйләнәсендә, сугышта җиңелгән әсир хәлендә яшиләр. Чөнки анда, Татарстаннан читтә, татарларны надан, аяусыз, кансыз, мәрхәмәтсез, кыргый кабилә итеп кабул итәләр, олы туганның канына сеңгән мондый күзаллау. Аларга кечкенәдән өйдә дә шуны сөйлиләр, балалар бакчасында да, мәктәптә дә шулай укыталар. Бигрәк тә тарих дәресләрендә. Имеш, өч гасыр буена татарлар аларны җәберләгән дә, аннары алар бу хәлдән туеп берләшергә уйлаганнар һәм татарларны тар-мар иткәннәр. Ягъни татар баласына тумас борын икенче сорт кеше итеп карый башлыйлар, аны типкәлиләр, кимсетәләр, хурлыйлар. Кадыйрның сүзләре әле дә исемдә. Мин күргән җәбер-золымны сез күз алдына да китерә алмыйсыз, мин бары тик Казанга килгәч кенә, үземне нормаль кеше итеп хис итә башладым, дигән иде ул. Чөнки мин белә идем, әгәр мине урамда тотып кыйнасалар, бу бары хулиганлык кына, Казанда татар булганым өчен сукмаячаклар, дигән иде Кадыйр. Нигә ул шундый, апасы башка төрле дигәнгә кайтсак, алар балачакта алган психологик травмаларын төрлечә чишкән: Кадыйр көрәшкә күтәрелгән «әйе, мин – татар!» дип, ә апасы көрәшергә теләмәгән, ул башка бик күпләр кебек бүтән халык массасында эреп югалырга теләгән, татарлыгын ничек тә яшерергә кирәк булган аңа, чөнки бу татарлык аркасында ул бик күп нужа күргән...

Хамис дәшми генә утырган Зөлмәткә карады:

– Ә син ничек уйлыйсың, Санчо?

– Синең өчен Зөлмәт! Белмим, мин психолог түгел. Бер әйберне генә әйтә алам: андый кешеләр турында сөйкемле сөяге бар, диләр. Бик оста аудара иде ул кешеләрне үз ягына, тегеләр сизми дә кала иде аның сихерләгәнен. Теләсә кем белән идарә итә ала иде, тик үзе белән генә түгел.

– Ни дидегез? – дип сорады кисәк кенә Илгизәр. – Кабатлагыз әле, зинһар, тагын бер тапкыр!

– Теләсә кем белән идарә итә ала иде, тик үзе белән генә түгел.

– Әйе! Нәкъ өстенә бастыгыз! Бу Кадыйрның нәкъ үзе, ул шундый: теләсә кем белән идарә итә ала, тик үзе белән генә түгел, – диде Илгизәр, төгәл билгеләмә табылганга шатланып. Аннары тынычрак өстәп куйды: – Ала иде...

– Кешенең күзенә кара да елмай Санчо, дип өйрәтә иде ул мине гел, – дип дәвам итте Зөлмәт. – Авторитетлар белән дә бик тиз уртак тел таба белә иде. Шул ук вакытта хәтта төрмәдә дә аның кансызлыгы, рәхимсезлеге турында легендалар йөри иде. Анысы, күрәсең, үзенең кул астында булган сугышчылар гел куркып торсын өчендер инде. Белмим, чындырмы, юкмы, шундый бер хәл турында сөйләгәннәр иде. Имеш тә, Профессорга бер блатной кәрт уйнаганда, бик зур суммага җиңелгән булган да, озак кына әҗәтен бирмичә йөргән. Кадыйр моңа соңгы срок куйган. Ул көнне дә акча булмагач, кулларындагы һәрбер бармагын чабып өзгән, кан югалтудан үлгән теге блатной.

Диләрә куллары белән битен каплады, Хамис чыраен сытып куйды, Галимҗан авыр сулап, башын күтәреп, түшәмгә карап утыра башлады, Илгизәр тагын идәндәге бер ноктага карап, тораташтай катты.

– Сезгә бу бәлки кыргыйлык булып тоеладыр, – дип дәвам итте Зөлмәт, – тик Кадыйр үзе: «Мин дөньяны җыен үләксәдән чистартам», – ди торган иде.

– Кәртне оста уйный идеме Кадыйр? – дип сорады Илгизәр.

– У-у-у! Оста гынамы соң?! Профессор белән кәрт уйнарга утырдыңмы, бетте инде, җиңелдең, дигән сүз, – диде Зөлмәт. – Аның бөтен сугышчылары да диярлек Кадыйрга бушка хезмәт итәләр иде. Дөресрәге кәрт уйнап оттыргач, әҗәтләрен шулай түлиләр иде. Аның хәтта утырып йөри торган мерины да...

– Кеме? – диде Галимҗан аңламыйча.

– Мерины, сарык! – диде Хамис. – Самый крутой машина – «Мерседес-Бенц»!

– Менә шул машинасы да кәрт уйнап откан мерин иде.

– Кем белән уйнаган соң ул шулкадәр? – Галимҗан тагын аңламады.

– Шулкадәр дип... Кадыйр чурт-пуртка уйнап та тормый иде ул, зур акчага гына! Ә меринның тарихы болайрак. Бер элеккеге эскортница килгән берсендә, «Чикаго» клубына кәрт уйнарга, яшь чакларын искә төшерә, имеш.

– Эскортницасы кем инде? – Галимҗан үз соравыннан үзе читенсенеп, күзлеген төзәтеп куйды.

– Элитный проститутка! – дип кычкырып җибәрде Хамис. – Буржуй,

җитте инде сиңа, тик кенә тор инде, ә! Туйдырып бетердең бит инде үзеңнең тупой сорауларың белән!

– Син үзең тупой! Сансыз!

– Бырат, әйдә, дәвам ит! Килгән клубка эскортница, шуннан? – диде Хамис, бик нык кызыксынып.

– Әллә ни сөйләр әйбер юк инде анда, – диде официант, елмаеп. – Сүз дә юк, Профессорга бөтен акчаларын оттырган бу – шәп кенә сумма инде. Аның бит әле кайтып, иренә ничектер аңлатасы да бар акчасын кая куйганын, күп бит анда! Кыскасы, шул оттырган акчаларын кайтарам дип, машинасын куйган бу хатын.

– Ире кем булган соң аның? – диде Галимҗан, үзе, куркып, Хамис ягына карады.

– Мәскәүдәге кайсыдыр бер илнең консулы. Бу хатын, әйтәм бит, яшьтән эскортница булган. Башта монда, шәһәрдә эшләгән, «Чикаго»да еш булгалаган, аннары Мәскәүгә киткән. Шунда аңа бу консул башы-аягы белән гашыйк булган, өйләнешкәннәр.

– Машинаны Кадыйрга язганмыни ул хатын? Нинди кәгазь тутырганнар соң алар? – диде Диләрә, кызыксынып.

– Анысын белмим инде! – диде Зөлмәт. – Кадыйрның бик шәп адвокаты бар иде, тапкандыр инде берәр җаен. Дөрес, ул да гел генә булышып тора алмый иде, адвокатның көче җитмәгән вакытлар да күп булды.

– Мәсәлән? – диде Илгизәр, кызыксынып.

## 10. Бәхәскә урын юк

– Сөйли башлаган идем бит, Профессор, бер гаепсезгә утырам, дигәч, башта моңа әллә ни зур игътибар да бирмәдем дип? – Зөлмәт, исегезгә төшерә торыгыз дигәндәй, пауза алды, үзенә су салып, ашыкмыйча гына эчте. – Ләкин берсендә ничектер сорап куйды бу миннән: «Санчо, син ничә тапкыр урлаштың, ничә тотылдың?» – ди. Кем санаган инде аны, мин әйтәм, үземне белгәннән бирле урлашам инде, – дим. – Тотылган чаклар да күп булды, 14 яшьтән бирле башның төрмәдән чыкканы юк», – дим. «Бәлки сиңа башка берәр нәрсә белән шөгыльләнеп карарга кирәктер? – диде Профессор. – Бик шәп карак димәс идем мин сине, рас шулхәтле күп тотылгач», – ди. «Ни соң ул берәр нәрсә?» – дим. «Анысын инде син үзең хәл итәргә тиеш, Санчо, – диде Кадыйр. – Үзеңә ни ошый соң? Кем буласың килә?» «Белмим», – дим. «Ну, ярар, нинди китаплар укырга яратасың?» – ди бу. «Китап укыганым юк, укый да белмим бит мин, иҗекләп, көчкә-көчкә укыйм», – димен. «Мин сине өйрәтермен, Санчо! – диде Профессор. – Китаплар укый торырсың, үзеңә шөгыль сайларсың, аннары, моннан чыккач, шул һөнәргә өйрәтә торган җиргә укырга керерсең», – ди. «Хәзер уку бөтен җирдә түләүле бит», – дим тегеңә. «Түләрсең, кирәк булса!» – диде Профессор. «Каян алып түлим соң, урлашыйммы тагын», – дим. «Урлашмыйча да аның кадәр генә акча табып була, – диде Кадыйр. – Мин сине официант эшенә өйрәтәм – манераларга, клиентлар белән ничек сөйләшергә кирәклеген аңлатырмын, башкасын да».

Зөлмәт Хамиска елмаеп карады:

– Сезгә газлы су кирәкме, газсызмы? – Аннары җитдирәк итеп дәвам итте. – «Эшләгән акчаңны укуга тотарсың, – диде Кадыйр. – Кеше булырсың! Санчо, сиңа бу сасы кишлактан арынырга кирәк!» – диде. Һәм сүзендә торды!

– Гафу итегез, аңламадым... Нинди кишлак? – диде Галимҗан. Хамис аңа усал итеп карап куйды.

– Кишлак, конверт, дядин дом – төрмәне икенче төрле шулай атап йөртәләр, – дип, аңлатма бирде Зөлмәт. – Чынлап әйтәм, мин Профессор белән очрашканчы юньләп сөйләшә дә белми идем, гел сүгенеп кенә аңлата идем бөтен нәрсәне. Эллочка-людоедка кебек утыз сүз белгәнмендер бәлки. Профессор мине китаплар укырга мәҗбүр итте, тел байлыгын арттырды, гомумән, белем эстәргә өйрәтте.

– Адвокат причём соң монда, аңламадым әле мин чё-то?! – дип бүлдерде Хамис.

– Ә, адвокатмы?! Дюманың «Граф Монте-Кристо» романын укып чыктым да мин, Кадыйр белән сөйләшеп утырабыз шулай. Бу граф турында китте инде сүз, үч татлымы, әллә ачымы, кеше үзенең язмышына хуҗамы, юкмы, гомумән, тормышта гаделлек бармы, юкмы – шулар турында. Шунда ул үзенең беренче мәртәбә ничек төрмәгә эләккәне турында сөйләде.

– Беренче мәртәбә? – дип сорап куйды Илгизәр? – Ә ул барысы ничә мәртәбә утырды?

– Тә-ә-әк, – дип, күңеленнән нидер исәпли башлады Зөлмәт. – Беренче юлы 105 нче статья белән унике елның тугызын утырган ул. Чыккач, бер ел чамасы иректә йөргән дә, 222нче статья белән сигез ел биргәннәр.

– Нинди статья соң ул? – дип сорыйсы итте Галимҗан.

– Незаконная купля-продажа, хранение и перевозка оружия, – диде Зөлмәт автоматтан аткан кебек. – Часть четвертая, пункт А – совершенная группой лиц по предварительному сговору. Без танышканда, ул сигез елның өчесен утырган иде инде.

– Сигезен дә утырып бетердеме? – дип кызыксынды Илгизәр.

– Юк, алты елдан соң чыкты, условно-досрочно. Тагын бер елдан 228 нче статья белән тагын өч ел бирделәр, анысы наркотиклар өчен. Ике елдан чыкты, – диде дә Зөлмәт тынып калды. – Чыкмаса, бәлки хәзер исән дә булыр иде...

– Ә адвокат причём? – дип, үзенекен тукыды һаман Хамис.

– Адвокатмы? – Зөлмәт Хамиска карап, аның балаларча беркатлылыгына ирексездән елмаеп куйды. – При том монда адвокатлар, чөнки алар да һәрчак булыша алмый дигәннән киткән сүз иде бит бу! Кадыйр үзенең беренче мәртәбә ничек төрмәгә эләгүен сөйләде дим бит. Кыш иде, ди, бик соң иде инде, ди, репетициядән кайтып бара идек, ди. Кыскасы, сез үзегез дә бик яхшы беләсез инде ни булганын. Профессор шул төн турында бәйнә-бәйнә сөйләгәч, бигрәк тә «Братва! Кипиша закололи!» – дип кычкырды кемдер дигәч, мин шундук Вальтерны искә төшердем.

– Анысы кем тагын? – дип сорады Галимҗан.

– Пановкага кадәр Ухтада 8 нче колониядә утырган идем. 158 нче статья белән өч ел биргәннәр иде миңа ул чакта, машина урлаган өчен. Нигә урладым инде мин ул машинаны, дурак? Исерек баштан инде шул һаман...

– Шунда таныштыңмыни Валет белән? – дип сорады Илгизәр.

– Валет түгел, Вальтер. Үз исеме Владимир Обухов. 162 нче статья – разбой, групповое вооруженное ограбление – ун ел, – дип төгәллек кертте Зөлмәт. – Аны Ухтага китергәндә, минем өч ай чамасы гына утырасы калган иде инде. Оятсызлыкның теге чигенә чыккан бер мудак инде ул Вальтер! Андыйлар хәтта төрмәдә дә сирәк очрый. Гел булмасын иде дә бит алар.

– Нинди соң ул? – Галимҗан борын очына шуып төшкән күзлеген тагын күтәртеп куйды.

– Нинди иде диген, юк инде ул, – Зөлмәт моны ничектер канәгатьлек хисе белән әйтте. – Холыксыз иде, ниндидер тынычсыз иде һәрчак, шырт иткән тавышка да, ачуым да бер килмәгәе, усрак җиле иссә дә куркудан тәннәре тартышып куя иде. Юкка гына да ярсып китүчән иде үзе. Теле гел тик тормый инде, бертуктаусыз нидер сөйли иде бу. Шул урлашулар, кызлар турында инде, хәтта ничә кешене, ничек үтергәне турында да рәхәтләнеп, тәмләп, озын-озаклап сөйли торган иде. Иң беренче булып, мин үземнең дустымны үтердем, дип сөйләде мактанып.

– Ничек дустын? – диде Галимҗан, кашларын сикертеп.

– Нигә үтергән инде ул аны? – дип сорады Илгизәр салкын гына.

– Кыскасы, урам бандасы оешкан булган боларның, пытыушниклардан торган, – дип сүзен дәвам итте Зөлмәт. – Вальтерның дусты булган Кипишь кушаматлы. Шул бандадан кемдер ничектер ялгышып, татарча КВН уенына килеп эләккән. Ошаган моңа, икенче юлы дусларын чакырган. Кипишь барган, Вальтер, татарча аңламагач, бармыйм, дигән. Икенче көнне Вальтерны үрти башлаганнар болар. Их, җүләр син, нигә бармадың инде, шундый чибәр кыз уйный анда, дигәннәр. «Чё за курица?» – дип кызыксынып киткән Вальтер. Ну, моңа әйткәннәр инде, Диләрә Бәхтегәрәева, журфакның өченче курсында укый, КВН командасы йолдызы, дигәннәр. Хәтта кайсы общагада, ничәнче бүлмәдә торганын, «50 лет СССР» ДКсында репетицияләргә йөргәненә кадәр белешеп куйганнар.

– Синең аркада башланган всё ызначит?! – диде Хамис, Диләрәгә ачу белән карап.

– Сансыз! Ни сөйлисең син?! – Галимҗан кулларын йодрыклап торып басты.

– Всё нормально, Буржуй, – диде Диләрә тыныч кына һәм никтер урысчага күчеп. – Если тебе от этого легче, думай так, Хамисик. Дуракам закон не писан.

– Җүләр сүзне чын булса да сөйләмә, ди торган иде минем бабай, Хамис, – диде Илгизәр. Ул уйларында һаман нидер анализлап утыра иде. Аннары официантка карап әйтте: – Шуннан?

– Ну, сөйләгәннәр инде тагын Вальтерга, – дип дәвам итте Зөлмәт. – Гел дүрт кешелек компания белән йөриләр – Диләрә һәм тагын өч егет, дигәннәр. Бик нык аптыраган моңа Вальтер. «Она со всеми троими что ли?..» – дигән. Юк, аның егете Кадыйр исемлесе, бу компаниянең лидеры, дип аңлатканнар. «Я думал её директор универа дерёт или хотя бы директор ДК», – дип көлгән Вальтер.

– Универда директор түгел инде, ректор, – дип куйды Галимҗан.

– Урам эте бит ул Вальтер! Ул каян белсен инде ректор икәнен, Буржуй?!

Кысылма инде кирәкмәгән җиргә, пажалысты! – диде Хамис, чырайларын сытып. – Бырат, давай, дальше сөйлә.

– Кыскасы, Вальтер әйткән: «Разобраться надо с этой тёлкой», – дигән. Менә шунда Кипишь үз гомерендәге соңгы хатасын ясаган. «Куда уж тебе с ней разбираться?! Она же звезда там!» – дигән. Бөтенесе кычкырып көлгәннәр Вальтердан. «Смешно тебе, Кипишь, да? Посмотрим, кто будет последним смеяться», – дигән Вальтер. Үпкәләү катыш нәфрәт кереп оялаган моның күңеленә.

Зөлмәт бераз дәшми торды, аннары нидер исенә төшкәндәй дәвам итте:

– Алга таба ни булганын беләсез инде. Алар сезне сагалап торган репетициядән кайтканда, килеп бәйләнгәннәр, башланган махач[1], шул ыгы-зыгыдан файдаланып, Вальтер дустына пычак белән кадаган. Ул бу турыда ничектер шулай әйтте... Әйтерсең ниндидер бер гадәти хәл, көн саен була торган әйбер турында сөйләде. «Маминкиным сынком уж был, вечно твердил мама, мама. И даже когда подыхал чё-то по-татарски про маму сказал», – дип лыгырдады Вальтер. «Әнигә әйтмәгез, үтерә ул мине!»

– Үлгәндә дә, әнисе өчен борчылган мескен бала, аңа хәсрәт китерәсе килмәгән, – дип куйды Диләрә.

– Кадыйрның икенче ходкасыннан[2] соң таптык без ул апаны, – диде Зөлмәт. – Җитмеш алты яшь иде инде аңа, Картлар йортында яши иде. Ничә тапкыр әйттем Профессорга, анда барудан мәгънә юк, башы киткән инде ул хатынның дип, юк, үзенекен итте – килеп, гаепле түгеллеген, аның малаен башка кеше үтергәнен, ни өчен үтергәнен сөйләп бирде. Махсус карап тордым шул карчыкның күзләренә, берни чагылмады аларда, аңламады ул бернәрсә дә.

– Җитмеш алты яшьлек карчык дисезме? Ничә яшьтә тапкан соң ул Кипишьны? – диде Илгизәр, кашларын җыерып.

– Кәримне, – диде Зөлмәт. – Кипишьның мулла кушкан исеме Кәримулла булган. Соңарып кына тапкан аны анасы – кырык бер яшьтә.

– Ә син каян беләсең?! – дип куйды Хамис.

– Беләм, – диде Зөлмәт. – Әйттем бит инде, мин сезгә караганда яхшырак беләм күп әйберләрне, дидем. Кыскача гына әйткәндә, ул апаның...

– Исемен дә беләсеңдер бит, ник әйтмисең? – диде Диләрә.

– Бер дә әйтмәдемме?

– Юк.

– Хәлимә исемле иде ул.

– Берәр бәхетле Хәлимә бар микән җир йөзендә? – диде Диләрә, ачынып.

– Ник алай дисең? – дип аптырады Хамис.

Диләрә дәшмәгәч, аның өчен Илгизәр җавап бирде:

– Диләрәнең әнисе дә Хәлимә исемле.

– Ул Хәлимә апаның Кипишьтан 18 яшькә зуррак кызы булган, – дип дәвам итте Зөлмәт. – Бик матур, бәхетле гаилә булганнар, ире белән икәүләп, кем әйткәндәй, җил-яңгыр тигерми 18 яшькә кадәр үстергәннәр кызларын. Мәктәпне бетергәч, ул Мәскәүнең ниндидер бик кәттә югары уку йортына укырга кергән. Август ахырында әтиләре кызларын машинага утыртып,

[1] Сугышу
[2] Ходка — төрмәдә утыру

кием-салымнарын багажникка төяп киткәннәр икәүләп Мәскәүгә. Юлда – автокатастрофа, аталары шундук үлгән, кызлары икенче көнне бүлнистә.

– Әниләре ник болар белән бармый калган? – дип сорады Илгизәр.

– Ә ул авырлы булган шушы Кәрим белән. Ире белән уйлашканнар да, кызыбыз өйдән чыгып киткәч, безгә бик күңелсез булыр бит дип, тагын бер бәби алып кайтырга булганнар. Күз алдына китерәсезме сез бу баланың анасына никадәр кадерле булганын? Ул аңа тузан да кундырмаган! Беркемнән бер кыек сүз дә әйттермәгән хәтта! Ә Вальтер... – диде дә Зөлмәт тынып калды.

– Ә шулай да бу Кәрим ни өчен алай әйтте икән? «Әнигә әйтмәгез, үтерә ул мине!» – диде Илгизәр. – Баласытыклык та бар бу сүзләрдә, әнисенә чиксез зур мәхәббәт тә, әллә ниләр бар монда!

– Мин дә күп уйладым бу турыда, – диде Зөлмәт. – Бәлки соңгы арада ана белән улы арасындагы мөнәсәбәтләр киеренкерәк булгандыр. Бәлки бер ачуы килгәндә анасы: «Бәреп үтерәм мин сине тагын шул малай-шалайлар белән урамда күрсәм!» – дип әйткән булгандыр. Кайсы анага баласының шпана белән бәйләнеп китүе ошасын? Без хәзер фаразлый гына алабыз инде, чамалап кына әйтә алабыз.

– Шул Вальтер кычкырганмы соң, «Братва! Кипиша закололи!» – дип? – Илгизәр бик арыган кыяфәттә иде, дога кылган кебек учлары белән битен сөртеп алды.

– Әйе, Кәримнән читкәрәк китеп баскан да кычкыра башлаган. Аның куана-куана сөйләгәне хәзер дә күз алдымда тора. Минем кулда перчатка иде, пычакны Кипишь янына ташладым, диде. «А этот фраер подошёл, взял перо в голые руки, там остались его отпечатки и дело на него повесили», – дип, шыр-шыр көлгән иде козёл! Хәзер көлә алмый инде, хәзер, гомумән, берни дә эшли алмый. Аңа эләккән җеннәр ялкау түгелдер, тырышып эшлидер, казаны астына утынны кызганмыйча, күп итеп ыргытып торалардыр дип ышанасы килә...

– Үлгәнен каян беләсез? – дип сорады Илгизәр.

Зөлмәт мыскыллы гына ирен чите белән елмаеп дәвам итте:

– Вальтер турында сөйләп биргәч, Кадыйр адвокатын чакырды. Мин чынлыкта кем гаепле икәнен беләм, әйдә яңа суд оештыр, диде. Тик адвокат, берни барып чыкмаячак, диде. Профессорның өмет утын яна башламас борын сүндерде. Мондый эшләрне судта яңадан карау законда бик тәфсилләп язылган икән, аның үз шартлары бар, ди. «Бер уголовникның икенчесе белән сөйләшеп утырганда ишеткәне алар өчен пүчтәк нәрсә генә бит ул! Эш буенча яңа тикшерү ачу өчен берничек тә нигез була алмый бу. Чифирны күбрәк эчеп ташлагансыз, диячәкләр генә. Вальтер да, әйе, мин үтердем аны, дими билгеле. Нишләп үзе теләп кимендә тагын ун ел төрмә өстәсен инде ул үзенә?!» – диде адвокат.

Зөлмәт Хамиска карады:

– Менә причём адвокат!

– Тәки язмадымы жалобаны ысволоч?! – дип сорады Хамис, нәфрәтләнеп.

– Язды язуын, файдасы гына булмады. Суд не нашёл оснований для пересмотра дела, диде адвокат.

– Шуннан соң Кадыйр үзе суд оештырды Вальтерга, шулаймы? – дип сорап куйды Илгизәр.

– Ә сез каян беләсез? – дип аптырады Зөлмәт.

– Тәгаен белмим инде, чамалыйм гына.

– Братва тиз тапты Вальтерны, Профессор сорагач, – диде Зөлмәт. – Кемеровода 40 нчы зонада утыра иде. Үлеме алдыннан Кадыйрдан хат тоттырдылар аңа. Хатның эчтәлеген яттан беләм, Кадыйр әйтеп яздырган иде. «Не могу пожелать тебе ни доброго дня, ни здравия, ублюдок. Знай, ты казнён за то, что убил Кипиша, изуродовав тем самым мою жизнь, а ты ещё исковеркал судьбы сотен, а может тысяч людей. Рад, что смог очистить белый свет от такой гниды, как ты. Сдохни, падла! Профессор».

Бераз дәшми утырдылар. Беренче булып, Диләрә телгә килде:

– Исләрең китәрлек инде! – диде ул. – Вальтерны кызганудан әйтмим, син әйткәндәй, тырыш җеннәр эләксен иде аңа, Аллаһының ачы каһәре төшсен! Тик шулай да, уйлап карасаң, кеше бит төрмәдә утыра, аны бит хөкүмәт саклый. Ә монда заказ биргәннәр дә, шалт (!) – ул үтәлгән дә! Пиццага заказ бирсәң дә алай җайлы гына булмыйдыр әле кайчак.

– Җайлы гына түгел, сез ялгышасыз, – диде Зөлмәт. – Бик катлаулы, үтә мәшәкатьле эш булды ул. Хәтта Профессор кебек авторитетлы, сүзе үтүчән кешегә дә! Вальтер ике елдан ирекккә чыгарга тиеш иде, воляда аның эшләрен төгәлләү күпкә җайлырак булыр иде, әлбәттә, тик Кадыйр көтә алмады. Бөтен булган абруен шушы эшкә җикте, акча кызганмады һәм һәрвакыттагыча үз дигәненә ирешә. Аның иң кызыгы шунда: 40 нчы колония начальнигы белә Вальтерга заказ килгәнен, кайсыдыр бер шестак әйтә аңа.

– Кем ул шестак? – дип сорады Галимҗан. Бу юлы нигәдер Хамистан.

– Стукач! – диде тегесе ачу белән.

– Тик барыбер берни эшли алмый, – дип дәвам итте Зөлмәт, елмаеп.

– Ничек инде төрмә начальнигы берни эшли алмасын? Шулай да буламы? – диде Илгизәр бик ышанып бетмичә.

– Тормышта була барысы да, агы да, карасы да, – дип көйләп җибәрде Зөлмәт. – «Бәхәскә урын юк» дигән фильмны караганыгыз бармы сезнең? Кемерово колониясендә дә шул кинодагыча килеп чыга инде.

– Ни турында әле ул фильм? – дип сорады Илгизәр.

– Боксчылар турында, нык кызык кино! – диде Зөлмәт. – Дөнья чемпионы отельдә горничнаяны тотып көчли дә, утыртып куялар моны. Ә бу төрмәдә бер карт карак утыра. Кәкрәеп беткән инде бу, бүген булмаса иртәгә үләсе. Шул карак дөнья чемпионы белән төрмә чемпионы арасында рингта очрашу уздырмакчы була. Бөтен нәрсәне дә әзерләп бетердек дигәндә генә, ЧП килеп чыга. Төрмәдәге тоткыннар теге яки бу чемпион җиңүенә акча куялар бит инде, шуңа алар ике лагерьга аерылган була. Ашханәдә төшке аш вакытында юктан гына ике зек талашып китәләр. Берсе дөнья чемпионы яклы була, икенчесе төрмә чемпионы яклы. Ну, шуннан китә инде ыгы-зыгы, махач ике лагерь зеклары арасында. Сугышны көчкә туктаталар вертухайлар. Туктатуын туктаталар да, тик төрмә начальнигы матчны тыя, уздырырга рөхсәтем юк, ди.

– Искә төште бугай. Аннары бу ата карак үз янына төрмә начальнигын чакыртып ала, имеш, – диде Илгизәр.

– Әйе, әйе! – дип тагын да җанланыбрак сөйли башлады Зөлмәт. – Мин

сезгә хәзер джентльменнарның эшләрен ничек алып барганын сөйләп күрсәтмәкче булам, ди карт карак төрмә начальнигына. Моннан утыз еллар элек мин мистер Лински белән эшли идем, ди. Безнең казино бар иде, тик шәһәрнең мэры комарлы уеннарга каршы иде, ул казинода начар кешеләр генә җыела, дип уйлый иде. Мистер Лински миңа әйтте, син ул мэрга аңлат, диде, казино ябылмаячак, ул һәрвакыт эшләп торачак, монда бәхәскә урын юк, мәсьәлә хәл ителгән һәм бу карар яңадан каралмаячак. Ә менә мэрның ике юлы бар: берсе – аның банктагы счётына зур суммадагы акча килергә мөмкин, икенчесе – аны үтерергә мөмкиннәр, үзе сайласын, диде мистер Лински, дип сөйли карт карак. Төрмә начальнигы сорый моннан, нишләде соң мэр, ди. Үлде ул, ди тегесе. Аның машинасы шартлады нигәдер, ә ул үзе шул машина эчендә янып үлде, ди. Төрмә начальнигы ярдәмчесеннән сорый, бу картның сүзләренә колак салырга кирәк дип уйлыйсызмы сез, янау бит бу, ди. Белмим инде, үзегезгә карагыз, ди ярдәмчесе, тик минем, мәсәлән, үз машинамда янып үләсем килми, ди. Шунда карт карак тагын телгә килә. Сезнең счётка күчәсе суммага килгәндә, без бу турыда сез ялдан кайткач сөйләшербез инде, ди. Нинди ялдан, дип аптырый төрмә начальнигы. Сез бит иртәгә диңгез буена ял итәргә китәсез, ди карт карак, без барыбыз да сез гаиләгез белән бик рәхәтләнеп ял итеп кайтырсыз дип ышанабыз, ди. Джентльменнар эшләрен менә шулай алып бара, ди. Кемеровоның 40 нчы колониясендә Сурик Андижанский утыра иде ул чакта, шул булышты Профессорга. Вальтерны одиночкага бикләп куйганнар шестак әләгеннән соң. Сурик шунда төрмә начальнигына «Бәхәскә урын юк» дигән шушы киноны сөйләп күрсәткән. Шуннан Вальтер янына Сурикның кешесен утыртканнар. Бер тәүлек буе диярлек җәзалаган ул аны, Вальтерның үкергәннәрен ярты төрмә ишетеп торган.

– Ниндидер абсурд дөньяда яшибез без, – дип авыр сулады Диләрә. – Бандитлар төрмә начальнигы белән сөйләшеп, икенче бер җинаятьчене тәүлек буена җәзалыйлар.

– Ә сезнең нишләп шулай исегез китә моңа, Диләрә ханым? – диде Зөлмәт. – Әйтерсең лә, үзегез төрмә начальнигы күрмәгән кеше.

– Күргән кеше, күргән кеше, – дип, тагын бер авыр сулады Диләрә. – Тик болай булырга тиеш түгел.

– Тиеш түгел әйбер до чурта инде ул! – дип кыстырды Хамис.

– Нигә?! Әйбәт бит инде! Кем әйткәндәй, бүре дә тук, куй да юк, – дип көлде Зөлмәт. – Төрмә начальнигы принципиальлек күрсәтә ала, әлбәттә, бик теләгәндә. Тик кирәкме соң ул аңа? Караклар иртәме-соңмы ул Вальтерны барыбер үтерә, заказ түләнгән чөнки. Зирәклек күрсәтмәсәң, Сурик Андижанский төрмәдә бунт күтәрергә, янгын чыгарырга да күп сорап тормый ул. Аның ише нәрсәләр өчен начальство баштан сыйпап мактамый, орден да бирмиләр, погонга йолдызлар да өстәлми. Ә зеклар гел сугышып, гел бер-берсен имгәтеп, үтереп тора инде алар. Шуның өчен аларга яңа срок өстиләр. Вальтерны үтергән өчен дә Сурик кешесенә җиде ел бирделәр.

*(Ахыры киләсе санда)*



Рифә
Рахман

# ИДЕЛ БУЕ – МИНЕМ ЙОРТЫМ УЛ

## Ил кирәк!

Яратырга җаным-тәнем белән
Ватан кирәк миңа, Илем кирәк!
Аңа мәхәббәтне җиткерергә
Милләттәшем аңлар телем кирәк!

Туган Иле диеп санамыйдыр,
Үз җиреннән Татар китә икән.
Туган Ил дә кайчак Үги була,
Сине үзе Ятим итә икән.

Сөйләвеңнән тыеп Ана телдә,
Ятим итә икән, этә икән...
Иле булганнарга (!) кайсы тел дә
Яшәү өчен бик тә җитә икән.

Үземнеке диеп саналырлык
Ватан кирәк миңа, Илем кирәк!
Һәр иртәдә теләк теләр өчен,
Милләттәшем аңлар телем кирәк!

Кирәк бик тә минем телне сөйгән
Кошлар, таллар, хәтта агар сулар...
Иделләрнең комлы ярларына,
Илең бар (!) иде... дип кагар сулар.

Кайтар аны, диеп елар кошлар,
Суда килеш (!) сызар яшел таллар,
Ватан диеп! Ник йоклыйсың, Татар?
Алар әнә барсы уянганнар.

---

Рифә РАХМАН (1962) *– шагыйрә, прозаик, галимә; Ф.Хөсни, Г.Исхакый, Җ.Вәлиди исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Онытырмын, димә», «Йолдызлар төстән язганда», «Таулар һаман ерак» һ.б. исемдәге китаплар авторы. Казанда яши.*

Яратырга җаның-тәнең белән
Үз Ватаның кирәк, Илең кирәк!
Үзең белән бер фикердә булган
Милләттәшең кирәк, телең кирәк!

***

Йорт арты йорт юкка чыга урамнардан,
Урам арты урам китә хушлашмыйча.
Танышырга өлгермәдем кайсы белән –
Никадәрле кешем калды дуслашмыйча!

Күршеләрнең яңалары, искеләре
Китеп бара көн арты көн бу дөньядан.
Бик күбесен белми калдым киткәннәрнең,
Йөрәгемә үкенүләр оялаган.

Кайта кеше калырга дип туфрагында.
Кайта кеше, китә кеше авылыннан.
Кайтканнары өзелгәннәр инде күптән,
Киткәннәре өзеләдер тамырыннан.

Кайтсалар да еллар узгач, килсәләр дә
Яшәргә дип, башка җирдә урын тапмый,
Йорт арты йорт юкка чыга урамнардан,
Кайтучылар тик бик азга аны саклый.

Урам арты урам китә – күрү авыр.
Авыл үлә карт кешедәй акрын гына.
Бөтенләйгә киткән көнен күрәм аның:
Арабызда еллар гына, чакрым гына...

## Уенчыга

Йөрәкләрең уйнаганда зур хисләрдән,
Ярым диеп, чын күңелдән кемне кочтың?
Йөрәгеңә сулык-сулык кан сауганда
Ватан диеп атыйсың син нине, дустым?

Яклаганда, мылтык тотып саклаганда,
Илем диеп, кай җирләрне сайлыйсың син?
Ничек итеп, ун сүз белгән башың белән,
Татар телен әнкә теле саныйсың син?!

Каеннарны, миләшләрне үзеңнеке
Дип таныйсың, башка милләт алгач тартып?!
Татарлыктан баш тартырга вакыт, диләр,
Таш миеңә көн дә, төн дә шакылдатып.

Җомгаларда мәчетләргә керәсең син,
Һәрбер язда каберлеккә кайтасың гел.
Милләт шунда күмелгән бит, дигән кебек
Кайтудыр бу, танудыр бу нибары, бел.

## Күл

Тамчылардан күл җыела, диләр,
Яшь җыела кайчак еларлык.
Хәсрәт килсә.
Гыйбрәт сөйләсәләр.
Эш эшләсәң
Башны кыярлык.
Тамчылардан күл җыела, диләр.
Чыгармыйм мин яшьне тамчылап.
Төеп-төеп җыям.
Аннан ява,
Битләремне төндә камчылап.
Хәсрәт килә –
Кысып җанга салам.
Күперәдер кара болыттай.
Битләремә таммый бөртек-бөртек.
Актарылып ага юк-юкта.
Ерыла да китә, ерыла да
Күз төпләрем,
Көче бетә дә,
(Яшем, саркып, буа ергандай бу...
Сабыр савытларым ватылгандай...)
Хәсрәтләрем күпкә китә дә.

## Ә мин күрәм!

Җил күренми, диләр, ә мин күрәм:
Кара күлмәгенә киенә дә
Йөгерә ул һәр көн таң белән!

Тәрәзәмә килә: сөртә корым.
Ишегемә килә: каралта!
Шәһәр җиле, хәтта таңгысы да
Никтер кара төсләр ярата.

Җил күренми, диләр, ә мин күрәм.
Су янында карап басып торам.
Үзе күрмәсен дип, кумасын дип,
Таллар арасына качып торам.

Җил күренми, диләр, ә мин күрәм:
Таллар арасыннан кулны сузып,
Тотам аның зәңгәр күлмәгеннән.

***

Зур тормышка диеп үстергәнсең,
Туган ягым – син бишегем минем.
Авыр чакларымда ачып кергән
Биксез көткән киң ишегем минем.

Тормыш үзе синдә булган икән.
Кайнаган ул тыныч кына, тигез.
Болыннарда, кырда, бакчаларда...
Көн дә бер үк булган бар эшебез.

Туйдырганмы алар, күренгәнме
Яшьлек күзлегеннән бик вак булып?
Тормыш анда! – диеп йөгергәнбез,
Мәңге кайтмас кебек, таңда торып.

Яшәгәндә берни уйламыйча
Еш кайтарган тормыш... нужа өеп.
Еш кайтарган җиңебездән тартып,
Туган яктан хәсрәт җиле килеп.

Тормышларның зуры, кечеләре
Яшең олыгайгач калмый икән.
Сабыйланган күңелең үз уенда
Бишек бавын тартып карый икән...

Туган ягын кабат сайлый икән.

## Теләк

Минем җирне сөеп җылытырга
Йомшак нурлар бирер булсын кояш.
Егылырдай торсын үскән үлән
Кышлык печән булып колач-колач.

Мулдан булсын кырда игеннәрем,
Кошларга да калсын бөртекләре.
Кояшның да, дымның җитәрлеген
Күрсәтсеннәр агач киртекләре.

Әйләнәсе каен-имәннәрнең
Калынайсын җәйнең җылысында,
Шытып калсын иген уңай килгән
Язларымда – айның дымлысында.

Урманнарга керсәң, кош сайрасын:
Рәхәт булсын җанга шат җырыннан.
Кырларыма оя корсын тургай,
Сәбәп булсын шул да шатлыгыма.

Яр чыпчыгы, киндер чыпчыклары,
Йортка оя корыр күгәрченнәр,
Хәтта бәбкә урлар тилгәннәрем!
Ризык телим, телим юньле көннәр!

Урман-үзәннәрдә йортын тапкан
Төлкеләрем, бүре, бурсык, куян!
Язсын Ходай җиңел көн күрергә,
Кешеләргә китермичә зыян.

Авыл кырын сөеп җылытырга
Йомшак нурлар бирер булсын кояш.
Урман-болыннарда үскән үлән
Чалгылардан аусын колач-колач.

***

Горур бул, дип үстерделәр мине.
Горур булдым, диләр, ник текә?
Текә түгел, кулга гына кермим!–
Мин иректә үстем, иректә!

Тырыш бул, дип үстерделәр мине.
Тырыш булдым, диләр: бик уңган.
Уңмаган мин, тырыш кына бары!
Мин куркамын ялкау булудан.

Туры бул, дип үстерделәр мине.
Чү-чү, диләр, сөйлә сак кына?!
Каләм иясенең бурычыдыр –
Туры сүзне әйтү халкына.

Тугры бул, дип үстерделәр мине.
Тугры булдым, диләр, ник кирәк?
Яндагы яр бал күк тәмле булса,
Читтәге яр, диләр, нәкъ ширбәт.

Текә түгел, кулга гына кермим!
Уңган түгел, әмма бик тырыш,
Турыдырмын, тугры... Бу сыйфатлар
Шулкадәр үкмени куркыныч?!

## Челләдә

Шәһәр урамыннан су буена
Көн эссесе алып килә исләр.
Шул эсседән качкан бөтен халык –
Дымлы комга яткан бөтен төсләр.

Җәй уртасы түгел әле юкса,
Кушылганнар инде тәннәр ярга.
Кызыл, зәңгәр, яшел купальниклар
Тибрәләләр йөгрек дулкыннарда.

Яшелләнеп беткән елга суы,
Уентыклар күкшел, көрән төстә.
Суырылып кына яр буена
Шавырманың майлы исе төшкән.

Ит исләре төшкән, бөккәннәрнең
Авыр исе кучкән яр буена.
Ашау белән мәшгуль бөтен кеше.
Суда бары ике эт коена...

## Болай гына

Комнар ефәк кебек, салкын ефәк,
Су тигезләп ярны чиккәннән соң.
Комнар ефәк кебек, кайнар ефәк,
Сине ярда озак көткәннән соң.

Яр буенда чепер-чепер дулкын.
Елга өсләрендә – ник тип-тигез?
Купсын әле эре дулкыннар да,
Бер ярышып йөзик тик икебез.

Бер куышыйк Идел өсләрендә,
Яшьлектәге кебек, булдыргандай.
Көтәм сине. Кояш кайтып китте,
Минем көтү җанын туңдыргандай.

Яр буенда чепер-чепер дулкын.
Елга өсләрендә тик ай гына.
Ефәк комнар дымнан дерелдиләр.
Бу шигырьне яздым болай гына.

## Ураза

Чыдамам күк иде ач яшәүгә –
Уразада бүген, синсез торам.
Синле гөнаһларны кичер, диеп,
Ятсам-торсам, ихлас дога кылам.

Кичер, Ходам: ялгыз чакларымда
Сөеклемне өзелеп көткәнем бар,
Димен аккан күз яшьләрем аша,
Хәтта тынсыз калып үпкәнем бар.

Яратырга тиеш түгеллекне
Беләидем – җиңде мине хирыс!
Бу ураза, бәлкем, соң көнгәчә...
Ходаем, син көч бирергә тырыш.

Авыр безгә уразада яшәү:
Ул ач тору кебек тәнгә, хискә!
Шартын тудыр миңа яр килмәүнең –
Ничек тә бит кирәк бирешмәскә.

Кичер, диеп, булган гөнаһларны,
Ятсам-торсам, ихлас кылам дога.
Бу әлегә чыны түгел аның –
Уразаны тотып карау гына.

Хискә, дәрткә ымсынуны тыю –
Белү өчен кирәк ачның хәлен.
Бу атнаны синсез яши алсам...
Кичерер Күк синле яшәлгәнен...

Бу атнада башны орып җиргә,
Кичер, димен, бәйнә-бәйнә санап
Гөнаһларны – Ул бит ярлыкаучы!
Гафу итәр! Гөнаһына карап...

Ә аннан соң... Яшим башкача мин.
Уразаның инде тотам чынын.
Ахырына якынлаша гомер...
Гел гөнаһлы... диеп борчылуым.

## Басып торам Идел буйларында

Басып торам Идел буйларында.
Бер тынлык юк хәзер ярларда.
Суда балык кебек йөзә идең,
Барып җиткән ярың кайларда?

Сине уйлыйм Идел буенда мин.
Йөзгән идек бергә ярышып.
Син бер балык идең, мин, тамырдан
Кубып аккан елга камышы.

Чыктым да мин ярга, тамыр белән
Шул урында ныклап беректем.
Ярда үсеп, һаман сине көттем...
Син еракка миннән ник киттең?

Басып торам Идел буйларында.
Идел буе – минем йортым ул.
Аның суы – сине алып киткән,
Миңа шифа илткән дулкын ул.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Алмаз
Хәмзин

# КАБУЛ ИТӘСЕЗМЕ?..*

РОМАН-ФАРС

**Илһам да өйләнмәгән...**

Инде кырыгы тулып килә Гаделҗанның. «Яшең җитсә кырыкка – эшләр китә шырыкка», диләрме әле. Шулайрак бугай шул... Өйләнмәгән дә бит әле. Тулай торактагы вахтёрша Галимә апаның консерваториядә эшләүче сердәше Сабира сөйләгәннәрне искә төшереп алды ул. «Шулай, Илһам Шакировның укып йөргән чаклары... Авыл егете инде, авылча киенгән. Кәчтүм-чалбары да юк, – ди. – Гел йә күлмәкчән, йә шул гел бер свитер белән күренә. Үзе гаҗәеп матур җырлый инде – ул тавыш дисеңме, моң! Сөйләштергәлим:

– Нишләп, Илһам, өстеңә берәр пинҗәк алып кимисең? – дим.

– Акча яклары бик сай бит әле, апа, – ди. – Ашарга гына җитә.

– Соң, – дим, – инде радиоларда чыгышлар ясыйсың түгелме?

– Анда җырлаган өчен әллә ни күп түләмиләр бит, – ди.

Икенче, өченче курслар җитә. Тагын сорыйм:

– Илһам, җаный, менә зур җырчы булып киләсең, һаман торырга урының да юк.

– Шулай шул...

– Кешедә яшисеңме әле дә?

– Әйе, Сабира апа.

– Йортка кер берәрсенә, – дип шаяртам. – Хакын җырлап түләрсең.

– Шулай гына итәсе калды инде, – дигән була, шаян үзе.

Тора-бара матур кәчтүмнәр киеп йөри башлады. Шулхәтле күркәм, матур егет төсләре керде үзенә. Радиолар аның тавышы белән тулды, концертлары гөрләде.

– Өйлән инде, – мәйтәм.

– Әй, Сабира апа, кая алып кайтыйм мин аны? Тукта, фатир алыйм әле, – дип тынычландыргандай итте.

---

* Журнал варианты.

Алмаз ХӘМЗИН (1947) – *прозаик, шагыйрь; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Озак яшисегез килсә» китабы, күпсанлы җырлар, юморескалар авторы. Казанда яши.*

Инде укуын тәмамлап, үз коллективын булдырып, гастрольләр белән ил гизә башлады. Китте, китте остарып, бөеклеккә үрләде. Кайткалаган чакларында консерваториягә кергәли.

– Нихәл, Сабира апа! – ди.

– И-и, Илһам җаный, нинди җилләр ташлады сине монда?

– Сине сагынып кердем, – дигән була.

– Өйләндеңме әле? – мәйтәм.

– Сабира апакаем, еллар буе кайтмыйча җырлап йөрүчегә кем кияүгә чыксын? – ди.

Менә шулай тәки ялгыз калды ул.

«Минем язмыш анықыннан бер дә ким түгел», – дип куйды Гаделҗан үзе турында. Аерма тик шунда – ул Бөек, ә мин беркем дә түгел. Алда әле бернинди ачыклык күренми – ни өйләнү, ни абруй... Дуслар арасында да сабакташ Даһидан гайре бүтән кеше күренми. Ул әле тагын күтәреләчәк, зур дәрәҗәләргә ирешәчәк.

Дусай? Бәлки, инде майор булгандыр. Чөнки егерме елга якын армия хезмәтендә. Аннан хәбәр алган юк. Галимгә дә район башлыгына кадәр үсәрлек еллар узды. Ни дисәң дә, башлы егет иде! Әүхәт турында яман хәбәр ишетте. Шикле кешеләр, төркемнәргә ияреп йөргән; күп күләмдә бурычка акчалар алып, бурычын түләмичә, алдап-йолдап яшәгән дә, әнә, подвалда асып киткәннәр үзен. Кемнәр шулай эшләгән – белүче дә юк. Тиз арада фатирлы булуы да шуңа бәйләнгән, күрәсең.

Гөлсиярнең дә тормышы еллар үтә-үтә җимерелә барган. Башта кызы юл фаҗигасенә юлыгып, әнисен кара кайгыга батыра, аннан ире ялгызын калдырып мәрхүм булган, соңыннан үзе дә...

Дусты Рәшит инде Яңа Калада зур предприятиенең транспорт бүлеге мөдире икән. Калганнарыннан хәбәрдар түгел. Каян белсен, кем җиткерсен аларны, үзенең дә адресы гел алышынып тора бит. Сукбай диярсең...

Беркөнне: «Сине Зиннәт эзли», – дигән хәбәр килде. Каян тапкандыр аны. Адресын язган, эшли торган урыны, ахрысы. Мәркәздәге «Байлыкка кызыгу нәфесенә каршы тору комитеты» диелгән.

«Оһо! – дип куйды Гаделҗан. – Кая үрмәләгән егет!»

Бара инде, әлбәттә, күптән күрешкәннәре дә юк. Байтак еллар үткән түгелме соң?.. «Карале, биш ел! – диде, озак кына уйланып утырганнан соң хәтереннән узган еллары турында баштан кичереп. – Ни әйтер икән? Кайчан барсаң да ярый торгандыр инде».

Гаделҗан икенче көнне үк җыенып, «болай гына кертмәсләр әле», дигән уй белән паспортларын алып, Зиннәткә юл тотты.

Менә ул әйткән идарә. Ишек төбендәге милиционерга кемгә килгәнен әйтте дә, паспортын калдырып, икенче катка менде. «Менә кайда оялаган икән», – диде ул, ишекне кагып. «Керегез!» – диде таныш тавыш. Күрештеләр, бер-берсенең иңнәрен кагыштылар, кочаклашкан булдылар. Ә нигә шулай итмәскә, күптән күрешкәннәре юк бит. Зиннәткә теләсә нинди кием килешә инде, монысы бигрәк тә, погоннары... Йолдызлары бар, сирәк әле, күбәерләр, шиге юк. Егет барысын да алдан күреп эшли!

Башта гомуми сүзләр әйтелде:

– Ни хәлләр? Эшләр барамы? Син хәзер кайда? – диде Зиннәт.

– Күрәм, үсәсең! Гаилә, тормыш ничек? – дип, Гаделҗан да сүз какты.

– Әйбәт. Үзгәрешләр юк, шул бераз картаебрак киттем.

– Кит инде, мин сизмим, син һаман шул килеш, – дигән булды Гаделҗан.

– Өйләндеңме?

– Юк әле, вакыт җитми. Ә синең тормышлар?

– Балалар үсә.

– Укыйлардыр инде?

– Наташа шулар белән мәш килә.

– Молодец! Ә Алина?

– Алина сине көтә.

– Шаярма, ул көтеп ята торган зат түгел. Режиссёрны ташладымы әллә?

– Кит инде, нишләп режиссёр аның белән маташсын? Беткәнмени аңа яшьрәкләр?.. Ну, ярар, минем синең белән килешеп эшлисе бер серем бар. Әйдә, «мужской»га, – дип, пышылдауга күчте, дөресрәге, башы белән ымлады, кулын колак яфракларына куеп зурайтты.

– Тиз генә байыйсың киләме? – диде ул аңа, «М» кабинетына кергәч.

– Аңламадым?

– Хәзер ныгытып аңлатам. Тыңла. Синең Ильф һәм Петровның «Унике урындыгын» укыганың бармы? Китабын?

– Ну, бар. Шуннан?

– Шуннан... Минем башта бер идея туды. Бездә – Татарстанда ничә обком секретаре булганын беләсеңме?

– Санаганым юк... Күп инде алар.

– Менә Ильф һәм Петровның әсәрендәге персонажлар – Воробьянинов белән Остап Бендер шул Ипполит Воробьянинов тещасының, ялганмычынмы, кәнәфигә тегеп калдырган бриллиантларын эзлиләр. Унике кәнәфинең төбен актаралар.

– Шуннан?.. Тапмый бит алар аны.

– Эзенә төшәләр, ләкин ул байлыкка инде пионер сарае төзелгән була. 1923–1927 нче еллар бу. Хәзер дә менә шуңа охшаган чорлар бездә.

– Һаман аңламыйм, синең-минем моңа ни катнашыбыз бар?

– Ашыктырма, аңлатам. Менә шул вакытлардан бирле хәзерге көнгә кадәр республиканы байтак секретарьлар җитәкләгән. Аларның һәрберсенең үз кәнәфие булган...

– Шулай инде.

– Алар бер тәхеткә килсәләр дә, элеккеге кәнәфигә утырмаганнар. Алыштырганнар, яңасын ясатканнар.

– Ник?

– Син үзең кеше кәнәфиенә утырыр идеңме? Эчне пошыра бит ул, язмышың элеккеге хуҗасыныкын кабатлар төсле тоела. Алар бит барысы да диярлек ул заманнарда репрессиягә эләккәннәр. Алыштыралар, әлбәттә.

– Әйе, мин дә шулай итәр идем.

– Мин дә. Монысын аңлаштык. Тагын... Җан ияләренең бер гаҗәеп гадәте бар, алар үзенә ошаган яки кирәкле әйберләрен җыялар. Мәсәлән, ана каз бәбкә чыгарырга ояда утыра, якын-тирәдә нәрсә бар, муены җиткәнче сузылып, шуны астына сала. Шулаймы?

– Шулай.

– Тагын. Саескан... Нинди ялтыравык әйбер күрә, шуны оясына ташый. Килешәсеңме?

– Килешәм.

– Беренче секретарьлар да шулай. Исбатланган инстинкт.

Безнең бурыч, боларның кәнәфиләрен табып, актарып чыгу. Бәлки, нәрсә дә булса табарбыз, һич тә булмаса – син язучы, берәр әсәр әмәлләрсең, ә мин сиңа үз дәрәҗәм буенча булышырмын, чүтеки минем дә кызыксынуым көчле – тиешле урында хезмәт итәм. Бер карасаң, бөтен ришвәт тә ачыклана.

– Кызык бу, бик кызык...

– Димәк, килештек.

– Килештек.

## Беренче кәнәфи

Озак та үтмәде, Зиннәттән хәбәр килде. Ул очраклы рәвештә «Болак» театрының «Онытмам үлгәндә дә...» спектаклен карап кайткан. Сәхнә түрендә теге кәнәфиләрнең берсе торуын күргән икән. Анда ничек килеп эләккән ул? Бик сәер... Зиннәтнең хыялый күзенә бөтен урындыклар да сихри нур сирпи мәллә? Бал корты түгелдер бит ул, бал сыланган җиргә кунарга?.. Шулай да, баш режиссёрдан рөхсәт сорап, утырып та караган Зиннәт аңа. Күзе белән әлеге кәнәфине йотардай булып әрсезләнсә дә, арт шәрифе белән бернәрсә дә тоймаган аның эчендә. Ләкин нәрсәдер бар да сыман. Баш режиссёр Галиар кунагының кәнәфигә булган мәхәббәтен үзенчә аңлаган. Кемгә нәрсә ошый бит!.. Берәүләр спектакльдән мәгънә эзлиләр, икенчеләре – артистларына гашыйк, өченчеләре – буфетына, дүртенчеләре – йокы рәхәтен таба, ә монысы – урындыкка хәйран калган.

Шул чакта авызыннан: «Сат миңа!» – дигән сүз атылып чыкканын үзе дә сизмәгән Зиннәт.

Юк, бирәме соң ул аны, иске җиһазлар кибетеннән, көчкә табып кайтсын да... Хәзер бушка биреп җибәр!.. Юк, юк...

– Нәрсәгә сиңа мондый иске урындык? – дип сорап куйган Галиар Зиннәттән. – Остап Бендер түгелдерсең бит?!.

Зиннәт әлеге сүздән дерелдәргә тотынган. «Әллә белә микән бу безнең планны?» – дигән уй баш миенең барлык чокыр-буразналары буйлап выжылдап узган.

– Авыр сүз әйттем, ахрысы, телсез калдың, – дигән, үзен гаепле сизгәндәй, режиссёр.

– Кая инде безгә Остап бөеклегенә җитәргә!.. – дип йомган әңгәмәне Зиннәт. – Уникe урындыкны каян табып бетерәсең аны?! Шутник икәнсең!..

Алар режиссёр кабинетына юнәлгәннәр. Өстәл артында режиссёр тантаналы рәвештә сүз башлаган:

– Мин ул кәнәфине бик тә талантлы драматургның «Юлбашчылар уены» дигән пьесасы буенча эшләнәчәк спектаклендәге төп персонаж – Чыңгыз хан өчен саклап тотачакмын.

– Кем инде ул талантлы драматург?

– Сине шул спектакльнең премьерасына чакырам. Шунда белерсең, үзен дә күрерсең.

– Дуслар белән килсәм ярармы?

– Бик шат булырбыз! Бик катлаулы, әмма ифрат та әһәмиятле эчтәлеккә бай әсәр. Спектакльдән кызык тапмасаң – кәнәфигә карап утырырсың. Кил!

...Менә шундый увертюра булып алган башта. Премьера көне килеп җиткәч, Зиннәт авырып киткән. Әллә сабышкан гынамы? Җен белсен... «Бармый икән, бармый... Курка торгандыр... алай-болай урлаганда эләксәләр, ахыры шәп булып бетмәячәк. Үзе бит нинди урында эшли! Хәзинә табылган очракта табыш минем кулда булачак», – дип куангандай итте Гаделҗан. Ләкин Зиннәтнең, бу афёрасына бирелүенә аның җаны тырнала иде. Юкка ризалашты ул моңа, юкка. Ә шулай да яхшы гына әсәр язар өчен чимал бар сыман – шунысы кызыктыра.

– Берәр кыз ияртеп барсам, каршы килмисеңме? – диде ул Зиннәткә шалтыратып, юлга чыгар алдыннан. Кызыгып йөри торган бер чибәркәе бар иде соңгы көннәрдә. Бер фирмада бухгалтер булып эшли. Кияүгә чыкмаган, яше утызга якынлашып килә. «Берәр премьераңа алып бар әле» дигәнен истә тотып эшләде ул бу чакыруын. Тора-бара бәлки өйләнеп тә куярмын шуңа дип йөрүе иде соңгы араларда. Тик менә үзенең таныш-белешләре: «Өйләнә күрмә, аларның нәселләре кысыр», – дип кисәтеп куйдылар, шунысы шикләндерә. Ә бүген барып кайтырга һәм алда да шаярып йөрергә ярамаган тагы.

Гаделҗан Лилиягә гел шигырь генә сөйләп барды, әлбәттә, үзе иҗат иткәннәрен. Сәнгатькә гашыйк кыз, күзләрен аннан алмый, йотлыгып тыңлый. Бу минутларда, әйтерсең лә, аннан да бәхетле кеше юк.

Шәһәрдән чыгып, сиксән чакрым киткәч, Лилия кафега кереп чыгасы итте. Әллә чәй эчәсе киләме, әллә кысталганмы, кем белсен... Көтә-көтә көтек булып бетте, чыкмый да чыкмый. Аптырагач, үзе керергә уйлады. Кызый, кызып-кызып, Кыса шәһәрендә яшәп иҗат итүче атаклы композитор Разиф белән сөйләшеп утыра. Алларындагы яртының яртысына төшкәннәр инде. Зиннәтне күрүгә кул изәделәр.

– Кил әйдә, нәрсә авызыңны ачып, карап каттың? – ди композитор. – Без монда сине көтеп, зарыгып, елашып беттек бит инде, – дигән була.

Менә сиңа мә. Алар түгел, Гаделҗан гаепле икән.

– Без сөйләшкәнне тыңлап утыр – шулхәтле кызык. Карале, теге вакытта мин сине кыйнап чыгара идем өйдән... – дип дәвам итте Разиф. – Син әйткән сүзләрне башка кеше әйтсә... Беләсеңме, Лилия, ул чакта бу миңа нәрсә ди?.. «Ну-ка выходи, подлый трус! Леопольд», – ди бит әле...»

– Ә нәрсә өчен шулай ди соң ул сиңа? – дип сорап куйды кыз, бернәрсә аңламагач.

– Үзем сөйлим, – дип әйтте дә Гаделҗан аңлатырга тотынды: – Без Разиф белән бергә районда концертлар куеп йөрдек. Халыкның да, колхозларның да, районнарның да акчасыз чагы. Булды бит инде шундый вакытлар...

Разиф безнең төркем җитәкчесе: үзе концертларны оештыра, үзе җырлый, үзе бии дигәндәй... Үзе түли... Ә менә түләргә дигәндә – кыенлык бар. Концерт куюын куябыз – акчасын бирүче юк. Шуңа күрә Разиф түләүне ашлыклата ала. Янәсе, ашлыкны эшләп ала да аны акчага әверелдерә. Бу урып-җыю чоры – көз. Ә колхоз үзе җыйган уңышын акчага әйләндерә алмый. Разиф нишли? Ашлыкны писүккә яки шикәргә алыштыра. Инде

хәзер писүкне акчага әверелдерергә кирәк. Ыхы! Андый хәйләкәрләр дә байтак икән. Клиентлар да күренми, ә шикәр заводына шикәрнең кирәге юк – үзе дә шул мохтаҗлыкта.

Разиф сүзгә кысылды.

– Аптырап беттем мин ул чакта... Артистларга акча түләргә кирәк бит. Өйләрендә бала-чагалары көтә, хатыны. «Әтиегез кайта, акча алып кайта – күп итеп!» Ярый да син гаиләле түгел, балаларың елап утырмый, – дип, Разиф Гаделҗанга карады.

Гаделҗан сөйләвен дәвам итте:

– Бу нишли? Шикәрне чүпрәгә алыша. Халыкка чүпрә бик кирәк. Әле ул вакытларда оеткычка кытлык бар иде. Көз, дидем бит. Җиләк-җимеш өлгергән. Бозылмасын өчен шәраб ясап, мәш киләләр. Аны чүпрәсез ясау мөмкин түгел!

Менә шундый ысуллар кулланып, Разиф безнең кесәгә акча салып җибәрде.

– Анысы шулай. Мин ул турыда әйтмим сиңа... Хәтерлисеңме, мине соңгы концерттан соң сүктең, өйдә, хатын алдында...

– Ә-ә, әйе шул, всё по делу! Искә төшердең. Соңгы концерт. Авыл клубы. Колхоз рәисе килде. Син нигәдер аның белән сөйләшә торгач, талашуга күчтең. Председатель ул чакта, ризасызлык белдереп, кулын селтәде дә клубтан чыгып китте. Ә син җырларга сәхнәгә атладың. Программа буенча бишме-алтымы җыр башкарасың бар. Шул вакыт председатель яңадан сәхнә артына керде. «Әйдәле, Гаделҗан, чыгып керик!» – дип, мине клубтан алып чыгып, машинасына утыртты.

Нәрсә эшләргә, ни әйтергә маташа инде бу дисәм, тутырып, аракы салды да тимер кружкага:

– Җиппәр, әйдә! – ди.

Мин каршы киләм:

– Син дә ачуны китереп торма инде! – дип, үпкәләгән сыман әйтеп куйды бу.

– Минем бит әле сәхнәгә чыгасым бар, ярамый, – дим.

– Ярый, – ди, – мин әйткәч, чуртым да булмый, тавышың гына ачылып китәр, илһамың куерыр, йөзеңдә нур балкыр!..

Каплап куйдым инде. Умырып, колбасасын каптым да:

– Җыры бетеп куймасын тагы, – дип, клубка йөгердем. Өлгердем. Сер бирмәскә тырышып, сәхнәгә чыгып бастым. Клубның сыек кына янган утлары җем-җем килә, тамашачыларның авызы ерык, әллә юри, әллә чын, кул чабып каршыладылар. Нәрсә сөйләгән, ничек җырлаган – истә түгел... Әйбәт кенә вазифамны үтәп чыктым бугай... Башкалар җырласын, биесен, сөйләсен...

Концерт бетте. Икенче тапкыр сәхнәгә чыгарга син юк. Әллә кайтып киткәнсең, психланып...

Без дә җыендык. Акча-мазар түләүче юк. Нишлисең бит, әле моңарчысын да бирүче булмады. Күнегелгән. Күңелсез генә кайтып киләбез. Авылны чыгып, байтак юл үткәч, арттан ниндидер машиналар куып җитте. Фаралары белән уйнатып, безне юл кырыена кысрыкладылар. Баш бетте, дип торабыз – хәзер кыйныйлар. Без кагылмасак та, «УАЗ»ыбызның ян ишеге ачылып китте. Председатель басып тора.

– Кайда Разиф?

– Юк, кайтып киткәндер...

– Чурт с ним... Менә бу кәгазьне ишек төбегезгә җәегез әле!

– Нигә?

– Сорап тормагыз! Җәегез!

Җәйдек. Зур сумкаларыннан кисәк-кисәк ит чыгара башладылар. Шешәләр шалтырап куйды. Берсенең бөкесен төбенә сугып, ачтылар да кружкага готгылдата башладылар. Исе – председатель машинасында эчкәннекенә тартым.

– Мә, Гаделҗан, йот!

Мин, үзең әйтмешли, ялындыра торган кешеме инде? Тоттым да елпыдым. Шуның, сез мишәрләр әйтмешли, гурлаларны яндырып төшүләре әле дә хәтердә. Закускага – ит. Әллә бер бозау! Рәхәтләндек без ул төнне сыйланып. Биюче кызыбыз – Кафия пред кочагыннан төшми.

– Барыгыз, китегез, калам, – ди. Әллә шулай бик үҗәтләнгәнгә тизрәк таралдык?.. Председатель совестлы булган инде, концертка дигән акчасын да, рәхмәтләр әйтеп, кесәмә тыкты.

Менә шул, кайтсак, йоклап ятасың. Кычкырам, кычкырам, чыкмыйсың бүлмәңнән... Ниһаять, ишегеңне ачтың да, председатель биргән акчаны күргәч: «Нәрсә, биреп җибәрде мәллә? Молодец! Син дә шәп егет икәнсең!» – дигән буласың.

– Ярый, булган беткән. Мин сезнең белән бүген театр карый алмыйм инде. Галиарга сәлам әйтерсез! – диде дә, кафеның кухня ягына кереп, әллә кая югалды.

Лилия Разиф белән кәеф-сафа кору нәтиҗәсендә рульгә утырырга батырчылык итмәде. Кыса ГАИларының бик усал булуларын бөтен тирә-як белгәнгә күрә, машинаны йөртү Гаделҗанга тапшырылды. Лилиянең шундыйрак хәлдә булуы аңа уңайрак та әле. Ул шул турыда уйлап, район үзәгендәге театрга юл тотты. Инде ерак түгел...

Анда аларны һич уйламаган яңалык көтә иде. Гаделҗан театр алдындагы белдерүләр тактасына күз төшереп узды. Нииндидер ят исемдәге спектакль афишалары тезелеп киткән, ә аныкы нигәдер күренми. Сәер хәл. Шул сәерлек белән театр бинасына керделәр. Әле тамашачылар юк. Әйе, алдан уйлаганча, алар иртәрәк килергә исәп тотканнар иде. Каршыларына баш режиссёр чыкты.

– О-о! Кемнәрне күрәм! Рәхим итегез!

– Без Зиннәт әфәнде тарафыннан җибәрелгән идек...

– Аңлашылды...

– Үзе авырып китү сәбәпле...

– Зыян юк. Менә ул карыйсы килгән премьераны күрсәтү тыелды бит әле. Күпме әзерләндек, күпме көч түктек, расходландык. Инде авторын да эзләтеп таптырган идек, аны да чакырттык. Күренми әле. Кушаматы Шамун исемле, «Юлбашчылар уены» дигән пьесаны язган шәхес. Безгә аны Мәркәз театрының баш режиссёры Даһи әфәнде җибәргән иде, гениальный әсәр дип. Чыннан да, андый гадәти булмаган стильдә язучылар бик сирәк, юк дисәң дә була. Ә без тотынган идек. «Югарыдан» хакимият вәкилләре килделәр дә безне пух-прах китереп сүктеләр. «Сез акылыгыздамы,

беләсезме тамырында бу пьесаның нәрсә ятканын?» – диделәр. Төрмә белән куркытып киттеләр. Шуңа күрә бүген буласы ул премьераны «Хатын түгел – аждаһа» спектакленә алыштырдык. Рәхим итеп, шуны карарсыз!

– Борчылмагыз, без сезне аңлыйбыз, – дип әйтеп куйды Гаделҗан, үзенең бу хәлдән чыккан җен ачуын яшереп. – Кара син аны – Зиннәтне, белгән бит бу хәлнең буласын... Белгән бит... Авырган сәбәп табып, эшендә калган. Ярый, килдем, ләкин бурычны үтәми ярамый.

Алар, спектакль башлануын белдергән соңгы звонок астында, зал караңгылыгына күмелеп, урыннарына утырдылар. Гаделҗан иңенә аскан сумкасындагы лобзигы белән кләшчәсен, боргычын капшап алды. Урыннарында микән, янәмәсе...

– Нәрсә капшанасың? – дияргә мәҗбүр булды Лилия.

– Болай гына...

Спектакль кызык, ахрысы. Халык баштан ук көлә, кул чаба башлады. Ничек көлмисең инде?.. Ир белән хатыны талаша... Һәркемгә таныш эпизодлар, бер-береңне битәрләүләр, үчекләүләр, рәнҗетүләр...

«Кайсы җирләрендә розеткалары бар икән җиһаз бүлмәсенең һәм Зиннәт күргән кәнәфи кай төштәрәк, шуны беләсе иде, – дип пошынып куйды ул үзалдына. – Разведка ясап керәсе булыр».

Гаделҗан Лилиянең колагына, «хәзер керәм», дип пышылдады да, бәдрәфкә кысталган кебек чырай ясап, ян ишеккә юнәлде.

Бәдрәфләрендә, бер лампочкадан башка, электр тоташтырыла торган нәрсә юк иде. Буфетындагы розетканы көчкә тапты, ләкин ул куллану өчен җайсыз урында, шкаф артында булып чыкты. Сәхнә артындагылары ян-якта, ә икесе арттагы җиһазлар өеменә күмелгән. Шуларыннан да кулайрак урын булмастыр, мөгаен, кәнәфи ботарларга.

Әнә ул янында гына тора – матур икән, затлы. Чынлап та, патшалар гына утыра торган. Гаделҗан, лобзик чыбыгын токка тоташтырырга җайлы булсын дип, берничә тумбочканы читкәрәк этте. Берсенең эчендә шешә чыңлавына сагаеп, колагын төбәп торды. Йозагы да бар икән. Ләкин бикле түгел. Аны салдырып, ишеген ачып караса, кәгазь бөтереп бөкеләгән яртылаш сыекчалы шешәгә күзе төште. Аракы микән әллә? Пылт итеп бөкенең тартылуы булды, күзләрне җебетерлек аракы исе борынга бәреп керде. Әһә, кырыйдарак ипи кисәге дә тора. Ул, кабаланып, бераз эчмәкче иде, шешә авып китеп, аракысы түгелә башлады. Яшен тизлегендә тотып калды ярый, югыйсә идәнгә төшеп, ватылган да булыр иде. Табышын яңадан урынына тыгып куйды.

Лобзикны розеткага тыкты да Гаделҗан кәнәфинең астагы тактасын кетердәтеп кисеп алды. Тавыш чыгармас өчен капланган пәрдәне алып ыргытты. Утыргычта йомшак булсын өчен тутырылган мамыктан башка бернәрсә дә юк иде. Караңгыда тактаның эчке ягына язылган ниндидер саннарны гына укып була: 1920 – ничәнчедер еллар...

Гаделҗан тузаннан өс-башын какты да, Лилия янына кереп утырды. Эче катып көлеп утыручы тамашачыларның игътибары үзендә түгеллеген ул белә инде. Лилия генә:

– Нишләп бик озак? – дип сорады.

– Бер дуска шалтыратасы барын искә төшердем дә, директор бүлмәсенә кереп, телефоннан сөйләштем, – дип алдады.

Ниһаять, спектакль тәмамланды. Тамашачылар артистларны аягүрә басып алкышлады. Фойега чыктылар. Банкеты да булачак икән. Гаделҗан Галиарны бер читкә алып китеп:

– Тамаша өчен зур рәхмәт, без инде банкетларга калып тормабыз, кайтасы юл ерак. Ничек диләр әле, «юл кешесенең юлда булуы хәерле», диләрме әле? – диде

– Анысы шулай. Ашап-эчеп китсәгез әйбәтрәк булыр иде. Ни дисәгез дә, сез бит олы кунаклар. Мәркәзебездән. Мондагы дусларыбыз белән дә танышыр идегез.

– Рәхмәт. Сез мәшәкатьләнеп йөрмәгез безне озатабыз дип, кунакларыгыз янында булыгыз!

Куллар бирешеп саубуллаштылар.

Юлда Гаделҗан уйланып кайтты. «Хәзер Галиар аңарга шик ташлавы бар. Шуннан ничек булса да котылу кирәк».

Ләкин юкка борчылган икән, ни ул, ни милиция, ни берәрсе сагайсын...

Уйларыннан аны Лилия бүлдерде:

– Нигә тындың?

– Болай гына, рәхәт бит синең белән... – дигән булды Гаделҗан.

– Миңа да.

– Спектакль ошадымы?

– Бик! Рәхмәт алып килүең өчен!

– Үзеңә рәхмәт! Синең машинаңа утырып бардык!

– ЗАГСка да шушының белән барырга язсын!

– Фантазияң чамасыз зур, чибәркәй – минем максат җитмәслек.

– Ник алай дисең?

– Язылышкач, мин кәләшне кая алып кайтыйм? Тулай тораккамы?

– Аңа да ризамын.

– Мондый карт кешегә кияүгә чыгарга дамы?

– Әллә кәләшең яшьме?

– Пар килгәнбез икән... Әле алтмыш-җитмешкә хәтле уйларлык вакыт бар.

– Гаделҗан, шаярма, мин бит чынлап сөйләшәм...

– Җә, ярый, башны бутама, рульдә барам, чүтеки...

Алар бер-берсенә карашып, тирән итеп тын алдылар да сөйләшми-нитми кайта бирделәр.

Бу минутларда театрдагы сәхнә эшчесе түгелүдән калган аракысын йотып бетергән иде. Әй, каргады да инде ул аракысына кул сузган кешене: «Дөмеккере, кулы коргыры, авызы кыйшайгыры, эче киткере...» Атасын, анасын, әбисен... берсен дә җәлләмәде, берсен дә калдырмады – сүкте...

## Икенче кәнәфи

Бу маҗараны Гаделҗан үзенең зур уңышсызлыгы дип таныды. Зиннәткә дә үпкәсе булганлыктан, хәбәр бирмичә торды. Шуңа күрә партия хәзинәсен эзләү беразга тынды. Әле күпмегә сузылыр иде икән, көтмәгәндә, Зиннәттән чакыру килде. Тагын бәдрәфтә сөйләшү башланды.

Мәркәзебезнең «Төп театрында» да шундый ук кәнәфи бар икән бит!

Борын астында гына. Монысы 1928 елдан алып 1933 елга кадәр Обкомны җитәкләгән Михаил Осипович Разумов кәнәфие.

– Мөгаен, хәзинә шундадыр?.. – диде Зиннәт, тирән уйга чумып.

Ул бу юлы операция «Б» планын төзеп, эшне Гаделҗансыз, үзе генә башкарырга уйлады. Беренчедән: ничек итеп урындык янына үтеп керергә; икенчедән: аның төзелешен өйрәнергә; өченчедән: ул кайда саклана; дүртенчедән: нинди кораллар белән эш итәргә һәм башка көтелмәгән очракларда нишләргә?..

Эшне фәнни югарылыкта алып барырга кирәк, кырык тапкыр үлчәп, йөз мәртәбә уйлап, мең тапкыр күнегү ясап, тәвәккәллек итәргә кирәк, дигән фикергә килде ул.

Операция җайлы гына ысул белән, ягъни кәнәфине сатып алып башкарылачак. Театрның директорыннан да түгел, режиссёрына да белдертмичә – сәхнә эшчесеннән сатып алып. Акча дигәндә алар теләсә нәрсәне саталар хәзер, шул исәптән әти-әнисен дә... Ярый, аларына кагылмыйк әлегә.

Бу вакытта Гаделҗан исә партия байлыгына кул тыгуны башкачарак хәл итү юлларын эзли иде. Әйе, халык телендә хәзинәләр һәр җитәкченең үзе утырган кәнәфие астында дип чутлана. Халыкка шунысы да ачык: бөтен «Первый»лар тәхеткә үз кәнәфие белән килә, ә инде ирегеннән мәхрүм ителгәч, утыргычын үзе белән алып китә алмый. Ләкин берәү дә аның арт шәрифе астына мөлкәт җыеп ятканын сизми.

Гаделҗан Зиннәтнең тавыш-тынсыз калуына шикләнеп куйды. Ниләр уйлап йөри икән? Аның бу халәтендә ниндидер сер бар. Башланган эш бер кәнәфи белән генә чикләнеп кала алмый. Ләкин ул вакыйгаларны ашыктырмады, шалтыратмады да...

Икенче көнне Гаделҗан, иң беренче эш итеп, Зиннәт янына китте.

– Бик йончыган сыман күренәсең? – дип каршы алды аны дусты.

– Вокзалда кундым, – диде аңа компаньоны, үз хәлен яшермичә.

– Нишләп андый тормышка дучар булдың?

– Институтның дүртенче курсында академический отпуск алдым бер елга, ул икегә сузылды. Аннан соң көндез төзелештә эшләп, кич укулары бик авырга әйләнде. Общагада ятам, тәмам сукбайга әйләндем.

– Барысы да әйбәт булыр. Ни... уку мәсьәләсе! Нәрсә дип укып йөрисең көчәнә-көчәнә, кем инде хәзер биш ел гомерен әрәм итеп, яшьлеген заяга уздырып, институттан диплом алырга йөри? Акчаң бар икән, аны сатып алырга да мөмкин бит. Менә безнең гениальный планыбыз бар. «Первый»ларның хәзинәсен эзләү. Барыбер табачакбыз аны һәм синең дипломлы булырга менә дигән мөмкинлек туа.

Ул сөйли тора, ә Гаделҗанның җаны көя. Егет бит чын диплом алып, белем туплап, менә дигән белгечлеккә омтылган иде.

«Их, әти, синең сүзне тыңласам, ак сакаллы карт була идем! Ә менә хәзер пеләш башлы шулерга әйләнеп барам. Кичерегез!»

– Ферштейн! – дип бүлде аның уйларын Зиннәт.

– Минем башка чарам юк, аңлыйм, – дип, моңсу күзләре белән ул аңа карады.

– Борчылма, укыган булып кыланып йөрүчеләр дә хәзер аны сатып кына

ала. Безнең отделда, шулай итеп, түр башларында, затлы кәнәфиләрдә Алланың кашка тәкәсе кыяфәтендә утыручылар исемлеге бар.

– Мине дә шунда язып куярсызмы?

– Язарбыз, зур түрә булгач... Ә ул сиңа янамый, син талант иясе, үз хезмәтең белән көн күрәсең, тормыш корасың, кеше чутыннан яшәмисең... Менә син безнең бу операцияне – хәзинә эзләүне, үз мәнфәгатьләребезне кайгыртып эшлибез, дип уйлыйсыңдыр. Юк, туган. Тапсак – бу сенсациягә әвереләчәк. Сиңа аның проценты биреләчәк, ә ул өлеш – диплом алырга гына түгел, әсәрләреңне бастырырга да җитәчәк. Турысын әйтсәм, Максим Горький кебек инде син яшәү рәвешең белән – тормыш университетын бетергән кеше. Моның өчен диплом бирмиләр, ләкин мондый тәҗрибәне теләсә кем үти алмый. Әйдә, изге эшкә тотыныйк.

Күңеле белән сизә, аны ниндидер афёрага тарталар. Ләкин Гаделҗан тирәнгә кермәячәк! Бу фикерен ул акылына, намусына салып куйды.

Зиннәт, «Тыкрык» театрындагы кәнәфинең инде реквизит ролен үтәүдән күптәннән туктап, хәзерге вакытта Габәши музеена куелганлыгын ачыклады. Ни өчен ул анда? Чөнки заманында бөек композиторыбыз әлеге кәнәфидә уйланып утырырга яраткан икән. Зиннәт аның шунда икәнлеген үз күзләре белән барып карады. Матур шул, даһилар гына утырырга тиешлеге күренеп тора. Юкка гына обком түрәсенә тәхет ролен үтәмәгәндер – зиннәтле, бизәкле итеп эшләгәннәр. Һәрберсе үз арт ягын кайгырткангадырмы, гомерлек итеп, затлы агачтан ясатканнар. Авыр, күтәрерлек тә түгел. Җитмәсә, тимер аслы.

«Гаделҗансыз актарып булмас, ахрысы, монысын», – дигән нәтиҗәгә килде ул.

Музейда байтак кызыксынып сораштырды Зиннәт әлеге кәнәфи турында. Кемнәргә хезмәт иткән, ремонт-фәлән ясалмаганмы, фәлән-төгән?..

Музей хезмәткәре:

– Нинди ремонт, чурт булсынмыни аңа, әле тагын, ким дигәндә, йөз ел торачак. Гайшә Җиһаншина да утырып сыта алмады аны.

– Ник ул шундый таза идеме? – дигән булды Зиннәт, театр мәсьәләсендә наданлык күрсәткәндәй. Белә инде югыйсә Җиһаншинаның бәдәнен, күргәне бар. Апакай узып киткәндә, сәхнә идәннәре сыгылып кала иде, диләр. Әхтар Хәсәнов та утыргалаган моңа. Менә аның мутлыгыннан шикләнергә була? Чөнки бу кешенең кулы, нәфесе тимәгән бер генә әйбер дә калмагандыр «Тыкрык» театрында. Ничек инде кәнәфине актарырга башы җитмәс?.. Хәер, ул аны өенә генә алып кайтып китәр иде. Нишләп калдырды икән?..

Димәк, реставрация үткәрелмәгән... Кирәклеге – музейга куярлык кына калган...

Кинәт аның йөрәге жу итте. Әле бит бу кәнәфидә атаклы Маннур Шәрипов та байтак еллар утырган кеше. Ах, менә монысыннан бернәрсә читтә калмас...

Зиннәтнең йөзенә чыккан борчылуны музей хезмәткәре дә сизеп алды. Маңгаена бәреп чыккан салкын тир бөрчекләрен кем күрмәс. Ул:

– Гафу итегез, сез авырып киттегез мәллә? – диде.

– Юк, юк, хафаланмагыз, монда бераз һава тынчурак бугай, – дигән

булды, гәрчә музей бүлмәсендәге температура тиешле шартларда тотылганын белсә дә. – Мине бернәрсә кызыксындыра, бу кәнәфидә Шәрипов та утыргандыр?..

– Әлбәттә...

Зиннәт үзе дә сизмәстән, кәнәфинең астын чүмәлтеп карады. Барысы да тәртиптә бугай, кайчандыр, кемнеңдер ерткыч куллары нәрсәдер кыланганга охшамаган, кадаклары да борынгы – җизме – шәхси осталар эше. Күңеле тынычланганга күрәдер:

– Шәрипов бүлмәсен бизәгәндер, тик утыра торган кеше түгел. Менә шул ышкый-шомарта, кәнәфине тишмәде микән дип каравым, – диде.

Музей хезмәткәре, Шәриповның нинди кеше икәнлеген бик яхшы белгәнгә күрә, рәхәтләнеп көлде. Әмма кисәк туктады: әллә үзендә әдәпсезлек сизепме, әллә театр директоры белән булган җылы мөгамәләләрен искә төшерде. Шуңадырмы:

– Ну, барыбер әйбәт кеше иде ул, яманлап сөйләрлек түгел.

Аның сүзләреннән соң Зиннәт бу миссиясен тәмамларга уйлады. Эченнән генә: «Гаделҗанны табарга кирәк, Гаделҗанны...» – дип, музейдан чыгып китте.

Алар кичен Татар ашлары ашханәсендә очраштылар. Соң булганга күрәдер, ул инде ябылырга тора иде. Сүзне кыска тоттылар. Зиннәт эшнең асылын сөйләде, план «В» төзеделәр дә, операция көнен билгеләп тормадылар, җае чыккач үтәрсең дигән ризалык белән таралдылар. Зиннәт – фатирына, Гаделҗан Язилә сөйләшкән Шоссейная урамындагы тулай торактагы 14 нче бүлмәгә. Тугыз квадрат метр дигән иде мәйданы – бик җитә инде берүзенә. Шәп бит!

Зиннәт Гаделҗанны музей ишеге төбендә көтеп алды. Сөйләшү буенча, ул пөхтә эш киемендә килгән. Күп теленә салынмаска кушылганга, хәзер үк эндәшми. Кулында осталар гына йөртә эш кораллары сандыгы, анда ачкыч-боргыч, фәлән-фәсмәтәннәре салынгандыр инде, бәлки – бер сүз белән әйткәндә, үз эшенең остасы икәнлеге күренеп тора. Киләселәре алдан ук хәбәр ителеп куелганга аларны баскыч төбенә үк чыгып, ике кеше каршы алды. Зиннәткә аның берсе таныш иде – ул музей хезмәткәре, икенчесе, күрәсең, аның начальнигы – дөресрәге, директорыдыр...

Сәламләшүдән соң хезмәткәр таныштыра башлады:

– Безнең музей директоры, республикабызның атказанган мәдәният хезмәткәре – Сальмушев, – диде.

– Фәрхәтов, – дип, кулын бирде Гаделҗан директорга, Зиннәт белән килешеп әйтелергә тиешле фамилияне аңа күрсәтеп. Дусты, башын селкеп куйды, бу «дөрес әйттең» дигәнне аңлатты. Сальмушевның эчке халәте һәм эш итү методы исем-фамилиясенә тәңгәл килүен Зиннәт белән Гаделҗан шундук сизеп алдылар. Оста, хәтта эше пешкәндәй, сандыгын баскычка куеп, кулларын уды. Әңгәмәне Зиннәт дәвам итте.

– Мин теге килүемдә, сездәге кәнәфине күреп, аның кыяфәтенә игътибар иттем. Дөресрәге, борчылып, ярдәм кулы сузарга булдым. Чүтеки, ул кәнәфидә бөек кешебез утырган, һәм илебезгә, һәм халкыбызга, һәм сәнгатебезгә зур хезмәт күрсәткән, әсәрләр язган, театраль тамашаларны классик музыка белән баеткан.

Гаделҗан Зиннәтнең белер-белмәс терминнар кулланып сөйләвенә сокланып карады. Кайвакытта аның көчле интонацияле сүзләренә ияреп, акцентлар ясаган сыман, кулларын болгап, дирижёрлык итеп торды. Бу халәтендә аңа караштыргалап алган шефы:

– Һәртөрле музыка уен коралларын көйләү һәм төзәтү остасы! – дип куйган булды. Тик үз исемен оныткандай, әллә башка берәр фамилия әйтергәме дип, пауза ясап торганда, Гаделҗан башына ни килә, шуны ярып салды:

– Чүрилин!

Ярый әле, Пановкин, димәде. Төрмәле авылыннан икән бу дип, шиккә калырлар иде.

– Сезнең документларыгыз бармы соң, кайсы оешмадан килүегез турында? – дип, директор сөйләшүне җитди тонга күчерде.

– Ничек булмасын инде? – дип, Зиннәт Фәрхәтов исеменә язылган «Ремонтная мастерская «Заря» дигән таныклык чыгарып күрсәтте – «Заречье»да ул оешма.

«Молодец та инде бу Зиннәт!» – дип сөенеп куйды эченнән Гаделҗан, чыгып качарга җиткән җиреннән.

Зиннәт музей телефоныннан шалтыратырга тотынды:

– Әлү, Илшат, «Газел»еңне музейга тарттыр!

Тегесе янәшәдәге урамда гына булганга, тиз килеп җитте. Кәнәфине Гаделҗан белән шофёр күтәреп, машинага салдылар. Гаделҗан Илшат янәшәсендә, Зиннәт – үзенең «девятка»сында, музей хезмәткәрләре баскычта – саубуллаштылар.

Алдан сөйләшү буенча алар кәнәфине җиһаз рәвешендә Гаделҗанның тулай торактагы бүлмәсенә алып кайтырга тиешләр иде һәм шулай иттеләр дә. Бик җайлы вакыт иде – тулай торакның вахтёры да каядыр киткән чак. Әле эш вакыты, күпләр кайтмаган. Илшатны озатып, кәнәфине тиз генә бүлмәгә керттеләр дә, иркенләп, затлы материясен тарттырган кадакларын суырып, эчен актардылар. Ләкин күңелләрен җылытырлык бернәрсә дә юклыгын күргәч, уфтанып алдылар һәм Зиннәт: «Тагын тугыз кәнәфи генә калды, шанслары арта», – дигән сүзен тезис итеп, бер дә борчылмаган кыяфәттә саубуллашты.

– Әйтергә онытып торам, иртәгә Илшат килер, син моны әйбәтләп, яңадан корып куй, урынына илтеп куярсыз. Ни... кире кайтару сәбәбен: «Заря» мастерское ябыла икән, хәзер бернинди дә заказ кабул итмиләр», – диген. Гафу үтен!

## Өченче кәнәфи

Гаделҗанның уенда яңа план өлгерде. Нигә әле ул Зиннәтне борчып йөри. Аның бит мондый кәсепкә үзенең дә маһирлыгы бар. Мондый кәнәфиләр Мәркәзнең төрле оешма, музей, театр, комиссион кибетләрендә еш очрый. Чамадан тыш баеган түрәләрнең коттеджларында да булырга мөмкин. Хәер, андыйлар иске кәнәфиләргә кызыкмаслар, ник дисәң, хәзерге байлар алтын унитазлар белән мавыгалар. Димәк, партия кәнәфиләре бары тик оешмаларның подвалларында яки картлар йортында, театрлар сәхнәсе артында һәм дә пенсиядәге элекке җитәкчеләрнең бакчаларында урын тапкандыр.

Уйлана торгач, күңелендә бер вакыйга ачыла башлады. «Кайда булды соң әле ул? Анда биючеләр бар иде... Әйе, әйе... Биючеләр. Ни сәбәп белән барылды?.. Җыр һәм бию ансамблендә күрде бит ул андый кәнәфине... Күптән инде... Аның матурлыгы күңелендә сеңеп калган. Зур гына зал: диварларында көзгеләр; тотынып, бию осталыгын шомарту өчен куелган борыслар, бер кырыйда шул – кәнәфи. «Бер, ике, өч, и, бер, ике, өч...» – дип кычкырып утыручысы, хореографларыдыр инде, кәнәфидә килеш, идәндә аякларын тыпырдата. Янәшәсендә баянчысы, бию тактына туры китереп, бөгелә-сыгыла уйный.

Ял итәргә туктагач, биючеләре бер кызык хәл сөйләделәр: ул урында әле элек шушы кәнәфи белән зур немец рояле торган булган. Байтак еллар үткән инде бу вакыйгага.

– Без тумаган чакларда, – дип көлдереп куйды шунда бер биючесе.

– Менә шулай, репетиция барган чакта залга комбинезон кигән, берсе кулына мембрано, икенчесе – ниндидер моңарчы күрелмәгән кораллар тоткан (пианино көйли торган әйбердер инде) кешеләр килеп кергән.

– Дуслар, сезне беразга эштән бүлдерергә мөмкинме? – дип әйткәннәр, ди. Рояль клавишаларына баскалап караганнан соң берсе:

– Ах, нинди тузган инструмент!.. – дип, чыраен сыткан.

Егетләр боларның кайдан килгәнен сораганнар. Икесе дә, кесәләреннән чыгарып, документларын күрсәткән. «Маркиз шәһәре музыка фабрикасы» дигән язуын күргәч, биючеләр ачылып ук киткәннәр.

– Инде ул күптән ватык килеш тора, ләкин безнең пианист анда бик матур уйный, – дигәннәр биючеләр.

Осталар рояльне урыныннан кымшата башлаган.

– Остаханәгә илтмичә булмас, – дип, өстен ачып, астында үрмәләп йөргәч, егетләр үзләре күтәреп, тегеләрнең махсус алып килгән, бортларын ачып әзерләп куелган машиналарына чыгарып озатканнар.

Артларыннан: «Бер айдан соң алып килербез», – дигән сүзләре генә яңгырап калган.

Менә, утызлап ел үткән, әле хәзер дә хәбәре юк шул рояльнең. Мәркәзендә бердәнбер иң шәп, кыйммәтле рояль булган икән. Очкан! Канатланган!..

Шушы хәлне искә төшерде Гаделҗан. Ә инде хәзер үзе күргән, теге рояль янында торган кәнәфинең язмышы ничек икән, исән микән? Һаман үз ролен үтиме? Биючеләргә күнегү ясатучы пианистлары яки балетмейстеры шул кәнәфинең рәхәтен күрәме? Гаделҗан шундук, ашыгыч карарга килде.

– Барып кайтырга кирәк!

План «В». Каядыр реставрациягә дигән булып алып китүләр бу очракта эшләмәячәк. Нишләргә? «Уйла, Гаделҗан, – дип, ул йодрыгы белән маңгаен төеп куйды. – Уйла!»

Озак хәсрәтләнмичә генә, бер максатка тукталды – Гаделҗан шунда вахтёр булып урнашачак. Әйе, әйе! Юкка күзе төшмәгән иде бит аның стенадагы «Җыр һәм бию» ансамбленең «Үткен» урамы, 2 нче йорт адресы буенча шушы бинасына вахтёр кирәклеге турындагы белдерүгә. Һәм шул ук төнне кәнәфине актаргач югалачак. Тагын бер иске хезмәт кенәгәсе бар бит аның. Кәнәфинең астын иплəп кенә ача, иплəп кенә яңадан ябып куя.

Әле, бәлки, аның монысында да бернинди өмет юктыр. Чүпрәк-чапрак, мамык... Китәргә кирәк булгач, эшкә юри исереп килгән була да, үзләре куачак. Әгәр кәнәфинең эче шатлык-куаныч китерсә, һәй, дүрт ягың кыйбла!

Тик бернәрсә аны борчыды – әгәр берәрсе таныса?.. Хәер, аны биюче халкы белми лә. Әйе, шагыйрь ул... Концертлар алып баргалады. Һәвәскәрләр белән генә... Кайчагында популярлык комачаулый шул... Әй, лә, танысалар ни?.. Ул бит әле бернинди начарлык эшләмәгән һәм эшләмәячәк тә. Бары тик партия акчасын гына эзли... Югалмый калганын гына... Тапса, бәлки, халыкка өләшергә уйлар... Үзе дә белми бит әле аның белән нишләсен... Менә табар – хөкүмәткә тапшырыр... Аны мактап гәҗитләргә язарлар. Әйбәт даны таралыр. Күккә чөеп мактарлар. Намуслы икән дип, җаваплы эшкә билгеләрләр. Начальник булыр. Аннан соң – депутат. Шулай, үсә-үсә, министр, президент. Гаделҗан, болай уйлап утырганын берәрсе сизмәде микән дип, як-ягына каранды. Юк икән. Шуны белгәч, үз-үзеннән көлеп куйды. «Каян күргәнең бар намуслы кешенең түрә булганын? Урламаганның акчасызның министр яки депутатлыкка хәтле күтәрелгәнен. Ул үзенең концертларда тамашачы каршында әйтә торган сүзләрен исенә төшерде. Ничек башлый әле?..

– Без бүген сезгә, хөрмәтле тамашачылар, зыялы концерт куябыз. Андый концерт ничек була дисезме? Әби җаным, зыялы кеше нинди кеше ул? Ул, әйе, тыйнак, әдәпле, белемле, әйе, акыллы, укымышлы, мәрхәмәтле, тагын, тагын – кешелекле һәм тагын?.. Әйе, ришвәт алмый торган... Әйе – бирми торганы да... Менә синең берәрсенә ришвәт биргәнең бармы? Юк, дисең. Дөрес. Чөнки синең ришвәт бирергә акчаң юк, шулай бит? Шулай. Сиңа да бирмиләр... Нигә? Чөнки сиңа ни өчен бирсеннәр аны? Син бит аның өчен бернәрсә дә эшли алмыйсың, синнән файда юк. Аннан соң алда әйтеп үткәннәрдән: син тыйнак – догада, намазда, әхлаклы – сүгенмисең, кеше җәберләмисең, гөнаһка батмыйсың; әдәпле – кычкырып та сөйләшмисең бит; синең йөзең нурлы... Нишләп шулай? Чөнки син гәҗит, китап укыйсың; театр карыйсың, музыка тыңлыйсың, җырлыйсың һәм башкалар... Димәк, син зыялы. Мин дә шулай, шундый. Мин тамашачыны хөрмәт итеп, яратып чыгыш ясыйм. Концерт бәһасен бары тик йөз тәңкә дип куйдым. Акчагызга журналлар өләшәм һәрберегезгә йөзәр сумлык. Яшәешебез турында яттан шигыр, хикәяләр сөйлим, тирән эчтәлекле җырлар җырлыйбыз. Фонограмма түгел – ялганны җенем сөйми. Сез бит концертка ялган акча түләп кермисез, концертлар да хәләл булырга тиеш – чын тавышың белән үзең җырларга тиешсең... Димәк, безнең чыгышларыбыз да зыялы булып чыга. Ә түрәләрне әйтәм, зыялымы алар? Нәрсә дисең, апа?.. Юк, дисеңме? Дөрес, чөнки алар ришвәт алмыйча яши алмыйлар. Китап укымыйлар, концертка йөрмиләр. Менә арагызда берәр түрә дип әйтерлек кеше бармы? Юк шул. Соң, зыялы булып чыгамы алар?

Зал гөж килә.

– Юк, юк, юк! Әйдә, җырлый башла, җаный!

– Шулай итеп, «Зыялы концертыбыз»ны башлыйбыз, җәмәгать!

Тормыш безне сыйпамады,  
Иркәләп үстермәде,

Күпме типкедә йөрсәк тә,
Үтереп бетермәде.
Эх, алмагачлары,
Татар халык ашларыннан
Хәрәм чыга башлады.

Гаделҗан иртәгесен, ялган паспорт һәм хезмәт кенәгәсен тотып, изге гамәлләр кылырга ансамбльгә килде. Кадрлар бүлегенә кереп:

– Сезгә вахтёрлар кирәк икән, – дип, үтә итагатьлек белән сүзен башлады.

– Документларыгыз үзегез беләнме?

– Әйе, шушылар җитәме? – дигән җөмләсен ул бигрәк тә назлырак әйтергә тырышты. Чөнки кадрлар бүлеге начальнигының чибәрлеге аның уен бутый башлаган иде. Кәнәфи ботарлау эше онытылып торды. Эченнән генә: «Бу кызыкай янында гомер буе бөтерелеп йөрсәң дә җәл түгел...» – дигән фикергә килгән иде. Бармагындагы балдагын күргәч кенә, гөнаһлы хисләреннән айныды. Гаделҗанның кызны ашардай булып карап торуын чибәркәй дә сизде булса кирәк – битенә алсулык йөгерде, иреннәренең бүртебрәк киткәне күренде.

Ниһаять, ул Гаделҗанның карашыннан арынып:

– Бүген үк төнге сменага килә алмассызмы? Вахтёрыбыз Нәгыймә апа инде өченче төнен ялсыз-нисез эшли, – диде.

Егет, кесәләрен капшап, документларын эзләүдән туктап калды. Башыннан зеңгелдәп, бер уй йөгереп узды. Шәп фикер әйтте бит, чибәркәй...

– Карагыз әле, документларымны таба алмыйм бит, өйдә калдылар микәнни, югыйсә кесәмә тыккан идем кебек, – диде егет, аптыраган кыяфәт чыгарып.

– Зыян юк, борчылмагыз! Икенче сменага алып килерсез, тик бүген, зинһар, булышыгыз инде?

– Әлбәттә, ышанычыгызны аклармын.

– Эшкә соңга кала күрмәгез! – диде дә чибәркәй урамга ашыкты. Героебыз вахтада утырган Нәгыймә апага:

– Кичке 6га, как штык! – дип, шәһәргә чыгып шылды.

Тик менә ул кәнәфи исән микән соң әлегә хәтле?.. Алдан тикшереп йөрүе шик тудырмасын өчен эзләмәгән иде шул аны. Юк, андый зиннәтле нәрсәне чыгарып ташламаслар, биреп тә җибәрмәсләр... Чүтеки, данлыклы шәхесләр утырган кәнәфиләр алай тиз генә югалмыйлар. Бәлки, музейлары бардыр, шундадыр? Кем белгән? Бөтен бүлмә ачкычлары аның карамагында була бит. Шул уй аңа тынычлык өстәде.

Кичен, смена алыштырырга килгәч, Нәгыймә апаның беренче сүзе шул булды:

– Син җүнләп урнаштыңмы соң?

– Ничек инде башкача булсын, Нәгыймә апа. Кадрлар бүлеге начальнигы белән сөйләшкәч, эшкә алынган исәпләнәм түгелме соң?

– Документларыңны тапшырдыңмы?

– Иртәгә китерәм. Нигә син миңа каныгасың?..

– Каныкмыйм. Матри, йоклыйсы булма!

– Каравылда йокламыйлар инде, апа, бар кайт, тыныч бул!

Ул бер китә, бер килә, арлы-бирле йөри торгач, ниһаять, китеп барды.

Гаделҗан иркенәеп калды. Кырык тапкыр бер фикергә килә бит инде – гөнаһлы эш эшләми, кәнәфине табып, өстен ертмыйча, астыннан гына ачып, эчендә нәрсә бар икәнен генә карый. Әйбере булса-булмаса да ябып куя. Кыскычы, боргычы, каергычы бар: сындырмый да, ватмый-җимерми дә.

– «Операция»не башларга кирәк», – диде дә бүлмәләр буйлап эзләнергә тотынды. Һәр кергән-чыккан җиреннән уңышсызлыкка очрау аның «җенен» чыгара башлады. Бармы икән соң ул? Тапмаса, җүләр, тинтәк, ахмак булып чыга түгелме? Подвалга төште – юк, аптырап, өметсезләнеп, чардак ачкычын табып, шунда менде. Ни күзләре белән күрсен – каршысында тора. Караңгырак, ләкин тирә-якка нурлар сибә түгелме?! И җаныкаем, исәнме-саумы? Ул, инде күптән искә алмаган бисмилласын укып, кәнәфине түбен өскә әйләндерде. Күптәнге икән. Кем утырган, кайсы «Первый»? Мөгаен, сугышка хәтлеседер. Шушыңа утырып торган җиреннән алып китteләр микән атарга?.. Гаделҗан, ул еллардагы рәхимсезлекләрне укып белгән хәтлесен искә төшереп, келәшчә белән кадакларын суыра башлады. Кулдан ясалган кадаклар икән. Шушы кәнәфи өчен генәдер. Тимер түгел, җиз, ахрысы, болар да. Кагылган такталары кипшеп какшаган инде, тиз суырылалар. Аслык җайлы ачылды. Буш. Ниндидер язуы бар: «Лепа Альфред Карлович» октябрь, 1933.

– Монысында да булмады, – дип, авыр сулап куйды Гаделҗан. – Иртәгә Нәгыймә апа килгәч, тыныч кына югалырга туры килер.

Һәм шулай итте, матур гына кизү торуын тапшырды да, ягымлы елмаюын апакайга бүләк итеп, Мәркәз үзәгенә юл тотты. Алда яңа бурычлар тора...

## Дүртенче кәнәфи

Партия җитәкчеләренең хәзинәсен эзләү Гаделҗан өчен комарлы уенга әверелде. Ул эченнән генә: «Бар бит инде ул, бар бит!» – дип кабатлап йөри башлады. Ләкин кайда, кайсы кәнәфи астында?.. Астындамы-түгелме?.. Әллә берәр җиргә күмеп куелганмы?.. Алай булырга тиеш түгел! Үзе уйлаганча, бәбкә чыгара торган каз кебек, оясында, димәк, кәнәфидә!.. Димәк, әлегә кадәр юнәлештә эзләнүләрне дәвам итәргә кирәк. Филармониянең музее бар, кайсы гына директорын алма, кәнәфиләрен озак саклап утыралар, әле пенсиягә чыккач та китәргә уйламыйлар.

Ул Зиннәткә шалтыратты. Нигә, эшләп ашасын!.. Барыбер аннан котылып булмас... Хәзинә табылган очракта, аның эзәрлекләвеннән арыныр мөмкинлек күренми, хәзердән үк һәр адымын тикшереп тора, ахрысы. Ахмаклар дөньяда күп күбен, ләкин бу андый түгел... Компаньонлык – дуслык дигән мәгънәдән ерак тора, байлыкка кагылганда...

– Нәрсә, берәр ни таптыңмы? – диюдән башлады Зиннәт сүзен, ачулырак рәвештә, озаграк шалтыратмый торуга үпкәләгән сыман.

– Нигә шулай каты сөйләшәсең, берәр начальнигың кәефеңне бозды мәллә? – дип җавап кайтарды аңа Гаделҗан, ризасызлык белдереп. – Әллә рәхәт дип белдеңме, мылтык көпшәсе астында йөрүләр...

– Шундый ук мажарага эләктеңмени?

– Юк. Пистолетлы сакчыны эчертү рәхәт нәрсә дип уйлыйсыңмы син? Ул бит җүләр түгел. Атты җибәрде. Вәссәлам!

– Ярар инде, гафу! Нәтиҗә нинди?

– «Алемасов кәнәфие» дип язылган сүздән башка нәрсә юк иде.

– Чынмы? Алдамыйсыңмы?

– Мин бит инде ул алагаем урындыкның бернәрсәсе дә юк икәнен күрсәтер өчен сиңа күтәреп бара алмыйм...

– Алга таба нинди планнар?

– Филармония директорының кәнәфиен белештер әле. Берәүләрдән колак очыма аның шунда барлыгы турында хәбәр эленеп калды.

– Белешермен. Телефонлырак җирдә, эшеңдә дип әйтүем, утыр!

Болай шикләнерлек сәбәп юк бугай бу дускайда, дип уйлап утырды Зиннәт, бераздан ул киткәч. Тапкан булса, күптән чит илгә ычкынган булыр иде.

Аның уйлары филармония тарафына күчте. «Кем соң әле анда хәзер директор? Әнәс Зөлфәтович Сабин бугай. Биюче. Шалтыратыйм әле».

Телефоннар китабын озак кына актарганнан соң, ниһаять, тапты ул аның номерын. Сүзен нәрсәдән башлаячагын дикъкать белән исәпләгәннән соң, «Әлү!» тавышын ишетүгә:

– Әнәс Зөлфәтович! Нихәлләрдә эшләп ятасыз?! – диде дә, сынаулы пауза ясап, җавап көтте.

– Кем әле бу, тавышыгыз таныш та кебек? – дигән җавап ишетелде.

– Әллә кем түгел, Төзелеш министрлыгында эшләүче бер урынбасар гына. Фәрхәтов минем фамилиям. Шулай дип кенә эндәшегез.

– Иптәш Фәрхәтов, сезнең кебекләр безгә бик кирәкле затлар. Ни әйтсәң дә, төзелеш тармагы – ремонт, фәлән-фәсмәтән...

– Шулай, шулай, шуның өчен безне бик якын итәләр...

– Берәр йомышыгыз бар иде мәллә? Концерт, билет, чакыру кәгазе?..

– Комачауламас иде, әлбәттә... Илһам, Әлфия кебек зур артистлар чыгышын бик яратып карыйбыз.

– Килегез, алып китәрсез.

– Бу арада эшләрем тыгыз. Минем ярдәмчем килеп алса, кимсенмәссезме?..

– Юк, әлбәттә.

– Мин Фәрхәтовтан, дияр, яме! Килештекме?

– Килештек.

– Сүземне тәмамлап, шуны әйтәсем килә, Әнәс Зөлфәтович, эшегезне бик яхшы башкарасыз, гел мактауда, филармония гөрли, тырыш хезмәтегезнең нәтиҗәсе хөрмәткә лаек, зур исемнәр алдыгыз – озак еллар утырган кәнәфиегез сезгә хыянәт итмәсен!

– Рәхмәт, рәхмәт! Ләкин мин ул кәнәфине, әле күптән түгел генә музеебызга тапшырдым. Миңа хәтле утырган бөек шәхесләребезнең истәлеге булып һәм дә экспонат рәвешендә халкыбызга хезмәт итсен дип.

– Реставрация кирәк түгел идеме?

– Кирәгрәк, кәнишне!

– Анысын да решать итәрбез, яме! Килештекме?

– Килештек.

– Минем ярдәмче килер...

– Эшләр җырлап бара бит, – дип куйды ул үзалдына. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар» диме әле халык?..

Зиннәт бу сөйләшү-килешүне минуты-сәгате белән Гаделҗанга җиткерде. Гаделҗан Сабинның кем икәнен белгәнгә һәм шул ук вакытта ул да аның белән таныш булуына борчылып, ничек бу хәлдән җиңел генә чыгу юлларын эзләргә кереште. Ярар, эш болайга киткәч, әйтер, хәзер ул шул министрлыкта Фәрхәтовның хуҗалык эшләре буенча ярдәмче ролен үтәр. Башта чакыру кәгазьләрен алып кайтыр, аннан соң күз күрер. «Алдан баш ватып утырмыйм әле», – дип, төгәллек кертте ул уйларына.

Аның күз алдына музейдагы «ревизия» ясалачак кәнәфигә утырган Илһам Шакиров килеп басты. Филармониянең хәзерге вакытта сәнгать җитәкчесе вазифаларын үтәгән бөек җырчыга аерым бүлмә табылмаганлыктан, ул шунда эш почмагы тапкандыр кебек тоелды аңа. Кеше өчен кабинет юк, ә менә кәнәфигә бар. Димәк, Шакиров шуңа утырырга тиеш – икесенә бер урын – бер атуда ике куян! Шәп бит!

Сабинның андый «куяннар»ны күп атканы бар. Мәсәлән, ул училище гына тәмамлаган артист, ничек итеп директор була алган соң? Гаделҗанның бу турыда сөйләгәннәрен күп ишеткәне булды. Сабинга, читтән торып, мәдәният институтында укырга киңәш бирәләр. «Синең кебек директорга укып йөрисе дә юк», – диләр. Концертка чакыру билетлары биреп, зачёткага билге генә куйдырып утырышлы икән. Тора-бара кабинетына килгән педагогларны, профессорларны күрүче кешеләр дә мондый фактларны дәлилләп торганнар. Шундый ысул белән югары белемле булган ул түрә.

Хәер, кем аны хәзер шулай итми? Акчасы булганнар да укып тормыйлар бу заманда. Кул кулны, ике кул битне юа торган чаклар.

Уйлана торгач, Гаделҗанның исенә монда урынбасар булып эшләгән танышы Хәмизулла килеп төште. Концертлар буенча җаваплы иде ул. Эш өчен дип, ватылгалап алгалый торган бер «Жигули» да биргәннәр иде аңа. Иң зур вазифасы шул машинаны гел юып, министр урынбасары Лия Саваповнаны эшенә алып килү һәм өенә илтеп кую булды. Әлбәттә, аны йөртер өчен яшь кенә шофёр дә билгеләделәр. Менә шул эш белән мәш килә иде аның танышы: машина төзек һәм шофёры аек йөрсен. Кайчагында, Сабин командировкага киткәндә, Хәмизуллага җаваплы эш тә йөкләнә – документына печать кирәк кешегә тамга сугып җибәрә. Ул шушы вазифаны өнәп бетерми башлаган. Нигә дисәң, үтенече төшкәннәр мәнфәгатьләрен үтәгәнгә хәтле теленә салынып, бик ягымлы итеп сөйләшәләр дә, печать суккач, чыгып шылалар. Синең кирәгең бетә.

Озак эшләмәде, китте ул аннан.

Гаделҗан җырлаштыргаласа да, филармониягә килмәде. Хәер, бервакыт монда җырчылар кабул итү конкурсында катнашкан иде. Биш урынга җитмешләп гариза бирелгән булып чыкты. Илһам Шакировның комиссия рәисе икәнен белгәч, күпләр каушады. Сабинов та шунда тыңлап утырды, җыр жанрында белгеч сыман. Югыйсә биюен дә ритмга аркылы-торкылы китереп, бутап бетерә иде бит. Ә монда җырчыларга тыкшынып утыра, берни белмәгән башы белән. Иң начар җырчыны мактый, янәмәсе, тавышы әче. Әче булгач, көчле икән инде аныңча.

Җитмештән икесен генә алган Шакиров. Шуннан соң Гаделҗан профессиональ җырчылыкка тыкшынмады.

Ул менә шундый уйлар белән филармония коридорына килеп керде.

Кемдер репетиция ясый. Маликов, ахрысы – тыны бетмәс җан, озак суза... Ибушев микән – чишмә чылтырата, кайдадыр Илһам күнегү ясый. Тавышында – урман шавы, дәрья чайкалышы... Фәридун да монда эшли микәнни?..

Иделләре, Иделләре...
Иделләре, күлләре...

Аның репертуарында иң матур җыр шул инде. Менә хәзер үзен күреп: «Теге төшен болай җырлыйсың, бу җирен тегеләй...» – дисәң, «Үзең дә шикәр түгел...» – диячәк.

Гаделҗан Илһам тавышы яңгыраган бүлмәне эзләп китте. Икенче кат, «Музей» дигән бүлмәдән ишетелә икән. Шакымыйча озак торды, комачауларга ярамый, яратмас...

Ниһаять, бераздан даһиебыз туктады. Күнегү генә ясаса да, җанны җылыта шуның моңлы тавышы!

Гаделҗан, кыюлыгын җыеп, әкрен генә ишекне ачты.

– Нәрсә, кер, нигә басып каттың? – дип сүз башлады бөегебез.

– Илһам абый, эшегезне бүлдем, ахрысы?

– Юк, юк. Инде тәмамладым. Менә син дөрес әйтәсең, энекәш, эшеңне бүлдем, дип. Җырлауны эшкә санныйсың. Кайберәүләр бит аны уенга, ялга гына тыңлыйлар. Имеш, җырлауны алар да җырлый, менә кайдадыр эшләргә кирәк, диләр. Заводтамы, колхоздамы... Җырчы белән җырлаучыны бутыйлар. Сиңа рәхмәт, эшеңнән бүлдем, дисең. Бүлмәдең, инде ардым. Бүгенгә җитәр. Җырларга өйрәнү зур көч сорый, түземлек һәм даимилек. Йә, җитәр бу турыда. Ни йомыш?

– Мин, Илһам абый, үз эшем белән. Менә бу синең яндагы тәхетне...

– Кызык әйттең, тәхет, дидең... Тәхеттә патшалар гына утыра, ә мин кем? Җырчы гына...

– Син утырган һәр урындык үзен тәхет дип чутласын, Илһам абый!

– Ай, зурладың, энекәш! Урындыкны зурладың. Ә югыйсә моңа миңа хәтле җыен әтрәк-әләм утыргандыр.

– Алай ук димәгез инде...

– Гафу, бәлки, син дөрестер, бәлки, миндер. Үзең кем буласың?

– Мин менә шундый кәнәфиләргә реставрация ясаучыларның берсе.

– Ай, әйбәт булыр иде бу, энекәш. Яңартып алып килсәң, минем күңелем сафланып киткән кебек булыр иде.

– Шулай дим мин дә. Синең өчен махсус эшләнгән яңа кәнәфи була түгелме соң инде?

– Хәзер алып китәсеңме?

– Юк, иртәгә.

– Ярар. Мин монда булмасам да, алып китәрсез. Директорга әйтеп куярмын, минем өчен генә булганга, түләүсез реставрация ясарга бер егет... ничек әле исемең?..

– Гаделҗан.

– Исемеңне онытырлык түгел, вахтёр янына чыгарып куярлар «тәхет»не, – дип тынычланды.

– Иң элек ниндирәк ремонт-реставрация кирәклеген төгәл белү өчен музеегызның бер почмагында тикшереп карыйм әле, риза булсагыз.

– Карагыз, кара. Мин беразга югалып торам, яме!

Илһам Шакировка ишек ачып, бер адәм баш әйдәде. Ул да, ым кагып, хәзер дигәндәй, кулын күтәрде дә чыгып китте.

Гаделҗан, музей кәнәфиенең астын өскә әйләндереп, келәшчә белән боргычын кесәсеннән чыгарып, чираттагы «операциясен» үтәргә керештe. Кулы остарган инде. Минут эчендә утыргыч төбе ачылып та китте, анда бу юлысы менә мондый сүзләр язып ябыштырылган кәгазь күренде. «Муратов Зиннат Ибятович (28 дек. 1943 г. – 28 дек. 1957 г.)». «Әйе, бу кәнәфидә обком секретаре булып татар кешесе дә утырган икән», – дип куйды ул үз-үзенә. Мондый утыргычларны бүсеп, Татарстан җитәкчеләре тарихына мәгълүматлар өстәргә була икән, – дигән канәгатьлек хисе өстәде Гаделҗан. – Партия алтыннарын эзләү буенча диссертация язсаң да комачауламас иде! – дип тә куйды.

Шунда ул тиз генә кәнәфинең артын кабат кадаклап та куйды. Таныш-белеш күреп, мәшәкатьләр, маҗаралар чыгарганчы дип, Илһам абзый кергәнче, музейдан чыгып шылды. Хәзер аңа Зиннәткә хисап тотасы калды. Әмма кәнәфигә, чыннан да, реставрация ясатуны үзенә бурыч итеп куйды. Әлбәттә, Зиннәт аркылы, аның көче белән. Ул эшләгән оешманың Бөегебез Илһам Шакиров кәнәфиенә ремонт эшләтүе зур абруй гына саналачак!

## Бишенче кәнәфи

Зиннәткә әлеге хәбәр көтелмәгән хәл түгел иде инде. Гаделҗанның хикәясен тыңлап бетермичә үк, ул яңа йөкләмә турында сөйли башлады. Ачулы тавыш белән, кисәтебрәк. Әлбәттә, мондый тондагы киңәш-өйрәтүне Гаделҗан «колагына да элми» инде. «Ярый, начальник булып кылансын минем алда, тагын үз араларында кемгә боерык бирә ала ул», – дип, тыныч кына йомды аның кәпрәюен.

Кыскасы, ул театр-студиягә барган. Директоры белән бер кызны шунда урнаштыру турында сөйләшеп утырганда, кәнәфиенә күзе төшкән. «Шул – партия казнасының бер өлеше тутырылган кресло түгел микән?» дигән шиге барлыкка килгән.

Аны бит инде, филармониядәге кебек, реставрация дигән булып актартып булмый. Андый хәлләр турында шәһәрдә күп сөйлиләрдер. Килеп керүең булыр, сүз кузгатырга өлгермәссең, һап, кулыңнан тотарлар да богау салып куярлар. Монда башкача эшләргә кирәк, башкача. Әмер биреп утырырга җайлы ул. «Бар, кара, тикшер, тап!» Ә ничек? Әй лә, Фәрхәтов уйласын! Үзе җаен тапсын, үзе барсын! Анда мин күренеп йөрмим инде, йә танырлар...

Телефоннан шундый шалтыратып сөйләшеп фикерләшкәннән соң берничә көн үтте. Гаделҗанның икеләнеп йөрүен сизгән кебек Зиннәт яңадан ул яшәгән тулай торакның номерын җыйды.

– Әлү, апакай, Гаделҗан дигән кешене телефонга чакырыгыз әле, кесәсендәгесен алмый, – диде вахтёрга.

Озак көтәргә туры килмәде – өйдә икән.

– Карале, нишлибез?..

Комбинатор турыдан бәрде:

– Ни... монысын үзең генә башкарып чык инде. Анда мине таныйлар, күзләренә чалынмаска иде.

– Киңәшләшү өчен күрешеп алыйк, дим.

– Алайса ярар.

– «Маяк» ресторанына кил!

– Нигә шулхәтле ихтирам күрсәтәсең миңа? Ярамаганмыни авыл хуҗалыгы институтының очсызлы, әмма күләмле порцияләр ашата торган ашханәсендә очрашырга?

– Юк, мәсьәлә катлаулы һәм җаваплы. Уйлап кил, нинди фикерләрең бар, синең бит инде ул объекттагы керү-чыгу урыннарын яхшы беләсең.

– Анысы шулай.

Гаделҗанның анда җыр түгәрәгендә йөргәндәге Әсхәт дигән танышы артистлыкка укый иде. Шуңа күрә берничә мәртәбә кереп чыкканы булгалады. Күрәсең, Зиннәт шуны исендә тоткан.

– Килештек, алай булгач. Кичке җидегә «Маяк»та.

Гаделҗан Фәрхәтовның юмартлыгын үзенчә аңлады. Ул һаман аны хәтәр эшкә куа. Ләкин бу юлы киләчәк белән боргычны кесәсенә тыгып барып, аның үзенә кәнәфи актарырга туры киләчәк. Шул ук вакытта Гаделҗанның күңелен шом басты. Әгәр дә утыргыч эче тулы партия байлыгы ятса?.. Ул нихәтле тир түгеп, тормышын куркыныч астына куеп, дәрәҗәсен төшереп йөргән ничәмә-ничә «операция» үткәргәннән соң хәзинәдән коры калса – хурлыгын кая куяр? Фәрхәтов бу очракта бүлешеп маташмаячак бит. Эче буш иде диячәк. Кайда байлык, анда дуслык юк.

...Аның хәтеренә балачактагы бер вакыйга исенә төште – мәктәптә укыган чаклар инде. Җиденчеме, сигезенчеме классларда. Бөтен укучылар көз көне бәрәңге алуда. Малайларда – көрәк, кызларда – чиләк. Уйный-көлә, ара-тала эш кайный. Шулчак аның көрәге астында нәрсәдер ялтырап киткәндәй булды. Ул, көрәген кырыйга кадап, ялан кулы белән дымсу туфракны актара башлады. Һәм... кулына тарих китапларындагы борынгы рим, грек чорындагы алтын ана дуңгыз фигурасы килеп капты. Күземә ялгыш күренәме дигәндәй, күзен чылт-чылт йомгалап-ачкалап тора башлады. Янындагы малайлар:

– Нәрсә таптың, нәрсә таптың? – дип, әле берсе, әле икенчесе табылдыкны кулларында әйләндерергә керештеләр.

Берсе:

– Алтын бугай бу, – ди.

Икенчесе:

– Бакыр, – дигән фикер әйтә.

Өченчесе:

– Бронза, – ди.

Дүртенчесе:

– Моны хезмәт укытучысы Бакый абыйга күрсәтик, – дип киңәш бирә. Әйе, монысы дөрес тәкъдим, бугай... Шундый фикерне кузгату белән:

– Нәрсә, эшләмичә монда җыелыштыгыз? – дип, үзе килеп җитте.

Малайларның берсе:

– Менә Гаделҗан дуңгыз тапты, алтын микән ул дип бәхәсләшеп торабыз.

– Кая күрсәтегез әле? – Бакый абзыйлары фигураны кулына алды.

– Ыхы, моның имчәкләре бигрәк күп икән, – дигәч, укучылар көлешеп алдылар.

– Абый, мондый дуңгызны китапта күргәнебез бар, әйеме?

– Әйе.

Бакыйның кулындагы чучканы бик озак әйләндереп карагач, мондый сүз әйткәне истә калган:

– Балалар, мин моны белгечләргә күрсәтермен, нәтиҗәсен әйтермен! – Шулчак тешләре коелып беткән авызын ерып елмайгандай итте.

Байтак вакытлар үткәч ул безгә:

– Теге дуңгыз алтын булып чыкмады – подделка, – диде дә авызы тулы тезелеп киткән алтын тешләрен күрсәтеп көлде.

Ул вакыттагы шундый хәлне, менә бүген, Фәрхәтов үзе генә башкарасы, «алтынлы эшкә» тотынасы булгач, Гаделҗанның күңеле яңадан кабынды.

Шуңа күрә, ул – гомерендә Аллага ялынмаган кеше, күккә карап, «Их, бу утыргыч та буш булса ярар иде», – дип, Аллаһы Тәгаләгә ялынды.

Ләкин ничек тә алда торган әлеге «операция»не башкарырга кирәк. Зиннәткә булышмыйча, киңәш бирмичә ярамый. Ярамый, ярамый...

Нинди генә уйларга чумып утырса да, башына бер юньле план да килмәде. Кыенрак шул монысы. Шулчак аның ми күзәнәкләре буйлап бер фикер зеңгелдәп узды. Бәлки, кайчандыр бу студиядә бераз укыган һәм тәмамламыйча, югарырак җиргә – югары уку йортына барып кергән кеше булып кыланыргадыр?.. Әйтик, Мәскәүгә... Сораштырсалар, сүзне шуңа борырга... Эзне югалтырга... Янәмәсе, әле ул вакыттагы кайбер укытучыларны белә, онытмаган. Төп театр артистлары да эшли икән дип шаккатырырга... Әнә Хәйрулла дигәне зур белгеч-педагог булып кәпрәеп йөри икән. Кайтып-китеп эшләүче студиянең директор урынбасары Хәмит тә анда булырга тиеш. Анысын дус дисәң дә ярый Гаделҗанга, бергә җырлаштыргалап йөргәннәр иде. Хәзер укыта, ди. Аның аркылы берәр җай кымтырыкларга булыр, бәлки, шул кәнәфигә. Аннан соң бит әле анда эстрада бүлеге ачып җибәргән, ләкин үзе Төп театрыннан куылган Әдәбулла да өч ел эшли бугай инде. Һаман шул исерткечкә уңай мөнәсәбәте аркасында күчеп йөридер инде ул эштән эшкә. Талантларның таланты югыйсә. «Тәртип» бозмый, ди, икән тагын, түзә, ди икән. Укытуын да шәп укытадыр...

Гаделҗан шундук Фәрхәтовка шалтыратырга тотынды.

– Әй, – дип башлады ул сүзен, – синең кулыңа чүкеч тотканың бармы? Келәшчә белән боргычны сорап та тормыйм инде.

– Нәрсәгә ул?

– Кәнәфиләрнең асты кадак белән кагылган яки шөреп белән беркетелеп куелган була, белдеңме, аңгыра баш. Шөрепнең дә ни икәнен аңламыйсыңдыр әле – саморез!

– Ник аның өстен генә ертып белеп булмыймыни?

– Була. Ләкин мин менә бүгенгәчә нигә иректә йөрим дип уйлыйсың?..

– Эләкмәгәнгә күрә.

– Дөрес. Эләкмәс өчен эшеңне чиста, пөхтә башкарырга кирәк. Әгәр дә син өслекне умырып атсаң, икенче көнне үк артыңнан килеп җитәрләр.

– Ә миңа нишләргә? Ничек эченә керергә?

– Вәт, аңгыра... Утыргычны әйләндереп каплыйсың. Өслек аска тарттырылган. Кара, кадакмы, шөрепме? Кадак булса келәшчә белән суыр, шөреп икән – борып ал! Белдеңме?

– Куркыта.

– Мин шуны эшләгәндә, сине куркытмый идеме?.. Шулайдыр шул. Йөрәгем читлегеннән чыгып качардай булып типкән чаклары булды. Белмисең генә. Әзерлән... Өйрәтермен!.. План өлгергәч, кабат күрешербез. Әйбәтрәк ресторан эзлә!..

Ул төнне Гаделҗан йокыга китә алмыйча интекте. Чөнки уйлап табылырга тиешле план җайлы гына чишелеш табар төсле иде. Башта разведка ясарга кирәк. Янәсе, ул элек йөргән студия белән нык кызыксынганга күрә, Хәмиттән уку-укыту бүлмә-кабинетларын, классларын күрсәтеп йөрүен үтенер. Мондый гына эшкә кем каршы килсен? Әлбәттә, риза булыр ул. Кәнәфи дә күзгә чалыныр шунда. Кайда кулланыш тапканлыгын күрер. Аннан соң реаль план туар. Шунысы киртә: зур кеше булып йөрү өчен кыяфәт кирәк, затлы кием.

Гаделҗан Фәрхәтовка шалтыратты.

– Әллә нинди фантазиягә тиңдәшсез ресторан эзләп йөрмә, син миңа бер шәп кенә кәчтүмеңне бир. Борчылма, ярты сәгатьлек фыртланып алу өчен генә.

– Ник, план турында сөйләшү кирәкмимени?

– Кирәк. Менә шул планның башы өчен кәчтүмеңне әзерлә миңа. Үзем башлыйм «операция»не, син дәвам итәрсең. Күп сорашып торма, хәзер үк китер, иртәгә иртүк студиягә барам. Калганын соңыннан сөйләрмен.

– Размерың?

– Яшьрәк вакытта киеп йөргән кәчтүмнәреңнең берәрсе исәндер бит?

– Гардеробта өчәү-дүртәү...

– Галстук, ак күлмәк, эшләпә, ботинка, яме?!

– Хәзер шофёр илтеп китәр. Кая?

– Шул – «Маяк» янына.

Ярты сәгать үтте микән, заказ килеп тә җитте. Төргәкне алып, Гаделҗан ресторан бәдрәфенә керде – анда иДәннән түшәмгә кадәр көзге. Ну, кәттә дә егет инде юньле кием кисә Гаделҗан! Көзге каршында боргаланып-сыргаланып торды да, канәгать кыяфәткә кереп, үзенең киемен китерелгән капчыкка тутырды. Хәзер иркенләп ял итсә дә ярый. Ул тулай торагына атлады.

Иртәгесен, Хәмитнең эшендәме икәнен белешмичә үк, сәгать тугызга студиягә килеп керде. Вахтёр булып утырган олы яшьтәге кешегә күптән белгән кебек итеп:

– Сәлам, апа! – дип, сүз катты.

Тегесе дә таныгандай:

– Исәнме, җаный? – дигән булды.

Гаделҗан аның болай сәламләвен яхшыга юрады. Ул шулай буласын күңеленә сеңдереп, Хәмитне сорады:

– Кәримов мондамы?

– Күптән сезне көтәдер, – дигән аптырашлы җавап алды Гаделҗан. «Кем беләндер бутады», – дип уйлады ул, вахтёрның әйткәнен. Хәер, мондый кәчтүм киеп килүчеләрне берәү дә тоткарлап тормыйдыр.

– Икенче катка менегез! – диделәр.

Дәрескә соңга калган студентларның карашларын да үзенчә аңлады ул. Карале, болай киенү, яшәргә уңай икән, дигән нәтиҗә чыгарды.

Хәмит аны танымыйча торды. Танығач, җилкәсенә кагып:

– Һәй, чукынмыш, монда укыганлыгың беленеп тора. Кара инде ничек киенгәнсең, министр, понимаешь, әле укып бетергән булсаң, ни дәрәҗәләргә җитәр идең?!

– Президент, кәнишне...

– Ни йомыш?

– Менә үзем укыган урынны сагынып килдем әле. Күрәсем килә, тагын бер... Ностальгия. Бераз экскурсия ясап алмыйсыңмы миңа?

– Рәхәтләнеп. Хәзер кайда эшлисең, кайларда йөрисең? Күренмисең, ишетелмисең.

– Роман, повестьлар язарга тотындым, Хәмит дус. Бик чыгып, күренеп йөреп булмый, пьесалар да...

– Шулайдыр, шулайдыр, молодец! Әйдә!

Алар бүлмәләр, аудиторияләр буенча ача-керә йөрергә керештеләр. Иң беренче директор кабинетыннан башладылар. Хуҗа үзе юк, министрлыкка чакырылган икән.

– Бик хөрмәткә лаек кеше, – дип кенә узды Хәмит үзенең начальнигын.

Гаделҗан өстәл артындагы ул эзләгән креслоны күрмәгәч, сорап куйды:

– Кәнәфи алышынган икән...

– Кәнәфине генә түгел, директорларны да алмаштырып торалар хәзер, монысы байтак утыра инде, бик нык береккән урынга, кубарып алырлык түгел.

– Яхшы эшлидер?..

– Начар түгел. Мәскәүдән килгән тикшерүчеләр дә гаеп табалмыйлар.

– Теге кәнәфие матуррак иде. Чыгарып аттыгыз мәллә?

– Юк, сәхнә артында ята ул.

– Кит аннан... Шундый хәлгә төштемени? Күрсәт әле?

Алар, зал ролен үтәгән зуррак бүлмәнең сәхнәсе артына кереп, искемосквы инвентарьлар арасыннан әлеге кәнәфине тартып чыгардылар. Исән калган аягыннан сөйрәгәндә үк, Гаделҗан аның аскы ягына күз төшергән иде. Арт такта шуышып йөри торган хәлгә килгән, инде ул әйләндерелеп, яңадан урынына куелган булып чыкты. Язу бар, ап-ачык, анда «Игнатьев Семён Денисович (28 дек. 1957–1960 28 окт.) диелгән. Үзе дә сизмәстән, Гаделҗан актарылган дип уфтанып куйды.

– Нәрсә дисең? – дип сорады аннан Хәмит.

– Актарганнар икән.

– Һәй, студент халкына чыдыймы соң?

– Берәр төрле тарихы барлыгын әйтмәделәрме?

– Нинди тарихы булсын аның? Илленче елларда обкомнан списать итеп китерелгән урындык инде. Студентлар эчәгесен чыгарып, туздырып бетерделәр өсте тишелгәч. Мамык иде. Соң, үзең дә бит әле шуннан мыексакал ясап уйнап йөргәнсеңдер...

– Шулай булырга мөмкин, бик мөмкин... – диде дә Гаделҗан, башка бүлмәләргә керүдән ваз кичте...

– Кәефең китте, ахрысы, кәнәфине бу хәлдә күргәч?

– Шулайрак булды шул. Әйбернең кадерен белү юк бездә, – дип, Хәмитне урамга әйдәде. Җайлы гына хушлаштылар.

– Министрлыкка безгә дә кил, – диде Гаделҗан аңа.

– Кайда?

– Фәрхәтов Зиннәт янына.

– Ярар, – дип, ишеккә борылды Хәмит, Фәрхәтовның кем икәнен дә сорамыйча.

Гаделҗан студиягә визитының шулай тәмамлануы турындагы отчётын Зиннәткә шул ук кичне тапшырды. Ул комбинаторны борчылып түгел, шатланып каршылагандай булды. Ник дисәң, ул үзен инде төрмәдәге бандитлар белән ничек тотачагын күз алдына китереп утыра башлаган иде.

– Ярар, молодец, эшен бетергәнсең, алдагысын уйлыйк, – диде, Зиннәт.

Хәзер кемнән нинди хәбәр көтеп, кая барасы һәм аны ничек хәл итәсен генә уйлыйсы калды. Тагын алты урындык актарасы бар, табып...

## Алтынчы кәнәфи

Партия алтынының печтик кенә өлеше мондый кәнәфи эченә яшерелүе, дөресен генә әйткәндә, Фәрхәтовта шик тудыра иде инде. Ул тирән уйга батты. Казан ханлыгының да байлыгы табылмаган. Әллә Кабан күленә батырылган, әллә Явыз Иван кулына эләккән, әллә башка җиргә күмелгән, әллә теләсә-кем тарафыннан таланган? Берәү дә белми. Рәсәйнең казнасы кая киткән? Чехлар нишләткән аны, Себер юлы буйлап чигенгәндә, коеларга батырып яшергәннәрме, вагоны-вагоны белән Байкалга чумдырганнар дип тә сөйлиләр. Хәзер менә партия алтыны?.. Бармы ул, булганмы? Рәсәйнеке бер мәсьәлә, Татарстанныкы – икенче... Шундый җаваплы оешмада эшләп, ничек ул аны белмәскә тиеш?.. Примитив рәвештә булса да, кыргый ысуллар табып эзләнергә мәҗбүрләр менә хәзер. Телевидение җитәкчесенең арт шәрифләрен җылыта торган утыргыч та нәкъ шундый объектларның берсе икән. Гаделҗан шул турыда Фәрхәтов дустына җиткерде. Телефоннан сөйләшүләр тыңланыла дип, яңадан «Маяк»та очрашырга булдылар һәм шул ук көнне күрештеләр дә. Эшлекле әңгәмә табын артында барды.

– Син, әлбәттә, бераз телевидениедә эшләштергәләп тә, чыгышлар да ясап алгалаган кеше, керү-чыгу юлларын да беләсең, гомумән, ситуацияне чамалыйсың, кабинетлар системасы да күз алдында, комитет җитәкчесенең бүлмәсендә дә булырга туры килгәндер... Димәк, разведканы син ясыйсың. Бармы андый кәнәфи анда, юкмы – син үтисең бу эшне...

– Минем салпы ягыма салам кыстыруың өчен рәхмәт, әйе, телевидение башлыгы кабинетында булгаладым, хәтеремдә, менә шундый кәнәфи күземә чалынган кебек иде... Ләкин бит инде аңа байтак вакыт үткән...

– Бәлки, анда арткы бүлмә бардыр?

– Булгандырмы, анысын әйтә алмыйм, арткы планда стенка тора иде, ишеген шәйләмәдем.

– Соң, шуның бер җирендә ачылып китә торган ишеге була бит инде. Бу – интерьер модасы. Эчтә – диван, комод, өстәл, тәм-том... Әле ул яшерен бүлмәнең дә арткы ишеге булырга тиеш. Кунак-фәлән килгәндә, аннан махсус кыз килеп чыга – «секретарша» исемле.

– Андый чакка туры килгәнем булмады. Безнең кебек «вак-төяк»кә анда сыйлану зур дәрәҗә саналыр иде.

– Димәк, безгә шунда үтеп керү кирәк.

– Ә нигә? Башта белгән кешеләрдән сораштыру яхшы, бармы ул бүлмәдә андый кәнәфи, юкмы?..

– Кем әйтә ала соң аны?

– Телевидениенең режиссёры Гариф.

– Кергәндер, күргәндер, дисеңме?

– Һәй, аның тыкшынмаган җире юк. Юкка гына кушаматы «Кавык» түгелдер...

– Димәк, аны вербовать итү синең өстә...

– Гариф, ул кәнәфинең кайдалыгын белү генә түгел, бәлки, әле аны бакчасына ук алып кайтып куйгандыр. Хәзер үк шалтыратыйммы? Бир телефоныңны?..

– Мә, шалтырат!

Гаделҗан кесәсеннән бөгәрләнеп беткән кәгазь кисәге чыгарды. Анда төрле телефон номерлары язылган иде.

– Менә монысы икән, – дип, бер номерны җыйды. Телефонның теге башыннан «әлү» дигән тавыш ишетелде.

– Карале, Гариф абый... – дию белән, әлеге тавыш аны бүлеп: «Гариф түгел әле бу, Мөсәев», – диде.

– Нинди Мөсәев?

– Мөсәев инде, Мөсәев, әйдә, әйт, нәрсә кирәк сиңа, Гаделҗан?

– Карале, тавыштан таныйлар, – дип, ул аптыраган кыяфәттә Зиннәткә бакты. – Аферист Мөсәевкә эләктем, – диде Гаделҗан, телефонын учы белән каплап. – Гариф абый «Мокамай» фильмын төшергәндә, мине директоры итеп билгеләгән иде. Иң беренче эш итеп, миңа әйтте бу: «Кайбыч лесхозы директорына барып, син аны яхшы беләсең, агач материаллары ташыйбыз. Мокамайның бабасы өен яңадан төзеп, павильон сыман җирдә төшерәбез, – ди.

– Әйбәт бит инде!

– Әйбәт.

– Телефоныңны сүндер! Нигә аңа сөйләп торасың боларны?

– Куйды бит инде ул телефонын.

– Бир алай булгач миңа... Менә хәзер дәвам ит анданиләр булганын.

– Шулай итеп, киттем телевидение шофёры белән йөк машинасына утырып, Кайбыч урман хуҗалыгына. Бардым, җитәкчесен күрдем, сөйләштем. «Мокамай» дигәч, ничек каршы килсен инде. Килмәде. «Пилорамга бар да, күпме кирәк төя», – диде. Төядек машинаның түбе җиргә тигәнче.

Әле ул гынамы? Фильм төшерәбез, дигәч, Гариф белән икебезгә «КамАЗ»дан ике «каблук» машинасы бирделәр. Тик аның миңа дигәне эләкмәде. Җитәкчеләр күп бит телевидениедә, шуның берсенә булды ул. Автопарк җитәкчесе күбрәк «сул»га йөрде бугай миңа тиячәге белән.

...Менә шул, алып кайттык материалларны – шәп такталар!

– Кая бушатыйк? – мәйтәм.

– Баш бухгалтерның дачасына, – ди режиссёр.

– Менә сиңа кирәк булса!.. Мин монда, панимаешь, яңа пәлтәне нарат

сагызына батырып, эштән чыгардым, хәзер «Мокамай»га дигән такталарны бухгалтер бакчасына бушатыйммы?.. Кызып киттем. Сез, рәшәткә артына эләксәм, передача да китермәячәксез бит, – дип, бияләйләрне ыргытып китеп бардым.

– Синең урынга кемне табыйк соң? – дип калды.

– Сезнең мондый эшегезгә Мөсәев бик кулай! – дигән сүзләремне әйтергә өлгердем.

– Гариф белән хәзер дуслык бармы? – дип сорап куйды Зиннәт.

– О-о! Шәп кеше ул, үпкә тотмады!

– Анысы ярый икән. Күрешеп сөйләшик алайса үзе белән.

– Бакчасындадыр инде.

– Бара беләсеңме анда?

– Проблема түгел.

– Киттек. Калган эшкә кар ява.

Гариф аларны кочаклап каршылады. Гаделҗан Зиннәтне үзенең иң якын дусты, полкташы дип таныштырды. Башта алар бакча буйлап караштырып йөрделәр. Гаҗәпләнгәндәй, соклангадай иттеләр. Хуҗабикәсен мактадылар. Хуҗа кеше хуҗабикәсе белән әллә ни дус яшәмәсә дә:

– Ул минем тормыш терәгем, иҗат чыганагым, илһамчым һәм бакчачым! – дигән булды. Ят кеше янында зарлануның ни файдасы бар?..

– Үзе кайда соң әле, үзе?! – дип, яхшы ниятле кеше икәнлеген күрсәтергә теләде, ахрысы, Фәрхәтов. – Чәчәкләр арасындадыр инде, – дип тә өстәп куйды.

– Чәчәк инде, гөл! – дип куәтләде аны бераз көлемсерәп Гариф. – Сиксәнгә җитеп килә торган Татарник – Шайтан таягы.

– Нигә алай тасвирлыйсың? – дигән булды Гаделҗан.

– Чәнечкеле булганга.

– Ә бит, бер карасаң, аннан да матур чәчәк аткан гөл юк болында!

– Шулай диегез инде! – дип йомгаклады сүзен Гариф. – Әйдәгез, коттеджга керегез, – дип, 3х4 озынлыкта буралап салынган өенә күрсәтте.

Бухгалтерга такталар ташып, йорт җиткерергә булышкан кеше үзе нинди «сыерчык оясында» тора дип уйлады Гаделҗан. Бакчасы каршында туктаган иске «каблук»ка да игътибар иткән иде инде ул килеп җиткәндә. Кузовы күгәреп беткән, әмма йөри, күрәсең.

– Машина белән киләсеңме монда? – дип сорап куйды Гаделҗан, өйгә керә-керә.

– Әнә бит каршыда тора иномарка – Ижевская, – диде җавапка бакча хуҗасы. – Йөртә, китерә дип әйтеп булмый инде аны. Ул хәзер мине ашый, кимерә генә. Запчасть җиткерерлек түгел. Аңа дигән детальләр дә юк инде хәзер.

Кунаклар өйгә аяк басу белән үзләренә кирәк нәрсәне эзли башладылар. Күзләре ястык, юрган өелгән, аяклары гына күренеп торган кәнәфигә төште. Утырырга урын аз булгангамы, Гариф түшәкләрне янәшәдәге караватка күчерде. Алларында чираттагы кәнәфи пәйда булды. Менә ул! Гаделҗан шаккаткан булып:

– Нинди реликвия бу гүзәл шедевр?! – дип гаҗәпләнгәндәй итте.

– Үзегез ясадыгызмы, әллә берәр алтын куллы мастер эшеме әлеге могҗиза! – дигән булды Зиннәт тә.

Кунаклар кәнәфине әйләндерергә керештеләр.

– Карале, карале, кадак түтәләренә хәтле бизәкле! Утыргычы да – күн! Ай-яй, малай, кемнәрне генә бәхетле иткәндер бу музей түрендә торырга тиешле дөньяви шаккаткыч экспонат?!

– Кайдан таптың? – дигән сорау белән тикшерүләрен тәмамладылар. Гаделҗан гына берничә мәртәбә кәнәфине күтәреп карады да:

– Кем утырганын белик әле? – диде.

– Ничек итеп? – дип сорады Гариф.

– Аның астын ачып карасаң, анда язу булырга тиеш.

– Кызык. Шуны белмәгәнмен, – диде дә Гариф келәшчә белән боргыч алып керергә тыштагы сарайга чыгып китте.

Зиннәт шуны гына көткән кебек Гаделҗанга ачулы караш ташлады:

– Син нәрсә, әгәр... Җүләрләнден мәллә?..

– Юк анда берни дә, авырлыгы элеккеләреннән җиңелрәк тә әле.

Шул арада коралларын тотып, Гариф килеп керде. Кәнәфине әйләндереп салдылар. Гаделҗан тактасына күз төшерде – шул инде – стандарт. Икесе моның оста гына кадак суыруына карап торды. Шалт-шолт! Кубарган тактанын эчке ягында – язу. «Фикрят Ахмедзянович Табеев (28 окт. 1960 – 2 ноябрь 1979 г.).

– Вәт, кем тәхетендә утырасың син хәзер, Гариф дус! – дип, тантаналы төстә әйтеп куйды Гаделҗан, кәнәфинең соңгы кадагын урынына какканда. – Ни хала-бала! – дип тә өстәде.

Гариф аптырап калды.

– Мондый урындыкны мин әле тагын бер җирдә күрдем. – Ул аны хәтеренә төшерә алмый азапланды.

– Ну, ну!.. – дип, хәтеренә көч өстәп торды болары. – Кайда, кайда?

– Точно... Әйе, шунда... Зоопаркта!

– Ничек анда барып эләксен ул?

– Үзем дә аптырадым аны анда күргәч. Директоры шуңа җәелеп утырган... Иң өстендә – маймыл, баш очында – попугай. Попугае гел: «Кар-р-рак, кар-р-рак!» – дип, кеше тавышлары чыгарып каркылдый иде. «Кемгә әйтә ул шулай?» – дип сорадым. «Миңа!» – ди. – «Кеше алдында хур иттереп бетерә инде мине», – диде шунда директоры.

Фәрхәтов белән Гаделҗан кәнәфи мәсьәләсендәге кызыксынуларын бераз киметә төштеләр. Чөнки Гарифта бу шик уятырга мөмкин иде.

– Дөнья булгач, ни генә күрмисең, ни генә ишетмисең. Булмас, димә, булыр... – диделәр дә кунаклар китәргә җыендылар. Гариф сорарга мәҗбүр булды:

– Ни йомыш белән килгән идегез соң?

Гаделҗан ачыклык кертте:

– Минем дус, Фәрхәтов, төзелеш буенча генеральныйның урынбасары, төзелеш мәйданнары эзләп йөри. Килдек менә. Берочтан, синең бакча монда икәнлеген беләм, кереп чыктык.

– Алай икән, димәк, киләчәктә сүтәчәксез бу урыннарны?..

– Планга кертелгән, кайчан башларбыз, әйтә алмыйм, – диде Фәрхәтов, машинасының тәрәзә пыяласын ябып.

Гаделҗан эчтән кул болгап калды. Киттеләр. Димәк, зоопаркта...

– Беләсеңме? – диде юлда Гаделҗан Зиннәткә, – Фёдор Михайлович Достоевский нәрсә дип әйткән?

– Нәрсә дип?

– Тормыш максатсыз тончыга! – дигән.

– Дөрес.

## Җиденче кәнәфи

Юлда план корылды, ләкин төгәл генә фикергә килә алмадылар. Аларга зоопаркны «эшкәртү» җиңел булыр кебек тоелды. Нигә дисәң, фил, бегемот, жираф, каргалар һәм башка хайван һәм кош-корт белән җитәкчелек итә торган түрә әллә кем түгелдер кебек иде – аңа әллә ни акыллылык кирәкми сыман... Кабат иркенләп утырып сөйләшү турында килештеләр дә, шәһәргә керүгә аерылыштылар.

Байтак вакыт үтте. Зоопаркта «операция» көйләп җибәрү тоткарланды, сузылды. Һәркем үз мәшәкате белән мәшгуль булды. Инде бернинди кәнәфигә өмет, ышаныч баглау бетте. Шулай бит ул – хыял чиксез, ә үтәлеше – чамалы. Инде күпме кәнәфине тикшерделәр, нәтиҗәдә – ноль. Кемнеңдер өстән карга кебек кычкырып, боерык бирүен үтәп йөрсәң, стрелочник гаепле була, шуңа дучар ителеп, соңгы чиктә читлеккә эләгүең дә мөмкин. Шундый уйларга бирелеп, Гаделҗан эзләүне дәвам итүгә сүлпәнлек күрсәтте.

Зиннәт Фәрхәтов та шундый уйлар белән йөргәнгә микән, ял көннәренең берсендә ул зоопаркка үзе генә килде. Йә таба – хәзинә – үзенеке генә, йә туктый бу эзләнүләрдән, кул селти.

Бу гүзәл җиргә халык күп йөри икән, байтак гаиләләр балалары белән килгәннәр. Маймыл читлеге яны гөрләп тора. Бигрәк яраталар инде бала-чага шуларны. Мартышкаларны котырталар, банан, конфет, прәннекләрне читлек эченә ыргыталар. Тегеләр ашаса куаналар. Еланнар янында кешеләр аз. Ни дисәң дә, шомлы инде ул сөйрәлүчеләр – куркыта. Зиннәт бик озак бегемотка карап торды. Суга чумган да, гыйфрит, ике бәләкәй туп кебек бүртеп торган күзен мытырайткан. Кымшанмый да. Өскә калкыр микән дип, байтак көтте ул аны. Ниһаять, иренеп кенә селкенеп алды. Бассейндагы су кисәк кимеде. Фил, дисәң, фил түгел, мамонт, дисәң, тиресе йонсыз, дуга сыман казык тешләре дә юк – бер әкәмәт килбәтсез хайван икән. «Зоопарк директоры да шундыйрак бәндәдер инде», – дип көлемсерәп алды Зиннәт. Ничектер, монда эшләүче хезмәткәрләр шушындагы җанварлар кебек пошмас, үшән җан ияләредер сыман тоелды аңа.

Ул зоопарктагы халык арасыннан бүксәле кешеләрне күзәтә башлады. «Берәрсе директор түгел микән? Монда йөргән кешеләр аның үзен дә, бәлки, ул уйлаганча, зоопаркның директоры дип узып китәләрдер. Үзенең дә корсагындагы чалбар каешы тиешле урында тормый».

Зиннәт Фәрхәтов шундый уйлар, күзәтүләр белән көн уртасына хәтле йөрде. Инде директорның кабинеты кайда икәнлеген беләсе генә калды. Мөгаен, шундадыр дип, ул зоопарк идарәсе янына килде һәм ялгышмады. Коридор буйлап барганда, каршысына очраган бер яшь кенә егет аны туктатып:

– Зиннәт абый, син түгелме соң? – дип күреште.

– Үзең кем буласың, таныш кешегә охшагансың.

Ул озак кына аңа карап торды. Кайдадыр күргәне дә бар кебек.

– Син мине танымыйсың, Зиннәт абый. Мин Кәнтәрле авылының Мотыйк малае булам.

– Мин дә шул авылдан бит инде. Беләм, беләм, Мотыйк абыйны, ничек белмәскә – Югары очта яшиләр.

– Хәзер әти исән түгел инде.

– Урыны оҗмахта булсын, яхшы кеше иде. Шулай да ул мине бәләкәй чакта бер тапкыр, ыштанны төшереп, кычыткан белән чәпәләде. Онытасым юк.

– Юкка түгелдер, мөгаен?

– Малайлар белән сезнең кыярны урларга кергән идек бакчагызга.

– Әйтәм бит, сәбәбе бар.

– Аннан соң, үсә төшкәч, мәктәп директорының бәрәңгесен алырга булышкан өчен әләкте.

– Анысы нигә?..

– Математикадан «өчле»не «бишле»гә төзәтеп булмасмы дигән идем.

– Менә, менә...

– Тагын бер мәртәбә сезнең Шамил абыйның кызы белән йөри башлап ташлаган өчен...

– Аның өчен генә әрләмәгәндер инде, гаебең зур булгандыр...

– Мәктәп директорының кызына күз төшкән иде. Ярый, яшь чакта ни генә булмый... Мәхәббәтнең үпкәсез үткәнен күргәнем юк минем. Хәзер башкалага күчтеңме?

– Әйе.

– Әллә монда эшлисеңме?

– Менә шушы зур хуҗалыкның директоры мин. Бик җаваплы эш.

– Карале, Кәнтәрле мәктәбе директоры һаман шул Фаиз абыйдыр бит? Аның кызлары бишәүме әле?

– Алтау. Менә шуларның алтынчысына өйләнгән идем инде мин. Ә син беренчесе белән йөргәнсеңдер – исеме Фәимә аның.

– Директорның кызлары чибәр иде инде. Шул төпчеге белән яшисеңме монда?

– Юк. Безнең тормыш юллары әйбәт тоташмады. Мәркәздә зур бер түрә кызына гашыйк булдым да...

– Аңлашылды. Тагын кабинетыңны күреп чыгыйм да инде...

Алар гөлбакчага охшаган киң һәм биек, якты павильонга килеп керделәр. Пальма астында озын өстәл урнашкан, чәчәкләр, чәчәкләр... Хуш исләреннән башлар әйләнә.

– Да-а-а! – дип сузып башлады әйтәсе килгән хисләрен Фәрхәтов. – Менә сиңа Мотыйк малае! Дизайн шәп – искиткеч! Монда тегенди-мондый җиһазлар килешми шул. Миңа әйткәннәр иде, сиңа хәтле директорда булгандыр инде ул, кайсыдыр обком секретареның кәнәфие бар дип. Аны, шул синең киләчәктә республиканың башлыгы булачагыңа төбәп, төрттереп шулай дигәннәрдер...

– Ә-ә! Беләм мин ул кәнәфине. Зиннәт абый, кара, урыны монда

түгел аның, шуңа күрә авылдагы өйгә кайтарып куйдым мин син әйткән антиквариатны. Әни патшабикә кебек шуңа утыра – прәме Екатерина Вторая!

– Ярый, ярый, бик әйбәт! Әниең бик лаеклы, бик!

Фәрхәтов, авылдашының исемен сорамыйча, җылы гына хушлашты да, Гаделҗанны шалтыратып таптырды. Бүлмәсендә ята икән.

– Карале дус, ул кәнәфи хәзер безнең районның Кәнтәрле авылындагы Мотыйк абзыйның сөекле карчыгына хезмәт итә икән. Тиз генә шунда сыпыр да тикшереп кил әле, күңелдә калмасын... Минем машина биш минуттан килеп җитәр яныңа.

Гаделҗан тиз генә чыгып, килешенгән җирдә аны көтеп торган иномаркага утырды да Кәнтәрлегә юл алды. Ялкауланып ятасы юк – юл ерак, әйләнеп тә кайтасы бар бит, әллә баеп үләсе, әллә җан тынычлыгын югалтмыйча, гомер сөрәсе...

Фәрхәтовның шофёры элдертә генә, радиода татар музыкасы яңгырый. Берсе артыннан берсен җырлаталар шул байның хатыннарын... Акча түләнгән – нигә җырлатмаска! Аннан соң, мәшһүрләрнең студентлары... Көн саен шулай... Гомер үтә юньле җыр тыңлыйсы килеп... Аннан соң Австралиягә күчкән татарлар җырларга тотынды, Финляндиядәгеләр, Алманиядәгеләр, Төркиядәгеләр... Инде бетте дигәндә, Фирүзә фонограммасын әйләндерә башладылар. Соңгы акчасын түләгәндер, җаныкай... Хәер, андыйлар байтак эстрадада – ун ел элек үк 500дән артык иде, хәзер мең чамасы бардыр, күбрәк булмаса!..

Кәнтәрле юлы сизелми дә кайтылды шуларны тыңлый-тыңлый. Һәрберсенең тормыш юлы, язмышы күз алдында бит.

Мотыйк йортына керү каушатыбрак та, дулкынлатыбрак та алды аны. Юлда уйлап килгән сүз башын ишектән килеп керү белән каршысында пәйда булган апага әйтеп салды.

– Антиквариат әйберләрегез юкмы, хөрмәтле ханым? – Аннан соң гына, исенә төшеп: – Исәнмесез! – диде.

– Аллага шөкер, бик яхшы, – дип, әллә ни исе китмичә җавап бирде апа кеше. – Нәрсә соң ул син әйткән, әллә нинди мин белмәгән сүзле әйбер?

– Борынгырак нәрсә, җиһаз, мәсәлән...

– Ә, шулай диген аны, бар иде, мин аны авылыбыздагы музейга бирдем, үзләре килеп алып киттеләр бик сөенеп. Ул инде бик сәләмә хәлгә килгән иде, төбе дә төште.

– Берәр нәрсәсе бар идеме соң эчендә?

– Юк, бернәрсәсе юк иде, коп-коры. Бер язу гына чыкты кәгазьгә язылган.

– Нәрсә дип сырлаганнар иде инде анда? Хәтереңдәме?

– Хәтеремдә. Бик зур кешенең исемен язганнар. Мусин, диделәр. Ул безнең башлыгыбыз булып торган икән, шуның урындыгы булган.

– Рәшитме, исеме?

– Әйе, әйе. Син аны беләсеңмени?

– Ничек белмәскә инде, ул минем бик якын дустым иде. – Юкка шыттырды монысын Гаделҗан. Менә хәзер бу апа аның турыда авыл буенча лыгырдап йөриячәк. Әнә бит:

– Чәй куйыйм әле алай булгач, – дип башлады.

– Юк, юк, рәхмәт, шул урындыгыгызны музейга кереп күреп чыгыйм да, китәрбез инде.

– Ярый, алайса, күргәч керерсез!

– Апакай, мәшәкатьләнеп торма, юл кешесенең юлда булуы хәерле, сау бул, озак яшә!

Гаделҗан машинага чыгып утырды. Шофёр:

– Эшләр уңдымы? – дигәч, – әйдә, киттек, безнең монда эш бетте, – дип җавап кайтарды.

Әйе, кәнәфинең хәлен тикшереп торасы юк, аны инде күптән тикшергәннәр. Хафаланырлык та түгел – аның эчендә: «Мусин Рашид Мусинович» дигән сүздән башка белешмә юклыгы төгәл ачык. Ә тәхеттә утыру елларын ул үзе дә бик яхшы хәтерли: 1979–1982 еллар.

Йөкләтелгән эшнең ни формада төгәлләнүен ул Фәрхәтовка шофёр телефоны аша җибәрде: «Әбине күрдек, күчтәнәчне тапшырдык. Исән-сау, үзенең буш урынында утырып тора».

Әлеге хәбәрнең мәгънәсенә төшенү кыен түгел иде.

Кеше яшәү мохитендә Алладан бигрәк могҗиза эзли дигән гыйбарәнең дөреслегенә ныграк ышанып кайтты ул юлда.

## Сигезенче кәнәфи

Хәзинәле кәнәфиләр табу көннән-көн кыенлашты. Зиннәттән дә хәбәр-хәтер килми. Тикшерелгән утыргычларда партия байлыгының исе дә юк иде. Моның белән мәшгуль ике «фидакарь»нең икесе ике фикергә тукталды. Фәрхәтов, өметен өзмичә, серле тактикага күчте – үз коллегаларын сөйләштереп, берәр төрле мәгълүмат эләктереп булмасмы дигәндәй, хәйләле разведка алып барды. Бу хәзинә турында әллә ул гынамы кызыксынган һәм кызыксына?.. Шуңа күрә һәр очракта – җыелышып торгандамы, мәҗлесләрдә очрашкандамы, күрешкән чакларда: «Партия алтынын таптың, ахрысы, бер дә сөйләшмисең, исәнләшмисең, баедың, малай, баедың», – дип төрттерә торган булып китте. Берәүләр бу сүзләргә игътибар бирмәде, икенчеләре исе китмичә: «Булды микән соң ул байлык?» – дип, чын-чынлап җитди шикләнүләрен белдерә иде. Кайберсе бу сүзләрне инкарь итмичә: «Булмас, димә, әнә Шәле урманында Рәсәй алтыны чумдырылган кое бар», – диләр. Ханлык алтыны да Кабан күле төбендә ятканын гел кузгатып торалар. Кем казыган да, кем эзләгән аны? Вагоны-вагоны белән Байкал күленә дә чумдырганнар дигән хәбәрләргә ышанып, әле дә батискафлар белән төшеп, күл төбен актаралар. Ник актармаска? Булган бит ул алтын. Димәк, кешенең нәфесе котырырга сәбәп бар. Тынгылык бирми бу нәрсә берәүгә дә. Әле менә монда республика казнасында булырга тиешле байлык та җанны кытыклап тора. Кайсы кәнәфидән килеп чыгар икән аның бәләкәй генә булса да бер өлеше?! Менә хикмәт... Моңа хәтлеләре буш иде бит. Мусиннан соңгысыныкыннанмы? Чиратта ул бит. Менә анда булырга мөмкин, бик мөмкин... Һәм аны кайдан эзләргә? «Димәк, башта утырган кәнәфиен табарга кирәк», дигән карарга килде Фәрхәтов. Һәм телефон аша Гаделҗанны эзләргә тотынды.

Бу минутларда Гаделҗан, ми күзәнәкләрен киереп, Зиннәттә хәйлә бармы-юкмы икәнлеген багып утыра иде. Күңеле белән сизә – астыртын

эш йөртә бит ул. «Бәлки, инде Зиннәт кәнәфиләрдә байлык юклыгын күптән беләдер», – дип уйлый башлаган иде ул соңгы вакытларда. «Хәйләкәр!» – диде дә, көрсенеп алды Гаделҗан. Шулай да «өметле» кәнәфиләрнең барысын да тикшереп бетерергә кирәк дигән төгәл фикергә килде.

Гаделҗан Зиннәтнең ни уйлап, нинди мәкер корып йөргәннәрен белмиме соң инде? Әлбәттә белә, сизә. Ә ул – миһербанлы бәндә, шуларның мәкерен фаш итүче – язучы буларак, Аллаһы боерса! Ул – материалда: ничек байлар һаман байыйлар, алар урлый-талыйлар, кемгә ришвәт бирәләр һәм кемнән алалар. Заман темасы, ягъни закондагы бурлык. «Акча – закон, закон – кесәдә, шулай булганда – комачауламый бернәрсә дә!»

Шул чагында Фәрхәтовтан телефон аша хәбәр килде.

– Нихәл? – диде ул, коры гына сүз башлап. – Нигә бер дә тавышың ишетелми?

– Шалтыратыр сәбәп юк бит. Үзең дә дәшмисең.

– Менә таптым әле. «Муса» театрына кереп чыккан идем. Шунда, директорның кабинетында шундыйрак кәнәфи күреп, күзем шар булды. «Агай»га утыргыч булып хезмәт иткән кәнәфигә хәзер шул театрның директоры утырып тора. Таныдым да, директорын урыныннан торгызып, кәнәфиенә үзем арт сикертеп карадым – болай тыгыз тоелды. Тикшерергә киңәш бирәм, җаен чыгарып.

«Бернәрсә дә юк икәнен белә торып актарта бит, – дип уйлады Гаделҗан. – Ә шулай да... Шайтан белсен», – дигән карарга килеп, «операция» планын корырга кереште.

– Директоры, директоры... Кем соң әле?.. Исеме?.. Әллә нинди бугай инде... Татар да түгел, яһүд тә... «Канифоль» кебегрәк. «Фоле», «фале» бар сыман. Шул Фаль театрга баш булгач, татарча куелыштагы постановкалар кимеде анда. Әле хәтерендә Гаделҗанның: бер тапкыр ул монда «Башмагым»ны карарга килгән иде. Залдагы тамашачылар – мәктәп балалары. Пәрдә ачылып киткәч, алар гөрләшеп, шаккатып куйдылар – бизәлешнең гүзәллегенә сокланмый булмый иде. Артистлар чыгып җырлый башлагач та, беркавым дикъкать белән тыңлап утырдылар. Бала-чаганың игътибары бит аның ун-унбиш минутка гына җитә, аннан соң түземлекләре бетә һәм син аны берничек тә тыя алмыйсың... Менә шул момент җитте – зал гөжли, кычкыралар, көләләр, кайберсе елый ук башлады. Укытучылары тынычландыра алмыйлар.

Дөресен генә әйткәндә, бу спектакль балалар өчен түгел иде. Аны әле олылар да түзеп карап утыра алмый кайчак. Мәхшәр булды анда. Артистлар, бернигә карамыйча, үз эшләрен беләләр – уйныйлар да уйныйлар. Сәхнәгә Рафаэль Сәхәбиев чыккач кына, залдагылар сәхнәне күзәтә башлады, чөнки ул бер тилемсәрәк персонажны уйный. Әллә ниләр кылана, эскәмия астына да кереп ята. Менә аның кабат сәхнәгә чыкканын көтә-көтә арып беткәч, зал яңадан гүли, кайный.

Гаделҗан шунда бер фикергә килде: бу, балаларга – безнең киләчәк буынга рухи байлык бирү түгел, киресенчә, татар сәнгатенә нәфрәт тудыру, уяту кебек тоелды.

Менә шушы бер мисал белән генә дә сәнгатьнең, бигрәк тә татар

операсының киләчәгенә тискәре йогынты ясаудан туктарга яки үсешенә якты юл күрсәтергә була югыйсә.

Директор ул юнәлешне сайламаган. Ул тоткан да чит ил классикасына күчеп, чит театрлардан җырчылар җыеп, чит илләргә гастрольгә чыгып киткән.

Ә менә республика башлыгы кәнәфиенең хуҗасы булу дәрәҗәсенә ирешкән. Ул болай уйлагандыр: бу утыргыч аңа бәхет китергән, миңа да китерер, дип. Күрәсең, дөрес уйлаган... Балда, майда йөзә.

«Бәлки, минем дә бәхетем шуның төбендәдер?..» дип, башына бик якты уй килгәндәй, күзләрен елтыратып куйды Гаделҗан.

«Ничек тә булса каезларга җай табасы иде. Ничегрәк?.. Уйла! Уйла! – дип, ул маңгаен төеп алды. Театрга барып белешергә кирәк: чит илгә китеп барышлары түгел микән? Реквизитларын төяргә, озатырга яки сәхнә эшчесе булып урнашырга кешеләр алмыйлармы? Андый мохтаҗлык еш туа бит. Кирәксә, мин бит инде менә дигән кандидатура!»

Шул уй килү аның зиһенен ачып җибәрде.

Шундый ук фикер белән Фәрхәтов театрга юнәлде. Директоры урынында түгел, министрлыкта йөри, диделәр. Чыннан да, Европага гастрольләр оештыру мәшәкате беләндер... Иртәгә-берсекөнгә декорацияләрне озата да башларлар. Төяү хезмәтен үтәүчеләр җитешмәгәнен дә әйтергә мөмкиннәр... Хәтта шул исәптән кулларын да уыштырып алды Фәрхәтов. Бик яхшы. Ул, очып, директор урынбасары бүлмәсенә кереп китте. Болай таныш булмаса да, күптән күргән кешесе кебек иде ул аңа. Хәер, монысы мөһим түгел, сүзен турыдан сөрде:

– Сезгә вак-төяк эшләрне башкаручы кул көче кирәк дип ишеттем, дөрестер бит шул хәбәр? Шундый бер кешене тәкъдим итәсем килә – профессионал!

– Шулайрак – кирәгеннән дә артыграк, Голландиягә ашыгабыз, иртәгә үк бер машинаны төяп җибәрү архиважно! Бүген үк килә аламы?

– Ала!

Фәрхәтов әйтүен әйтте, әмма Гаделҗан монда – шәһәрдә микән соң?

– Килсен, түләвен сдельно, ягъни кулына бирербез.

– Бик әйбәт!

Әйбәтен әйбәт. Табып булмаса, уңайсыз хәлдә калуың бар бит әле монда.

Урынбасар тагын бер үтенечен әйтеп салды.

– Ни... Безгә, төнгә калып, төягән әйберләрне саклаучы да кирәк, ул риза булмас микән?

– Мин әйткәч, каршы килмәс.

– Ай, яхшы булды әле бу сезнең килеп чыгуыгыз. Тау үзе Мөхәммәт янына килгән кебек.

– Паспорты кирәкме?

– Ю-у-у-к. Килешү кәгазьләре тутырып маташсак, мәшәкате күп була, карак-фәлән түгелдер әле?!

– Юк инде, төрмәдә дә утырмаган хәтта. Ярар, кул бирешик...

Алар, бер-берсенең исемнәрен дә сорашмыйча, уч чәпештеләр. Фәрхәтов ашыгып, урамга чыкты да, театр каршындагы Ленин һәйкәленә карап, телефон аша Гаделҗанны эзләргә тотынды. Бер тапкыр җыйды яңа алган кесә телефонының номерын, ике, өч – алмый. Ленин да аңа:

«Алмыймы, илне талауны дәвам итәсезме?» дигән караш ташлагандай тоелды.

– Кайда йөри инде? – дип, Фәрхәтов сүгенеп тә куйды. Ленин ишетмәсен тагы дигәндәй сагаеп калды. Аннан соң аклангандай: «Владимир Ильич, без пүчтәк, без инде кырык тапкыр таланган, урланганнан калганны гына җыештырып йөрибез», – дип, кабат үз эшенә – Гаделҗанны эзләргә кереште. Юк, һаман алмый телефонын. Әллә куллана белмиме? Кабахәт! – диде аптырагач. – Өе дә, төп торган урыны да юк бит, ичмасам...

Кинәт телефонына җан керде. Ул кабаланып аны колагына терәде. Гаделҗан тавышы. Фәрхәтов аны тыңлап бетермәде, үзе:

– Син кайда югалдың, сукбай? Иртәдән бирле эзлим бит инде мин сине, сволочь! – дип, аты-юлы белән тегенең тетмәсен тетәргә тотынды.

– Ике көн эч китә, үлсәм дә хәл белә торган кеше түгел син, – дип, монысы ике сүзнең берендә Фәрхәтовның ата-анасын катыштырып сүгәргә кереште.

Ике арада биш минут чамасы сүз дуэле булып алды. Ниһаять, Зиннәт Гаделҗанның туктавын үтенеп, гозерен әйтте.

– Карале, бүген үк, дөресрәге – хәзер үк «Муса»га бар, анда реквизитлар төяргә эшчеләр кирәк. Театр Европага китә. Сине директор урынбасары көнлеккә-төнлеккә дигәндәй эшкә ала. Анда элек «агай» утырган кәнәфи дә озатылачак. «Отелло» операсын уйнаганда, шуны кулланачаклар икән. Ярар, монысы сиңа кагылмый. Сине төнге каравылга да калдырачаклар, шуны бел. Эшең өчен акча да түләячәкләр. Менә шул. Ферштейн?!

– Ферштейн.

– Паспортың кирәкми.

Гаделҗанның эче авыртуы шундук онытылды. Ул, «операция» коралларын алып, әйтелгән объектка юл тотты. Урынбасар көтә иде инде. Тик бер борчуы бар – таныш кеше була күрмәсен берүк дип теләде. Очрашкач, күңеленә хуш килде – ул аны белми торган кеше булып чыкты. Күрешкәндә, әйтүе буенча, яһүд, йөзе-бите дә тач шул тарафлардан. Хәер, гаҗәпләнәсе юк, алар Мәркәз тулы.

Эш күләме һәм төяүчеләр белән танышканнан соң, Гаделҗан үзенең төп вазифасына кереште. Ишегалдында һәм бина эчендә таралып яткан декорацияләр, реквизитлар арасында алар эзләгән кәнәфи дә бар иде. Искиткеч гүзәл – сәнгати осталык белән эшләнгән экспонат! Музейда гына тотасы югыйсә. Ә аны теләсә кайларга йөртәләр... интектереп, бәргәләп-суккалап дигәндәй... Спектакль куеп һәм җырлаулары белән дә тамашачыны шаккатырырлар, әлбәттә, ә бу кәнәфи аларның күз явын алачак!

Төяүчеләр аны фургонның иң түренә, иң өскә урнаштырдылар. Селкенмәслек һәм кырылмаслык итеп, йомшак ястыкка төрделәр. «Эх», – дип, уфтанып төреште аны Гаделҗан, бүсеп тикшерергә мәшәкатьле булачак. Җитмәсә, төнлә. Ярый әле фонарь алырга онытмады.

Ниһаять, төп бурычны үтәү вакыты җитте. Ул хәзер каравылда – берүзе. Кәнәфине бәйләгән бауларны төбенә үтеп керердәй итеп чиште, ястыкның шул төшен ачып, гадәттәгечә, кадак-шөрефләрне тиз генә борасын борып, суырасын суырып, тиешле җиренә үтеп керде. Аннан «1989, 23 сент. – 1990, 30 август» дигән язуны тартып алды. Гаделҗанның мондый табышка юлыгуы көтелгән хәл иде инде. Ул бу билгеләмәне әйбәтләп бөкләп,

кесәсенә тыгып куйды. «Зиннәт Фәрхәтовка күрсәтергә дәлил булыр, сүз белән генә әйтүгә ышанып бетмәс», – дип уйлады ул.

Кәнәфи җайлап кына, яңадан җыелды, төрелде, бәйләнде. «Эше бетте, кодагый...» – дигән булып, кулларын тузаннан какты да эченнән генә калган сүзләрен әйтеп куйды. Хәзер инде иртән фураны юлга озатасы да, эшләгәннең әҗерен алып, Зиннәткә нәтиҗәсен җиткерәсе калды.

Гаделҗанның докладыннан соң Фәрхәтов:

– Операция ахырына якынлаша, – дип кенә белдерде. Күңелендә ахылдау да, ухылдау да сизелмәде. Ә менә башында ниләр күперәдер, анысын әйтүе кыен...

## Тугызынчы кәнәфи

Соңгы араларда Фәрхәтов тынгысызламый әле Гаделҗанны. Салкын көз көннәре җитте. Мәркәздә ярминкәләр гөрли. Кибет киштәләрендәге азык-төлеккә исе китмәгән халык, базардагысына агыла. Бәяләре дә түбәнрәк, тәмлерәк тә... Кышка запас туплау өчен менә дигән ярдәм. Ярдәм дип, чарасызлыктан оештырылган ярминкәләр инде бу. Бер уйласаң, таралып беткән колхозларга соңгы тыпырчыну, икенчедән, хакимияткә карата ачуы чыккан халыкны тынычландыру. «Ярап тора, һич булмаганда...» – дигән булалар бит кайбер кешеләр, бигрәк тә карт-коры.

Бу чорда районнарның потребсоюз оешмалары җанланып куя. Алар ярминкәгә китерелгән продукцияләрен сату өчен төрле форма эш күрсәтәләр. Хәтта үзләре белән район һәвәскәрләрен алып килеп, кызыклы концерт программалары күрсәтәләр, аукционнар оештыралар... Тагын да куәтлерәк булсын дип, профессиональ артистларны җәлеп итәләр. Мондый чакта Гаделҗанның таныш артистлары алыштыргысыз роль уйный. Алар үзләре мәзәкчеләр дә, җырчылар да, биючеләр дә.

Бөек комбинатор Мәркәздә ярминкәләр башланачагын белеп, Чехов базарына юл тотты. Әйе, бу турыда телевизорлардан шаулый башлаганнар иде инде. Элегрәк, Арча кулланучылар җәмгыяте җитәкчеләре алдан ук хәбәр җибәреп, Гаделҗанга белгертеп куя тордылар, ә хәзергә никтер тыннары чыкмый. Шуңа күрә, аның күңелендә борчу бар. Ни дисәң дә, бераз акчасы, анысы булмаса, казы-тавыгы, бер сүз белән әйткәндә, күчтәнәчен бирә торганнар иде. Нүжәли бу юлы аларга мөрәҗәгать итмәсләр?..

Базар эче гадәти җанлылыкта. Кемнәрдер ит ала, кайберләре сөт-каймак, эремчек тирәсендә. Бал сатучылар да бар. Әле иркенлек, этелеп-төртелеп йөреш юк. Әнә ниндидер эшлекле кыяфәтле төркем базар буйлап әйләнә. Карыйлар, ниндидер план коралар... Кайда нинди павильон ясарга маташалар сыман. Ныклабрак күз салгач, Гаделҗан араларында Арчаның район башлыгын күреп алды, янәшәсендә райпотребсоюз җитәкчесе дә бар икән бит. Алар аңа таба якынлаштылар. Ул үз урынында тора бирде. «Күрерләр микән, игътибар итәрләрме, нәрсә әйтерләр икән?» – дигән уй туды. Үзең барып исәнләшсәң, «иснәнеп йөри» дип уйларга мөмкиннәр. горурлыкны тота белергә кирәк.

Шулчак райпотребсоюз җитәкчесе аңа таба килә башлады. Кай арада күреп алган, югыйсә Гаделҗан сизмәгән иде бит.

– О-о, кемне күрәбез! «Бирәм, дигән колына, чыгарып куяр, юлына!»

– диләр бит. Бик шәп булды әле сине очратуыбыз. Менә озакламый без тагын ярминкәләр белән Мәркәзебезгә киләчәкбез. Безнең дип әйтәм, чөнки ул инде сезнеке дә – уртак эшебез. Сезнең төркем чыгыш ясамаса, сәүдә бәйрәмебез бераз китек булыр иде. Киләсе шимбә-якшәмбедә очрашырбыз дип өмет итәм. Ризадыр бит?!

– Риза, әлбәттә. Сәгать ничәгә килик?

– Җидегә. Шул вакытта җырларыгыз шәһәрне яңгыратып торсын! Уятыгыз халыкны! Тутырыгыз күңелләренә җыр-моң, шатлык! Белеп торсыннар без килгәнне, ярминкә башланганны! Түләү – элеккечә, гарантияләнгән. Өстәп – банкет. «Агай» килүгә – иң яхшы номер!

– Шамкай белән Шәрәфи инде – икәүләп, берьюлы.

– Әйдә, син дә чык, өчәү булыгыз!

– Син әйткәнчә эшләрбез!

Шул арада район башлыгы килеп, Гаделҗанның кулын кысты.

– Егетләр, моңа хәтле сынатмадыгыз, рәхмәт сезгә. Мәркәз ярминкәләре оештыруда сезнең ярдәм белән беренчелекне бирмәдек, хәзер дә бирмәбез. Шамкай, Дәү абзый килүгә, теге «ишәкнең күпер салуын» сөйләсен... – дигәч, янында ияреп йөрүче урынбасарлары, буыла-буыла көлештеләр.

Гаделҗан, болар белән «вәгъдә-иман» дигәндәй, кул бирешеп саубуллашты да:

– Эшләр уңачак! – дип, кулын уып алды. – Әйе, әле монда партия байлыгына өмет итеп ятканчы, – дип тә өстәп куйды.

Берничә җырчы кызны да әзерләү сорала. Монысы чүп нәрсә – җиңел. «Акчасын түлим», – дигәндә, берсе дә каршы килмәс.

Шулай килеп чыкты да. Көне килеп җиткәндә, иртәнге җидегә хәтле үк бөтенесе җыелган, аппаратура корылган, музыка яңгырый. Инде бер төркем халык мәйданны әйләндереп алган, күбесе Шәрәфи янында. Бөек артист эшен башлаган. Көлдерә. Көлдерә генәме соң – үтерә көлдереп. Әнә берсе тын алалмый тончыга, ахрысы – аркасын төяләр. Юк, бу төркем беркайчан да башланыр вакытны көтеп тормый, кайда кеше бар – эшкә керешәләр. Халык бик ярата үзләрен, сөйкемле сөяклеләр, үзләре дә халыкны сөяләр.

Бервакыт шулай, Гаделҗан Шәрәфидән сорарга мәҗбүр булды:

– Равил абый, менә сез зур кеше, бөек шәхес, сезне белмәгән адәм юк. Сезне мондый җирләрдә, ягъни базарларда концерт куеп йөрүләр рәнҗетмиме? Чүтеки кара эш бит бу. Кеше уйларга мөмкин: «Нишләп йөри икән Шәрәфи мондый җирләрдә? Акчасы җитмиме яшәргә? Ашарына юкмы? Тегесе-монысы, фәлән-төгән...» Кеше бит синдәй шәхесләрне әүлия итеп күрә.

Шунда Шәрәфи: «Гаделҗан, без кемгә хезмәт итү өчен яратылган? Шушы халыкка бит. Базардагысы халык түгелмени? Менә мондагысы анық чын халык, иң әйбәте һәм иң гаделе. Мондагысы безне күрергә, ишетергә зарыкканы. Аннан соң, кем әле безнең хезмәтне бәяләп, хөрмәтләп безгә акча түләргә риза, ә? Юк, мин рәнҗемим, мин шатланам гына, чөнки мин үзебезнең гади халыкка, эш кешесенә хезмәт итәм. Ә ул базарда... Базар кайный: монда сату-алу бара – тамак хакына йөрүчеләр. Бу базар гади халык өчен. Моннан башка бүтән базарлар бар: анда шушы халыкның рухын, әхлагын, эшләгән эшенең күп өлешен үзенә бирмичә талау бара. Менә монысы гөнаһ, ә без эшләгәне – изгелек, белдеңме?» – дигән иде.

Җиде тулыр вакыт җиткән. «Киләләр!» – дигән хәбәр таралды. Димәк, хакимият күче базарга якынлаша. Гаделҗан микрофон каршына Шәрәфи, Шамкай, Җәләл, Сабирны бастырды – шулай, көчле номер белән чыгыш ясагыз алар килүгә дигән иделәр бит ярминкә хуҗалары. Шәрәфи башлап җырлаучы:

– Шәр, Шәр, Шәр, Шәр,
Шәрәфи – хи-хи, шәрә!
Шәрәфидән көлә-көлә,
Каласыз бит шәп-шәрә!

Җырның кушымтасын барысы бергә җырлыйлар. Заманча биегән дә булалар әле, килештереп.

Ниһаять, түгәрәк уртасына башлыклары белән хакимнәр килеп керде. Баш хаким, җыелган халыкка карап:

– Базар эчендә кеше бармы соң? – дип шаярткандай итте. Нигә дисәң, базар каршындагы мәйдан халык белән тулган иде. – Менә быел, Аллага шөкер, пенсионерларга бурычыбызны түләп бетердек, – дип дәвам итте сүзен Баш хаким.

Гаделҗан үзенең кулындагы икенче микрофоннан файдаланып:

– Әллә миңа да пенсиягә чыгасы инде? – дип төрттерде, эшләгән кешеләрнең инде айлар буе хәләл хезмәт хакларын ала алмый тилмергәннәрен белә торып.

Баш хаким аңа аптырап карап торды да әйтер сүзе булмагач:

– Ну бу Гаделҗанның теле – бигрәк хәтәр, – диде. – Әйдәгез, җәмәгать, базарга, – дип өстәде.

– Барыгыз, хөрмәтле дуслар, керегез! Анда бөтен нәрсә бушлай, Баш хаким әйтте!

Хакимнәр төркеме борылып аңа карады да, кул селтәп, базар бинасына кереп китте. Мәйданда бары тик бушка концерт караучылар гына, ит-сөт, бәрәңге һәм башка шундый әйберләр алырга акчасы булмаганнар гына калды.

Шулар арасыннан Фәрхәтов килеп чыгуы Гаделҗанны таң калдырды. «Нишләп йөри бу монда? – дип, уйга батты ул. – Бер дә юкка түгелдер?»

Фәрхәтов аңа ым какты. Бу Гаделҗанга «бераздан күрешеп сөйләшербез, яме», дигәнне аңлата инде. Күрәсең, аның янындагы кешеләр комачаулый.

Инде Баш хаким дә ярминкәне карап бетерде, чыгып, машинасына утырды да каядыр китеп барды. Аны озатучылары да китеп югалдылар. Бүгенгә эшләре бетте, ахрысы...

Алардан соң Арча потребсоюз җитәкчесе килеп:

– Әкренләп йомгакласагыз да була инде, – диде. – Расчётка банкет залына кер, яме? – дип, кабат базар эченә чумды.

Гаделҗан, чакырылган җиргә – банкет залына керде. Анда, гөр килеп, унлап кеше кәеф-сафа корып утыра. Түрдә, аңа бик таныш кәнәфигә җәелеп, Шәрәфи Пушкин, Лермонтов шигырьләрен үзенчә тәрҗемә кылганнарын сөйләп, өстәлдәгеләрнең ушын ала, тегеләре тәгәри-тәгәри көлә иде. Ул Гаделҗанны күрү белән:

– Оһо! Минем шеф керде. Талантище! – дип, якындагы буш урындыкка күрсәтте. – Монда кил, Гаделҗан! Кыенсынма, барысы да үзебезнекеләр! – диде тантаналы рәвештә.

– Үзебезнекеләр микән – болар бит министрлар! – дип, төзәтмә кертте аның сүзләренә Гаделҗан, араларында берничәсен генә абайлап.

– Үзебезнең түрәләр. Менә шуларны сыйлап утырам әле, кеше табынында. Югыйсә үзләренең мине чакырып, бер дә кунак иткәннәре юк, – дип чеметеп алды бөек мәзәкчебез. – Ничек анда хәлләр?

– Барысы да – ал да гөл!

– Шулай булырга тиеш. Расчёт бармы?

– Бар.

– Мин әйткәнчәме?

– Әйе, – дигән булды Гаделҗан, гәрчә Шәрәфинең әлеге ярминкәдә чыгыш ясауга түләнеләчәк суммада бернинди катнашы булмаса да.

– Менә болар да булышкаласа, тагын да әйбәтләнер иде ставка югыйсә! – дип, өстәлдәге нигъмәтләрне урып утыручы министрларга ымлады ул.

– Мин курорттан кайткач, кереп чыгарсыз! – дип, хәлгә кергәндәй итте министрларның берсе.

Гаделҗан боларның аклануларын бүлеп, Шәрәфигә соклану хисе белән:

– Равил абый, кимсенмә, карале, үзең нинди кәнәфидә утырасың. Король! Патша, император! Кая, тор әле, ныгытып карыйк!

Шәрәфи, аптырап, нишләмәк була икән бу, дигәндәй, торып басты. Гаделҗан кәнәфинең арт ягын әйләндерде, чүмәлтеп астын карады. Төбе куптарылган, әмма кымшанып торган фанерасын кулы белән каерып алгач, үзе дә гаҗәпләнеп:

– Карагыз әле, Баш хаким тәхетендә утырасың икән бит син! – дип, бармагын өскә күрсәтте.

– Әйтәм җирле башыма әллә нинди акыллы фикерләр килә башлады... – дип, серле дә, сәер дә кыяфәткә керде Шәрәфи. – Чыннан да, күңелгә дөнья белән җитәкчелек итәсе килү... – диде дә туктап калды. Җөмләсенең әйтеп бетерелмәгән җире табын артындагы кешеләрдә көлү уятты, ләкин озакка түгел, бу халәт кисәк тукталып, саубуллашу тостына күчте. Рюмкаларны чәкешеп, тамак төбенә җибәргәч, урыннарыннан кузгалдылар... Гаделҗан Шәрәфи белән алыш-биреш ясап алды да китүгә юнәлде. Шәрәфи дә аңа иярде. Базардан чыккач, алар кул бирешеп аерылыштылар.

Кәнәфинең төбендә инде аңа кадәр хуҗа булучылар Гаделҗанны борчуга салды. Тапканнармы алар анда берәр нәрсә? Актарулары – факт. Хәер, нигә ул байлыгын анда җыеп барсын? Хәзерге заманда үз астыңа мөлкәт туплау бетте бит инде, акыллы башлар аны капиталга тыгалар – предприятиеләр төзиләр, банклар ачалар, дусларына милек күчереп хуҗа ясыйлар, туганнарына язалар – олигарх итәләр.

Мондый фикер сөрешеннән соң Гаделҗан үзенең ахмаклыгыннан елый-елый көлде.

– Ә мин урындык астын актарам – дивана! Алтыннар, акчалар күптән офшорда бит!

Ләкин аның бу идеяне тагучы Фәрхәтов белән аның шефына шиге туды. «Җүләр түгел лә алар? Үзләре дә катнаша, ни мәҗбүр итә шундый җитәкчеләрне мондый афёрага? Димәк, үзләре утырган кәнәфи буш түгел... Менә хикмәт нәрсәдә?.. Имәндә икән чикләвек, диярсең».

Гаделҗан төгәл карарга килде. Фәрхәтовның кабинетындагы утыргычын

актарырга! Мөгаен, анда йөз процент ышаныч белән нәрсәдер булырга тиеш. Йорт төзүчеләрнең өлешкә укмашып җыйган акчасы да шундадыр. Әнә халыкны алдап, акчаларын җыйдылар да, бераз төзегәч, банкротка чыктылар. Эшләре судта. Ә керем кайда? Кесәдә. Юк, кесәгә тыгып йөрмәсләр, берәр җиргә яшererләр. Утырып чыксалар чыгарлар, ләкин халыкка кайтарып бирүне уйламаслар. Әле бит аның тагын бер җае бар: төрмәгә япкач, монда утырып, бурычын түли алмый ул дигән сәбәп белән аны чыгарачаклар. «Эшләсен, эшләп түләсен», – диярләр. Аңа нәрсә, тоткынлыктан ireккә чыккач, унбиш меңлек эшкә урнаша да, шуннан «яшәү минимумы»ннан калганын йөзәрләгән кешегә тиенләп түли һәм банкротлы теге миллионнары белән рәхәтләнеп яши.

Чыннан да, тентергә кирәк «дускай»ны дигән ныклы фикергә килде ул. Тентергә, тентергә!

Әле бит аның «Ышаныч» дигән автосалон тоткан чаклары да бар иде. Алтмыш кешегә Мәскәүдән машина кайтартам дип җыйган акчалары белән тотылган вакытларны онытмагандыр әле. Бер елга якын утырып та чыккандай итте бугай. Физик банкрот ясатып, кай арада бу эшкә урнашкан соң әле ул? Тапкан бит – нәкъ үзе шикеллеләрне эләктерә торган урынны.

«Болар белән бәйләнеп, «стрелочник» ясап куймасыннар тагы, – дип уйлады Гаделҗан кинәт. – Шулай итәрләр, гаепле ясардай кешене үзләре белән йөртәләр, дөресрәге – «эш» кушалар. Менә ни хәтле урындык актарттылар... Ә эләксәң? Читлеккә ябачаклар. Юк, коткармаячаклар, передача да китермәячәкләр».

Гаделҗанның фикере тагын да төгәлләнә төште – боларга бүтән бәйләнмәскә! Зиннәт Фәрхәтовны үзе тикшерәчәк! Ә ничек?

Инде менә ике көн буе башына бер юньле уй килми. Ми күзәнәкләрен киереп йөри торгач, өченче көнгә башын сызып, кызыклы фикер йөгереп узды. Бәлки, алар, инде корабль бата башлагач бәрелә-сугыла кая качарга белмичә, чабыша башлаган күселәр халәтендәдер?.. Фәрхәтовның Яшәү фонды директоры булып эшләүче Милләтов дигән дусты бар. Алар, әлбәттә, бу мәсьәләләр буенча фикердәшләр. Бәлки, бергә бүлешкәләп тә яшәгәннәрдер. Коткарырга кирәк «дустын».

Гаделҗан Фәрхәтов турындагы уйларының чынлыгын белү өчен, Милләтовка шалтыратып тормыйча гына, Яшәү фондына килде. Кабул итү бүлмәсендә кешеләр күп булуга карамастан, сәркатип кызга кул болгап кына сәламен бирде дә эчкә атлады. Бакса, анда Фәрхәтов белән Милләтов икесе генә утыра икән. Уйга батканнар. Гаделҗанны күргәч җанланып киттеләр.

– Ә бәлки, – дип, сүзен башлады, сәлам димичә Милләтов. – Син аңа кабинет ачкычын бирерсең...

– Нигә?

– Менә шуның өчен...

– Урындыкны алып килергәме?

– Үзең әйтәсең бит, урындык кирәк, дип. Апкилсен!

– Шәп идея!..

– Сәркатип кызың урынындадыр бит? Шалтыратып куй! Рөхсәт бир!

– Ярый да «тегеләр» килмәсә...

– Бик мөмкин...

Боларның сәер сөйләшүе Гаделҗанга аңлашылды булса кирәк. Ләкин ул бернәрсә дә аңламаган булып кыланды. Әмма Фәрхәтов янаган сыман:

– Кара аны! Бер болтигына да тиясе булма! – диде.

– Кайчан тигәнем бар, – дип җавап кайтарды Гаделҗан. Инде тугызыннан өмет булмаганны... – дигәч, сүзе өзелеп калды.

Милләтов, әлбәттә, бернәрсә дә аңламады.

– Бир ачкычыңны, йөгерсен! – диде.

Гаделҗан Фәрхәтов кулыннан бер төргәк ачкыч янчыгы алып, урамга томырылды. Аның артыннан Фәрхәтовның:

– Минем машинада шофёр утыра, элдертегез! – дигәне генә ишетелеп калды.

Алар Фәрхәтов утырган офиска килгәндә, бернинди шикләнерлек сәбәп юк иде. Гадәттәгечә, тирә-юнь тыныч, кешеләр эскәмияләрдә ял итеп утыралар, «Фәрхәтов, акчамны кайтар!» дип язылган плакат тоткан әби генә ялгыз басып тора. Гаделҗан аны элек тә күргәләгәне булды, ләкин әллә ни әһәмият бирмәгән иде. Хәзер бу әбинең халәте актуаль икәненә төшенде, шуңа күрә тукталып, аны кызганып карап торды. Һәм бераздан шофёрга:

– Үзем алып төшәм, көт! – диде дә офиска кереп китте.

Сәркатип кыз янында нииндидер хәрби киемдәге кеше сүз боламыгы ясап торган сыман тоелды аңа. Кем булмас та, кем нишләмәс, аның эше тыгыз... Ул ачкычын селкеп, кызга күрсәтте дә болай да ачык торган кабинетка керде. Урындык шунда. Озак маташырга ярамый – төбенә тибеп карады. Аннан тонык кына тавыш кайтарылды. «Нәрсәдер бар! – дигән уй бөркеп куйды Гаделҗан башында. – Тегендә хәтле барып җиткәнче актарырга иде бит... Ярый, бара-бара күз күрер», – диде.

Гаделҗан, шактый авыр урындыкны күтәреп, кабул итү бүлмәсенә чыкты. Шул арада монда берничә милиция җыелган.

Алар:

– Кая барышың? – дип, аны туктаттылар.

– Сораган җиргә.

– Кай төш инде ул? Ә бу нәрсәгә?

Гаделҗан үзенең килеп капканын аңлады. Урындыгын кире урынына кертеп куярга кушып, аны милиция бүлекчәсенә алып киттеләр.

Милләтов белән Фәрхәтов Гаделҗанны көтеп аргач, ахыр чиктә, хәлнең мөшкел икәненә төшенеп, «син мине, мин сине белмим» дигәндәй, берәм-берәм арткы ишектән чыгып шылдылар.

Бу вакытта милиция Гаделҗаннан сорау алу белән шөгыльләнә иде. Нишләп ул бу бүлмәгә кергән? Фәрхәтов аның өчен кем? Нигә кирәк булган аңа урындык? Анда керүен ул, Фәрхәтовның шәхси йомышы буенча дип аңлатты, ә менә кулына бер уч ачкыч тотып килүен һич аңлатып бирә алмады – тотылды. Дөрескә якын фаразын сөйләп бирде. Ләкин ул фараз да соңгы җөмләләрендә буталчыкка әйләнде. Шуңа күрә сөйләшү башка төс алды:

– Нәрсә урларга иде исәбең?

– Урындык.

– Нәрсәгә кирәк ул сиңа? Бүлмәдә бит кыйммәтрәк әйберләр дә бар...

– Мин аны актарырга уйлаган идем.

– Ни өчен?

– Кешеләрдән җыйган акчаның кайдалыгын белү өчен.

– Син аны шундадыр дип уйлыйсыңмы?

– Әйе.

Милицияләр урындыкны алып килергә киттеләр. Сорау алучысы җентекләп сораштыруын дәвам итте.

– Син кем булып эшлисең? Кайда?

– Мин ирекле язучы, – дип аңлатты ул үзен. – Маҗаралар тикшерергә яратам. Яңа әсәр язмакчы идем.

– Ильф һәм Петров шикелленеме?

– Шундыйракны...

– Син Остап Бендер инде алай булгач, урындык актарып, байлык эзлисең...

– Юк, мине байлык кызыксындырмый, мине түрәләрнең әхлак югарылыгы, дөресрәге – дәрәҗәсе җанны борчый.

– Димәк, син Остап ролен үтисең, җәмгыятьтән көлеп яшисең һәм шул турыда язачаксың. Шунда мине дә персонаж итеп кертәсең инде, әйеме?

– Бәлки...

Менә урындыкны да алып килделәр. Милиционерлар урындык астын кубарырга кереште. Аннан тыгызлап тутырылган ниндидер кәгазьләр папкасы килеп чыкты.

– Әһә! – диде кубаручыларның берсе. – Нәкъ без эзләгән документлар – халыкны алдаган, йортларны төзеп бетерергә җитмәгән отчётлар...

– Молодец! – диде тикшерүчеләрнең өлкән чиндагысы Гаделҗанның иңеннән сыйпап. – Син безгә зур ярдәм күрсәттең, награждениегә тәкъдим итәчәкбез үзеңне.

– Шайканың башка әгъзаларын да әйтсәң, үзебезнең сафка эшкә дә алырбыз, риза булсаң, – дип тә өстәде документларны актаручысы.

Гаделҗанга Милләтовның фамилиясен атаудан башка чара калмады. Ул:

– Милләтов, – диде.

– Аңлашылды, – диделәр.

Ул арада берничә милиция хезмәткәре күздән югалды. Аңа бу эштә шаһит булырга кушып һәм бу араларда беркая да китмәскә вәгъдә яздырып кайтарып җибәрделәр.

Гаделҗан Фәрхәтовка куркыныч янау турында кисәтеп кую кирәк дип уйлап, телефон аша белдерергә дә теләгән иде. Ләкин башына телефон тыңланылырга мөмкин дигән акыллы фикер килде. «Буласы – булган», – диде дә кичке шәһәрнең тынчу һавасын саф һавадан да яратыбрак сулап, алга атлады.

Әлбәттә, ул элеккеге партия җитәкчеләренең һәм шуларның байлыгына хуҗа булган хәзерге түрәләрнең мөлкәте кәнәфиләрендә түгел, ә башка – тагын да ышанычлырак урыннарга урнаштырылганын төгәл белә. Алар – читтә! Калдык-постыгы гына монда – илендә. Илендә, дип әйтү дә туры килеп бетми, чөнки күңелләре белән үзләре дә бу илдә яшәмиләр, ә балалары шуннан кайтып та керми, хатыннарының табышы иренекеннән күп мәртәбә артыграк. «Теләсә нишләсеннәр, ник дөмегеп бетмиләр шунда», – дип уйлады да, эченнән генә: «йокым тыныч, милкем юк, юкка – суд та, чурт та юк», – дип әйтеп куйды.

**Фаразлар... Хакыйкатьләр...**

Гаделҗан кәнәфиләр актарудан ил җитәкчеләренең киләчәк тормышы, аның ничек тәмамланачагы турындагы фаразлар белән кызыксынуга күчте. Аларның язмышы шул биләгән урыннарына, дәрәҗәләренә бәйле инде. Ул байтак банкирларның, ил башлыкларының хакимияттән ничек ваз чиктерүләрен искә төшерде.

Үзенең соңгы елларда мәгънәсезгә кылынып йөргән гамәлләрен башыннан кичереп утырды. Ярый әле соңгы хакимнең кәнәфиләрен актарудан бәхетле очрак – хокук саклау органнарының боларның чынга ашмастай ниятләренең эзенә төшүләре булышты. Баксаң, ныгытыбрак уйласаң, соңгы кәнәфиләрне тикшерәсе дә юк икән бит. Партия байлыгы, Ильф һәм Петров әсәрендәге кебек ниндидер «тёща» урындыгына тегелмәгән ул, табылып, Пионерлар сараена гына түгел, яңа Болгар шәһәре булып, яңадан торгызылган.

Соңгы елларда гына исемнәре милициягә үзгәртелгән хакимият сакчылары Гаделҗанны тынычлыкта калдырдылар. Күрәсең, әлеге җинаятьчеләр бандасында ул бик бәләкәй «чәкүшкә», көннәр арты көннәр тынычлыкта үтә торды. Һәм ул хәйләле ысуллар белән җиңел генә комарлы уйларын тормышка ашыру максатыннан ваз кичте. Юкка Зиннәт йогынтысына эләгүенә үкенеп куйды. Ә бит никадәр изге хисләр кайный иде уенда. Күпме көч түгеп язылган пьесалары, җырлары, шигырьләре өстәл тартмаларында тузып ята? Яраткан шөгыле – концертлар, очрашулар өзелеп калган шушы кәнәфи маҗаралары аркасында?.. Өйләнелмәгән, гаилә корылмаган, өй салынмаган, агач утыртылмаган, бала үстерелмәгән, ягъни ир кешенең бер генә вазифасы да үтәлмәгән. Аның йөрәге сыкрап куйды. Әллә бу ялгышуларның, дөрес яшәмәүләрнең, кылынган гөнаһларның беренче кисәтүеме?.. Ул, күзен йомып, тын алырга куркып торды. Менә сиңа мә!.. Тамагын ачы төер ярып үтте. Аның янында бөтен дөнья әйләнә түгелме?.. Укшыта... Маңгайда салкын тир... Әти, әни... Китә, китә бит ул... Бармак очлары, чигәсе чымырдый... Гаделҗан хәлсез кулларын өстәлгә сузды, башын шунда салды.

Күпме шул халәттә ятканын хәтерләми. Аңына килгәндә, кулларының һәм башының уң ягы оеганын аңлап уарга тотынды. Исән икән бит, исән икән!..

Шулчак ишеккә шакыдылар. Күршедә яшәүче Рамилнең хатыны Айгөл икән, яшь баласын күтәреп, хат сузып тора.

– Гаделҗан абый, вахтёр апа бирергә кушты. Сиңа, нишләптер үзе күренми, кайткач ук тапшырырсың әле, диде.

Ул калтыранган кулы белән хатка үрелде.

– Абый, авырыйсыңмы әллә, йөзең дә агарган, кулларың да?..

– Әллә нәрсә булып алды әле, үзем дә аптырадым, салкын тиргә батып уяндым...

– Кан басымың төшкәндер... Хәзер даруын бирәм.

Айгөл бүлмәсенә йөгерде. Гаделҗан караватына ятты. Гәүдәсендә һаман хәлсезлек. Тиз арада шәфкатьле күршесе стаканга су салып, даруын да алып керде.

– Йот менә шуны! Хәзер рәтләнерсең.

Гаделҗан аны, рәхмәтен әйтеп, озатып калды. Ашыкмый гына конвертны ачты һәм анда:

«Хөрмәтле дустым Гаделҗан! Сине бүген булачак «Юлбашчылар уены» премьерасына чакырам. «Килми калма!» – дигән язу иде. Астарак: «Даһи», – дип тә куелган.

Гаделҗанның йөзенә кызыллык йөгерде. Күкрәгендә җылы рәхәтлек бөркелде. Күзләрен шатлык яшьләре басты. «Барам, барам, Даһи дус!» – дип, үзалдына сөйләнде ул, бертуктаусыз. «Барам, барам... – Ничек шулай булган соң әле?.. Ничек кыюлыгы җиткән?..»

Гаделҗан сәгатенә карады. Инде җыенсаң да була икән. Алданрак күрешү кулайрактыр. Күптәннән киелмәгән, аны сагынып көткән кәчтүме дә бераз картаеп киткән кебек тоелды аңа. Элгеченнән алып караганнан соң, бөгәрләнеп беткәнлегенә игътибар итте, күршесе – Айгөл янына кереп:

– Айгөл үскәнем, вакытың юктыр инде дә, менә моңа карале, нинди хәлгә килгән, үтүкләп бирче, театрга чакырганнар, – диде.

– Хәзер рәткә кертәбез без аны. Бүген иң кәттә егетләрнең берсе булырсың театрда, Гаделҗан абый! Унсигездәге кебек итәбез сине.

– Илле тулса дамы?

– Өйләнмәгән ир – егет бит инде ул.

– Егет түгел – буйдак.

– Менә булды да...

– Үтүк алмый булмый инде үземә...

– Хатын да ал, үтүк тә, яме, Гаделҗан абый. Нинди спектакль карарга чакырганнар соң?

– Үземнекен.

– Кит аннан!

– Әйе.

– Безне дә чакырырсың әле, берәр вакыт.

– Әлбәттә. Башта карыйм әле, ни кырдылар икән...

– Син шундый әсәрләр дә язасыңмыни?

– Күптәнге пьесаны казып чыгарганнар, белмим, гомере озакка барырмы? Шикләнәм. Ярый, Айгөл, ашыгам.

– Уңышлар телим сиңа, Гаделҗан абый!

– Рәхмәт.

* * *

Ул театр каршына элеп куелган «Юлбашчылар уены» афишасын еракган ук күреп алды. Гадәттә, премьераларны лозунг шикелле итеп, зур хәрефләр белән язып, шулай элеп куялар иде. Пьесаның авторы Кушамато Шамун дигәне дә, режиссёрының Даһи икәнлеге дә талгын кына искән җилдә дулкынланып тора. Шул дулкынга Гаделҗанның да күңеле иярде, ахрысы, туктап хисләнеп алды, күзләрендә сөенү чыклары, йөзендә шатлык нурлары җемелдәде. Нихәтле тормыш киртәләрен үтеп, өмет чаткыларын югалтып, максатларының чынга ашмаслыгына күнгән чорда атылган бәхет билгесе бит бу мизгел! Театрның парад ягындагы киң баскычыннан атлаганда, ул аякларында хәлсезлек сизде. Әйе, сөенечтән буыннар йомшый, ә

нәфрәттән – катылана икән. Гаделҗан, үткән гомереңнең гел аяусыз көрәштән торганлыгын тагын бер мәртәбә күңеленнән кичереп, андагы күп гаделсезлекләргә каршы җаны-тәне белән яңадан ачуын кабартып, ныклы адымнар белән дусты янына атлады.

Даһи аны күптән көткән шикелле каршысына чыгып килә иде. Алар, гадәттәгечә, кул бирешеп кенә түгел, кочаклашып күрештеләр. Режиссёрның беренче сүзе үк шаяру катыш җитди булып чыкты:

– Үсеп беткәнсең инде!.. Нихәлләр, Кушамато Шамун?!

Гаделҗан үзен тыйнаграк тотарга тырышып:

– Кем белән исәнләшәсең син? – дигәндәй, аптыраган кыяфәт ясады.

– Ярый, кыланма! Мин сине һәр җөмләңнән, сүзеңнән генә түгел, уеңнан, мөмкинлекләреңнән, талантыңнан таныйм, сулышыңнан сизәм. Менә, ниһаять, әсәреңне халыкка тәкъдим итәргә уйладым. Беләсең, шәхес, бигрәк тә сәнгатьтәгесе, күп эшләр башкарырга мөмкин, ягъни бөтен гомерен сәхнәгә багышлар, шактый гына катлаулы пьесалар куяр, көчле һәм дәвамлы алкышларга күмелер, әмма үзеннән тамашачының ушын алырлык, күңеленә, акылына өмет, рухи максат, яки йоклаган җанын уятырлык, тапталган намусына сихәт бирерлек, милләтенең бөеклеген аңлатырлык әсәр тудыра алмас. Бу мәсләкнең барысын да үз эченә алган әлеге пьесаны куйсам, үз башым кыелырга мөмкин икәнен белә торып та, халыкка тәкъдим итәргә булдым. Ятарга тиеш түгел ул өстәл тартмаларында. Афәрин! Бергә булыйк, бердәм булыйк! Моңарчы үз арабыздагы дуслыкның чынлыгын исбатлаучы нәрсә – шуны – «Юлбашчылар уены»ның сәхнәгә менүе.

– Рәхмәт, Даһи дустым! Исемең җисемеңне аклый!

Алар кул бирештеләр.

Зал шыгрым тулган, басып карарлык урыннар да юк. Ике дус, үзләренә билгеләнгән аерым кәнәфиләргә барып утырдылар. Утлар сүнде. Яшен яшьнәгән, күк күкрәгән, ялт-йолт килгән нурланышлар, җемелдәүләр астында пәрдә ачылып китте. Анда, әле бер якка, әле икенче якка халык агымы бик тә борынгы моң астында, бөек күчеш чорларын чагылдырып, җан тетрәндереп, вакыйгалар алышы башланды. Бу манзараның үтә катлаулы хәрәкәтләр белән башкарылуы халыкны таң калдырды. Аларның алкышлары сәхнәдәге шауга кушылып, тасвирлану куәтен тагын да көчәйтте. Гаделҗанның: «Бу минем пьеса буенча куелган сюжетлар микән соң», – дип шикләнә башлаганын сизеп, Даһи:

– Хәзер, хәзер, синеңчә китәчәк! – дип, колагына пышылдады.

Ике дусның да спектакльнең уңышлы үтәсенә шиге юк иде. Тамашачы әле тын алырга куркып, әле үзен-үзе белештермичә онытылып-онытылып, ярсый-ярсый кул чабып, кыяфәтен югалтып көлеп утыруын алар шул уңышка ниятләделәр. Бары тик зал уртасындагы рәттә утыручы хакимияттәге кәттә кешеләр генә куркулы караш белән тирә-якларын күзәтә иделәр.

Спектакль тәмам. Тамашачы дәррәү күтәрелеп, автор һәм режиссёрны сәхнәгә чакырдылар. Даһи Гаделҗанның кулына сугып:

– Әйдә, нишләп утырасың, – дип куйды.

– Мин бит, мин бит...

– Әйдә, дим. Күрсәтермен, Кушамато шушы, дип!

Алар сәхнәгә менеп бастылар. Халык залдан күтәрелеп, чәчәкләр бирә башлады. Тамашачы Кушамато Шамунны чакыра:

– Ку-ша-ма-то! Ку-ша-ма-то!

Даһи, залга тынычланырга кушып, кулын өскә күтәрде.

– Хөрмәтле тамашачылар! Сезнең каршыда басып торган менә шушы шәхес – минем авылдашым, классташым Гаделҗан Аетов – бу пьесаның авторы Кушамато Шамун була!

Зал яңадан алкышларга, ә Гаделҗан чәчәккә күмелде.

Пәрдә ачыла да ябыла, ачыла да ябыла. Артистлар, горур күкрәкләрен киереп, әле алга, әле артка чигенә. Алар – чәчәктә... Күңелләре, әйтерсең лә, бәхетле, шатлыклы киләчәккә ашкан...

Икенче көнне Гаделҗан дөньяга яңадан тугандай уянды. Озак йокланылган. Тәрәзәне ачты. Телевизорын кабызды. Күктә Кояш көлә. Яңалыклар бирәләр. Сюжет театрда узган кичәге спектакльгә күчте. Анда баш режиссёрның алышынуын әйттеләр.

Гаделҗан калтырап куйды. Тиз генә телефоннан Даһиның номерын җыеп:

– Даһи, нинди хәбәр ул?.. – диде.

– Әйбәт хәбәр. Эшләгәч-эшләгәч, менә шундый эш күрсәтергә кирәк! Моңа хәтле мине кем белде? Менә хәзер бөтен дөнья беләчәк! Борчылма, Гаделҗан дус, мине бик күп башка театрларга чакыралар. Бармы тагын шундыйрак пьесаларың?

– Бар.

– Китер! Рәхмәт сиңа!

Ул, пьесаларын күтәреп, дусты янына очты.

### Соңгы мизгел

Даһи кабинетыннан чыкканда, Гаделҗанны таныш булмаган егет көтеп тора иде.

– Исәнмесез! – диде ул корырак, ләкин зур дулкынлану белән. – Әнинең кырыгын үткәрдек, Язилә исемле. Үләр алдыннан әйтте: «Синең әтиең менә шундый-шундый кеше», – дип. Исемем – Насыйп. Кабул итәсеңме мине улың итеп, әти?

Гаделҗан, ни әйтергә белми, аңа мөлдерәп торган күзләре белән карап торды да кочагына кысып: «Улым!» – дия алды. Чыннан да, аның каршында үсмер чактагы тач үзенә охшаган егет басып тора иде...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең 75 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Без аңа исәнлек-саулык, әдәбият сөючеләрне яңа әсәрләр белән шатландыруын теләп калабыз.*



Фәүзия
Солтан

# САЛ ХӘСРӘТЕҢ ТИРӘН ДӘРЬЯГА...

## Телем

Акыл әйтә: тукта, сабыр ит, ди,
Уйлап әйт, ди, әйтер сүзләреңң.
Сүз генә бит. Оча – китә алар.
Тота алмый калам үзләрен.

Уйлагандай гына буламын да,
Әйтеп куям кирәк-кирәкмәс.
Үз телеңә хуҗа булалмасаң,
Тыныч тормыш һич тә эләкмәс.

Әйтсәгез лә миңа кайчакларда,
Бар бәлаң бер – шушы телең, дип.
Сизми каласызмы, ә мин сезгә
Тик яхшылык кына телим бит.

Әче чакларым да бик буладыр,
Төрле хәлләр була дөньяда.
Үз телем бит, нишлим, әмма һәрчак
Әйтер сүзем минем өр-яңа.

## Баллы миләш

Дивардагы рәсемемнән миңа яшьлегем карый.
Җитди, сынаулы карашы киләчәгемне барлый.
Бик еракта калган инде чәчәкле унсигезем.
Суык баллаган миләштәй каршылыйм гомер көзем.

---

Фәүзия СОЛТАН (1958) – *шагыйрә, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты; «Учларымда – җиләк», «Күзге шәфәкъ», «Нигез сагышы» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Баш иелгән

Иелгән башны кылыч кисмәс, диләр,
Иелмәсәң – башсыз калырсың.
Шулай да бит... Күккә баш чөймәсәң,
Бу дөньяны ничек танырсың?

Шулай да бит... Яз утырткан идем,
Чәчәк аткан икән гөлләрем.
Шул гөлләргә үрелгәндә генә
Баш иелгән икән – белмәдем.

## Җан сафлана

Яшьни яшен, күкләр күкри, яңгырлар ява.
Җир һәм күк бергә кушылган, сафлана һава.
Җаннарны да чистартырга
Күк күкрәү һәм яшен кирәк.
Күңелләрдә җыелып, күпме юшкын кала.
Хакыйкатьне табу өчен,
кайчак шундый халәт кирәк:
Яшьнәсен яшен, күкрәсен күк – җан сафлана!

## Әткәй керә төшемә

Әткәй бик еш керә төшләремә,
Ир уртасы – матур чаклары.
Ак оекбаш, яшел эшләпәдән,
Нык адымнар беләп атлавы.

Су китерәм аңа чишмәдән мин –
Ишек ачып көтеп тора ул.
Сөртенмә, дип, палasларны рәтли,
Өйгә дәшеп, тамак кыра ул.

Рәхәт чаклар, табын тулы муллык –
Уянгач та аны сагынам...
Күзем йомып китәр идем тагын
Шушы йортка – әткәм янына.

Бүген тагын әткәй төшләремдә
Сөя мине, кысып куенына.
«Авырлыкка, кызым, бирешмә, – ди, –
Бәхетле бул барыр юлыңда».

Уянам да, әткәй юк янымда,
Китеп барган безнең арадан.
Төшләремә кереп кисәтә ул
Авырлыктан, хәсрәт, бәладән.

«Әнкәң белән бергә чәй эчтек, – ди,–
Тамагым тук, ризыгыбыз – мул».
Юрап куям: алар разый, димәк,
Догаларым булгандыр кабул.

## Суга сал сагышыңны

Елмаюың – кояш балкышы,
Күз карашың моңсу, сагышлы.
Гомер юлың авыр уздымы?
Тормыш җиле бик тә тозлымы?

Очкын чәчеп ала бер мизгел
Күз карашың. Бетсен сагышың.

Сал хәсрәтең тирән дәрьяга,
Алып китсен сулар агышы.

Елмаюың белән балкып тор,
Җан сөенсен синең караштан.
Һәр минутта әйтик сөенеп:
«Дөнья ямьле! Яшим! Яратам!»

## Нигез сагышы

Килдем әле менә туган йортка,
Ачып кердем бикле капкасын.
Беләм инде, кайттыңмы, кер, диеп,
Әнкәй бүтән тәрәз какмасын.

Капка төпләренә кар өелгән,
Тәрәзәләр сукыр. Бозланган.
Алар аша юлга карап, көтеп,
Безне сагынып әнкәй сызланган.

Әвеслектән, сәнәккә таянып,
Әткәй чыгар кебек күңелгә.
Аяк арасыннан песи үтәр,
Абзарында сыер мөг(е)рәр...

Шыгырдатып ачтым ишекләрен,
Яме дә юк өйнең, җаны да.

Матчадагы Коръән кемне көтә?
Почмак сәке кемне сагына?

Билдән карны ерып китеп барам.
Тагын кайчан кайтып күрәсе.
Кыектагы бозның сөңгесеннән
Тамчы тама... Өйнең күз яше.

## Көрәш

Ак төс хуҗа бүген дөньяга –
Кар юрган ябынды Җир-ана.
Йокыга талган ул, ял итә,
Көч җыя киләсе язларга.

Ак карга күмелеп оеган –
Агачлар йокыга талганнар.
Җир-ана куеныннан сут җыеп,
Язларда уяныр алар да.

Үзәккә үтүче кышкы җил
Сыкратып башларын идерә.
Тик юкка... Бирешми агачлар –
Җир-ана аларга көч бирә.
.......................................
Таралып сибелгән татарлар
Бирешми зилзилә-туфанга.
Тамыры, нигезе, туфрагы
Көч бирә һәр туган оланга.

## Шул рәсемгә баккан уйларым

Мәһабәт ир, сылу хатын анда –
Тотынышкан кулга кулларын.
Өстәлемдә минем – фотосурәт,
Шул рәсемгә баккан уйларым.
Ир һәм хатын... Пар аккошлар гүя.
Сөю назын сирпи карашлар...
Аккош булып очар кебек алар,
Иңнәрендә әллә канат бар?
Әй, очасы килә алар белән,
Их, менәсе килә югары.
Һәм беләсе килә: кая илтә,
Сөю канат биргән юллары?

Өстәлемдә – сурәт. Шуңа багам,
Таң тууга яңа көн белән.
Бу сурәтнең серен беркем белми,
Аның серен бары мин беләм!
Шул сурәткә карап сизми калдым
Уйларымның ерак киткәнен...
Кеше шулай сизми кала, диләр,
Яшьлегенә кайтып җиткәнен.
Мин сурәткә карыйм, ә ул миңа
Карый кебек өметләндереп.
Дәртләндереп, ымсындырып бага
Һәм кабатлый: сөю мәңгелек!

## Җаның барда сөю калыр

*Мин сөюне күмдем йөрәккә...*
Газинур Морат

Сөюеңне йөрәгеңә күмеп,
Озак яши алырсыңмы?
Йөрәгеңдә сөю булыр,
Күз алдыңда торыр сыны.

Күмү булыр микән соң ул,
Йөрәгеңдә сөю булгач.

Типкән саен, кан йөреше
Саныңа көч биреп торгач.

Салмак кына вөҗүдеңне
Сөю хисе чолгап алыр.
Күмгән булып азапланма –
Җаның барда сөю калыр.

## Төшләремдә яшим

Төшләремдә яшим синең белән,
Ә өннәрем – тоташ соры көз.

Шыксызлыгы көзнең – ялгызыма,
Төннәремдә тагын бергә без.

«Тик мине күр төшеңдә», – дип, миңа
Әйткән идең саубуллашканда.
Төшләремдә йөрим синең янда,
Югаласың таңнар атканда.

Уянам да, тагын синсез көнем,
Дөнья мәшәкате иңемдә.
Ярый әле татлы төшләрем бар,
Сындырмаска мине өнемдә.

Хыялыйлар шулай яши икән –
Төшләреннән көнгә көч алып.
Чынга ашса иде шушы төшләр,
Бәхет өчен яңа юл сабып.

## Үлчәү

Сүзне үлчәп сөйләп кенә узып булмый гомерләрне.
Кызасың да, очкын оча, кала аннан күмерләре...
Күмердән кала салкын көл, утсыз көйри бары йөрәк.
Хисне үлчәүләргә салып, сүндермичә яшәү кирәк.

## Парлылар

Пар күгәрчен үз итте дә оя корды кыекта.
Бик матур фалдыр – яшәрбез күгәрчендәй бу йортта.
Шул көннән соң гел күзәтәм – яши алар гөрләшеп.
Быел язда әллә каян килде бер ак күгәрчен.
Килә, китә, тагын куна... Күгәрчен, ник киләсең?
Нинди хәбәр алып килеп, миңа сабак бирәсең?

## Ирләр

Сездән башка нишләр идек бу дөньяда? –
Янмас идек, көймәс идек, сөймәс идек.
Яшәүнең һич яме юк бит, сез булмагач,
Сездән башка утка-суга кермәс идек.

Янган утка керә, диләр, хатын-кызны...
Ут ягучы, дөрләтүче сез бит аны.
Чапкан атны туктатучы хатын-кыз ди,
Чабучы ат сез түгелме, ир затлары?

Хатын-кызны чәчәк-гөлгә, назга күмеп,
Алиһәм дип иркәләүче – ир-ат булыр.
Сагыш-хәсрәт, күз яшенә күмүче дә,
«Убырлы», дип сүгүче дә ир-ат булыр.

Сер бирмичә йөргән була хатын-кызлар,
Күңелләрен аңлый белер йөрәк кирәк.
Иңнәренә башны куеп сыенырга,
«Юньсезем», дип сагынырга да ир-ат кирәк.



Ландыш Әбүдәрова

# КАРА КАПЛАН[*]

ХИКӘЯ

*«Әгәр татулашып була икән – татулаш, юк икән – көрәш киемнәрен ки дә билбау тотып көрәш».*
Йосыф Баласагунлы
«Котадгу белек» (XI гасыр)

## Беренче тарих

Агыйдел төн караңгылыгына күмелеп, күктә йолдызлар кабынырга да өлгермәде (нибарысы унбишләп кенә йолдыз күренсә күренгәндер), офык чите ястү намазы алдыннан була торганча алланып та килә башлады. Төннәр якты вакыт, хәтта ки җәядән аткан ук ераклыгында кеше торганны абайлап була. Ай да күк турысына ук менеп тормый, яртысына кадәр җитеп, кырыйда берәр сәгать чамасы эленеп тора да офык сызыгын күзәткән арада юкка да чыга.

Таң атканда, Агыйдел үзе дә алсу-кызыл төскә манчыла. Кояшы да бит аның болыт кадәр, олы шар булып тәгәрәп килеп чыга. Чыга да кызыллыгын шактый вакыт җуймыйча тора.

Бу якларның кырыс табигатенең оҗмахка тиң бер фасылы бар, дисәләр – ул да булса, елның шушы иң озын көннәредер. Әнә шундый көннәрнең берсендә бу җирләргә аягын нык терәп яшәүче халык эштән арынып, тугарылып, кинәнеп, бер бәйрәм итеп ала. Бүген – шундый көн. Бүген – Сабан туе.

Барыс төн йокысы белән туеп, таң сызылганны күзәтергә дип, гөлбакчада күтәрмәгә куелган чыбылдыгының бер читен генә күтәреп чыкты да күлмәк-ыштаннарын, йомшак сафьян күннән теккән өр-яңа читекләрен киеп, ак

[*] Кара Каплан – төрки халыкларның сугыш сәнгате. Ул билгеле булган барлык сугыш коралларын (ук, кылыч, сөңге, хәнҗәр һ.б.) куллана белү техникасын; көндәшеңне җиңү өчен кул астында булган әйберләрне куллану техникасын; кул сугышы техникасын; яшертенлек техникасын; ат асрау буенча белемнәрне һәм атта йөрү, ат чабышы техникасын; чыдамлылык, исән калу, үз-үзеңне контрольдә тоту техникасын; теоретик белемнәр һәм рухи үсешкә китерә торган практикаларны үз эченә ала. Кара Капланның төрле дәрәҗәләре, шул исәптән һәркемгә мәгълүм булмаган серләре дә бар.

таш түшәлгән сукмактан елга буена төшеп китте. Сабан туе иртәсенең ләззәтен күбрәк татып калырга иде исәбе. Таңнан ук Агыйдел суында коенып, тәнне язып алсаң, шифасы көн буена җитәрлек була, аруның ни икәнен дә белмисең. Барыс колачын киң алдырып, елга уртасына ук йөзеп керде дә ярга борылып туктап калды.

Үзәкләрне өздереп, чут-чут килеп сайраган былбыллар, су өстеннән тәгәрәп искән таң җиленә толымнарын сүтеп салган иркә таллар, зифа камышларның талгын пышылдашуы – Агыйделнең буеннан-буена моң җәелгән, еламыйча, җырламыйча түзеп кара! Сөекле хатыны Карлыгачы боларны күрсә, һичшиксез, шатлыгыннан күз төпләренә бөялгән яшь тамчысын күрсәтмәс өчен озын керфекләрен түбән төшерер, бит алмаларына алсулык йөгерер, озын толымнары уйнаклап алыр, шул вакытта ул дөньядагы гүзәлләрнең шаһинәсе булып күренер иде. Барыс аны уятырга базмады: хатын-кыз өчен таң йокысы кирәгрәк, чөнки ул иртәгәсе көнне хәстәрләп, иң соңгы булып ята. Карлыгачын исенә төшереп, ир елмаеп куйды. Ыруларының Алып батыры Барысның үзенә охшаган нинди уллар табып бирде бит! Нәсел-нәсәп терәкләре булып үсеп киләләр әнә. Буласының бишегеннән үк күренә, малайлары бишектә чакта ук кулларына эләккән әйберләрен күтәреп чөя иде. Нәни генә куллары белән эләктереп алуларына караганда, беләкләренең юан буласы әллә каян билгеле иде.

Барыс ел буе ир балаларын Сабан туендагы ярышларга әзерләде. Бүген алар башка малайлар белән бер тигездән колгага менеп, аркан тартып, чүлмәк ватып, кашыкка йомырка салып йөгереп караячак. Нәкъ менә быел ул аларның Кара Капланга әзерлеген сынамакчы. Сабан туе – егетлеккә сынала торган чак. Вакыты җитте, батырларны бәләкәй җиңүләрдән әзерли башларга кирәк. Быел җиңмәсәләр, җиңелүләрдән башларлар, әүвәл аның файдасы күбрәк тә булырга мөмкин.

Кашыкка йомырка салган көенә, аны ватмый-нитми, беренче булып килә икән – димәк, анда капланга хас сыгылмалылык, җитезлек, төгәллек бар. Күзен бәйләгән килеш чүлмәк вата икән, димәк, әйләнә-тирәне караңгыда да тоя ала. Ат ярышын, аркан тартуны әйткән дә юк – көч, елгырлык билгесе. Капчык киеп йөгерсә, колгага, кыек баганага менсә, тигезлекне саклый, гәүдәсенә үзе хуҗа дигән сүз. Ә гәүдәңнең үзеңнеке булуы – ул ирек дигән сүз. Гәүдәсенә үзе хуҗа булмаган адәм баласы кол инде ул, тагын кем? Юк, улларына кол язмышы теләми ул, моңа юл да куймаячак.

Әнкәләре дә ир балаларының алып гәүдәле әтиләре кебек булып үсүләрен тели: иртәдән кичкә кадәр учак, казан янында кайнаша. Тәмле булсын дип кенә түгел, файдалы булсын дип әзерли. Ага-базарга барганда, Барыска җиде дәрья кичеп килгән әллә нинди үләннәр, тәмләткечләр алып кайтырга кушып җибәрә. Тыйб гыйлеменә дә осталыгы бар үзенең.

Барыс татлы уйларына бирелеп, аръякка йөзеп чыгуын сизми дә калды. Ярга чыгып, сулу алыйм әле дип аяк басуы булды – нәкъ каршына җәядән атылган бер ук килеп төшеп, ярның кызыл балчыгына кадалды.

«Баскынчылар!» Башыннан сызылган беренче уй шушы булды ирнең. «Сабан туенда!» – бусы икенче уе. Хәер, сине буйсындырып тезләндерергә, байлыгыңны таларга килгән дошманыңнан хәерхаһлык көтү артыгы белән беркатлылык булыр иде. Бәйрәм үткәнне көтеп торса, дошман саналамыни ул?

Ул шулай ук каплан җитезлеге белән суга сикерде һәм кондыз кебек су астыннан гына бу якка йөзеп чыкты. Тиз генә киемнәрен киеп, биленә билбавын да урап куйгач, «Мин сөйләшергә әзер!» дигән кебек яу каршына килеп басты. Тын да алмый күзәтте бу сәер кешене дошман гаскәре. Һәрхәлдә, Барысның кыланмышлары аларга сәер тоелды.

Сөйләшү кыска булды. Ике аягы белән дә җиргә нык басып, курыкмыйча, ике уйларга урын калдырмаслык итеп сөйләште Барыс.

– Без – җир кешеләре. Җиргә береккәнбез. Әле монда үзем генә булсам да, без бердәм. Чәк-чәк кебек. Иген игеп яшибез. Без беркайчан да сугышмыйбыз, әмма без көрәшәбез. Шушы җир – ул иелеп, учына туфрак алды, – туган җир хакына соңгы тамчы канга кадәр көрәшәчәкбез. Шуның өчен яхшы чакта сез әүвәл минем белән көрәшеп карагыз. Әгәр мине җирдән аерып ала аласыз икән, бу җир дә, байлыкларыбыз да – сезнеке. Юк икән, бигайбә, мин әйттем! – диде Барыс, чабаталы гаскәрнең каршына берүзе басып. Сүзен әйтүгә ул тынып калды. Ике арага тынлык эленде һәм бер мизгел үттеме-юкмы, ул шартлап ярылды: теге як ук-җәясен, сөңгеләрен селкетә-селкетә шаркылдап көлә башлады.

Әмма Барыс аларны ишетми иде, ул нәкъ кендек турысында бер гайрәтле көчнең гүләвен тоеп алды. Ул көч тимерче мичендәге ялкын сыман дөрләп кабынды да тиз арада чүлмәкче мичендәге кебек кайнарлыкка җитеп, аның бөтен тәнен чорнап алды. Озакламый ул бармак очларына килеп җитте, куллар йодрыкка төйнәлде. Бармак араларыннан очкын чәчрәп чыкты. Барыс каш астыннан сөзеп кенә, яу башлыгына карады. Тегесе утлы карашның кызуыннан куырылып килде, көлүеннән кинәт туктады, хәтта ки артка чүгеп куйды һәм башкаларга да тын калырга боерды.

– Синеңчә булсын, – диде ул, Барысның күзләренә туры карарга тырышып. – Көрәшеп карыйк. Син берәү генә, без күп. Хәлең беткәч, барыбер җиңелерсең.

Әмма Кара Каплан рухы биләгән Барысны җиңәрлек көч булдымы икән ул көнне? Алып батыр Барысның аяклары җиргә береккән кебек, аерып алырлык түгел. Ул көрәшкәндә, читтән карап торучылар аның җитезлегенә, елгырлыгына, осталыгына, хәрәкәтләренең зәрканчыларныкы кебек төгәллегенә, сыгылмалылыгына, уйланганлыгына сокланмыйча булдыра алмады. Сандалга салып чүкегән кебек әйләндереп кенә сала барды аларны Барыс. Тегеләре таудан түбән тәгәрәгән чүлмәк кебек тәгәрәп чыгып, мәйдан тирәли тезелешә бардылар. Көрәшкә кергән берсе хәле бетеп егыла, ә бу Алыпка көч өстәлә генә кебек. Ул күзгә күренеп зурая, гүя һәркайсының җелеген суырып, үзенә ала бара. Ә инде билендәге сөлгесен дә алып, бер очын кулына да урап тоткач, тегеләр ягыннан бергә-бер чыгарга теләүче калмады. «Без күбәү, күмәкләшеп юк итик!» – дип шаулаша башлаганнар иде, гаскәр башы аларны ым кагып кына туктатты.

– Әгәр сез барыгыз да шундый икән... – диде ул, батырга карап.

– Барыбыз да. Алтыдан алтмыш яшькәчә. Без сугышмыйбыз, без көрәшәбез! Шушы җирдә яшәү өчен, ярату хакына, балалар хакына! – дип, нокта куйды Барыс бу алышка.

Агыйделдә колмак йөзеп, таш батты бу мизгелдә.

## Икенче тарих

Сабан туйлары җитә башласа, Хәсәнне эчтән ут ялмап ала. Башта кендек турысында әйләнә ул, тора-бара күкрәгенә менә, беләкләренә төшә, бөтен тәненә үрли. Бәләкәй чагында малай бу утны танымый, төннәр буена саташып, манма тир булып, бәргәләнеп чыга иде. Әнисе төн буена улының маңгаен салкын чишмә суында чылатып, чүпрәк белән сөртеп чыга. Сабан туйлары үтүгә үзеннән-үзе бетә шушы зәхмәте. Тәмам аптырадылар шушыңа, ник бер дәвасы булсын! Ел әйләнәсе үзен бер дә сиздерми, җәй җитүгә ега да сала малайны. Бер даруның шифасы да тимәгәч, Хәдичә өшкерүчегә алып барып карыйк дисә дә, әтисе Хәйрулла коммунист булгач, андый ырым-шырымга ышанмады. Шулай да Хәдичә ел саен Сабан туе вакытында улының чирләп ятуына эче пошып, кача-поса гына, улын сукыр Сабир картка алып китте.

– Көрәшче бит синең бу малаең! – диде Сабир карт, Хәсәннең күрешергә сузган кулын кысып карауга. – Эчендә көрәш уты яна моның. Сүндермә ул утны, батыр бул!

Хәсәнне алыштырып куйдылармыни?! Чирләшкәдән батырга бер адым: туп-туры Сабантуй мәйданына атылды ул. Җиде яшендә беренче тапкыр чордашлары белән көрәшеп карады, кемнедер җиңде, кемнәндер җиңелде. Батыраеп китеп, үзеннән яшькә дә, гәүдәгә дә олырак Җәмилгә каршы чыкты. Икесе дә бер авылда туып, бер чишмә суын эчеп үскән малайлар. Җәмил олы була белде, егып салгач юатырдай сүзен тапты: «Син беренче генә көрәшкә керсәң дә, җиңүләрең бар. Беренче елны мин берәүнең дә билен ала алмаган идем!» – диде. Моны ишетүгә Хәсәннең күзләрендә мөлдерәгән яшьләре шундук кипте. Шушы сүзләр егылгач торырга курыкмаслык көч бирде. Әтисе Хәйрулла да өйгә кайткач, Хәсәнгә беренче тапкыр катнашкан өчен бүләк итеп бирелгән бәләкәй сөлгене түргә элде. Булачак көрәшче малае белән горурлануын шулай белгертте. Мәйданда күзәтеп торды: малайда көрәшчеләрдә була торган бер чаткы бар, сүндермәскә кирәк. Басып торышларына кадәр алдан өйрәтеп куйган кебек, югыйсә көрәшне беренче күрүе. Әтисе: «Улым, син тәпи атлап киткәндә, гел егыла идең. Егылгач, торырга курыкмый идең, егылуың турында уйлап та карамый идең», – дип искә төшергәндәй, кыеклатып әйтеп куйды һәм Хәсәннең аркасыннан кагып алды.

Әнә шул рәвешле Сабан туйлары Хәсән өчен ел саен түземсезләнеп көтеп алына торган бәйрәмгә әйләнде. Кендек турысындагы ут та тора-бара идарә ителә торган көч чыганагына әйләнде. Хәсәннең бик борынгыдан килгән нәсел-нәсәбендәге кан үзе турында шулай белгертә, шул аны мәйданга алып чыга, тыныч, мул, иректе тормышта яшәүнең бер шарты булган бил алышта катнашырга чакыра иде.

Җиңүнең дә, җиңелүнең дә тәмен күп татырга туры килде аңа. Җиңүче бер сыналса, җиңелгән ике сынала. Җиңелгәндә, бик гарьләнсә дә, җиңүченең хаклыгы, көрәшнең чисталыгы, киресенчә, аны колагыннан тартып торгыза; иреннәрен кысарга мәҗбүр итсә дә, колачын кыршау кебек ныклы итәргә, күңелен киң тотарга өйрәтә иде. Көрәш мәйданы аннан алмаз ясады, булат итеп чыныктырды. Аңа сукыр Сабир карт юл

күрсәтсә, әткәсе Хәйрулла фатихасын бирде, кордашы да, көндәше дә Җәмил үзе белгәннәрен өйрәтеп, көрәш серләренә төшендерде. «Көндәшең үзеңнән көчлерәк булсын», – дип әйтә торган иде. Сабан туе мәйданы исә теләктәшлек белдереп, көч биреп торды. Шул рәвешле, балигълык яшенә җиткәндә, тирә-як авылларда Хәсән батырга каршы торырдай көрәшче исеме башка юк иде диярлек. Тиңе юк көрәшче, яшь комбайнчыны бөтен район халкы данлады. Һөнәрне дә ата-бабаларының мирасына тугры калып сайлый белде Хәсән: игенче булды. Иксез-чиксез иген кырларына комбайн түбәсенә менеп карап торырга ярата ул. Штурвал артыннан җиргә сикереп төшә дә җиргә башын игән тук башакны ала, ышкып, бодай бөртекләрен киң учларында тәгәрәтә...

Мәңге-мәңге шулай булыр кебек, чөнки шулай иң дөресе: игенче иген игәргә, гаилә корып, балалар үстерергә тиеш. Көрәш Сабан туенда гына булырга тиеш. Әти кеше ир балаларын бил алышка – көрәшкә әзерләргә тиеш. Әйе, мәңге шушылай дәвам итәргә тиеш. Менә Хәсән батыр да авылның иң гүзәл кызы, укытучы Нурия белән гаилә корып җибәрер, алар да берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе батыр балалар үстерерләр. Гүзәл генә түгел, уңган да, чая да әле аның Нуриясе. Бер челтерәтеп көлеп җибәрсә, тәнгә чишмә суы эчкәндәге кебек сихәте тарала, елмаюы күңелгә бал-май булып ягыла. Үзе горур, Хәсәнне ошатып йөри-йөрүен, әмма сер бирмәгән була. Гәрчә бөтен авыл Нурияне Хәсәнгә ярәште инде...

Ә бәла көтмәгәндә килде. Хәсән армия сафларында туган илгә бурычын үтәп йөргәндә, алар авылына колхоз рәисе итеп, бөтенләй чит-ят бер кешене китереп куйганнар. Үзләренең элеккеге колхоз рәисе Мансур абыйлары бик мактаулы, абруйлы ил агасы булырлык кеше иде – тәки ил агасы иткәннәр, югарырак урынга күтәргәннәр булып чыкты. Яңа рәис – Хәмит исемле, базык кына гәүдәле, урта яшьләрдәге бер ир баштарак тыйнак кына булып күренсә дә, Хәсән армиядән кайтыр вакытка авыл урамнарыннан хуҗаларча басып, дөресрәге, «Волга» машинасында каз-үрдәкләрне, бала-чаганы тузанга күмеп, выжылдатып үтә торган эре кыяфәтле бер бәндә булып өлгергән иде инде. Җитмәсә, Хәсәннең күңеленә тигәне, ниндидер бер сизгер тойгысын сискәндереп җибәргәне шул булды: Хәмит, имештер, үзен көрәш белгече итеп белеп, Сабан туенда чын, матур көрәш күрсәтәм мин сезгә дип, ике ел инде көрәшкә үз малаен чыгара, ди. Дамир гәүдәгә таза булса да, камыр кебек – ничек әвәләсәң дә, булдыра алмый. Тагын да начаррагы, Хәмит бирегә килүгә йомшаграк үзәкле кешеләрдән үз тирәсенә яраннар, куштаннар да туплап өлгергән, ә инде авылның дөреслекне яратучы сөрәнчесе Әхмәт абыйны көн саен исертеп, үз ягына аударып бетергән, ди. Әнисе авыл яңалыкларын бер җепкә тезеп сөйләгәндә, егет күңелен шик корты тәмам кимерә иде инде. Нурия көткәндер бит?

– Көтте, көтте, улым. Хәмит тә – очлы күз – бик тиз күреп алды чибәр кызны, үзенең малаена димләп йөргән, ди. Нурия әйбәтләп тә әйтеп караган, кырт кисеп тә җавап биргән, тегесе бертуктамый юлына төшә икән. Шуннан бөтен кеше алдында кыз бала: «Мин Сабан туе батырына гына чыгам!» – дип, вәгъдә биргән. Армиягә киткәндә, батыр башың белән шул

орчык кадәр кызның вәгъдәсен дә алып китә алмагансың, – дип шелтәләп тә алды Хәдичә улын. – Менә хәзер вәгъдәсен бөтен кеше аша җиткерергә мәҗбүр булган.

Нуриянең чыннан да армиядән кайткан елны ук, ул Сабан туе батыры булып калачак Хәсән белән никах укыту иде исәбе. Муенына тәкә атландырган батыр – Сабан туе күрке. Ул бәйрәмнең иң югары ноктасы. Кая, бәйрәмнең генә түгел, бөтен елның иң матур мизгеле. Бу адәм баласының табигать белән берлегенең, берегүенең, таза көчнең җиңүе тантанасы. Менә шул вакытта Нурия Хәсәнгә үзе чиккән сөлгене бүләк итәр. Ул иң матур чигүле сөлге булыр. Шунда «Мин риза!» дигән газиз сүзләрне әйтер. Батыр янында тагын да гүзәлрәк булып күреним дип, кыз күк йөзе төсле җирлеккә вак кына чәчәкләр төшкән тукымадан бик килешле итеп күлмәк тектерде, күпереп торган чәчләрен икегә аерып, чәчәкләр кушып үрде. Иң гүзәл пар булсыннар әле менә бөтен авылга дип ниятләде ул.

Хәсән армиядән кайтканны ишетүгә Хәмит аны үз янына чакыртып алды. «Комбайныңа икенче берәүне утырттык, син әнә искесенә утырырсың. Көзгә кадәр вакыт бар, ремонтлап өлгерәсең әле», – диде колхоз рәисе, бик эшлекле кыяфәт чыгарып. Үзе Хәсәнне күзәтте. Сындыра алмасам да, бөгә торыйм, ничек тә Сабан туенда җиңелергә тиеш бу, дип уйлады. Хәсән дә төшеп калганнардан түгел, быелгы Сабан туеның киеренке буласын сизеп-белеп торды. Үзен тыныч тотарга, курку, шик кебек хисләргә игътибар итмәскә тырышты. Көндәшеңнең йомшак якларына түгел, үзеңә таянырга кирәк татар көрәшендә, шуңа да җирәбә салып хәл ителми анда келәмгә кем белән кем чыгасы. Көчле көчле белән генә чыга ала.

Ә үзенә, үзенең көченә ышана иде ул. Дамирга карап торды-торды да, быел батыр исеменә Җәмил белән көрәшергә туры килер, бу камыр чүлмәген дә ул әһ дигәнче чөеп атар дип ышанды. Күңеле ярсыды, йөрәге җилкенде. Үзе күз кырые белән генә Нуриягә карап-карап ала: кызның борчылуы йөзенә чыккан. Кызый, борчылыр урын юк, тагын берничә минуттан син – минеке, мин синеке булачакбыз, дип тынычландырасы килеп, күз алдына ләззәтле мизгелләрне китереп елмаеп куйды.

Тик ул уйлаганча булмады: Җәмилнең озын аякларының терәк эзләп, һавада чәбәләнүен күргәч, Хәсән үз күзләренә үзе ышанмыйча торды. Халык аһ итте. Мәйдан гөж килде. Хәсән «Сез дә күрдегезме моны? Нәрсә булды соң әле бу?» дигән кебек як-ягына каранды. Җәмил янына килеп утыргач, Хәсән аның күзләренә карарга тырышты. Тик тегесе Хәсәнгә таба башын да бормый, карашын яшерә иде.

– Син нәрсә? – дип, кабыргасына төртте аптырагач. Тегесе җилкәсен генә сикертте.

Мәйданга Хәмит атылып чыкты.

– Хәсән, чык. Куркасыңмы әллә? – дип, өстән генә дәште ул егеткә. Аннан Нуриягә ымлап: «Сабан туе батырына чыгам, диде», – дип өстәде.

Хәсән урыныннан торды. Бер тын күзләрен йомып, кендек турысындагы көчне барлады. «Үзеңә таян!» диде ул үз-үзенә. Аннан соң карашы белән Нурияне эзләп тапты, аңа карап елмайгандай итте. Әтисе белән

әнисенә ым какты. Әнә, халык арасында сукыр Сабир баба да утыра. Сөрәнче Әхмәтне эзләде, тапмады. Мөгаен, исергәндер дә берәр куак төбендә йоклыйдыр инде. Эх, Әхмәт абый... Мәйданның иң алдында Хәмитнең яраннары, куштаннары тезелешеп утыра. Рәис кушуы буенча килгәннәрдер инде...

Бер, ике, өч... Тукта, Хәсән Дамир белән көрәшә, ә Хәмит аяк астында бутала. Боларның ничек көрәшкәнен кеше күрмәсен дигәндәй, бөтен гәүдәсен әле алай килеп җилфердәтә, әле теге якка алып селки. Чыгып кит, комачаулыйсың, диючесе дә юк, әдәп саклап, авызларына су капкандай утыралар. Хәсән игътибарын җыеп, бу борчак чүмәләсе кебек ташып торган көндәшен күтәреп алган иде, Хәмит чырыйлап кычкырып җибәрде:

– Иптәшләр, хәрәмләшмәгез!

Кем хәрәмләшә? Хәсәнме? Менә тагын Хәсән батырга шул яланы гына ягасы калган иде. Моңа кадәр көрәштә хәрәмләшү дигәнне аның исенә дә алганы юк иде, чын батыр өчен хәрәмләшеп җиңүнең ояты җиңелүгә караганда да зуррак аның, беләсең килсә! Ә шулай да Хәсәнгә балл бирмәделәр. Тагын шулай бер-ике тапкыр санамадылар. Нишләгән соң бу казый Гамил абый? Авылның мәңгелек казые кебек иде бит ул, иң гаделе, иң белгәне. Картаюы җиткәнме?

Бер, ике, өч... Ул көрәш утын барлар өчен эченә йомылды. Сүрәнәя төшкән... Әйдә, көчеңне җый, җыел Барыс батыр нәселеннән Хәсән Хәйрулла улы!

Бер, ике, өч... Һәм менә инде Дамирны алып чөям дигәндә, мәйданның асты өскә килде дә офык әйләнеп капланды. Хәсән аны-моны аңлап өлгергәнче, колак төбендә янә Хәмитнең чәрелдек тавышы ишетелде:

– Чистага салды, чистага! Дамир батыр калды!

Хәсән телгә килүгә Дамирга эндәште:

– Хәрәмләштең бит!

– Шайтан аягымы, фәрештәнекеме? – дип ыржайды тегесе. Хәсән торып басты. Ул өмет белән мәйданга текәлде. Халык күргәндер бит, дәшми калмас дип уйлады. Мәйдан телсез калган иде. Ул аһылдамый да, гөжләми дә. Тып-тын калып карап тора. «Нәрсәсе аңлашылмый, күрмәдегезмени?» дигән кебек ул таныш йөзләргә инәлеп бакты. Мәйдан әйләнә, Хәсән тирәли әйләнә, әмма тавышсыз гына, тарая-тарая әйләнә, гүя батырын терелә́й төрбәгә тыгарга әзерләнә...

Хәмит инде ул арада колгага бәйләнгән тәкәне өстерәп алып килеп, Дамирның җилкәсенә салып та куйган. Моңа кадәр бернидә гаме булмаган үшән тәкә дә «мине дөрес муенга салмадыгыз» дигән кебек тыпырчынган була. Әнә анда йөзен каплап, Нурия мәйданнан йөгереп чыгып китеп бара... Хәсән дә мәйдан уртасында кукраеп басып торуының мәгънәсе юклыгын абайлап, чыгу ягына юнәлде.

Мәйдан көрәшчене көрәшче итә, ул аны юк та итә. Көрәштә көндәшләр генә түгел, мәйдан да хәлиткеч көчкә ия. Батыр егет шуны аңлады һәм хәрәмне күтәрә алган мәйданнан өметен өзде. Кулына урап тоткан ак сөлгесенең бер очы яшел чирәмнән сузылып барды да, сөлге бераздан «минем кирәгем бетте» дигәндәй, кыл уртада сузылып ятып калды...

– Мин синең батыр каласыңа ышанып бирдем ул вәгъдәмне! – дип

такмаклый-такмаклый елады Нурия, Хәсәннәрнең өенә үзе килеп. Әмма Хәсән ул көнне берәү белән дә сөйләшмәде. Кайтты да караватына ауды. Стенага карап, күкеле сәгать әллә ничә тапкыр кычкырганчы селкенмичә ятты да ятты. «Мин җиңелмәдем әле, ул сез җиңелдегез!» – дип калды үзалдына, Нурия чыгып киткәч, үпкәсенә тыгызланып тулган һаваны чыгарып бетерергә тырышып.

Икенче көнне ул сукыр Сабир карт янына китте.

– Сүнде. Көрәш уты сүнде, – диде ул керә-керешкә.

– Җиңелү – бетү дигән сүз түгел әле, көрәшне дәвам итәрлек көчең калган икән, димәк, син җиңелмәгәнсең, – дип җавап бирде Сабир карт аңа.

– Ә мин башка көрәшмим, – дип киреләнде Хәсән. – Мәйданга көрәш кирәкми. Чисталык бетте. Китәм мин моннан.

– Үзеңне җиңсәң, син әле мең көрәштә җиңә алыр идең.

– Көрәшче чиста көрәш күрсәткәннән соң да, гаделлек даулап йөрергә калгач – юк инде ул. Көрәшкә өндәмә мине, Сабир баба, түбәнлеккә каршы көрәштә үзеңнең дә түбән тәгәрәвең ихтимал. Ул көрәшкә чыксам, мин ирегемне югалтачакмын. Миңа үз ирегем кадерлерәк. Мәйдан хәрәмләшкән кешене батыр итеп таныды.

– Танымады ул аны.

– Алайса нигә каршы чыкмады?

– Тук башак башын ия, диләр бит.

Хәсән чыгып киткәч, Сабир карт озак уйланып утырды бу турыда. «Әй, бала, синең көрәш башлана гына әле. Бик озак булачак ул», – диде аннары үзалдына.

Шул китүдән Хәсән туган авылының Сабан туйларына кырык ел рәттән кайтмады. Нурия Хәсәнне икенче Сабан туена кайтып, үзенең хаклыгын раслар дип көтсә дә, аның да өметләре акланмады. Бер елдан соң Хәсәнне күмер шахталарына барып эзләп тапты, кайтырга үгетләде. Тыңлата алмады. Шул китүдән Нурия дә туган авылына кайтып тормады. Алар икесе ике якта гомер кичерде, гаилә кордылар, балалар үстерделәр. Хәсән улына катгый рәвештә әйтеп куйды: көрәш дип авыз ачасы түгел. Ә менә оныгын аралый алмады, аңа көрәш уты кагылган иде.

Җәйнең иң кыска төннәрендә дә ут эчендә саташып яткан оныгын күрүгә үк аңлап алды ул: Сабан туйларына алып бармыйча булмый малайны. Менә бит язмыш дигәнең ничек, күпме генә качарга тырышмасын, барыбер куып тотты. Тик кире Хәсән язмышына бер шарт куйды: оныкны ул авылга әзер батыр итеп алып кайтачак. Һәм шулай итте дә. Алар яшәгән Кемеровода татарлар күп иде, арада көрәшчеләр дә житәрлек. Көрәш секцияләренә йөртүдән тыш, Хәсән үзе генә белгән алымнарын да өйрәтте оныгы Азаматка.

Хәсән батыр Сабан туена кайткан дигән сүз яшен тизлегендә таралды авылга. Туган нигезенә атлап кергән саен Хәсәннең күзе түрдә эленеп торган иң беренче сөлгесенә төшә торган иде. Күпме генә алырга кушса да, тәки урынында сакладылар бит шуны Хәдичә белән Хәйрулла. Бүген алар үзләре фани дөньяларда юк инде, әмма өмет-ышанычлары өйләре түрендә эленеп тора, бу бусагадан батырларның тагын бик күп тапкырлар үтәсенә тамчы да шикләре булмаган.

Хәсән кичтән үк Сабан туе таңын каршылармын, Агыйделгә төшеп мендәрмен дип уйлап куйган иде. Төнлә дә күзенә йокы эленмәде, таң сызыла башлауга ул торып, ак ташлар җәелгән сукмактан елгага төшеп китте. Нәкъ аның яшь чагындагы кебек былбыллар өздерә, иркә таллар таң җиленә толымнарын сүтеп салган, су эченә үк кереп үскән камышлар пышылдаша. Бу хөрлеккә, бу хозурлыкка сәйран кылып, хет ела, хет җырла.

«Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделдә таң ата...»

Хозурлыкка кинәнеп торганда, аркасы белән генә артында кемдер барлыкны тоеп борылып караса, Дамирны күреп имәнеп китте. Кинәт борылгангадырмы, әллә Хәсәннең бөркет карашыннанмы, Дамир артка чүгеп куйгандай булды. Әмма үзен тиз кулга алды.

– Җиңелүемне син китүгә үк аңладым инде мин, – диде Дамир, кыюсыз гына саулык сорашкач. – Үземең хәрәмләшүемне танырга куркып яшәдем. Заяга узган гомер булды бу, – диде, үкенечле карашын офыкка төбәп.

– Ә авыл халкы? Мәйдан?

– Сабан туйларының яме китте шуннан бирле. Әтине дә әйтер идем инде, – диде ул, кулын селтәп.

– Әйе, мәйданга әти белән чыкмыйлар шул аны. Көрәшче үзенә генә таяна.

Аңлаштылар, иңнәрдән тау төшкәндәй булды. Сабан туенда аларның бергә утырганын күреп, халык эчтән сөенде. Кырык ел элек булган хәлләр авыл халкының хәтерен тырнап, кичә генә булган кебек саклана иде әле. Ә инде бәйрәмнең иң югары ноктасы – Азаматның иңнәренә мөгезләре кояшта елкылдап торган кашка тәкәне салганда, мәйдан аягүрә торып алкышлады. Авыл уянды, авыл дәртләнде, авыл тантана итте.

– Чиста көрәш, матур көрәш булды! Рәхмәт, батыр! – дип, шау-гөр килеп, кепкаларын күккә чөеп сөенделәр.

Азаматның кендек турысында кайнаган ялкын – Кара Каплан уты Сабан туеның кайнар җиле булып, мәйданны бер камлап, бәйрәмгә килгән һәркемне иркәләп үтте дә колгага эленгән сөлгеләрне аралый-аралый җилфердәтә башлады. Шунда арадан бер сөлге – иң матур чигүлесе бәйләнгән җиреннән сүтелеп очып китте һәм каурый сыман талгын гына итеп, кыл уртага төшеп ятты. Тәкәсен җиргә куярга иелгән җиреннән Азамат батыр аны күтәреп алып, муенына салды. Һәм сөлге хуҗасын эзләп, мәйданга күз йөгертте.

– Кем сөлгесе? – диештеләр анда.

– Нурияттәй оныгыныкы, – дигән җавап ишетелде.



Атлас
Гафиятов

# ЧУЕН АЮ

ДОКУМЕНТАЛЬ ХИКӘЯ

Әйе, бар андый аю! Гап-гади бер авылда, мәгъсум карашын көнгә төбәп, басып тора ул... Сүземне Сабантуйдан башламакчы идем. Көтмәгәндә, шушы аю күз алдыма килеп басты.

«Сабантуйларның саны юк, юк сабантуйның яше» дип язган халык шагыйре Ренат Харис. Тагын бер могтәбәр әдибебез Мөхәммәт Мәһдиев әйтмешли, үз гомеремдә байтак сабантуйлар күрдем – авылныкыларны да, хәзер инде федераль дәрәҗәдә үткәрелә торганнарын да. Ә ул елны... Җитмешенче еллар башында Казанның Тынычлык бистәсендәге Каенлыкта уза торганы үзенең статусы буенча да, зурлыгы ягыннан да республикада иң олуг, иң төп бәйрәм булгандыр, мөгаен. Чөнки милли бәйрәмебезнең дәрәҗәсе анда катнашучы батырларның күплегe белән бәяләнә. Ә ул елны... Бирегә чыннан да батырларның да батырлары җыелды. Әнә көрәшчеләре белән мыжлап торган Балтачның үзендә унсигез яшендә үк баш батыр булып танылган, аннан соң инде 80, 90 һәм авыр үлчәүдә республикада берәүгә дә бил бирмәгән Фидаил Шакиров. Аның остазы, авырлыгы 80 кило тирәсе булса да, җайлап кына центнерлыларны да чирәмгә тәгәрәтүче Васыйл Гарифуллин да шәкертенә көч бирергә генә түгел, үзе дә бил алышырга дип килгән. Питрәчнең инде легендага кереп баручы пәһлеваны Виссарион Канашев та, соңрак Россиянең сигез мәртәбә батыры булып танылачак Данил Галиев та биредә. Яшьләр арасында Россия чемпионнары булып танылып, инде өлкән абыйлары белән курыкмыйча бил алышучы Фәрит Шәйхетдинов, Шамил Сәлахов, Якуб Ибраһимов, Фаил Әхмәдиев, Азат Ногмановларны да, ветераннар саналучы, әмма көч-куәтләре ташып торган Сабирҗан Шакиров, Әсгать Гайфуллин, Зөфәр Хановларны да, инде байтак шәкертләре титуллары буенча үзләрен узып китсә дә, сөлгеләрен ташламаган Гайнетдин Мөхәммәдиев, Фәрит Мадъяровларны исәптән чыгарырга ярамый.

Электән килгән матур гадәт буенча жирәбә салынып, кемнең кем белән бил алышасы билгеле булуга каенлыктагы табигать үзе ясаган амфитеатр кебек чокыр уртасында мәйданга чыгучы батырлар саны да әйләнеш саен икеләтә кими барды. Ниһаять, финал! Алып баручы мәйдан уртасына авырлыклары центнердан арткан ике пәһлеванны чакырды. Аларның берсе инде кырыкка якынлашып килүче Минзәлә батыры, Россия чемпионы дигән исемне дә моннан ун-унике еллар элек алган Раббани Гайфуллин һәм Баулы батыры, биредәге авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган

Бастам Газизов. Алып баручы тамашачыларны аларның титуллары белән таныштырды. Раббани абый да, Бастам да – Россия чемпионнары. Әгәр беренчесе бу титулны моннан ун еллап элек алса, Бастам әлеге дәрәҗәгә әле узган ел гына ирешкән. Өстәвенә әле ул – ирекле көрәштә дә СССРның спорт остасы. Әле узган ел гына сабакташы Шамил Сәлахов белән Мәскәүгә СССР халыклары спартакиадасына барып, шунда җыелган тамашачыларга татарча көрәш алымнарын күрсәтеп кайткан баһадир.

Билләргә сөлгеләр салынып, хөкемдар алымны башларга дип, сыбызгысын сызгыртуга кечерәк буйлы, ирекле көрәш алымнарын да яхшы белгән Бастам Раббани абыйсының ике аягы арасына кереп, аны күтәреп чөймәкче иде, тик Минзәлә батыры аны җирдән аерып алды һәм үзе аркылы чирәмгә ыргытты. Мондый очракта тамашачыларның фикере икегә бүленә. Менә бу юлы да алардан төрле бәяләр ишетелде:

– Булды бу...

– Чиста салды...

– Юк, булмады, аркасы җиргә тимәде бит...

– Яңадан көрәшсеннәр...

Әллә алышны тиз генә бетерәселәре килмәде, хөкемдарлар бераз киңәшкәннән соң, Минзәлә көрәшчесенең алымын бер балл белән генә бәяләде. Тагын бер тапкыр тотыныштылар. Раббани көндәшен янә җирдән аерып алып, үзе аркылы чирәмгә ыргытты. Бастам бу юлы кулыннан сөлгесен ычкындырып, чирәмдә бер-ике тапкыр тәгәрәп үк китте. Хөкемдарлар бу юлы да Раббанига бер очко биреп, Бастамга көрәш алымнары кулланмаган өчен кисәтү ясау белән чикләнделәр.

Раббани абзый урынында берәр кызурак канлы көрәшче булса: «Булды бит инде, тагын нәрсә кирәк?» – дип, судьялар белән бәхәскә керер иде яисә сөлгесен үк ташлап чыгып китәр иде. Ә аның кыяфәте элеккечә җитди калды. Чөнки ул ничә меңнәр еллар тарихы булган көрәшебезнең чын сәнгать икәнлегенә гомер буе ышанган, шуңа табынган, иң мөһиме халкын, тамашачыларны хөрмәт иткән искиткеч нечкә күңелле пәһлеван иде. Менә ул янәдән елмаеп, сөлгесен көндәшенең биленә салды да бер мизгелдән аны һавада әйләндереп, җиргә сылады. Мәйдан «аһ» итте. Секундомер телләре бу мизгелдә алышка бирелгән ун минутның бары дүртенче әйләнешен генә саный башлаган иде әле. Тамашачылар «Булдырдың, Раббани!» дип мәйданга чыгып, аны һавага чөйгәндә дә, баш батырга дип бирелгән дәү тәкәне җилкәсенә салып мәйдан әйләнгәндә дә, батырның кыяфәте үзгәрмәде.

...Алты яшендә ул әтисез калды. Әтисе Гайфулла сугышка китте дә ике-өч айдан соң аның батырларча һәлак булуы хакында кәгазь генә килде. Әллә шул кайгыданмы, әллә тормыш авырлыгыннан, ике елдан соң әнисе дә аяктан егылды. Әнисенең җаны чыкканда, ачлыктан шешенгән Раббани да аның янында торалмыйча ята иде. Кабер казучыларның берсе өйгә кереп, аны күрүгә: «Моның улы да тынсыз ята, үлеп җиткәнен генә көтик тә...» дип әйтүгә мәеткә ясин чыгучы карт: «Җәмәгать, чыкмаган җанда өмет бар, әнисенең мәетен алып китеп күмә торыгыз», – дип әйтә. Ни хикмәт, соңрак үзенең көрәш осталыгы белән Минзәлә төбәген генә түгел, ә бөтен татар дөньясын шаккатырачак Раббани исә терелеп, әкияттәгечә ай үсәсен көн үсә башлый. Аны абыйсы Габделнур үз тәрбиясенә ала.

Шулай итеп, малайга яшьтән үк өлкәннәрнең кул арасына керергә – нинди эш бар – шуны башкарырга туры килә.

«11-12 яшьтә мин инде өлкәннәр кебек үк печән чаба идем, – дип искә ала ул. – Бәләкәй арба да тартырга туры килде. Җәйләрен үгез җигеп, басудан ындыр табагына ашлык ташыдым. Кулга чалгы тотып, печән чабу, утын кисү, аны яру – көрәшчеләр өчен менә дигән күнегү».

Басуда эшләгәндә, ял вакытларында, су коенырга баргач, яшьтәшләре белән бил алышкалаганын бераз хәтерләсә дә, тәүге кабат кайчан Сабан туе мәйданына чыгып көрәшә башлаганын оныткан ул. Әмма күп яшьтәшләреннән буйга бер башка диярлек озын булгач, аңа гел үзеннән өлкәнрәкләр белән тартышырга туры килгән. Искиткеч тыйнаклыгы, оялчанлыгы нәтиҗәсендә аңа үзенә тиешле урынны яисә бүләкне бирмәгән чаклар да еш булган.

Тыйнаклык дигәннән, игътибар иткәнегез бармы: тыйнак, сабыр кешеләрнең дә кайчак сабырлыклары соңгы чиккә җитеп шартларга мөмкин. Раббани белән дә, армиягә алынгач, шундый хәл килеп чыга. Шулай бервакыт «картлар» җыйналып, авылдан килгән татар егетенә «сабак укытмакчы» булалар. Башта карт солдатлар аның яңа хәрби формасын салдырып, аңа искерәк киемнәрен бирәләр. Ул әле монысына сүз әйтми – түзә. Ә инде «картлар» солдат каешы белән аның ялангач тәненә сугып, үзләренчә «хәрби ант» бирдерә башлагач түзми, җиде-сигез карт солдатны тирә-якка чәчеп ташлый. Менә кайда кирәге чыга ятим калып, яшьли эшләп үсүнең. Шул бәрелештән соң ике-өч солдат госпитальгә эләгә, ә Раббанинның үзен гауптвахтага ябып куялар. Әмма егетнең гаепсез икәнлеге ачыклангач, аны чыгаралар. Үзен спорт ротасына чакырып, бокс секциясенә йөрергә тәкъдим итәләр. Ул йөри, көндәшләрен дөмбәсли генә. Армиядә калып, шул ук бокс яисә көрәшнең берәр төре белән ныклап шөгыльләнсә, бәлки әлеге төрләрдән спорт остасы дәрәҗәсенә җитәр иде. Әнә якташы – Яңа Маҗын авылы егете Виталий Кузнецов армиядә көрәшнең берничә төре белән берьюлы шөгыльләнеп, соңрак аларның байтагы буенча ил, Европа чемпионы булды, дзюдо буенча Олимпия уеннарында көмеш медаль отты.

Ә Раббани хәрби хезмәттән соң туган якларына кайтып, Чаллыдагы 8 нче училищеда шофёр һөнәрен үзләштерде һәм лаеклы ялга чыкканчы туган авылында машина йөртте. Авыр үлчәүдә ике дистә еллап мәйдан тотып ул күп тапкырлар Минзәлә, Чаллы, Тукай, Сарман, Мөслим, Актаныш, Казанның Идел буе һәм Бауман районнары Сабан туеның баш батыры булып танылса да, рәсми титуллары әллә ни күп түгел. Ул ике тапкыр республика, тагын ике мәртәбә Россия чемпионы, өч мәртәбә Муса Җәлил турниры җиңүчесе. Монысы инде аның кемгәдер җиңелүе аркасында түгел, ә көрәшергә дип, өч-дүрт көнгә эштән китә алмавы аркасында гына шундый титуллардан мәхрүм калуы дип аңларга кирәк. Әнә 1959 елда ул Казандагы Үзәк паркта баш батыр исеме өчен шул чорның атаклы көрәшчесе Әхәт Закировтан гына калышып, икенче урынны алгач, аларны көрәштергән судья Николай Морящичев Раббани янына килеп: «Әйдә, кил минем янга. Мин синнән дөнья чемпионы ясыйм» дип, аны Казанга чакырды. Тик үз авылын, туган кырларын, һөнәрен яраткан Раббани бу тәкъдимгә риза булмады. Чыннан да, әгәр үз вакытында яхшы тренерга эләгеп, ирекле көрәш, самбо, грек-рим, дзюдо көрәшләре юнәлешендә осталыгын арттырса, Раббани Гайфуллиннан да бәлки ил, Европа,

дөнья күләмендә танылган батыр чыккан булыр иде. Чөнки әкияттәге Алып батырга хас озын гәүдәле, тумыштан табигый зур көчкә ия пәһлеваннарга көрәшнең бөтен төрләрендә дә ихтыяҗ зур. Чыннан да, Дагыстан, Осетия, Чечня, Ингушетия, Карачай-Чиркәс кебек Кавказ якларында дөньяга килсә, Раббанидай пәһлеваннарны уч төбендә генә күтәреп йөртеп, күнегүләр ясау һәм ярышларда катнашу өчен барлык кирәкле шартларны тудырырлар иде. Ә бездә... Атаклы пәһлеванның үзенең эштән китә алмавы аркасында бик күп кенә ярышларда катнаша алмавы, ә бер җыеннан ашарына җитмәгәч качып кайтып китүе хакында ачынып сөйләгәнен ишеттем.

Кайбер журналистлар үз язмаларында атаклы көрәшчеләр хакында «Келәмнән җиңелмичә китте» дип шыттырырга яраталар. Әмма тормышта алай була алмый. Көрәшчеләрне остазлары да бит иң беренче булып егарга түгел, ә егылырга өйрәтәләр. Бөекләр дә кеше һәм аларның да дүрт аяклы ат абынган кебек сөртенгән һәм егылган чаклары була. Раббани пәһлеванга да үзеннән җиңелрәк үлчәүдәгеләргә һәм үзеннән яшьрәкләргә җиңелгәләргә туры килде. Әмма ул бервакытта хөкемдарлар белән бәхәскә кермәде, көндәшенә кулын биреп, «Булдырдың, апаем!» дип аның җилкәсеннән кагып чыгып китә иде. Әнә чордашы, ирекле көрәш буенча өч тапкыр Олимпия уеннарында, ун мәртәбә дөнья беренчелегендә җиңгән Александр Медведьның спорт биографиясен дә күзәтеп барды ул, соңрак грек-рим көрәше буенча шулай ук өч мәртәбә Олимпиаданы откан Александр Карелинныкын да. Дүртенче Олимпиадасында бөек Карелин да моңарчы әллә ни билгеле булмаган американ Гарднерга оттырды. Димәк, аңа Олимп үренә дүртенче тапкыр менәргә язмаган...

Спорт дөньясында титуллар гына түгел, «халык мәхәббәте» дигән төшенчә дә бар. Әгәр инде тамашачылар арасында «Егерменче гасырның иң оста көрәшчесе кем?» дигән сораштыру үткәрелсә, Раббани Гайфуллин анда, һичшиксез, беренчеләр рәтендә аталыр иде.

Моннан унбиш-егерме еллар чамасы элек төрле һөнәр ияләренә һәйкәл кую модага кереп китте. Урам себерүче, сантехник кебек гади һөнәр ияләренә дә куйдылар аны. Менә шул уңайдан Сабантуй батырына да һәйкәл кирәк дигән тәкъдим дә булды. Хәтта ул һәйкәлнең прототибын да күрсәттеләр. Ул Россия, республика чемпионы, гомере буе колхозда шофёр булып эшләгән Раббани Гайфуллин иде! Иң куанычлысы шунда: 87 яшьлек Раббани абый бүген дә исән-сау: туган авылында җәмәгате белән чөкердәшеп яшәп ята. Әнә улы Ришат та әтисе дәрәҗәсенә үк күтәрелә алмаса да, республика чемпионы булды, Тукай, Минзәлә районнарында күп тапкырлар мәйдан тотты. Хәзер күп кенә район, шәһәр баш батырларына җиңел машина бүләк итәләр. Раббани абый көрәшкән вакытта иң зур бүләк тәкә иде. Дөрес, лаеклы ялга чыкканда, Раббани абыйга да колхоз идарәсе «ГАЗ-53» машинасын бүләк итте. Ул да хуҗасына охшаган: сәгать кебек эшли, теләсә кайсы вакытта юлга чыгарга әзер.

...Әгәр дә сезгә, хөрмәтле укучым, кайчан да булса Тукай районы Иске Абдул авылы аркылы үтәргә туры килсә, бер гараж өстенә бастырып куелган чуен аю сынына игътибар итегез. Биредә осталыгы белән меңнәрчә тамашачыларны сокландырган, көрәшүе белән дә, эше белән дә, гадилеге белән дә, үз-үзен тотышы белән тарихка кереп калган пәһлеван Раббани Гайфулла улы яши!

Чуен аю да көч-кодрәт, батырлык символы булып, мәгъруранә басып тора.



*1982 елның 1 сентябрендә Кукмара районының Төркәш авылында дөньяга килгән Ландыш Равил кызы Равилова (Мөхәммәдиева) Авыл хуҗалыгы академиясенең икътисад факультетын тәмамлаган.*

*Шигырь сөючеләр аның иҗаты белән әүвәл тәрҗемәләре аркылы таныштыр. Соңгы берничә елда ул Татарстан китап нәшриятында рус классикларын татар теленә тәрҗемәдә бастыру проектында актив катнашкан авторларның берсе, Н.Некрасов, М.Лермонтовның аерым шигырьләрен ана телебезгә тәрҗемә итте, шулай ук «Хәзерге якут прозасы» антологиясен булдыруда да үзеннән өлеш кертте. Ә үзенең аерым шигырьләре моңарчы «Безнең гасыр авазы» альманахында, көндәлек матбугатта дөнья күргән, «Тәртип радиосы» эфирларында яңгыраган. Кукмара районында гомер итүче Ландыш Равилова язган сүзләргә хәзер Фирзәр Мортазин, Лилия Таһирова, Гөлнара Тимербулатова, Искәндәр Мостафин кебек композиторларыбыз көйләр иҗат итә, җырларын татар эстрадасы солистлары, хор ансамбльләре башкара. Татарстан китап нәшриятында «Ник яраттың, дисәң...» исемле китап җыентыгы да якын араларда дөнья күрәчәк.*

Ландыш
Равилова

# БАЛАКОШЛАР ИНДЕ БЕЛМИ ХӨРЛЕК ТӨСЕН

***

Тәрәзәмә сарылган да кемдер елый,
Яман сыкрый йөзлекләрне тырный-тырный.
...Тарих икән.
Аптырагач, дөреслекне миннән даулый,
Шаһит итә кыя-тауны, далаларны,
Күпне күргән ап-ак ташлы диварларны...
Идел суын бөрки-бөрки дикъкать барлый.
Каһарманнар рухы иңгән җаны күнми.
Күзләремә төбәлгән дә әрнеп елый.
Күз яшьләрен Чулпан йолдыз еллап саный.
Олуг ташны, шаһит диеп сыйпап карый,
Язуларын үзе генә булыр аңлый.
Вакыт чаба, елларына җилләр кунмый,
Тизләнешен калганнарның зары узмый.
...Караңгыда өзгәләнеп, тарих сызлый –
Күпме буын кире борган бусагадан.
Шаһитләргә мәкер-ялган пәрдә корган,
Авазлары күңел биреп тыңлый торган,
Ә урамда колак чоры аңны буган.

***

*Гаҗәп түгел моңсыз җырлар, ишексез йортлар,*
*Шикәрдән генә бал җыйган данлыклы кортлар…*

Акны – кара, караны ак итә заман.
Бушлык тутыралмас сүзләр яңгырый һаман.

Канатсызлар өйрәтәләр очу серен,
Канатлылар очалмыйлар никтер бүген…

Читлек белән гөлбакчага куйган кошка:
«Хөрлек шушы, – диләр, – сайрап түли башла!»

Балакошлар инде белми хөрлек төсен,
Тик анакош хәтерлидер күкнең исен.

Моң өзелгән, нур өзелгән, ямь киселгән,
Өмет кенә сулып йөзә ай эзеннән.

Тальян моңын кабатларга тели җилләр,
Азан тавышын тараталар соры җиргә,

Тәрәзәгә дулап-елап сарылалар,
Якаларга килеп-килеп ябышалар…

## Югалтулар

Югалттым мин яшьлегемнең яшеллеген,
Кабатланмас шау язларның исен.
Берәм-берәм җуйдым дусларымны,
Борчу белмәс шат көннәрнең төсен.

Хыялларның югалтканмын күпчелеген,
Онытканмын сагышланмас өчен.
Сабыйлыгым җуйган күңелемнең
Кайда киткән канатланыр көче.

Газизләрнең күпмеләре озатылган,
Юклыклары били җәйләремнең таңын.
Җуйган җаннар, хисләр, ямьнәр бихисаптыр,
Югалттым мин хәтта югалтулар санын.

## Эзлә

Иртәгене куа килә бу көн –
мең йөзләрдән елмаюны сөртер өчен.
Билгесезлек кара пута тарта күзгә,
хәйләкәрләр юлга һаман казык тезә,
күз яшеннән үзләренә камыр изә.
Яраланмас чара эзлә, эзлә, эзлә!..

Син «күзсез» булганда, биштәрең алалар,
ипиең ур(ы)нына ком-ташлар салалар,
ком өчен, таш өчен түләвен язалар.
(Күрәсеңме, якаларга дәвер-энә
Каеп-каеп: «Тиеш» дигән әмер чигә.)
Тамак ялгар чара эзлә, эзлә, эзлә!..

Син телсез булганда, яңаклый мут сүзләр.
Каләмне мул итеп ялганга маналар,
Язалар, язалар, тузларга язалар.
Исемең үзгәртеп, үзеңә тагалар.
(Туачак һәр гамьгә ләхетен алалар.)
Хәтер саклар ара эзлә, эзлә, эзлә!..

Өмет-көймә белән хыял-канат килә,
ничәнче кат чынбарлыкның җиле өзә,
каурыйларын йолкый-йолкый ятак итә.
Ничек туймый, һич бирешми, гарьләнми дә
Һәм ыржая ястыгына чумган мәлдә.
«Үлгән» көе яшәр өчен чара эзлә!
Эзлә!..

## Әти

Әти!
Сине сагынуым шул кадәрле көчле!
Ишетәсем бик килгәнгә,
тавышыңны... ишетәм дә төсле...
Җәһәт-җәһәт тезгән төпле адымнарың
Зар-интизар булам
Бер күрергә янәшәмдә тагын.
Синең акыллылык, синең сабырлыкны,
Киңәшләрең (бер аксакал бирмәс)
Һаман әле терәк итеп тоям.
Синле дөньям – башка үлчәүләрдә!
Синле дөньям – төсле кино сыман!
Ничек кенә бары бер мизгелгә
Үксез җанны кабат алдалыйсы? –
Зикер итәм...
...Нәүмизлекнең һәр сәйләне саен:
«Кайтып керер»,
        «Кайтып керер»,
                «Кайтып керер»...
Туган көнем...
        Син түзмәдең!
Ишектән үк колач җәеп килдең!
Бар зарыгу белән атылдым!
Синең кочак кына шундый! – бәхет үзе!
Шул тойгыны миңа... төшләремдә
Газиз бүләк итеп калдырдың...



*Венер Айрат улы Исхаков (1967) – Башкортстан һәм Россия Федерациясе Язучылар берлекләре әгъзасы, Башкортстанның атказанган матбугат һәм мәгълүмат хезмәткәре. «Шоңкар» журналының җаваплы секретаре. «Таяк», «Өй иясе», «Шәп күчтәнәч» исемле юмор китаплары авторы. Уфада яши.*

Венер
Исхаков

# ДУСЛАР

хикәя

– Ишеттеңме, Әкрам Мөэминов үлеп киткән!
– Кайчан?
– Кичә.
– Карале, ураза аеның җомга көненә туры килүен әйт әле.
– Шулай шул!
– Урыны җәннәттә булыр.
– Әйбәт кеше иде.

Бу хәбәр калада гына түгел, бөтен җәмәгатьчелеккә тиз таралды. Телевидениедән дә, радиодан да хәбәр иттеләр. Аның хезмәт юлы, уңышлары хакында сөйләделәр. Якыннарының, гаиләсенең кайгысын уртаклаштылар. Мәрхүм белән хушлашу фәлән мәдәният сараенда төгән көндә була, диделәр.

Аның менә ничәнче ел инде түшәктә ятуын белүчеләр:

– Ярый, туудан калмагач, үлемнән калып булмый, – дисә, икенчеләре шуны җөпләде.
– Улына авыр инде.
– Авызына суны пипетка белән генә тамызып торганнар, ди.
– Чынмы?
– Хатыны Әлфия дә йончыды инде.
– Әйтмә дә!
– Шулай да ник бер тапкыр булса да зарланганы ишетелсен!
– Бу тикле дә йомык кеше булыр икән!
– Гомер бакый шулай булды бит ул! Эчендә эт үлсә дә белмәссең!

Берәрсе үлеп-мазар китсә, аның сәбәбен үзләренчә җәһәт кенә ачыклап куючылар табыла бит. Бу юлы да шундыйлар булмады түгел.

– Теге ни үлеп киткән, диделәр, телевизордан әйттеләр.

– Нәрсә булды икән соң?

– Шул күп булса, эчеп үлгәндер инде, ай чамасы элек базарда күреп калган идем, аю кебек шәп иде әле.

– Гомер буе җитәкче булган. Бушка аша, бушка эч, дигәндәй. Йә, шундый авыр эш күрмәгән адәмнәр дә тәгәрәр икән.

Бүген каланың мәдәният сарайларының берсендә мәрхүм белән хушлашу була. Аны оештыруны дусты тиешле кешесе Кәрим үз өстенә алган. Менә әле шунда китеп барышы. Әкрам Хаҗиевич иҗат кешесе булгач, халык аны яхшы белә иде. Командировкаларга да күп йөрде, халык белән очрашты. Еш мактап яздылар, гәзит-журналларда сурәте басылды. Картиналары мәктәп дәреслекләренә кертелгән. Күргәзмәләренә халык күп йөрде. Хезмәтләре зур-зур түрәләрнең кабинетларын бизәде. Кайберәүләр өчен аны күрү зур мәртәбәгә исәпләнде. Чынлап та, төз гәүдәле, дулкынланып торган кара чәчле, һәрвакыт зәвык белән киенеп йөргән рәссам кала урамында әллә кайдан күзгә ташланып тора иде. Аның ниндидер иҗат әһеле икәнлеген бөтенләй белмәгән кеше дә шунда ук чамалый. Урамда аны танып калучылар бер-берсенә:

– Әнә, әнә, кара, шул рәссам китеп бара, – дип пышылдый иде.

– Кайда, кайда?

– Әнә, матур кәчтүм кигән агай.

Аны шулай күздән югалтканчы энәсеннән җебенә хәтле тикшереп калалар. Азактан форсаты чыккан саен «Мин шул агайны күрдем» дип, үзенә күрә бер горурлык белән сөйлиләр.

Концертлар, төрле тамашалар вакытында гөрләп торган мәдәният сараенда җан өшеткеч салкынлык. Уртага табут куелган. Фотодан бер кулы белән ияген тоткан рәссам моңсу гына бага. Гүя мәрхүм портретыннан дусларын сынап күзәтә. Әнә, атлас мендәрдә медальләре, республиканың иң югары ордены ята. Агасы өчен Кәрим горурланып куйды.

Халык килә дә килә. Танышлар да, таныш булмаганнар да күп. Агасының дуслары күп булды. Гаҗәп изге күңелле, ихлас, юмарт кеше иде ул. Ходай бер кешегә юмартлыкны ничек шул кадәр өеп бирә алгандыр? Ул моңланып җибәрсә, юк-бар артистларың бер читтә торсын. Ә гармунда сыздырса, иллә-мәгәр, аяксызлар да биергә чыгар иде. Шуңа да юбилейларга, төрле бәйрәмнәргә аны теләп чакырдылар. Абруе бар. Эчсә дә, чамасын белеп кенә. Җиңгәсе белән икесе табынның яме булдылар. Вакытында әллә күпме авылдашларының, дус-ишләренең балаларын укырга кертергә ярдәм итте.

Кәрим табут янында үз дәрәҗәсен белеп кенә торган агайга күз салды. Ул да – танылган кеше. Мөхәммәт Насыйрович. Иң якын дусларының берсе. Берничә ел элек агасының юбилей мәҗлесләрендә Уфада да, район үзәгендә дә табынның түрендә утырды. Хәтта аның турында мактап аерым китап та чыгарды. Һәрвакыт беренче сүзне ул әйтте. Тик агайның сәер холкы ошап бетми аңа – күбрәк «төясә», чамасын оныта. Теге вакытта да бәйрәмнең ямен җибәрә язды. Ярый, ул тикле генә була торгандыр. Әлбәттә, аның беренче булып сүз әйтергә хакы бар. Янәшәсендә икенче дусты тора

– Корбан Әхмәтович. Аннан ары – билгеле композитор Гаян Мөхтарович. Бигрәк бала күңелле кеше. Аның зур сурәтен төшергәнен бүгенгедәй хәтерли. Шулчак композитор агайның куанганын күрсәң! Рәхмәт укып бетерә алмады. Әй бу иҗат кешеләре, шул тикле дә сабый күңелле булырлар икән. Кәрим агасы өчен янә куанып куйды. Булгач, дусларың шундый «мировой» булсын... Бәйрәмнәрдә соң! Агасын да, җиңгәсен дә сорап-сорап җырлаттылар. Ә алар беркайчан каршы килмәде. Әнә «Дуслык» җырын ничек шәп башкаралар иде:

Саубуллашып, ерак китсәк тә,
Без кайларга гына җитсәк тә,
Дуслык җырлары калыр йөрәктә...

Мөэминовларның җырлап бетерүләре була, барысы да гөрләтеп кул чаба.

– Әнә нинди дуслары бар!

– Әнә шулай!

– Афәрин!

Ярым кызмача булып алган табындашлар җырны күтәреп ала.

– Мәңге бергә яшәргә язсын! Әйдәгез. Бокалларны шул хөрмәткә күтәрик!..

Кәримнең уйларын Мөхәммәт Насыйровичның сүзләре бүлде:

– Якын дустыбызны югалтуга табигать тә кайгыра, елый кебек. Кичә генә чалт аяз кояшлы көн булса, бүген күктә, сөмрәеп, болытлар йөзә. Әкрам Хаҗи улы кебек талантлар сирәк туа. Дустым бик әйбәт җырлый иде. Әгәр язмышын сәхнә белән бәйләгән булса, анда да зур казанышларга ирешеп, танылган, халыкның яраткан җырчысы булыр иде. Әмма ул җитәкчелекне дә, рәссамлык эшчәнлеген дә, җырны да, шигырьне дә бергә куша алды. Шуңа да аның һәр әсәре җырлап торды. Күп рәссамнар аннан үрнәк алырга тырышты. Бихисап портретлары әллә нихәтле фатирны, музейны бизи, халыкны тәрбияли, матурлыкны аңларга өйрәтә.

Кордашы беркавым халыкка карап алды да, дустының күз яшьләренә төелеп утырган хатынын күреп, үзенең дә дымланган күзләрен кулъяулыгы белән сөртеп алды. Имән кебек ирләр дә елар икән.

– Хуш, кадерле дустым, – диде ул калтыранган тавыш белән. – Синең картиналарың халыкның күңелен, дөньясын бизәр, моңлы җырларың мәңге безнең йөрәкләрдә яшәр.

Аннары чал чәчле олпат кордашы сүз алды. Менә ул уң кулы белән чәчен өскә таба сыпырды, тамагын кырды. Аннары мәрхүмнең еш кабатларга ярата торган шигырь юлларын искә төшерде:

Яз гомере бик тә кыска сыман –
Бер шаулашып бозлар агуы.
Җәй гомере бик тә кыска сыман –
Чалгының бер чыңлап алуы...
Үзәк өзеп, кәккүк кычкырганда,
Яшеннәрнең яшьнәп алуы.

Аннары ул хушлашу сүзен башлады:

– Якын дустымның гомере чалгының бер чыңлап алуы кебек кенә булды.

Без Әкрам Хаҗи улы белән бер үк елны туганбыз. Яшьлегебез бер чорда үтте, бер төркемдә укыдык, бергә хезмәт юлыбызны башладык. Иң авыр вакытларымда ул миңа таяныч, дус булды. Үкенечкә каршы, бүген аның кебек дуслык кадерен белгән кешеләр сирәк. Бәхил бул, якын дустыбыз. Синең хакта хатирәләр күңелләрдә мәңге сакланыр...

Менә хушлашу минутлары тәмам. Берничә кеше, табутны сак кына күтәреп, машинага таба юнәлде. Әкрам Хаҗи улы туган авылында җирләүләрен сораган икән. Халык әкренләп таралыша башлады. Кемдер янә авыр уфтанды:

– Әй Ходаем, үткән гомер!

– Бу дөньяда барыбыз да кунак кына, бүген – бар, иртәгә юк, дигәндәй.

Бәй, Мөхәммәт Насыйрович әллә кая китеп бара лабаса! Мөгаен, машина барлыгын белмидер. Кәрим кичә үк таныш агайлары аша алар өчен яхшы машинаны хәстәрләп куйган иде. Ул агасының дустын куып җитеп:

– Сез әнә теге машинага утырырсыз, яме, – диде.

Мөхәммәт Насыйрович ул күрсәткән якка карап алды да:

– Ул тикле мәшәкатьләнмәсәгез дә ярар иде, мин моннан еракта яшәмим бит, җәяү дә кайткан булыр идем, – диде.

Кәрим гаҗәпләнеп:

– Машина Әкрам Мөэминовичның туган авылына бара, – диде.

– Юк, туганым, мин берничек тә авылга ук бара алмыйм, башка мөһим эшләрем бар.

– Ничек инде алай? – Егетнең күзләре акайды. – Бүген шуннан да мөһимрәк эш булуы мөмкин микәнни?..

– Әйттем бит, вакытым юк, – дип, егеткә каты итеп җавап бирде Мөхәммәт Насыйрович.

– Юк, туганым, мин дә ерак юлга чыгарлык итеп киенеп килмәгән идем. – Монысы композитор дустының җавабы булды.

Өченче дустының да сәбәбе җитди иде:

– Бүген – оныгымның туган көне, бер яше тула, бүләк әзерләгән идем.

Машина тигез юлдан мәрхүмнең туган ягына кузгалды. Барасы юл ерак кына. Кәримнең миендә йөз төрле уй буталды. Адәм баласының төрле кыяфәткә керә алуын ул башына сыйдыра алмады. «Мәрхүмнәр сайлый алмый шул», – дип кабатлады ул эчтән генә.

Зиратта халык күп иде. Күрше-тирә авыллардан укучылар, олылар, хәтта бөтенләй ят кешеләр дә килгән иде. Һәркем атаклы шәхеснең каберенә бер уч булса да туфрак салып калырга тырышты...

*Башкортчадан* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәсе.*

# ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ: НИЖГАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

*Укучыларыбыз күрәдер, журналыбыз республикада гына түгел, бөтен Россия буенча да үз ишләре арасында, әдәби басмаларны күз алдында тотып әйтүем, иң зур тираж белән – сигез меңгә якын данәдә нәшер ителә. Бу бердән, милләттәшләребезнең әле әдәби сүзгә мөнәсәбәте уңай, ихтирамы зур булуы хакында сөйләсә, икенче яктан редакция коллективының да әдәбият сөючеләр белән аралашып, бәйләнештә яшәргә омтылуы нәтиҗәсе дип уйларга кирәк. Без әбунәчеләребез белән дә, Россиянең төрле төбәкләрендә тупланып яшәүче милләттәшләребез белән дә әледән-әле очрашып торабыз. Соңгы араларда гына да Башкортстан, Удмуртия, Мордовия, Марий Эл республикалары, Киров, Ульяновск өлкәләрендә шундый очрашуларда йөреп кайттык. Соңгы шундый сәфәребез әдәбиятыбызга, сәнгатебезгә Кави Нәҗми, Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев, Рамил Курамшин кебек күренекле шәхесләр биргән Нижгар якларына булды. Билгеле булганча, соңгы егерме елда Башкортстаннан кала бүтән төбәкләрдән әдәбиятыбызга яшь каләм әһелләренең килүе нык кимеде, бетеп бара дисәк тә дөрес булыр. Кая гына барсак та, без шундый каләм ияләрен эзлибез. Әлеге сәфәребездә дә Кызыл Октябрь районы Үзәк китапханәсендә булган очрашуда, төбәк каләм әһелләре хакында сорашкач, очрашуның үзендә үк катнаша торган шагыйрь булуын әйттеләр. Ул 2014 елда Казанда «Сүз» нәшриятында шигырьләр китабын чыгарган Ришат Рамазанов атлы егет булып чыкты. Без Ришатның китапханәгә бүләк иткән ул китабын сорап алдык. Укып чыккач, аның шактый ук өлгергән шигырьләр иҗат итүен күрдек һәм журнал укучыларыбыз игътибарына да тәкъдим итәргә дип, сүз дә биреп кайттык.*

*2012 елда, Татарстан Язучылар берлегендә эшләгәндә, миңа шул ук Кызыл Октябрь районының Чүмбәли авылыннан чыккан, хәзер Мәскәүдә яшәүче, рус телендә язучы шагыйрь, Россия Язучылар берлеге әгъзасы Хәйдәр Бәдретдинов белән танышырга туры килгән иде. Хәйдәр ул чакта миңа үзенең «Белый свет» дип аталган китабын бүләк итте. Аның шигырьләрендә миллилек, татар җанлы кеше булуы, аеруча бөек Тукайга мөнәсәбәте, мәхәббәте ярылып ята иде. Мин хәтта аның рус телендәге шигырьләреннән Тукай аһәңнәрен ишеткәндәй булдым. Аларда Тукай рухы сизелә иде. Ул сөекле Тукаебызга, Казаныбызга багышлап, Казанга һәр килгәне саен махсус шигырь цикллары иҗат иткән. Шунысы кызык һәм әһәмиятле: Хәйдәр иҗатына Мәскәү язучылары тарафыннан да югары бәя бирелгән. Ул Сергей Есенин, Владимир Маяковский, Михаил Лермонтов һәм Николай Некрасов исемендәге әдәби премияләргә лаек булган.*

*Хәйдәр белән миңа берничә тапкыр очрашырга туры килде. Автограф язып бүләк иткән соңгы китапларын укып чыккач, минем күңелдә Хәйдәрне татар укучысына җиткерү теләге барлыкка килде.*

*Шушы ике шагыйрьнең әсәрләрен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

**Рафис КОРБАН**



*Ришат Таһир улы Рамазанов 1975 елның 5 сентябрендә Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь районындагы Кече Рыбушкино (Рбишча) авылында туа. Мәктәптә укыганда ук шигырьләр язу белән мавыккан егет, армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң, өлкәдә чыга торган «Туган як» газетасында эшләп ала. Шул чакта актив рәвештә иҗат белән шөгыльләнә башлый. Җыр текстлары яза.*

Ришат
Рамазанов

# ХӘТЕР БУЙЛАП КАЙТАМ ЕГЕТ ЧАККА

## Бәхет киче

*(Шаяру)*

Мәхәббәтнең бакчасыннан
Гөлләрен өзәр идем –
Синең тәрәзә төбенә
Аларны тезәр идем!

Айлы кичтә көтәр идем
Тәрәзәңнең астында.
Гөлләр күреп, килер идең
Шул тәрәзә каршына!

Бәлки, чыгарсың да әле,
Утырырсың янымa –
Матур-назлы елмаюың
Шифа бирер җаныма!

Төне буе йолдыз санап,
Таң атканны сизмәбез...
Уклау тотып әнкәң чыгар,
Балта тотып – җизнәгез!

Әткәң чыгып, әйтеп салыр:
– Алып кит, зинһар өчен...
Шулай итеп тәмамланыр
Минем бәхетле кичем...

## Ярый әле

Ярый әле, син бар бу дөньяда,
Яшәү өчен өмет бирәсең:
Авыр сулап йоклап яткан чакта,
Төшләремә килеп керәсең!

Ярый әле, син бар бу җиһанда,
Күзләреңнән нурлар сибелә!
Бәлки, күңелемнең тынычлыгын
Саклыйсыңдыр бары син генә!

Ярый әле, сине күрү мөмкин –
Синнән башка, күңел боега...
Ташып чыккан кайнар олы хисләр,
Күңел тулгач, сиңа сыена!

## Авыл кызы

Нечкә билле чибәр авыл кызы
Керләр чайкый иелеп басмада.
Җемелдәшә кояш нурлары да
Чәчләренә үргән тасмада.

Шушы сихри күренешкә карап,
Әсир булып назлы күзләргә,
Хәтер буйлап кайтам егет чакка,
Яшьли сөйгән ярны эзләргә.

Кая китте икән матур яшьлек?
Кайтарыплар иде аласы...
Һәм шул чакны, һич тә көтмәгәндә,
Сыкрап ала йөрәк ярасы.

Тик соң инде, яшьлек ерак киткән,
Еллар үтеп – юллар күмелгән...
Ике кабат яшәү язылмаган,
Сынау итеп гомер бирелгән!



*Хәйдәр Сөләйман улы Бәдретдинов чыгышы белән Түбән Новгород өлкәсенең Чүмбәли авылыннан. Бүгенге көндә ул Мәскәүдә яши һәм шигырьләрен рус телендә яза. Россия Язучылар берлеге әгъзасы, дистәдән артык китап авторы. Шигырьләре татар теленә тәрҗемәдә Казанда беренче тапкыр дөнья күрә.*

Хәйдәр
Бәдретдинов

# КЕР СИН МИҢА ТӨННЕҢ УРТАСЫНДА...

## Нурлы Казан

Таң калдырып ал таңнан,
Каршылый нурлы Казан.
Уятып күңелләрне,
Яңгырый моңлы азан.

Самолётлар, кораблар,
Поездлар алып килә
Җиһанның дүрт читеннән
Кунакларны бирегә!

Идел-суда чайкала
Меңьяшәр бөек кала!
Манаралары белән
Кол Шәриф каршы ала.

Ышана күз яшенә,
Ышана үз яшенә.
Йөрәккә яга бәлзәм –
Меңьяшәр бөек Казан!

Мең ел инде баш вата
Монда галим-голәмә:
Шәрыкмы ул, Гарепме,
Табалмый билгеләмә.

Биш йөз ел инде менә,
Казансуның ярында
Сөембикә елавын
Ишетә халык монда.

Йөз елдан моннан борын
Югалтып ятим улын,
Сагынып яши Казан
Пәйгамбәрен – шагыйрен.

Күрик бөтен байлыгын,
Ач ишегеңне, Сезам!
Балкый күңел түрендә
Зиннәтле, затлы Казан!

## Дуслык

Күп тапкыр суытты тормыш
Холкымның кайнарлыгын.
Күздән очкыннар очканда
Дуслык сузды үз кулын.

Күпме кагылдым, сугылдым,
Җуйганда барыр юлым,
Ялгызым ни кылыр идем,
Дуслык сузды үз кулын.

Дустыңа ярдәм итүнең
Күрмим бер авырлыгын.
Кыен хәлдә калсаң үзең,
Дуслык сузар үз кулын.

Шулай җыр белән узганга
Язмышым, тормыш юлым,
Дусларыма бурычлымын –
Суздылар ярдәм кулын.

## Чакыру

Кер син миңа төннең уртасында,
Уртасында җәйнең йә кышның.
Искә алып бергә утырырбыз,
Якты мизгелләрен тормышның:

Борынгыдан калган йолаларны,
Сәрхуш ямщик сузган җырларны,
Бабайларның гореф-гадәтләрен,
Алтынга тиң гүзәл чорларны.

Аек баштан аннан гәп куертып,
Яшьлек гөнаһлары хакында,
Онытылып барган шигырьләрне
Искә алыйк табын артында.

Аһ, бу дөнья ыгы-зыгысында
Төштә дә юк тынгы, өндә дә.
Дусларыма кирәгем бар икән,
Шөкер, яшим, димәк, дөньяда!

## Чүмбәли

Чүмбәлине бер күрәсем килә,
Бабамнарның гүзәл Ватанын,
Нурга күмеп иркен басуларын,
Алсуланып таңнар атканын!

Уйларымда сиңа мин, Чүмбәли,
Һаман кайтам, кайтып җиталмыйм.
Бабам истәлеге булып калган
Тупылларны кайтып күралмыйм.

Балачакта бергә уйнап үскән
Дусларым да күптән киткәндер.
Тимерченең алачыгын тапмам,
Конюшня да инде беткәндер.

Сирәгәйде күптән безнең нәсел.
Күпләребез читтә, еракта.
Кем дә булса инде каршы алмас,
Кем – шәһәрдә, кемдер – зиратта...

Яңа йортлар күп салына, диләр.
Мин таный да алмам күк сине.
Таныр, бәлки, басу капкасының
Артындагы ике күл мине.

## Рәсәй шагыйре

Рәсәйдә шагыйрь – шагыйрьдән дә зур,
Әгәр ул сөйгән халкы хакына,
Җырлары белән сипсә яктылык,
Гомерен куеп афәт астына.

Әгәр ул дошман җырын җырласа,
Таралып барган илен хурласа,
Шулмы соң шагыйрь, шигырь хакына
Чит илдә яшәр ышыгын тапса.

Койрыгын өзеп качкан кәлтәдән
Аерыла соң кай җире белән?
Ватаны узган юлга төкереп,
Үзе буялган төкерегенә.

Хәзер ишетми ул халык зарын,
Вак ләззәт өчен сатып Ватанын;
Шагыйрь Рәсәйдә шагыйрь булалмый,
Гражданины булмаса аның!

*Рус теленнән* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәләре*

# «ЧОРЛАР ТУА ҮЗ ҖЫРЧЫСЫ БЕЛӘН»

*«Чорлар туа үз җырчысы белән,*
*Илтер кеше кирәк алга карап,*
*Тарих битләрендә кабатлана*
*Бөек сүзләр: Шагыйрь, Каләм, Талант».*

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче, мөгаллимә, шагыйрә, язучы Рифә Рахман (Рифә Фатхрахман кызы Харрасова) язган әлеге юллар әдибәнең үзе турында кебек.

Рифә Харрасова (Сабирҗанова) тумышы белән мөгаллимнәр гаиләсеннән. Язмыш аны гүя Казан университеты мөгаллиме һәм галиме булырга гаиләдә үк әзерли. Арча педагогик көллиятендә башлангыч сыйныф укытучысы белгечлеген алган яшь татар кызы 1982 елда Казан университетының филология факультетына килә һәм, укуын тәмамлаганнан соң, татар гыйльмиятенә, әдәбиятына хезмәт итү юлын гомерлеккә сайлый. Әдәбият нәзариясе, тарихы, милли тәнкыйть хакында күпсанлы чыгышлар, мәкаләләр, фәнни китаплар авторы булудан тыш, талантлы галимә татар теле гыйлеменә, халык авыз иҗатын өйрәнүгә караган хезмәтләр дә яза. Казан университеты доценты Рифә Фатхрахман кызы Харрасова Казан, Чуваш һәм Удмурт дәүләт университетларында филологларга «Текст теориясе», «Текстка филологик анализ», «Журналистика нигезләре», «Журналистның иҗат лабораториясе», «Әдәби тәнкыйть теориясе», «Иҗат психологиясе», «Әдипнең иҗат лабораториясе», «Халык авыз иҗаты», «Әдәбият белеменә кереш», «Әдәбият теориясе», «Шәрык халыклары әдәбияты», «Сәнгатьле уку нигезләре», «Нәшрият хезмәте», «Әдәби редакцияләү» һ.б. предметлар алып бара, һәркайда шәкертләренең яраткан остазы, олы исемле мөгаллимә буларак хезмәт куя. Бүгенге көндә Р.Харрасова – егерме алты укыту-методик әсбап авторы.

Әдәби тәнкыйть, әдәбият гыйльмияте өлкәсендә күпсанлы хезмәтләре белән танылган галимә Рифә Харрасова кандидатлык диссертациясендә өйрәнеп яктырту өчен остазы, Казан университетының атаклы профессоры Р.К.Ганиева җитәкчелегендә Гаяз Исхакый иҗатының башлангыч дәверен сайлап ала һәм уңышлы яклап чыга. Әйтергә кирәк, Р.К.Ганиева – милли әдәбият гыйлеменә көчле галимнәр әзерләп биргән профессор. Академик Д.Ф.Заһидуллина, галимә А.А.Шәмсутова, Л.Р.Фәезова, Л.Н.Шарова һ.б. кебек милләтебезгә гаярь хезмәт итүче шәхесләр рәтендә Рифә Харрасованың исеме аерым урында. Галимәнең шактый хезмәтләре «Татар әдәбияты тарихы» академик томлыклары өчен махсус хәзерләнә. Остазы Р.К.Ганиева эзеннән Р.Харрасова, Г.Тукайның тормыш һәм иҗат юлының моңарчы игътибарга алынмаган якларын өйрәнеп, «Тукай энциклопедиясе»нә ике йөздән артык мәкалә тәкъдим итә, матбугат аша киң җәмәгатьчелеккә җиткерә.

*«Әйдаманның аты булган сүзләр,*
*Чын останың хакы булган сүзләр.*
*Тамырлары туфрак капшаганда,*
*Һәр килер чор үз баласын күзләр!»*

Казан университетында татар студентларына иҗат кодрәтен, сүз көчен тоярга өйрәтүче түгәрәк бар. Милли әдәбиятыбызның кабатланмас затлы шәхесе, мөгаллим Мөхәммәт Мәһдиев җитәкләгән «Әллүки» түгәрәгенең чираттагы әйдаманы тукайчы галимә Рифә Рахман булуы бик тә табигый. Язучы-мөгаллимә студентларны «Әдәби сүз» исемле гәзит чыгару дәртенә тарта. Бу дәвердә мәгърур университетыбыз гүя әйдаман, сүз остасы Рифә Фәтхрахман кызын үз чорының асыл сүз остасы итеп танытырга ашыктыра, талантлы язучыга соңрак «Мәгърифәт», «Идел», «Гаилә һәм мәктәп» журналлары мәйданы ачыла. Җитди теоретик әзерлеге булган галимә журналистика өлкәсендә дә үзен, беренче чиратта, остаз итеп күрә. Р.Харрасова бу өлкәдәге эзләнүләрен «Татар матбугаты: бүген һәм иртәгә» (2010), «Остаз кадерен оста белер» (2011) «Яшь редактор киңәшләре» (2009) һ.б. күпсанлы китапларында, хезмәтләрендә тәкъдим итә.

1995-2022 еллар аралыгында милли поэзиябез киштәсен унбер шигырь китабы белән баеткан Р.Рахманның иҗади куәтенә үз заманында Роберт Әхмәтҗанов иң гадел һәм тулы бәя биргәндер кебек тоела: «Татар шигъриятендә Мәхәббәткә шулай табынган, аны төрле яклап, төрле интим балкышлары белән сурәтләгән тагын берәр шагыйрь бар микән? Белмим. Китаптан китапка күчеп, бу татлы, газаплы моң дәвам итә... «Шук алма, моңсу алма» җыентыгына карата түбәндәгеләрне әйткәнмен. Ә бу фикерләрем бүген дә шул ук килеш кала…: «Мондый шигъриятне стандартчылар, гадәти шигърият түгел бу, дияргә мөмкиннәр. Дөрес уйлыйлар. Ә минемчә, шигырь технологиясендә «җан биргән» адәм буларак әйтәм, бәям: тапталган сукмак түгел бу. Рифәнең рухи атмосферасы, күңел дулкыннары – үзенеке, бу яктан аның почеркының үтә индивидуальлеген аерымларга мөмкин». Шагыйрәнең «Шук алма, моңсу алма» дип исемләнгән поэтик җыентыгы (1997) һәм «Төнге кояш» (1999) тупланмасы «Ел китабы» бәйгеләрендә III дәрәҗә дипломга лаек була. Каләм иясенең поэтик иҗаты С.Сөләйманова исемендәге әдәби бүләк (2008) белән билгеләнә.

«Айлы күлдәвекләр», «Онытырмын димә», «Йолдызлар төстән язганда», «Таулар һаман ерак» исемле җыентыклар Р.Рахманны киң катлам укучыга прозаик буларак танытты. «Сөннәтче әби», «Бер микъдар былбыл», «Судан тапкан йөземнәр», «Сары шарф» һ.б. әсәрләрендә үзәккә татар тормышы алына. Прозаик Рифә Рахман Ф.Хөсни (2012), Г.Исхакый (2014) исемендәге бүләкләргә лаек була.

Әдәбият теориясен студентларга фән буларак укыткан галимә, үзенчәлекле каләм остасы күптән түгел яраткан укучысына «Татар кызы» дип исемләнгән романын бүләк итте. Роман жанры аша укучысы белән сөйләшүне Рифә Рахман болай башлый: «Ирләр белән иңгә-иң торып тормыш тарткан Татар кызы! Кем Син? Нинди Син? Узган гарасатлы гасыр, яшәгән тирәлегең ничек үзгәртте Сине? Ниләрдән рухыңны сындырмаслык көчләр аласың? Нинди сыйфатларыңны балаларыңа, оныкларыңа биреп калдырырга ашкынасың? Синең хакта башка кавемнәр ничек уйлый? Илең, халкың, нинди булуыңны тели, заман Синнән ни көтә?».

Гаяз Исхакый мотивларын хикәяләрендә яңгыраткан язучы романда татар хатын-кызының архетипик моделен сакральләштерә. Романда гыйлемле, көчле ире янәшәсендә үзен гаярь итеп тойган, тырыш, хезмәт сөюче, хыялый һәм нечкә күңелле, тирән кичерешле хатын-кыз идеаллаштырыла. Татар әдәбиятында Рифә Рахман прозасында актуальләшкән сөннәтче әби образы романда мифологема төсендә тәкъдим ителә: «Безнең нәселдә буыннан-буынга кызлар гайрәтле. Эшен дә ирләрне уздырып эшлибез», – дип горурланучы Зәмниха образында татар хатын-кызының нәселдән-нәселгә күчкән архетипик сыйфаты атала һәм сакральләштерелә. «Нәселен кумаган эт булмас, дигәндәй, гаярьлекләре, дөньяны аңлаулары, авыр чакларда куркып калмаулары» белән аерылып торган, «тормышны тартышырлык, кирәк чакта киңәшен бирерлек хатын-кызлар белән яшәү җиңелрәк тә, күңеллерәк тә иде» дигән фикерләр сөннәтче әби, кендек әбисе мифологемасы эчтәлеген тулыландыра.

Алда куелган сорауларга җавапны әдибә геройлары теле белән әйтеп бара. Әйтик, кыргыз мәргәне Муса уйларында автор карашы тоемлана. («Хыялый булу, чиктән артып китмәсә, кешегә бик кирәк. Ул сыйфат өметле итә, сәфәргә тарта, дөньяны беләсе килү теләгән көчәйтә»; «Татарларның кызлары белемле, дип соклана иде атасы, аларга шуңа да дәрәҗәле адәмнәр өйләнә»; «Аларда дин көчле, белем көчле. Үзләренә, гамәлләренең нәтиҗәсенә ышаныч көчле. Шулай булмаса, җәһәннәмнән бу якларга күченерләр, заводлар салырлар, кибетләр ачарлар идемени?!»

Нечкә тоемлы шагыйрә Р.Рахман романда ирдәүкә белән чын хатын-кыз арасындагы аерманы ассызыклауны тиеш таба. Зәмниха – көчле, укымышлы, тирән фикерле, тырыш, затлы Әхмәтгалим янәшәсендә генә чынлап ачылган урман кызы – үзендәге ирдәүкәлекне тоеп, йөгәнли алган хатын итеп бирелә. Шул рәвешле, язучының идеалы – «йортны сакларлык, безне якларлык ир» янәшәсендәге «иманлы, намаз-ниязлы, ата-ананың кадерен белүчән» хатын.

Рифә Рахман хатын, килен образын милли гореф-гадәтләрне тасвирлау аша мифлаштыра, сөннәтче әби, урман кызы сыйфатларын үз эченә туплаган архетип шулай тудырыла. Әдибә иҗтимагый проблематиканы фәлсәфи мотивлаштыра: гореф-гадәтләр югалуын хәзерге заман фаҗигасенә әверелгән проблема – кешенең кадере бетүенең асыл сәбәбе итеп күрсәтә: «Нишләптер гел актан киенгән, бар нәрсәне, чип-чиста гына түгел, агартып юган, дөньяны җигелеп тарткан, көмәнле чагым дип тә тормаган Таифәгә бигрәкләр дә шаккатты Зәмниха. Бәбәй китергәндә, кендек әбисенә кеше эзләп мәшәкатьләнәсе килмәгәнме, моның сәвитнекеләргә ошамавыннан курыкканмы, больницаны – еракка, анда баруны эш калдыруга санаганмы, белмәссең. Баласын өендә ялгыз калып кына таба да, кендеген кисеп, тазартып, биләүгә салгач, аркасына утын күтәреп, су буйларындагы мунчаларын ягарга китә икән. Әнисе Нихан, кырык көнгә кадәр бәби алып кайткан хатынны да, сабыен да бик сакларга кирәк, дип әйтә торган иде. Нинди күтәрү, нинди мунча! Хәзер хатын-кызның, яңа туган баласын алып, уракка китүе дә табигый бер хәлгә әйләнде, кырда гына бала табуы да. Элек авырлы чагында да ялгызын калдырмаганнар аны, өйдәгеләре бер-бер җиргә китеп барса, төн кунарга күршеләре кереп калган. Андый вакытта хатыннар хәлсез, йомшак була, албастыдан бастырылуы, көмәне төшүе бар дип курыкканнар. Кадере китте кешенең, кадере китте хатын-кызның...»

Романда гаилә-нәсел-ил мотивы хатын-кыз образы белән бер дәрәҗәдә сакральләштерелгән ир заты идеалы эчтәлегенә урнаштырыла. «Кеше дә, хыяллар да үзгәрә, хәтта тамырларында аккан кан да гел бер үк булмый торгандыр, әмма илеңне тою, аны ярату барыбер узмый икән», дигән караш автор фикере кебек аңлашыла. Татар кызы белән беррәттән, татар ирендәге сыйфатлар, аның үзгә эчке дөньясы ачыла. Авторның иҗтимагый проблемаларга фәлсәфи бәясе дә нәкъ менә ир-ат геройлары уйланулары аша бирелә («Акылы-уе булган бөҗәк, гамьсез бер суръттә, сытылырмын дип тә курыкмыйча, бер кирәкмәгәнгә, аягы буйлап сәяхәттә йөрер идемени...»; «Агачның черек кайрысын кайчаннан бирле тукылдаткан тукран Әхмәтгалимнең бу утыргычта тиккә генә утырмаганын, иң соңгы, әлегә чардугансыз каберлектә аның сабые ятканын беләме? Юктыр. Белсә, йөрәкнең ашыгып типкәнен дә уздырып тукылдаудан туктар иде» «Йөзләгән, меңләгән кешеләрне ачлы-туклы тормышка калдыру, иленнән куу шул ук тереләй үтерү белән бер түгелмени» һ.б.). Ир-ат геройлары теле белән бирелгән ватанпәрвәрлек мотивын язучы Вюнсдорф лагере тоткыны Әхмәтгалим исеменнән туган нигез кадере эчтәлеге аша аңлата: «Урыс саналган татар тоткынының тел белүенә дә, эшкә кулы ятуына да, әдәбенә дә, динилегенә дә таң калдылар. Солыхка кул куелып, сугыш тәмамлангач, хуҗалары Әхмәтгалим белән елый-елый хушлашты. Монда кал, яшь хатын алырсың, укырсың, үзебездә торырсың, дип үгетләделәр, каласы итмәде, Зәмнихасын, балаларын сагынганын әйтте. Берничек җаен таба алмагач, аларны да үзеңә алдыра аласың, дип тә карадылар.

– Туган җирне монда алып килеп булмый шул, – диде».

Туган нигез мотивын шәҗәрә мотивы тулыландыра. Әхмәтхәсән башлаган шәҗәрә Әхмәтгалим кулында: «Әлеге шкафта Әхмәтгалименең нәсел тамырларын чагылдырган шәҗәрә дәфтәре дә бар. Ул аңа исән калган биш баласының, кияүләренең исемен өстәде. Өстәде дә сызды». Шәҗәрә мотивын исә кеше язмышы, милләт язмышы проблемасына балага исем кушу йоласы тоташтыра: «Зәмниха яннарыннан кайтып озак та үтмәде, Әхмәтгалинең малае туды. Габделбари дип кушканнар. Шул хактагы хатында Аннасы белән икесенең, исемен кыскартып, Бари дип йөргәннәрен язган. Иптәшләребез – Борис... Ананың йөрәге шушы сүзләрдән жу итеп китте. Кыскартсалар кыскартсыннар да! Анысы халык гадәтендә. Мулла кушкан исемне бөтенләй бозарга ярыймы соң?! Икенче кешегә әйләндерү бит бу. Бариларына ниндидер бер урысның – Бориснең язмышын бирүгә ризалашу».

Нәсел тарихы аша Р.Рахман «Татар кызы» романында XX йөздәге милли-иҗтимагый барышның иң четерекле проблемаларына, чорның җанөшеткеч вакыйгаларына бәя бирә. Нәтиҗәдә, дилогиядә татар тормышы тулаем бер образ буларак тәкъдим ителә.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, (ул шулай ук Җамал Вәлиди исемендәге бүләк иясе дә) Рифә Рахманның нечкә тоемлы, ярсу хисле шигърияте таң калдыра, күңелнең иң тирән кылларын кузгата, экзистенциаль әрнү-сагышлардан үрелгән прозасы тетрәндерә. Тынгысыз галимә Р.Харрасованың ялкынлы гыйльми сүзе сискәндерә, гамьле итә, тәнкыйтьченең үткен публицистик каләме уйга сала. Шагыйрәнең «лирик мин»е үзенең – талантның дөньяга килүен гайре табигый хәл итеп сурәтли:

*«Йолдызларның аңы киткән чакта,*
*Йолдызларның төсе уңганда*
*Туганмын мин.*
*Инеш, елга суы*
*Ярларына тәмам тулганда.*
*...Бик газаплы диләр йолдызларның*
*Яралуы Галәм эчендә.*
*Мин дә йолдыз кебек җан алганмын*
*Шуңадыр да йолдыз төсендә».*

Рифә Рахманның шигъри фәлсәфәсендә яшәү мәгънәсе, гомер озынлыгы, килер буыннар турында уйланулар зур урын алып тора. Алардагы моңсу интонациягә һәрвакыт өмет хисе килеп кушыла. «...Безнең урыныбызга да никадәрле йолдыз табылыр», – дип белдерә ул шушы ук шигырендә.

Чорыбыз җырчысы, шагыйрә, каләм иясе, талантлы киң колачлы галимә Рифә Фатхрахман кызының түгәрәк юбилее якынлашып килгән көннәрдә әдибәнең шул сүзләре күңелгә килә. Рифә апаны Казан федераль университетының татар әдәбияты кафедрасы исеменнән чын күңелдән туган көне белән котлыйбыз, фәнни һәм иҗади уңышлар телибез.

**Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА,**
*Казан федераль университеты доценты*

# КҮРЕНЕКЛЕ МӘГЪРИФӘТЧЕНЕҢ ҖАН АВАЗЫ

Академик Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның «Горур булыйк / Быть достойными сынами своего народа» (2022 ел, Казан, 303 б.), «Милләтебез иминлеге сагында / За развитие нации» (2022 ел, Казан, 560 б.) дигән һәм соңгы елларда басылган башка китаплары белән танышып чыккач, авторның кыюлыгына, тирән акылына, дәлилле мисалларына, киләчәк буыннарыбызны кайгыртучанлыгына хәйран каласың. Китаплар йөгерек тел, ихласлык белән хикәяләү рәвешендә язылган. Шуңа күрә аларны уку рәхәт, җиңел. Тагын да тәгаенләбрәк әйтсәк, татар халкы, аның туган теле, милли мәгарифе, яшь буынның, балаларыбызның киләчәк язмышы турында борчылып, милли мәгарифнең кирәклеген, Казан педагогика университетын кабаттан торгызуның Татарстан Республикасы, халык өчен кичектергесез гамәл булырга тиешлеген раслап, чаң суга академик. Мондый борчылулар галимнең республикабыз матбугатында игълан ителгән «Алтыннарга алыштыргысыз асыл туган телебезнең кадерен белик!..», «Баланы газиз ана теленнән аеру – җинаять...» , «Телебезнең тамырлары халкыбызның йөрәгенә барып тоташкан, аны өзәргә, бала җаныннан тартып алырга ярамый, туган телебезгә тупас күнел, явыз ният белән кагылырга беркемнең дә хакы юк» рухында язылган күпсанлы мәкаләләрендә дә чагылыш таба.

Кемнәрдер «Ана теленә кизәнү», «Үз телеңне санламау», «Туган телебезгә кадер җитми» кебек сүзләрне, язу түгел, кычкырып әйтүдән дә куркып яшәгән заманда Рүзәл Юсупов, битарафлык белән килешмичә, газета-журналларда – татарчаларында да, русчаларында да – бер-бер артлы берәгәйле мәкаләләр бастырып тора, эфир дулкыннарыннан да ике телдә дә тәэсирле чыгышлар ясый. Иң мөһиме һәм сокландырганы: зур тәҗрибә туплаган, ярты гасырдан артык шушы өлкәдә кайнаган мәшһүр мәгърифәтченең йөрәк авазы булып яңгырый алар. Җаны әрнеп, Күкләргә дә, Җирдәгеләргә дә, уң яктагы «фәрештәләребез»гә дә, сул яктагыларына да урынлы, дәлилле таләпчәнлек, үтемле сүзләр белән эндәшеп оран сала Рүзәл Юсупов. Көнкүрешнең четерекле якларын, авырлыгын күреп, бала чактан ук үз җилкәсендә татып, кырыс тормыш мәктәбен үтеп, яшәүнең мәгънәсен белергә кирәклеген аңлап үскәнгәме, бөтен аңлы тормышын камиллеккә омтылу, халык өчен яшәү тәшкил итә аның.

«Миңа 4-5 яшьләр булгандыр, – дип яза профессор Р.А.Юсупов. – Абыйлар саламны, кочаклап, өйгә кертеп ташлыйлар да, мин аны мичкә ягып торам. Саламны, учлап, мич авызына төртеп кертеп җибәрәсең, ул шундук гөлт итеп кабынып китеп, минут та узганчы янып та бетә... Бервакыт, янып торган салам кисәге, мичтән идәнгә очып төшеп, ут өй буенча тарала башлады. Ул арада караваттагы юрганга да кабып өлгерде. Мин өйдән чыгып кычкыргач, ярый әле абыйлар якында булып, йөгереп кереп, янгынны сүндерә алдылар...»

Урмансыз якларның күбесенә хас күренеш иде бу салам ягып, өйне җылытырга тырышу. Әйе, «тырышу» гына шул... Кышкы ачы суыкта авыл йортын салам ягып җылыту бик кыен эш. Шулай ук, без үскәндә, авыл баласының, бишектән төшүгә дигәндәй, әти-әнисенең кул арасына керә башлавы да табигый иде.

«Безнең Кышкар авылы фәкыйрь табигатьле җирдә урнашкан, – дип дәвам иттерә

Рүзәл абый хатирәләрен, «Милләтебез иминлеге сагында...» китабының «Балачак һәм мәктәп еллары» бүлегендә. – Урман-болыннары да, зур суы да юк. Өч коры елганың берсендә колхоз көтүе, икенчесендә авыл халкыныкы йөри. Өченчесендә колхоз малына чабу өчен печән үстерәләр. Кешеләргә, үзләрен ачка үлүдән саклап тора торган бердәнбер сыер яки кәҗәсен, бер-ике сарыгын асрау өчен, терлек азыгы әзерләргә мөмкинлек юк. Без энем Әнәс белән, ерак басуларны иңләп-буйлап, бөртекләп дигәндәй җыйган печәнебезне колхоз рәисе яки бригадир тартып алып калмасын дип, әйләнгеч урыннардан качып-посып алып кайта идек. Бер-ике бөртек малыңнан никадәр итен, сөтен, маен, йонын налог исәбенә дәүләткә бушлай бирдертеп, авыл халкының үзенә ашарга калдырмыйча, мыскыллап яшәттеләр бит. Ул елларда кешеләрнең михнәтле гомер кичерүен искә төшергәндә, дәүләт җитәкчеләренең үз халкына шулчаклы миһербансыз булуын, аны шулкадәр җәфаларга дучар итүен уйлап таң каласың...»

Рүзәл Юсуповның, зур гыйльми дәрәҗәдәге дан-шөһрәткә, публицистика өлкәсендәге күпсанлы хезмәтләргә ия булса да, «язучы» дигән исеме юк. Чын әдәп-әхлак иясе буларак, үзенә купшы исемнәр тагарга ашыкмаган бу галим. Юкса ул үз гомерендә бик күп фәнни-публицистик мәкаләләр, очерклар, хезмәттәшләре турында иҗат портретлары язган, камил эшләнешле тәрҗемәләр ясаган. Менә бу китапларга кергән хезмәтләре буенча гына хөкем йөрткәндә дә, теленең байлыгына, каләменең йөгерек булуына, тирән акыл һәм ихласлык белән иҗат ителгән пөхтә язмаларына хәйран каласың (гадәттә, фән кешеләренең стиле шактый коры була бит). Аның язмаларын укыйсы килеп укыйсың.

«Җәй ае. 10-11 яшьләремдәге чагым. Әни сәгать 4-5ләр тирәсендә йокымнан уятып, авылыбыздан 15 чакрым ераклыктагы Әтнә базарына, бер кадак (400 гр.) сарык йоны сатып кайтырга җибәрде. 25 сумнан. Яулыкка төрелгән бер йомарлам йонны тотып, җәяүләп, район үзәгенә юнәлдем. Барып җиттем, кулымдагы йонны ачып куеп, базар буйлап йөрим. «Күпмедән сатасың?» – дип сораштыргалыйлар. «25 сумнан», – дим. «Кыйммәт, 20 сумнан алам», – диләр. Нишләргә? Кире алып кайтыргамы, 20 сумнан сатып җибәрергәме? 20 сумнан биреп, җәяүләп кайтып киттем. Кичкә генә кайтып кердем. «Йонны харап иткәнсең икән», – дип, бик нык ачуланды әни, мин акчаны кулына тоттыргач... Ул елларда халыкның никадәр авыр, фәкыйрь яшәгәнлегенә, һәр тиеннең кадерле булганлыгына бер мисал бу...» Ихтыяр көче, күзәтә һәм нәтиҗә ясый белү менә кайчаннан ук формалаша башлаган үсмер егеттә.

Кызыксынган кешегә «Милләтебез иминлеге сагында» дип аталган бу китапны табу кыен булмас. Хәер, басманың тиражы 300 данә генә... Ә күпме тарих, күпме мәгълүмат, анализ, сугыш вакыты газапларының картиналары анда...

«Без әле сугыштан соң да күп еллар угычтан чыгарылган бәрәңге кушып пешерелгән, лыҗырдап торган ярым чи ипи ашадык. Кар эреп, җир ачылгач, көздән калып чери башлаган бәрәңге җыярга басуга барабыз. Өшегән балчык аяк киемен суырып ала. Шуңа күрә чабатаны яки агач башмакны басу кырыенда салып калдырабыз да ялан аяк йөреп җыябыз. Кайбер урыннарда туң китеп бетмәгән була, шома боздан аяклар таеп-таеп китә. Ничек суык тиеп, авырып китмәгәнбездер? Алып кайткач, ярым черек бәрәңгене юып, чистартып, «кәлҗемә» дип йөртелә торган күмәч пешерәбез.

Һәр атнаны ике зур чиләк бәрәңгене тимерче алачыгында ясаткан угычтан уабыз, угычның чәнечкеле тупас тешләре бармакларны умырып-умырып ала... Шулай итеп, газаплы сугыш михнәтләре әле озак дәвам итте.

Хакыйкать шул: татарлар – тырыш халык. Кырыс яшәү шартлары безне кечкенәдән үк крестьян тормышындагы авыр, кара эшләрдән дә курыкмаска, чирканмаска өйрәтте...» дип яза автор.

Гыйбрәт алу өчен, язмышларны, язып, сәхнәгә менгерү генә димәгән. Менә шушылай китаптан укып та күп сабаклар алып була икән. Рүзәл Юсуповның «Милләтебез

иминлеге сагында...» китабының алдагы битләрендә авторның 14 яшеннән башланган мөстәкыйль тормышы, товаровед белеме алып, сәүдә системасында «адашып» йөрүләре тәэсирле итеп язылган. «Сайланырга мөмкинлегем юк иде, кооперация сүзенең нәрсә икәнлеген белмәсәм дә, гаризамны кооперация техникумына бирергә булдым. (Чөнки мәктәптән бирелгән таныклыгындагы бер сүз хатасын төзәттереп, арлы-бирле йөргән арада башка техникумнарда кабул итү тәмамланган була – **Э.Ш.**) Техникумда уку минем тормышымдагы беренче җитди сынау булды», дип искә ала автор Казанга килеп «мөстәкыйль яши башлау» еллары турында. Курган өлкәсендә товаровед булып эшләве, аннары, солдат каешы белән билен буып, армия сафларында хезмәт итүләре, хезмәтнең дә ниндие диген әле, Памир тауларында, Әфганстан чигендә кавалерист, ягъни атлы чик сакчысы. Шулай итеп, ерак Курган, Әфган чикләреннән туган якларына әйләнеп кайтып, булачак төп һөнәренә якыная төшеп, тәрҗемәче һәм журналистлык эшенә чумулары һәм, ниһаять, 1964 елдан кантарлы да, катмарлы да фән юлына кереп китүләре, бер адым ераклыкта гына җитәкчелек вазифасының «көтеп» торуы... Болар барысы да мавыктыргыч итеп, Эзоп теле кулланмыйча, һәр кешенең исем-фамилиясен әйтеп язылганнар. Алай гына да түгел, җорлык-мәзәкчәнлек тә кызык төсмерләр бирә аның хатирәләренә...

Ниһаять, фән һәм җитәкчелек гамәлләре...

Кышкар басуларында бата-чума өшегән бәрәңге җыю гына түгел икән шул тормыш юлындагы баткаклыклар. Аяк киемеңне генә түгел, җаныңны суырып алырга әзер торган каршылыклар да күп тора икән монда...

Бөтен тәҗрибәсен, белемен, тырышлыгын, егәрлеген җигеп, җилкәсендәге зур җаваплылыкны бер минутка да исеннән чыгармыйча, педагогика институтының дәрәҗәсен күтәрү, укыту-тәрбия системасының, укытучы эшенең сыйфатын камилләштерү, фән эшләрен җәелдерү, матди базасын ныгыту, тәрбияле, чын халык мөгаллимнәрен әзерләүгә ирешү бурычларын алга куеп, эшкә чума ир-егет.

Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның 1986–2002 елларда Казан педагогия институтындагы (1994 елдан Казан педагогика университеты) ректор вазифасын башкару еллары бу югары уку йорты өчен чын мәгънәсендәге реформа еллары була. Үсеш бөтен өлкәләрдә бара: факультетлар, кафедралар саны бермә-бер арта, Чаллы шәһәрендә Казан педуниверситетының филиалы ачыла, чит ил югары уку йортлары белән педагогик, гыйльми элемтәләр булдырыла, кандидатлык, докторлык диссертацияләре яклау советлары ачыла. Укытучы һәм хезмәткәрләрнең тормыш шартларын яхшырту буенча күп эшләр башкарыла, һәм бу зур көч, зур тырышлык, күп вакыт сарыф ителгән изге гамәлләрнең нәтиҗәсе булып, Казан пединституты күрсәткечләре буенча Россиядәге йөзләгән педагогика югары уку йортлары арасында беренче унлыкка керә. 1994 елда исә Казан педагогика институты Казан педагогика университеты статусын ала.

Бастырыклап төялгән, фил сырты сынарлык бу эшләр, бу мәшәкатьләр белән күмелгән кешенең суларга да вакыты калмагандыр кебек, ләкин юк, вакытын дөрес бүлә белгән сәламәт рухлы кеше – тагын тау кадәр эшләр башкара ала икән. Фәнни эшләре, гыйльми яңалыклары – аның инде бик теләсә дә бизә алмаслык «чир» булып канына сеңгән. Нәтиҗә күз алдында. Җәмгысе: 600гә якын фәнни-публицистик мәкалә, 70тән артык монография, дәреслек һәм уку ярдәмлекләре, аның җитәкчелегендә якланган 35 кандидатлык һәм докторлык диссертациясе...

«Милләтебез иминлеге сагында...» дигән китап, нигездә, автобиографик характерда булса, «Горур булыйк!» дип исемләнгәне туган илнең чын патриотларын үстерү, ана телебезнең тулы хокук белән яшәргә тиешлеген кичектергесез хәл итү мәсьәләләрен кайгырту юнәлешендәге педагогик кодекс кебек. «Туган телебезнең перспективасы, татар милләтенең алгарышы мәсьәләсендә хәлнең бик җитди һәм хәтәр булуы хакында безнең барыбызга да ныклап уйланырга кирәк!» ди автор һәм

аеруча әһәмиятле мәсьәләләргә аерым-аерым туктала. «Милләтебезгә тугры булыйк!», «Иң мөһиме – милли мәгарифне алга җибәрү», «Яшь буынны тәрбияләү», «Горур булыйк!», «Әдәби телебезгә реформа кирәкми», «Эфир галәмәтләре», «Телебезгә кадер-хөрмәт булсын!». Язмаларның исемнәреннән үк күренгәнчә, никадәр борчулы уйлар галим башында. «Хәзерге глобализация чорында интернациональлек тәэсирендә миллилек сыйфатларының кимүенә юл куярга ярамый. Халыкларның, аларның мәдәниятләренең гармонияле рәвештә алга баруы – бүгенге кешелек тормышының иң мөһим шартларыннан берсе!»

Бер телне дә, бер милләтне дә кимсетмичә, читкә тибәрмичә, шул ук вакытта телебезнең мең еллык тарихын, халкыбызның казанышларын, тыныч хезмәттә дә, фронтларда да үзләрен аямаган каһарманнарыбызның батырлыкларын яшьләр белергә, өйрәнергә, *«тутыкмас вә күгәрмәс»* шул рухи байлыкларыбызны үзеннән соң киләчәк буыннарга тапшыру эстафетасын кабул итеп алырга тиеш. Ә без балаларыбызны шушы вазифаны тайпылышсыз дәвам иттерерлек итеп тәрбияләргә бурычлы.

«Безнең халыкның ирекле, бәхетле, шатлык-куанычлар белән телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, йолаларын саклап гомер кичерергә тулы хокукы бар. Бу хокукны ул күп гасырлар буена тәрбияле, күркәм, һәр яктан үрнәк булырлык итеп яши белүе белән яулап алган... Шунысы аяныч: без дәшмибез, үзәк хакимият тарафыннан закон бозуларга түзеп торабыз...» дип, ачыктан-ачык ярып сала Рүзәл Абдуллаҗан улы.

Дәшсеннәр иде шул зыялыларыбыз, үз фикерләрен әйтеп, академикның гозерләренә теләктәшлек күрсәтелсен иде!

«Рүзәл Юсупов Татарстан халыкларының бәхетле яшәве өчен, үз халкының югары культурасын, камил туган телен саклап, алга баруы өчен кыю көрәшүче зур галим, зирәк җитәкче, миһербанлы кеше...» – дигән фикерне без күренекле галим, шагыйрь Әнвәр Шәриповның, «Ватаным Татарстан» газетасындагы «Олуг галим һәм җәмәгать эшлеклесе» исемле мәкаләсендә дә укыйбыз. Курсташының белемгә омтылышын, үҗәтлеген, студент елларыннан ук рухының көчле булуын, зур тормышка, зур эшләргә әзерлеген менә ничек аныклый ул: «Безгә соңыннан гына мәгълүм булганча, Рүзәл бу абруйлы уку йортына «татар теле һәм әдәбияты» белгечлегенә мәктәпне тәмамлавына инде 8 ел узганнан соң һәм татар мәктәбенең 8-10 классларында бөтенләй укымаган килеш, үзлегеннән әзерләнеп кергән булып чыкты. Имтиханнарны уңышлы тапшырып, бер урынга биш кешелек конкурсны узып...» – дип, күпләр белмәгән серне ача Әнвәр Мәгъдәнур улы. Күргәнебезчә, гыйлем эстәүгә нинди зур омтылыш, хәйран калырлык тырышлык! Бу урында Рүзәл Юсуповның республикабызның данлыклы Кышкар авылыннан икәнлеген искә төшереп, халкыбызның олуг фикер иясе Шиһабетдин Мәрҗани галиҗәнапларының «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») исемле китабыннан өзек китерү – урынлы булыр: «...Кышкар авылы борынгыдан дәүләтле байлары булганлыктан, муллалары мәдрәсә тотып, күп шәкертләр җыеп, дәрес әйтеп, дан һәм шөһрәт казанганнар. ...Кышкар кешеләре шәкертләрнең төрле гозеренә колак салырга күнеккән. Шәкерт Кышкар кешесенең кайсына гына мөрәҗәгать итсә дә, «юк, булмас», дигән җавап ишетми... сораган әманәт, мәсьәлән, шул көнне үк тиешле кешесенә тапшырыла... «Киләчәккә карап яшәүче, тынгысыз, авырлыклар алдында тез чүкмәүче, ярдәмчел Рүзәл Юсупов шәхесенә әнә каян күчкән икән бу гүзәл сыйфатлар. Туган туфрагыннан. Аның булдыклы, укымышлы халкыннан. Эшсөяр, әмма сынмас, сыгылмас әнисе Лотфикамалдан. Утлар-сулар кичкән, иманлы Йосыф улы Абдуллаҗаннан! Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсуповның җитәкчелек еллары турындагы язмаларында, бүгенге көндә дефицитка әйләнгән кешелеклелек төшенчәсе еш искә алына.

Академик Р.А.Юсупов, гыйльми-педагогик, административ эшләреннән тыш, республиканың иҗтимагый тормышында да актив катнаша: Казан шәһәре советы

депутаты, Татарстан парламенты депутаты һәм аның даими комиссиясе (хәзергечә комитеты) рәисе, теләктәшләре белән бергә оештырган Татарстанның Республика партиясе председателе вазифаларын һәм тагын башка төрле җәмәгать эшләрен башкара.

Тукта әле, дип уйлыйсың кайчагында, балаларча беркатлылык белән, әйтергә генә җиңел булган бу кадәр эшләрне башкарып чыгу өчен нинди егәр, нинди баш кирәк булды икән Рүзәл Абдуллаҗан улына? Бу шәхеснең яшәү һәм эшләү шартлары безнеке кебек тәүлектәге 24 сәгатьлек форматтамы икән?.. Бер кеше гомерендә башкарып булмас кебек күренгән бу кадәр эшләрне ничек тормышка ашырган?.. Шундый сорауларга чумып, якташым, язучы Фарсель Зыятдиновның «Яшәү мәгънәсе» («Тернистый путь к звездам») китабын кулыма алам.

«Укуда Рүзәл Юсупов дәрәҗәсенә ирешүчеләр бик сирәк булгандыр. Ул гел «биш»кә генә укыды, икенче курсны тәмамлагач та, СССР мәгариф министры карары белән, Ленин стипендиаты булды (мондыйлар берничә мең студент исәпләнгән бөтен университетта 3-4 кенә...»). Ә инде китапның эченә кереп укый башласаң?.. Җанлы, гөрләп торган чын студент тормышы. Имтихан-зачётлары, колхозларның бәрәңге басулары, мәхәббәт кыйссалары... Студентның такы-токы табыннары, әмма бик тә бай күңел хатирәләре, яшьлек романтикасы!.. Бәй, баксаң, синең белән *«мин һәм Мөхәммәтәмин»* кебек үк гап-гади кеше икән китапның төп герое Рүзәл Юсупов! Әмма кылган эшләре, якты гомер юлы белән яшәүнең чын мәгънәсен аңлаган, үзе җитәкләгән университетның гына түгел, республикабызның да зур горурлыгы саналырга тиешле фидакарь әйдаманы!..

Көнне-төнгә ялгаганмы, ял дигәнне дә белмәгәнме – алар инде үткәндә калган. Ә бүгенге көндә алдыбызда, өеп куйсаң, Каф тавы биеклегенә тиң булырдай кыйммәтле хезмәт! Әгәр инде, академикның балачак елларына кайтып, кабат уйлансаң, бер тәүлекнең ике тәүлек кадәр озын булып сузылу очраклары күп булган аның язмышында. Ачлы-ялангачлы сугыш еллары, сугыштан соңгы мохтаҗлык...

Бер әниләренә дүрт ир бала булып үсә алар... Чү, монда да әкияти могҗиза түгелме? Башта Фин сугышында катнашып, аннан Бөек Ватан сугышына киткән әтисе Абдуллаҗанның 1943 елда «батырларча һәлак булды» дигән хәбәре килә. Ишетеп, якыннары гына түгел, бөтен авыл халкы кайгыра. Ә бер заман?... Хәрби киемнән, балаларына дип, букчасына берничә шакмак шикәр салган Абдуллаҗан үз аягы белән кайтып килмәсенме?.. Билгеле инде яраланып, озак кына госпитальдә дәваланганнан соң, инвалидлык алып... Биш ир баланың (бишенче егетне сугыштан соң алып кайта Лотфикамал әниләре) әтиле булу бәхетен (ул елларда бигрәк тә!) Аллаһы Тәгаләнең гүзәл бер бүләге-могҗизасы дими, ни дисең тагын?!

Әйе, иксез-чиксез җиһанда серләр дә, хикмәтләр дә күп. Безнең буын, Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов кебек, намуслы, гадел, көчле рухлы, халык бәхетенә туган шәхесләр белән бер елларда, күрешеп, аралашып, тел-ләгать алышып яшәве белән бәхетле. Чөнки алар үзләренең табигый күңел матурлыгы, калебләреннән ургылып чыккан игелек белән дөньяны нурландырып, бизәп торалар! Ул саф та, бәрәкәтле дә нурлар озак еллар балкып, киләчәк буыннарны да илһамландырып торыр әле.

**Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА**

# БЕР ЗАМАННАР ЮЛЛАРЫ АНАДОЛУДАН КИЧКӘН ТАТАР ХАТЫННАРЫ...

Анадолу җирләре һәр заман төрле җирләрдә яшәгән төрки халыкны җәлеп итү үзәге булган. Истанбул хаҗ кылырга барганда тукталып, дога кылырга кирәкле урын, дини гыйлем ала торган шәһәр, капкасы һәрчак ачык йорт, һәр төрле эштә мөрәҗәгать итә, ярдәм сорала торган абый сыйфатын саклаган.

Татарлар Казан ханлыгы таркалганнан соң дини, социаль һәм икътисади басым аркасында Анадолуга төрле елларда тупланып та, берәм-берәм дә килгәннәр. 1890 елда Рус патшасының дини сәбәпләр аркасында китәргә теләүчеләргә рөхсәт бирүе, 1891 елдагы ачлык, 1897 елда халык санын алу вакытында руслаштырудан курку күпләп китүгә этәрә. Моннан тыш, хаҗ кылып яки дини гыйлем алып йөргәндә һәм башка сәбәпләр аркасында туган җирләренә кире кайтып китмәүчеләр була. Анадолуның уңдырышлы җире күпләрне кызыктырган.

Төркиягә бигрәк тә республика чорының беренче елларында бик күп татар галимнәре килә. Аларның кайберләре Ататөрек белән янәшә хезмәт итте, яңа Җөмһүрият корылышында зур файдалар китерде. Бүгенге көнгә кадәр төрекчә басылган әсәрләрдә күп кенә танылган татар галимнәренең, гаскәриләрнең, сәясәтчеләрнең һәм активистларның тормыш хикәятләре аңлатылды, киләчәк нәселләрнең дә аларны онытмавына өмет бар. Әмма бу хезмәтләр, күбрәк ир-егетләр турында, хатын-кызлар исеме еш телгә алынмый. Җөмһүриятнең беренче елларында Төркиягә килгәнче үк академик әзерлек чоры узган укымышлы, Төркиядә бик аз кеше белгән рус, япон, кытай, инглиз телләрен өйрәнгән татар хатын-кызлары булганны да онытмаска кирәктер. Алар арасында эшлекле Сафия Имрә (Мәнгәр), Төркия Бөек Милләт мәҗлесендә сенатор булган дипломат Адилә Аида (Садри Максуди кызы), профессор, доктор Сәгадәт Чагатай, доктор Сахип Байдар, доктор Таифә Акчурина, теш докторы Маһирә Байчура, Алия Аги, фармацевт Зиннәт Нурмөхәммәт һәм Зөһрә Аги исемнәрен хөрмәт һәм рәхмәт белән искә төшерәбез. Татар хатыннарының исемнәрен дәвам итеп, сезне Төркия язучысы Рәҗаи Санайның «Кызыл Русиядә бер төрек хатыны» биографик романы белән таныштырасым килә.

Айнелхәят – Патша Россиясендә туган, Госманлы Төркиясендә, Истанбулда җитешкән, Истанбул «Дарүлмуаллимат» – укытучылар әзерли торган кызлар мәктәбендә белем алган бер төрек мөгаллимәсе, шимал төрекләреннән бер хатын-кыз укытучы. Китапта Патша Россиясенең соңгы көннәре, бөек рус революциясе, бу инкыйлабтан соң бөтен вәхшәте белән башланган кызыл режим дәвере, ГПУның йөрәкләргә кан саудырган кызыл җәһәннәме, төреклек, татарлык булган бөтен төбәкләре кичә... Шулай ук Р.Санай кереш сүзендә Айнелхәятнең Россиядә кызыл режим, коммунистлар партиясе өчен күп еллар эшләп, депутат дәрәҗәсенә күтәрелгәнен, соңрак рухында, күңелендә бер төрле сүнмәгән милли хисләр тәэсирендә бу режимга һәм идеологиягә «төгәл генә» яраклаша алмавын искәртә. Китабында ничек итеп татар хатынының башына төшкән гаделсезлекләрдән, золымнардан, газаплардан рухы, вөҗданы изелеп, большевиклардан күңеле кайтуын, 16 елдан соң яңадан Төркиягә кача алуын тасвирлый. Китапны язганда, каһарманына 69 яшь икәнне әйтә.

***

Айнелхәят ханым – Идел буенда Саратов өлкәсенең Мәстәк авылыннан Зәйнетдин исемле бер авыл морзасы оныгы. Россиядә узган балачагы, һиҗрәт юлы китапның беренче битләрендә ачык тасвирлана.

Бабасы Ирбит базарыннан өенә кайтканда агулап үтерелә, ятим калган ике баласы уллыкка бирелә. Айнелхәятнең әтисе үзен уллыкка алган гаиләдән кача, бер мәдрәсәдә, аннары рус ятимнәр мәктәбендә яши. Билгеле бер вакытлардан соң ул сәркатиб булып, Акчуриннар фабрикасында эшли, гаилә кора, Урал елгасы буена җирләшә.

Башка татарлар кебек үк гаилә башлыгы һиҗрәт юлына басарга карар итә. Төркиягә килгәч, хатыны һәм ике баласы холерадан үлә. Икенче хатынга өйләнә. Истанбулда яши башлагач, Айнелхәятне үги анасы бер өйгә хезмәтче кыз итеп урнаштыра. Өй хуҗасы үлгәч, ул кабат әтисе янына кайта. Әмма бу юлы үги әнисе аны «тәмәке тарта» дип гаепли. Нәтиҗәдә ата кеше кызын өйдән куып чыгара. Шулай итеп, кыз бер хәерче кардәшләрендә яшәргә мәҗбүр кала.

1896 елда уналты яшендә аны әтисе 17 алтынга Мәдинәдә сәүдәгәрлек иткән 55 яшьлек Россияле төрекләрнең берсенә икенче хатынлыкка бирә. Айнелхәятне ире Мәдинәгә беренче хатыны һәм 5 баласы янына алып китә. Кызы туа, әмма сабый озак яшәми. Берникадәр вакыттан соң ире үлә, яшь хатын җирсез-йортсыз кала. 20 яше тулганда, әтисенең танышлары аны кабат кияүгә бирәләр. Берара иренә Төркестаннан хәбәр килеп ирешә. Абзыйсыннан калган малны бүлешер өчен Төркестанга җыенган иренә ияреп, күкрәк баласы белән Әстерханга кадәр китә. Әмма аннан мең газаплар чигеп, баласы белән үзенә генә әйләнеп кайтырга туры килә, чөнки ире хәбәрсез югала. Күп тә узмый сары чиреннән икенче баласы да үлә.

Әтисе кыз кардәше белән бергә Истанбулда бер өйне арендага тотарга ярдәм итә. Кардәше беренче сыйныфка, үзе 26 яшь тулуга карамастан, бары тик икенче сыйныфка укырга бара. Берничә көннән соң өченче, бер айдан соң дүртенче сыйныфны тәмамлый. Шулай итеп ул, олыгаеп барган кызларга укырга керергә беркайчан соң түгеллеккә бер үрнәк күрсәтә.

Мәктәпне тәмамлаганда, ире килеп чыга. Өенә бер хәзрәт белән килеп җитә. Казый кеше ирләргә кагылышлы диндә никадәр язулар булса, һәркайсын сөйләп биргәч, Айнелхәят хатыннарга кагылышлы никадәр аять, хәдис бар, барысын әйтеп бирә. Шуннан казый: «Аңлашылды, синң хуҗаңа (ireңә) лаек түгел», – дип китеп бара.

1913 елда 28 яшен тутырган тол хатынны лицейларга кабул итмиләр. Ул төрек хатыннарының иң бөеге, иң хөрмәтлесе саналган Халидә Әдипкә (1884–1964, язучы, академик, мөгаллимә) мөрәҗәгать итә.

Халидә Әдип аны ул вакытта мәгариф министры белән элемтәсе булмау сәбәпле, Америка мәктәбенә җибәрә. Әмма Айнелхәят анда китәргә теләмичә, укытучылар мәктәбенә керер өчен, Мәгариф министрлыгына гариза бирә. Шуннан соң Әхмәт Агауглы (милләте буенча азәрбайҗан булган хокук белгече, язучы, сәясәтче) ярдәме белән икенче сыйныфта укый башлый.

Укып йөргәндә, әтисенең вафат хәбәрен ала.

Җәйге ялларв вакытында Беренче Бөтендөнья сугышы игълан ителә. Кыен көннәр башлана. Ачлык һәм фәкыйрьлек өстенә суык тигезеп чирли. Ашарга, даруга акчасы юк. Укуга бара башлагач, чире көчәеп китә. Бик зур авырлык белән кичкән уку елы иртә тәмамлана. Мәктәп Төркиянең Чанаккале шәһәре янында бәйсезлек өчен барган сугышта яраланганнар хастаханәсенә әйләнә, кыз шунда шәфкать туташы булып эшли башлый. Икенче елны мәгариф министры Шөкер бәйнең имтиханын биреп, мәктәпне тәмамлый.

Сугыш беткәч, Айнелхәят Халидә Әдип тәкъдимен кире какмый: иптәшләре белән Сүриягә укытучы буларак китә. 7 ай Бәйрутта калганнан соң инглизләрнең Сүрияне басып алулары сәбәпле, Истанбулга кире кайталар. Аннары ул Кырым һәм Казан җәмгыятендә эшли

башлый. Россиядә дә бу вакытта революция була, Кырым һәм Казаннан килгән вәкилләр белән шул вакытта шактый аралашырга, аларга төрле ярдәм күрсәтергә туры килә.

Берникадәр вакыттан соң большевикларның Кырымнан чигенүе, Казанда, Кавказиядә халыкның үз хөкүмәтләрен корулары турында хәбәрләр килеп ирешә. Госманлы Тышкы эшләр министрлыгында Көнчыгыш илләр бүлеге – «Шәрык шүбәсе (филиалы)» төзелә. Әлеге оешма яңа корылган хөкүмәтләр белән элемтәгә керә, газеталарда укытучылар кирәклеге турында белдерүләр бастыра. Айнелхәят шул белдерүләрне укып, Кырымга китәргә карар итә. Шактый хезмәт хакы бирелүгә игътибар итә, чөнки бу вакытта гаиләсе белән ачлы-туклы көн күрә, Истанбулда чыккан зур янгында өйләре яна. Хәлләре бик мөшкел була. Ул Кырымга сигез яшендәге сеңлесе Салиханы да ияртеп китә.

Истанбулдан киткәнче, Кырымдагы Гөрбәгел авылы морзасыннан акча алынган өчен шул авылга укытырга бара. Гимнастика, рәсем, музыка, табигать, тегү дәресләрен укыта башлагач, авыл хәзрәте: «Истанбулдан килгән мөгаллимнәр безгә Госманлы әдәбиятын, тәрбиясен өйрәтер дип уйлый идек», – дип сөйләнә башлый. Имам белән авылныкылар сүзгә килгән көннәрдә Кызыл Армия Алушта шәһәренә җирләшә. 1 Май демонстрациясендә бөтен балалар белән җырлап йөргәнгә күрә, икенче көнне мәктәп ишегендә зур бер йозак каршы ала. Айнелхәят авылдан китәргә мәҗбүр була. Алуштада бер тол хатын өенә туктала.

Эшсезлек һәм акчасызлык аркасында эш сорап, большевикларга бара. Алар акча бирәләр. Бер ай үтүгә Деникин армиясе килә һәм кызылларны Кырымнан куып җибәрә. Шулвакыт берсе Айнелхәят большевиклар яклы дип, Деникин кешеләренә әйтә. 1 Май көнне танышкан Тегермән авылыннан Хөсәен аганың ярдәме белән Алуштага кире кайта. Монда да мөгаллим дусты Бәкер бәйнең тотылганын, өйдә әйберләре тентелгәнне күрә һәм Шәрык шүбәсе биргән документын таба алмый. Мәктәп дипломы һәм паспорты Истанбулда янгын вакытында юкка чыкканга күрә, бу көннән соң ул бернинди документы булмаган бер хатынга әйләнгәнен аңлый.

Кызыллар Кырымны яңадан алгач, Врангель һәм байлар бер төндә качып китәләр. Айнелне Севастопольдә Казан татар мәхәлләсендәге мәчет мәктәбендә укытучы итәләр. Шул көннәрдә большевиклар Татарлар бүлеген кора һәм аның башына Мөхәррәм Фәйзи Тугайны куялар.

Севастопольдә укытуын дәвам иткәндә, мәгариф идарәсен кулына алган Бәкир Чобанзадәдән чакыру хаты ала һәм Акмәчеткә китә. Чобанзадәнең большевиклар партиясенең хатын-кызлар бүлегенә юнәлтүе белән чараларга кушыла башлый. Соңрак ул үзенең никадәр ялгышканын аңлый...

Яхшы оратор булганы өчен хатын-кызларның гына түгел, ирләрнең дә очрашуларына чакырыла башлый. Конференцияләрдә большевиклар исеменнән гаҗәеп чыгышлар ясый. «Яңа дөнья» газетасында мәкаләләре чыга. Комитет Айнелхәятне Мәскәүдә беренче мәртәбә узачак «Шәрык хатын-кызлары съезды»на җибәрергә карар итә.

Бахчасарайга Совет Президиумы президенты Калинин һәм Молотов, Ворошилов кебек большевик җитәкчеләр килә. Кырымның баш комиссары Галиев Айнелне делегациягә көнчыгыш хатын-кызлары җитәкчесе буларак тәкъдим итә.

Айнелхәят сайлауларда, һәм депутат, һәм үзәк башкарма комитет әгъзасы, һәм Мәскәүгә баручы вәкил буларак, сайлана. Ул Мәскәүдә Кремльдә Калинин резиденциясендә кунак була.

Аңар Кырымга кайтып, районнарда, авылларда яшәүче халыкка Совет хөкүмәтенең беренче мәҗлесе турында мәгълүмат тарату йөкләнелә. Шул сәбәпле Мәскәүдән Керчька кайта һәм пропаганда эшен башлый. Ләкин чыгышлар ясап йөргәндә, бер юлдашы аны совет принципларын үтәмәүдә һәм коммунистик идеяләр урынына халыкка тирән милләтчел фикерләр таратуда, кешеләрнең милли рухларын күтәрүдә гаепли. Әлеге хәлдән соң пропаганда эшеннән читләшә, белем алу өчен Мәскәүгә университетка китә. Әмма аны, укырга керергә әле өч ай вакыт барлыгын исәпкә алып, Төркестанга эшкә юллыйлар. Зур кыенлыклар белән Ташкенттан кабат Мәскәүгә

кайтуга ирешә. Бу вакытта үзенең төрек дуслары укый торган шәрык университетына укырга керә. Уку йортын тәмамлый алмый, бер төркем буржуаз балалары дип саналган студентларны куганда, ул да университеттан чыгарыла. Бу вакытта аңар доктор, Азәрбайҗан сәяси лидеры Нариман Нариманов ярдәм кулы суза: Шәрык нәшрият мәркәзенә эшкә урнаштыра. 1925 елда Наримановның вакытсыз үлеме сәбәпле, бу эшеннән чыгарыла. Соңрак Бакуда хатын-кызлар бүлегендә эшли башлый, тора-бара партия хатын-кызлар мәктәбе мөдире була. Кызганыч, аңа теш кайраучылар очрап тора, янә милләтчелектә гаепләүчеләр табыла.

1927 елда үзе белән Истанбулдан Кырымга ияртеп килгән кыз кардәше ире белән бергә Төркестанга сөрелә. Айнелхәятне исә партия мәктәбеннән читләштерәләр.

Ул Тбилисига бара, анда тулы хезмәт хакы белән икенче инспектор итеп билгеләнә. Ләкин өченче көнне биредә дә эше туктатыла.

1928 елның 30 августында Дәүләт сәяси идарәсе (ГПУ) тарафыннан кулга алына. Тбилисига кайчан һәм кем белән килгән?.. Ни өчен килгән?.. Төркиягә качарга телиме?.. Кемнәр белән берлектә эш йөртә?..

Үзе яшәп торган өйнең хуҗабикәсе аның һәр сүзен, төрле шикле фикерләр уятырлык итеп, боларга җиткереп торганны аңлый. Бу вакытта аның кулында бер документы да булмау эшне тагын да катлауландыра, Төркиянең тышкы эшләр вәкилләре биргән документын Кырымда акгвардиячеләр юкка чыгарганына да ышанырга теләмиләр.

Айнелхәят үлемгә хөкем ителеп, Мәскәүгә җибәрелә. Авыру сәбәпле, төрмә хастаханәсенә салалар. Нәкъ бер ел төрмәдә ятканнан соң, Мәскәү җәза карарын үзгәртә: өч елга йә Томскига, йә Омскига сөргенгә җибәрү карары чыгарыла. Ашхабадка җибәрүне сорый, әмма кабул итмиләр. Төрмәдәгеләрнең Казанда да төрки халык яшәгәнне әйтүләрен тыңлап, шунда китәргә сорый, ачлык игълан итә. Нәтиҗәдә аны Казанга сөргенгә җибәрәләр.

Казандагы иске дуслары аның сөргендә икәнен белгәч, сөйләшеп тә тормыйлар. Биредәге ГПУ кешеләре аңар ярдәм кулы сузгандай, төрек пешекчеләре янына күндерәләр, алар арасында шымчылык итүне телиләр. Аннары китапханәдә бер эш табып бирәләр. Әмма ул ГПУ хезмәткәрләренең башкалар турындагы төпченүләренә иң мөһимсез нәрсәләрне әйтүдән яки алар белгәннәр хакында юк-бар сөйләүдән узмый.

Кыз кардәше Владикавказга кунакка чакыргач, ГПУдан рөхсәт алып, берничә көнгә китә. Батуми шәһәренә бара, барлы-юклы әйберен сатып бетерә, урамда яши, аннары бер мәчеткә сыена. Шулай тегендә-монда сугылып, Төркиягә китү хыялы белән йөргәндә, кабат ГПУ кулына төшә. Янә тугыз ай төрмәдә утыра. Аннан чыккач, акчасызлыктан шарфын сатып торганда, кабат тотыла. Бу юлы Тбилиси төрмәсенә җибәрелә. Ләкин, нинди генә сәбәп белән эләксә дә, аңар гади җинаятьче түгел, ә сәяси җинаятьче буларак карыйлар. Тоткыннар белән бергә Казанга җибәрелә. Каты авыру сәбәпле, башта Сызрань, аннары Рязань төрмәләре хастаханәләрендә яткыралар. Шәһәрдән шәһәргә йөртелгәндә, ул һәр җирдә төрмәләрнең кулга алынган хатын-кызлар белән тулы булуын күрә. Гаепләре шул: кырык тавыгы булып та, дәүләткә елына – өч йөз йомырка, сыер асраганнар дәүләткә кырык килограмм май бирмәгәннәр... Яки өйдә тукылган тукыманы базарда сатканда тотылганнар...

Айнелхәят Казанга кайтарылгач, Төркиядәге абыйсыннан хат ала. Туганы Бөтенсоюз чит ил гражданнары белән сәүдә берлеге – «Торгсин»га 18 лира күләмендә акча юллавын яза. Шулай итеп абыйсы аны ачлыктан коткара. Бу арада, ниһаять, Төркиядән җибәрелгән паспортын кулына алу бәхетенә ирешә. Һәм бик зур бер хата кыла: виза алу нияте белән Казандагы Чит ил эшләре комиссариатына мөрәҗәгать итә һәм паспортын шунда калдыра.

Берникадәр вакыт абыйсы җибәргән акчалар белән үз көнен күреп яши. Әмма ипи пешерүче танышы аны алдап, акчаларын үзләштерә. Ачлы-туклы яшәгән көннәренә кире кайтып, зур өметләр белән визасын көтеп йөри. Әмма айлар уза, виза бирүче

юк. Аңа совет паспорты алырга, совет хөкүмәте өчен алты ай эшләргә һәм алтын белән өч йөз илле сум штраф түләргә кушалар. Әлбәттә, алар Төркиядән акча килүен беләләр! Ә совет паспорты алса, аңа инде Төркия турында хыялланасы да калмаячак! Хәтта Төркия гражданины булуына карамастан, аны бер гаепсезгә төрмәдән төрмәгә йөртәләр, сөргендә тоталар, күп еллар дәвамында партиягә хезмәт итүен исәпкә алмыйлар икән, димәк, алга таба хәер көтәсе юк... Һәм Айнелхәят бернигә карамастан, качарга дигән карарга килә, план төзи.

Башта ул поезд белән Владикавказда яшәүче сеңлесенә бара. Салиха янында берничә көн тора. Сеңлесе карта юнәтә. Үзе бер авылга киткән булып, чит бер шәһәргә бара, антиквариат сатучыдан компас алып кайта. ГПУ шымчыларын адаштырыр өчен Төркиядәге абыйсына үзенең паспортын юллап, Мәскәүгә барачагы турында яза. Бөтен хатлары укылганны белә. Шуңа күрә Сталинград һәм Петроградтагы дусларына алдагы көннәрдә кая барачагы,ниләр эшләргә җыенуы турында ялган хатлар җибәрә.

1934 елның 24 августында, Ереван һәм Мәскәү поездларының ярты сәгать аерма белән кузгалуларыннан файдалана. Мәскәүгә китәр урынга, яшерен рәвештә билет сатып алып, Ереван поездына утыра. Ул Әрмәнстандагы Сердабат станциясендә төшә. Шул җирләрдә эшләүче улын эзләгән хатын кыяфәтендә басуларны, авылларны үтә. Бер төнне дөге кырларын кичкәннән соң Арас елгасы аша йөзеп чыга, Ыгдырдагы (Төркия шәһәре) Кити авылындагы жандармерия станциясенә сыена. Ыгдырда һәм Карста тикшерүләр тәмамлангач, Трабзон аша Истанбулга җибәрелә. Аннары Айнелхәят Анкарада туганнары белән күрешә.

Китап эчтәлегенә таянып ясаган кайбер нәтиҗәләрне китерәсем килә:

*– Айнелхәят, әтисе туган җире булган Саратов губернасы Мәстәк авылыннан башлаганда, тимер юл һәм көймә белән 55 мең км юл узган. 22 шәһәрдә булган, кайберләренә берничә мәртәбә барган.*

*– Маҗара тулы тормышы дәвамында Шүкрү Сарачуглы, доктор Лүтфи Кырдар, доктор Рәшит Галип, Нуман Чәләбиҗиһан, Җафер Сәет Әхмәт, Мөхәррәм Фәйзи Тогай, Климент Ворошилов, Назым Хикмәт, Вала Нуреддин, Шәүкәт Сүрия Айдемир, Хөсәен Сәит, Зиннәтуллах Нәвширван, Әхмәт Җәват (Әмрә), доктор Шәфик Хөснө (Деймер), доктор Нариман Нариманов һәм Һади Максуди кебек үз чорының күренекле һәм абруйлы шәхесләре белән таныша һәм аларның кайберләре белән кыска бер вакыт эшли.*

*– Россиядә яшәгән чорда бер тапкыр сөргенгә (Казанга) җибәрелә, ике мәртәбә төрмә хастаханәсендә һәм алты төрмәгә 7 тапкыр ябыла (Тбилиси, «Батырская турьма», Мәскәү, Казан, Батум, Рязань төрмәләре).*

**Шәүкәт КУНТАЙ**

## Айнелхәят һәм аның хатирәләре

Төркия татары Шәүкәт Кунтай Анкарадан «Кызыл Россиядә бер төрек хатыны» («Kızıl Rusya'da Bir Türk Kadını») дигән татар хатыны турындагы китапны һәм Татарстанга җибәрүне сорап язган хатын юллаганга бер елдан арткандыр инде. Әллә әсәрдә сурәтләнгән, телгә алынган вакыйгаларның, реаль шәхесләрнең күплеге, әллә башка язу эшләре белән мәшгуль сәбәпле, кул җитми торды. Соң булса да уң булсын, диләрме әле... Ниһаять, Шәүкәт әфәнденең төрекчә язган мәкаләсен татарчага тәрҗемә иттем һәм 236 битлек, моннан ким дигәндә, 70-80 ел элек язылган төрекчә китапны кулыма алдым. Әмма китапны укыгач, мәкаләне тәрҗемә итү белән генә чикләнү аз тоелды.

Шуңа күрә тагын берничә ай дәвамында өстәмә мәгълүматлар тупларга тырыштым. Күзәтүләрем, тикшерүләрем, һәм китапны, һәм аның герое Айнелхәятнең кем икәнен тагын да яхшырак аңларга ярдәм итәр.

Әлбәттә, иң беренче чиратта мине татар хатыны турында шундый күләмле, маҗара тулы роман чыгарган язучы Рәҗаи Санай үзе кызыксындырды. Ул Төркия каһарманы

Әхмәт Эсат Томрук (1892–1966) турындагы шактый шау-шу кузгаткан, күп серияле фильмнар төшерелгән «Төрек шпионы инглиз Кәмал» дигән китаплар авторы. Исеме телгә кергән язучы үзе, әмма җентекләп язылган ни биографиясен, ни фотосын таба алмадым. Төпченә торгач, 1935-40 елларда Төркиядә чыккан иске гәзитләрдә аның шактый мәкаләләренә тап булдым. Аннары берара югала кебек, 50 нче елларда исә матбугат битләрендә күбрәк хикәятләре, әдәби әсәрләре басылган.

Автор «Кызыл Россиядә бер төрек хатыны» китабының кереш сүзен: «Төрек шпионы инглиз Кәмал»дән соң маҗаралар белән тулы янә бер тормыш тәкъдим итәбез: «Айнелхәят» тормышын...» – дигән җөмлә белән башлаган. Алга таба Айнелхәят сөйләгәннәр буенча язуын һәм аның исән-сау икәнен, яше 69 га җитүен әйтә.

«Төрек шпионы инглиз Кәмал» әсәре, кайбер төрек галимнәре язуына караганда, 1964 елда басылган. Айнелхәят хакында да шул вакытта язылган, шул вакытта ул әле исән булган дип әйтә алабызмы?! Юк, чөнки башка бер чыганакта – «Гаскәри тарих тикшерүләре» журналында 2006 елны чыккан мәкаләдә күрсәтелгән роман язылу вакыты башкача уйларга этәрә. Зәкәрия Төрекмәннең «Bir türk istihbarat görevlisi olan Ahmet Esat Tomruk (İngiliz Kemal)» мәкаләсендә Әхмәт Эсат Томрукның маҗаралар тулы тормышы Рәҗаи Санай тарафыннан алты сериялек бер роман рәвешендә 1940-50 елларда, каһарманнан сораштырып язылуын һәм Нәбиуглы нәшриятында басылуын искәртә. Бу очракта Айнелхәят тормышы 40-50 еллар арасында язылган дип уйлый алабыз. Һәм бу фикер дөрестер дә.

«Кызыл Россиядә бер төрек хатыны» әсәре тулысынча Айнелхәят авызы белән язылган. Шуңа күрә ул Айнелхәят китабы буларак кабул ителә. Шулай да, бу хатын чын тормышта яшәгән кешеме соң? Әллә роман каһарманы гынамы?

Мөгаллимә Айнелхәяткә бәйле мәгълүматлар эзләгәндә, аның туган елы, үлгән вакытына һәм бик сәер фамилиясенә Халидә Әдип Адыварга багышланган фәнни хезмәтләргә тап булдым. Аларда тулы исеме Айнелхәят Вайноф (Оракугыллары) дип күрсәтелә, үлгән елы – 1948, ә менә туган елы төрлечә: 1889, 1887, 1880. Туган елы әсәрдә язылган кайбер мәгълүматларга таянып санаганда да буталчык. Бертуган гаскәри абыйсының туган елы – 1880 булганны исәпкә алганда, аны соңрак туган дип әйтә алабыз. Вайноф – Россиядән килгән әтисе фамилиясе, Оракугыллары дигәне Төркиягә килгәч өстәлгән, «урак уллары» дигәнне аңлата.

Сүриядә мәктәп ачкан Халидә ханым Әдип бер хатында биредә яшәргә рөхсәт ителгән мескен әрмәннәр турында язган һәм Айнелхәятне шундый җөмлә белән тасвирлый: «Россия төрекләреннән булган, үзем белән алып килгән бер кечкенә мөгаллимә, бер фәрештә кебек фидакарь һәм мәхәббәтле, алар арасында эшли...»

Менә шулай Айнелхәятнең шәҗәрәсен, шәхесен ачыклаучы азмы-күпме мәгълүматлар тупланды. Ул әсәрдә үзенең балачактан язуга һәвәслеген, еллар узгач, большевиклар чыгарган басмаларга мәкаләләр язуын әйтә. 1918 елда Истанбулда нәшер ителгән «Кырым» журналында да аның бер мәкаләсен укырга мөмкин.

Китапта язылганга караганда, Мәскәүдә Айнелхәятнең үлем хөкемен сөрген җәзасына алыштыралар. Казанда сөргендә яшәгәндә, берничә мәртәбә Төркиягә качу нияте белән юлга чыга. Соңгысында теләгенә ирешә. 1934 елны Арас (Аракс) елгасын йөзеп, Төркия ягына чыга. Төркиядә чыккан иске гәзитләрнең берсендә төрле төбәкләргә җибәрелгән укытучылар исемлеге басылган. 1935 елны ул исемлектә Айнелхәятнең Коньяга кызлар мәктәбенә укытучы буларак билгеләнүе күренә.

Кулымнан килгән кадәр әсәрдә күрсәтелгән, сурәтләнгән географик урыннарны табарга, Айнелхәят язганнарны шәхесләрнең мәгълүм биографияләре белән чагыштырдым.

Әтисенең исеме – Әсфәндияр Вайноф (1854–1912). Беренче хатыны Хәтиҗә. Ике хатыннан тугыз баласы була. Малайлары барысы да хәрби. Беренче Бөтендөнья сугышына кадәр Җиддә шәһәрендә Рус консуллыгында баш тәрҗемәче булып эшләгән, Беренче

Бөтендөнья сугышы алдыннан мәрхүм. Бер бүлектә Айнелхәят аның сәясәтче, дин әһеле Габдерәшит Ибраһим белән дуслыгын искә ала. Үзе укыган мәктәптән ялгызы чыгып йөрергә рөхсәт ителмәгәч, дин әһеленә хат юллаган. Габдерәшит әфәнденең ул укыган мәктәпкә «Айнелхәят – безнең кызыбыз» дигән хат җибәрүен, аңа ярдәм итүе турында әйтә.

Чынлыкта да әлеге дуслык булганмы?! Булган. Хәзрәт үзенең бер сәяхәтнамәсендә: «Җиддә безгә бик чит тоелмады. Бездән алда анда «бик ерак җирләрдән» килгән дусларның берникадәрен күрдек. Бик иске дусларыбыздан Әсфәндияр әфәнде дә анда рус консуллыгында баш тәрҗемәче икән. Әсфәндияр әфәнденең өендә калдык. Самими һәм җитди сөйләштек», – дип язган («Yirminci Asrın Başlarında Alem-i İslam ve Japonya'da İslâmiyet'in Yayılması», Abdürreşid İbrahim. 2012 елда нәшер ителгән басма).

Әсфәндияр әфәнденең биографиясендә янә бер кызыклы факт: ул Константинопольдән (Истанбулдан) Толстой белән хат алышкан кеше – Толстой сүзе белән әйткәндә – «магометанин». Аның язучыга ике хат язуы һәм ике мәртәбә җавап алуы мәгълүм. Лев Толстойның барлык әсәрләре тупланган җыентыкның *(Л.Н.Толстой. «Полное собрание сочинений. Серия третья: Письма», Москва, 1954)* 73 нче томында бөек язучының хатлары урын алган. Шулар арасында Әсфәндияр әфәндегә ике җавап хаты (№ 352,374) һәм хат язучы турында түбәндәге мәгълүмат урнаштырылган: «Әсфәндияр Зәйнетдинович Воинов (1855-1913) тумышы белән Саратов губернасы, Хвалынский өязе, Иске Мәстәк саласыннан, Төркиягә эмиграциягә китә, Төркия гражданлыгы ала. Күп еллар дәвамында волостной писарь вазифасын башкара. Дини мәсьәләләргә кагылышлы берничә мәкалә яза (кульязмалары калган). 1914 елда барлык кәгазьләре, шул исәптән Толстойның аңа язган хатлары Истанбулда яна. Воинов Гарәбстанда үлде. 1902 елның 29 сентябрендә килгән Воинов (Константинополь) хатына җавап П.И.Бирюков китабында («Tolstoi und der Orient», Leipzig, 1925) алман теленә тәрҗемәдә басылган».

Айнелхәятнең әтисе менә шундый күптарафлы шәхес: бер яктан ул җитәкче вазифалар башкаручы руслар янында эшли, икенче яктан татар дин әһелләре белән тыгыз элемтә тоткан. Хәтта Толстойның чиркәүдән читләшү вакыйгасына битараф калмыйча, аңар Ислам турында хатлар язган...

Әлбәттә, Айнелхәятне милләт герое буларак күтәрергә ниндидер зур сәбәпләр юк кебек, әмма аның китап булып тупланган хатирәләре инкыйлабка кадәр һәм аннан соңгы вазгыятьне дистәләгән детальләр белән шул кадәр җанлы итеп күз алдына китереп бастыра, аерылмыйча укыйсың. Сөрген юлын кичкән милли рухлы большевик хатын хатирәләре күп сораулар да уята... Кыскасы, битараф калдыра торган биография түгел.

Миңа калса, аның кайбер истәлекләрен Төркиядә мәгълүм шәхесләрнең биографияләрен өйрәнүдә файдаланганнар, шулай ук бездә татарларга, русларга, әрмәннәргә, кырым татарларына кагылышлы мәгълүматлары кызыксыну уятырга мөмкин.

Мин «Казан утлары» журналына «Кызыл Россиядә бер төрек хатыны» әсәреннән берничә бүлек тә тәкъдим итәргә булдым. Әлегә китапның беренче сәхифәләрен – Айнелхәятнең әти-әнисе, туган җире, ничек итеп һиҗрәткә чыгып китүләре турындагы хатирәләрне тәрҗемә иттем. Аннары Тукайның дусты, шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләйгә һәм гыйлем иясе Әхмәтһади Максудига багышланган бүлекләр кызыксыну уятты. Шулай ук Айнелхәятнең төрмәләргә бәйле шактый хатирәләреннән берсен тәрҗемә иттем. Ягъни аның Россиядә узган балалык чорына, Төркия тарафыннан рәсми юллама белән Кырымга укытучы булып киткән вакытына һәм сөрген елларына бәйле хатирәләреннән берничә кисәк.

Төркия татары Шәүкәт Кунтайга китапка игътибар юнәлткәне өчен зур рәхмәтемне белдереп, алдагы көннәрдә Айнелхәят хатирәләрен бөтен килеш тәрҗемә итеп, Татарстан укучыларына да тәкъдим итәргә язсын дигән теләктә калам...

**Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА.**
*Төркия, Искешәһәр.*

# Рәҗаи Санай

# КЫЗЫЛ РУСИЯДӘ БЕР ТӨРЕК ХАТЫНЫ

РОМАННАН ӨЗЕКЛӘР

## Әтиемнең тормыш маҗарасы

Мин, асылда, Россияле шимал (төньяк) төрекләреннән.

Әтием Волга ярындагы Сараков (Саратов-Сарытау) губернасындагы бер авыл морзасы нәселеннән. Белмим, нигә «фәлән малае» димәдем?! Бәлки дә әтием алты яшендә чарасыз, ятим калган өчендер тел очыма шушы рәвешле килде...

Әтиемнең әтисе Зәйнетдин, бер көн, пар ат җигеп, арбасына авылдан җыелган мал-туар төяп, «Ирбит» ярминкәсенә китә. Ярминкәдә сәүдә иткәч, җыелган акчасын янчыгына тутыра да авылга кайтырга чыга. Кайтышлый бер урыс авылында куна калырга туры килә. Ул төнгелеккә кергән өй хуҗалары янчыгы калын мосафирларын кунак итеп кенә калмыйлар, ризыгына агу салырга да онытмыйлар!

Мосафир үзенә аерылган бүлмәгә кереп ята, рәхәт бер йокыга тала. Таңга каршы тәне авыртуга чыдый алмый йокысыннан уяна. Ат арбасында йоклаган хезмәтче үсмер малай янына кергәндә беткән бер хәлдә: «Хөсәен... Хәлем бик начар... Мине агуладылар!» – ди. Үсмер егет хуҗасын авыр хәлдә күргәч, аның куркыныч сүзләрен ишеткәч, үз җаны өчен куркып, тизрәк табанын ялтырата.

Башка авылдан булган бу егет, еллар узгач кына, Мәстәккә килеп, ярминкә юлындагы фаҗигале хәлне кешеләргә аңлата. Әлбәттә, бушка тырышу!

Ул заманда Россия ярым вәхши хәлдә. Ни йөк ташучы арадашчылык, ни почта, ни газета бастырулар тәртипле оештырылмаган. Шуңа күрә бу вакыйга турында хәбәр таралмый. Бары тик мәхәлләдә бер бәет чыгаралар.

*Мәстәкнең (авылыбызның исеме) сулары агым су, йөзәдер үрдәк, эзе юк,*
*Зәйнетдин (әтиемнең әтисе) мескенкәйне булган кемләре килә, үзе юк.*
*Минем менгән атым күк ала, атлаганда чакрым юл ала,*
*Яшь хәләл зәвҗәм (хатыным) ир табар, ике ятим баламны кем багар?*

Әтием – алты, абзыем өч яшендә ятим кала. Әниләре бер елга кадәр ирен көткәннән соң, килгән авылына кабат килен китә. Ул арада улларының фаҗигале үлем кайгысын күтәрә алмаган әби белән бабай бер-бер артлы бакыйлыкка күчә.

Ике ятимнең кечесен, ягъни абзыемны бер туганнары асрамага ала. Җиде яшемдәге әтиемне дә сабан атларын йөртергә ярар дип, башка берәүләр уллыкка ала. Шул рәвешле туганнар, ятим калган балаларны урнаштырып, вөҗданнарын тынычландыралар да мал-мөлкәтне үзара бүлешәләр.

Әмма... Әтием үзен уллыкка алган адәмнән генә түгел, авылдан ук кача.

Әтием качкан авыл Мәстәктән 25 чакрым ераклыктагы Зәминҗә (Зимничи). Биредә бер шәех карамагындагы зур гына мәдрәсәдә тирә-як авыллардан җыелган шәкертләр укый. Авылларга имамнар җитештерәләр. Иске мәдрәсәләрдә һәр кеше үзе теләгәнчә кереп-чыгып йөри алган. Ятим калган әтием дә шушы мәдрәсәгә килә. Эчкә уза. Исеме белән кызыксынган да юк: «Ятим» аска төш, «Ятим» югары мен!

Мәдрәсә югары бер калкулыкта урнашкан, аста бер елга аккан.

«Ятим» үзеннән яшькә олы һәм бай шәкертләргә хезмәт итә: чүлмәкләрен су белән тутыра. Моңа каршы аңар бирәр телем икмәк бирәләр...

Әтием акыллы бер бала була. Эчендә гыйлемгә тартылу уты көйри. Мәдрәсә мохитендә бу ут көннән-көн көчәя һәм күңеленә нурлы бер ялкын булып сарыла. Шәкертләрнең дәресләргә хәзерләнгәнен игътибар белән күзәтә. Алардан отып алганнарын практик яктан сыный: кулына эләккән күмер кисәге белән диварларга хәрефләр яза. Шушы рәвешле әлифбаны үзлегеннән өйрәнгәч, сүзләр яза, аларны кушып, җөмләләр төзи башлый. Һәм укырга, һәм язарга өйрәнә! Әмма моңар әһәмият биргән кеше генә күренми!

Бер ел уза. Ятимнең һаман ни өстендә, ни башында юк. Үзе шәкертләргә тәһарәт алырга су ташу белән мәшгуль.

Ниһаять, бер очраклы вакыйга аңа ярдәм итә!

Шәкертләр уртак аш әзерлиләр, казан тутырып ботка пешерәләр. Ятимгә дә:

– Кил, ботка ал! – диләр.

Ач малай учын ача, башкалар кайнар ботканы чүмеч белән алып, аның учына салалар. Кулы пешкән ятим ботканы читкә ыргытып кычкыра-кычкыра, бакчага йөгерә. Менә шул вакытта мәдрәсәгә килүче шәехкә юлыга. Шәех сораштырып, мәсьәләне өйрәнә. Шәкертләрен бик нык ачулана, тиешле җәзасын да бирә. Җәза биргәннән соң бай укучыларына:

– Бу баланың өсте-башы, ризыгы сезнең карамакта. Даими карыйсыз һәм укытасыз, – дип боера.

Ятим малай күз яшьләре белән:

– Мин укый беләм, – ди. – Фәкать китабым юк!

Шәех аңар башта ышанырга теләми. Имтихан белән тикшерә һәм гаҗәпкә калып:

– Сигез яшькә бик әйбәт – дип сөйләнә.

Мәдрәсә шәкертләре ятимнең «хөсни хат»ына – матур язуына хәйран калалар. Һәм дәфтәрләрен аннан яздыра башлыйлар. Әтием – Әсфәндияр бәйнең, хакыйкатьтән, энҗе кебек язуы бар иде...

Бу мәдрәсәдә өч ел шушы рәвешле укыганнан соң, әтиемне Рус патша хөкүмәте ятимнәр өчен рус лицеенда ачкан бер мәктәпкә көчләп китерәләр. Әтисез-әнисез балаларны шунда җыялар.

Ятимнәр мәктәбенең укытучысы ялкау һәм шул ук вакытта залим бер кеше була. Мескен балаларны тимер чыбык белән кыйнаганда, каннары диварларга кадәр чәчрәгән. Әтием, акыллы бер бала булганга күрә, русча язарга-укырга тиз йөрәнә. Укытучының күзенә керә һәм аның ярдәмчесе сыйфатында өч ел балаларны бушка укыта. Бер яктан дәрес бирсә, икенче яктан русчага адәмчә сөйләшергә өйрәнә. Әмма барыбер, мәктәптәге авырлыкларга түзә алмыйча, качарга дигән карарга килә. Шулай итеп, Сембер якларына китеп бара.

Бу качу әтиемнең тормышында бер борылыш ноктасы. Ул Сембер губернасында бер бай сәүдәгәр янына бара. Аңарда өч ел сәркатиб булып эшләгәннән соң, мәшһүр фабрикант Акчураларның фабрикасында катип-сәркатиб була.

Берникадәр вакыттан соң фабриканың баш машинисты кызы – рәхмәтле әниемә өйләнә. Өч балалары туа. Аннары Урал таулары итәгендәге бер мәхәлләгә күчеп, утар коралар.

«Ятим» каралты-курасы, җире булган, балалары үсеп килгән адәм мәртәбәсенә күтәрелә...

***

***Тәрҗемәчедән өстәмә аңлатма:***

***Ирбет*** *– Эрбет ярминкәсе – инкыйлабка кадәр елга бер мәртәбә Пермь губернасының Эрбет ( Ирбит) (хәзерге Свердловск өлкәсе) шәһәрендә уздырылган зур ярминкә.*

***Мәстәк*** *– Сембер өлкәсенең Иске Кулаткы районында Мәстәк елгасында урнашкан сала. Элек Сарытау губернасының Хвалын өязенә кергән. 17 гасырда нигезләнгән.*

***Зәминҗә** (Зимничи. Яңа Зимницы – Сембер өлкәсенең Иске Кулаткы районында урнашкан сала. Октябрь инкыйлабына кадәр Сарытау губернасының Хвалын өязенә кергән. Бу авылда зур хөрмәт яулаган суфый дин әһеле Хәбибулла ишан Хансәвәров (1805–1897) яшәгән. Хансәвәр мәдрәсәсе даны еракларга таралган уку йорты була. Татар байларының нәкъ менә биредә балаларын укытырга тырышулары мәгълүм. Әсәрдә сүз шул мәдрәсә турында барырга мөмкин.*

***Бәет** сүзләре төрек телендәге китапта, җирле сөйләм телендә дип, татарча язылган.*

## Балалык елларым

Утарда узган балалык елларымны бик әйбәт хәтерлим. Бала чагымның иң бәхетле көннәре шунда узды.

Безнең җирлек саладан ике чакрым ераклыкта, Урал елгасының аягы – кушылдыгы Шынгырлау елгасы ярында иде. Елганың каршы ягы агачлык, яшеллек. Йөзәргә көймәбез бар. Җәен елганың каршы ярына чыгып, чатырлар корып утырабыз, мосафирларыбызны кунак итәбез...

Сул тарафта бер бәләкәй күл, алдыбызда – апрель һәм май айларында төрле төстәге чәчәкләр белән бизәлгән дала... Басуларда бодай, кавын, карбыз җитешә. Утарда хезмәт иткәннәр Кавказиядән килгән малаканлар. Сыерлар савыла, катык, май аертыла...

Утар белән әнием идарә итә иде. Әтием төбәктә волость писаре вазифасын башкарды.

Бу Урал губернасында кыргызлар яши иде. Күчмәннәр. Безнең районга йөзләрчә авыл бәйле иде. Бер җинаять кылынган очракта докторлар, хакимнәр, шаһитлар һәм башкалар җыелыр, әтием дә алар белән бергә авылдан авылга йөрер. Кайчак айлар буе югалып торыр. Чөнки кыз качырулар, төрле җинаятьләр еш булып тора. Шуның өчен дә әтием утар эшләре белән әвәрә килә алмый, әнием хәл итә. Әтигә калса, шәһәргә китү, шәһәр тормышы белән яшәү күпкә яхшырак. Ләкин әни аңар каршы каты торды. «Гөл кебек, җәннәт кебек утарым бар икән, тузанлы, исле шәһәрдә нишлим?!» – дия иде.

Кыргызлар бөтен җәйне, нигездә, чатырларда уздырырлар, хайван көтәрләр. Аларның чатырлары җитен чатырларга охшамас. Диаметры 8-10 метр булган түгәрәк киез чатырлар. Бу киезләрнең тышкы ягы ак, эчке ягы бик матур нәкышлар белән бизәлер. Бай кыргызлар меңнәрчә ат, бия һәм меңнәрчә сарык, сыер, дөя тотарлар. Бияләр савылыр, сөтләреннән кымыз ясалыр. Әмма сарыкларны саумыйлар, бәрәннәре имәр. Йөзләрчә сыер сөтеннән май аертылыр, тиредән ясалган капчыкларга тутырырлар. Һәм сөттән «эремчек» исеме бирелгән сыр, катыктан да әче, әмма ашарга татлы, тәмле «корт» ясарлар. Боларны корытып, торбаларга – тиредән ясалган капчыкларга тутырып куярлар. Дөя сөтеннән дә яз көннәрендә әйрән кебек бер эчемлек ясалыр. Моны да кымыз кебек кайнатмыйча әчетерләр. Гаять тәмле. Бия сөтеннән тагын да куерак булыр.

Фәкыйрьләр исә кәҗәләрен саварлар, сыер сөте белән катыштырырлар. Бары тик сарык саву гадәте юк.

Кыскасы, кыргызларның тормышы бик кызыклы, йөзләрчә сәхифә язылса да бетмәс. Әмма бөтен милләтләрнең тормышын тар-мар иткән большевиклар, аларны да кыен хәлдә калдырдылар. Иң гүзәл җирләрен алып, ул урыннарга башка милләтләрне җирләштерделәр. Байларның мал-туарларын алып, үзләрен Себер тарафларына сөрделәр. Фәкыйрьләре дә 1920-21 елларында Кырымда булган кебек авыл-авыл ачлыктан үлделәр. Анасыз, атасыз калган, тирә-якка таралган балаларны ятимнәр йортына җыеп тәрбия иттеләр. Кыргызлар җирләренә җирләштерелгән яһүди һәм молоканлар арасына аларны үрнәк күрсәткәндәй җирләштерделәр. Соңрак ул җирләрне кыенсынмыйча «Кыргызстан җөмһүрияте» дип атадылар!

***

***Өстәмә аңлатма:***

*Шынгырлау елгасы– хәзерге исеме Утва.*

*Кыргызлар дип язылган, әмма казакълар дөресрәк булыр. Чөнки Шынгырлау елгасы хәзерге Казакъстан территориясендә, Урал елгасына коя.*

*Урал губернасы – Россия империясе вакытында Җаек өлкәсе. Үзәге – Уральск – Җаек шәһәре. Бүгенге көндә Казакъстан Республикасы территориясенә керә.*

*Молоканлар – православиедән аерылган «рухи христианнар».*

## Укырга, язарга өйрәнәм

Әнием үзе шәһәрдә яшәргә теләмәсә дә, балаларының гыйлем алуына әһәмият бирде. Абыемны башка бер бистәдәге имам булган абзыем янына җибәрде, Коръән укырга өйрәтте. Икенче елны шәһәрдәге бер өйгә пансионер итеп урнаштырды, рус мәктәбенә яздырды. Кече кардәшемне башка бер бистәгә юллады, бер мөгаллим өенә укытырга бирде. Башка өч кардәшем әле укыр яшьтә түгелләр иде.

Миңа килгәндә... Әле бик бәләкәй чагымда без яшәгән җиргә вак-төяк сатып йөрүче берәү килгән иде. Әлифба, бер җыентык догалар да сата иде. Аларны күрүгә төймә-алкаларны оныттым. Әнигә ялварып төймә, алка түгел, әлифба алдырдым.

Әле әнидән, әле этидән сорый-сорый, кыска вакыт эчендә хәрефләрне өйрәндем. Бер-берсенә ялгап укырга, соңрак хәтта язарга керештем. Әмма этиемнең язуханәсендәге кәгазьләрен бозганга һәм диварларга күмер белән язганым өчен этиемнән әйбәт кенә таяк та ашадым! Соңрак мине Коръән өйрәнсен дип, абзыемның өендә 6-7 ай укыттылар. Абзыем өендә гадәти бер мәдрәсә корган иде. Биредә олырак яшьтәге шәкертләр укый иде. Алар кечкенә булганым өчен минем язуларыма гаҗәпләнеп карыйлар, сокланалар, кәгазь-каләм бүләк итәләр иде. Ләкин абзыемның өеннән үзебезгә кайткач һич акылыма килмәгән, һәм күңелемә тигән бер вазгыять белән очраштым. Әнием укуымның алга китүенә, бик матур итеп яза башлавыма кызды. «Бераз үскәч, егетләр белән хат алышыр өчен матур итеп язарга өйрәнгән!» – дип авызын ачты, күзен йомды, тәүбә иттергәнче төйде, төйде!

## Россиядән Төркиягә һиҗрәт итәбез

Утардагы тормышыбыз рәхәт дәвам иткәндә, урталыкта бер хәбәр тарала башлады. Рус патшасы ни кадәр мөселман мәктәбе бар – барысын ябачак, имеш! Коръәндә ни кадәр «кяфер» сүзе булса, барысы сызылачак, Коръәннәр яңадан нәшер ителәчәк, имеш!

Бу хәбәрләр тирә-якка таралыр-таралмас мөселманнар арасында ыгы-зыгы башланды. Кешеләр хәбәрләрнең чынмы-юкмы икәнен бер-берләреннән сорашып та, бер-берсен котырталар иде. Һәр тарафта Төркиягә һиҗрәт башланды. Этием дә бу агымга иярде. «Мин балаларымнан рус гаскәрие ясарга теләмим», – дип, ул да һиҗрәт итәргә карар итте. Әнием никадәр: «Безнең балаларыбыз бәләкәй әле. Бераз аларны үстерим... Бераз мая туплыйк... Әйберләрне, җирне акрын-акрын сатыйк, аннары уйларбыз...» – дип, һаман һиҗрәткә чыгарга риза булмаса да, сүзен сүз итә алмады.

Җиребезне, мал-туарны, мөлкәтебезне очсыз-очсыз сатып, юлга чыгарга хәзерләндек.

И-и-и, бездәге сөенеч! Миндә һәм туганнарымда! «Төркиягә китәбез», – дип шатланып сикерешәбез. Тик... Мәгәр соңгы кат шатлануыбыз шул булган икән!

Ярый... Ниһаять, юлга чыктык. Мөһаҗир гаиләләре белән станцияләр күмелгән! Әйтерсең, артларыннан куа киләләр, ыгы-зыгы! Тимер юл хезмәткәрләре русча белмичә борчуларын, йомышларын аңлата алмаган мескеннәргә төрле мөгамәлә күрсәтә, сүгеп кычкыралар. Әнием русча белгәнгә күрә, бу манзараны күреп, йөрәге сызлый, ул мескеннәргә булышырга тырыша, вокзал хезмәткәрләренә каршы килә...

Өч ай, әле паспорт, әле виза мәсьәләсен чишәргә тырышып, шәһәрдән шәһәргә, тегеннән-монда сөйрәлеп йөргәнннән соң, ниһаять, Төркия белән кавыштык. «Аллага шөкер, Истанбулга килдек», – дип сөенгәндә, безне рус көймәсеннән чыгармадылар. Бары тик икенче көнне иртән кечкенә бер көймә безнең янга килде һәм шатлыгыбызны каралтучы бер хәбәр китерде. «Мөһаҗирләрнең Истанбулга чыгуы ясак, тыела.

Искешәһәргә китәсез», – диделәр. Теләсәк-теләмәсәк тә, буйсындык. Нәтиҗәдә, йөзләрчә мөһаҗир Хәйдәр пашага – диңгез буендагы тимер юл вокзалына китерелде. Аннары поезд белән Искешәһәргә җибәрделәр.

Инсанның бәхете бер кат тискәресенә килсә, кайгылары, фаҗигаләре бер-бер артлы тезелер. Без килгән вакытта Искешәһәрдә холера чире таралган вакыт иде. Һәр көн йөзләрчә кеше үлә.

Без ике кечкенә бүлмә табып җирләштек. Озак та узмый башыбызга килгән фаҗига тыйнак гаилә учагыбызны төбеннән корытты. Әниемә холера чире эләкте һәм өч көн эчендә алты баласын калдырып, бу дөньядан күчте.

Әти белән ялгыз калдык. Моңа кадәр сәүдә эшләре алып бармаган һәм әниебезнең үлеменнән шашкын хәлгә төшкән әтиемә кайбер комиссиончылар: «Акчаң бар икән, хәзер үк сәүдә эшенә кер. Мал алып сат, көнеңне күрә башларсың. Акчаң никадәр күп булса да, аның белән эш йөртү мөһим...» – димешләр. Сәүдәдән, алыш-бирештән аңламаган, аның өстенә, уң кулы булган әнидән дә мәхрүм калган әтием, берара черек товарлар белән өебезне тутыра башлады. Абзыебыз яныбызда булса икән... Бу эшләрдән аңлар, әтигә ярдәм итәр иде. Тик ул Искешәһәрдән 20 чакрым ераклыктагы бер авылга имам булып киткән иде.

Бераздан сатып алган малларының эчерек булганын аңлаган әтием, аларны үзенә сатучыларны эзли башлады. Ләкин таба алмады. Шул вакыт берәү янә акыл биргән: «Син боларны авылларга барып сат». Шулай итеп әтием, арендага бер ат яллап, 15 яшьлек абыемны янына алып, авылларга китте. Маллар сатылдымы, юкмы, белмим, хәтерләмим.

Бу вакытта тормышымның фаҗигаләр чылбырына янә бер боҗра өстәлде. Йөрәгем, рухым, җаным өзгәләнде. Әнинең үлеменнән соң бер ай да узмастан әтием өйләнде! Безнең белән бергә килгән мөһаҗир тол хатынга. Хатын бик нык кырыс, ямьсез һәм ачуы ташып торган бер кеше иде.

Фаҗигаләр чылбырына боҗралар тагылып бетмәгән икән. 5 яшендәге кыз кардәшем күз яшьләренә буылып-буылып елый, авырый башлады. Чәчәк төсле сулды, саргайды. Ун көн эчендә ул да кара туфракка төште. Әнием янына күмдек. Әмма фаҗигаләр бетмәде, дәвам итте. Янә бер ай узмады, 2 яшендәге кардәшем дә хасталанды һәм әнием янына ятты. Өч яңа каберлек башында еладым... Болар нинди чир эләктерде? Нигә үлделәр? Доктор килмәде, беркем берни аңлатмады...

Әтием беркөн: «Артык бер эш табарга кирәк!» – дип, Истанбулга китте. Ул вакытта 15 яшендә булган абыем Күтәһия шәһәрендә тимер юл эшенә керде. Абзыем авылдан килде, ике кечкенә туганымны танышлары янына урнаштырды. Мине авылга алып китте. Без бу рәвешле уңга-сулга таралганда, үги әнием дә үз әнисе янына китте.

Ул кышны шулай кичердек. Яз килде. Әтием Истанбулда эш тапкан, арендага өй тоткан. Искешәһәргә кайтып, төрле тарафка таралган гаиләсен туплады, барыбызны да Истанбулга алып китте.

Искешәһәрдән китәр алдыннан безне озатырга килгән мөхтәрәм абзыем һәм укытучым Хәсән Тимер Булатны, ул көнне соңгы мәртәбә күрдем, башка күрә алмадым. Хәзер иң якын туганнарым буларак, аның оныклары белән күрешәм. Һич онытмам, без тәгәрмәчле ат арбасына төялеп, Бурсага таба киткәндә, ул аркабыздан догалар укып калды...

## Сталинның дусты булган кырымлы бер шагыйрь...

...Ул көннәрдә Кырымлы шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләйдән бер хат алдым. Бу – авыру бер шагыйрь, большевикларның Кырымга икенче мәртәбә килүендә килгән, Сталинның дусты иде. Большевиклар белән бәйләнешле шәхес икәнен яшерү өчен бер авылда укытучы булып эшли иде.

Мин бу зат белән Алуштада акларның бирегә беренче кергән көннәрендә бер балда очраклы таныштым. Алушта укытучыларыннан Җәлил бәй балда миңа:

– Кара, Хәят ханым, – диде.– Сиңа Казаннан килгән бер шагыйрьне тәкъдим итәм. Синең якташың.

Һәркем үз дөньясына чумып биегәндә, без Җәлил бәй тәкъдим иткән бу шагыйрь белән озын-озак сөйләштек. Мәгәр шагыйрь Сәгыйть минем авылдашым һәм анасы тарафыннан туганым, имеш! Ул бу хакта әйткәч, мин дә хәтерләдем.

Без Истанбулга һиҗрәткә чыгар алдыннан авылга киттек. Авылда болар безнең күршеләр иде. Ул чакта әтисе югалган вакыт. Яшь кенә әнисен һәм әбисен хәтерлим. Болар ике кардәш. Зурысына – биш, Сәгыйть ике ярым яшендә иде ул заман. Без аңар: «Авыр башлы Сәгыйть», – дия идек. Чөнки йөзе һич көлмәс. «Сәгыйть, бераз көл, шикәр бирәбез», – дисәк, иреннәрен кыйшайтып көләр иде. Сәгыйть ул вакыттан соңгы тормыш хикәясен сөйләде, мин тыңладым. Әбиләре үлгәннән соң әниләре белән ялгыз калган ике кардәш фәкыйрь бер хәлдә әле Оренбурга, әле Уфага барып, гыйлем туплыйлар. Бераздан абыйсы Уфада укыта башлый, әнисен дә янына ала. Сәгыйть үзен әдәбиятка багышлый, шигырьләр язып, нәшер итә башлый. Казан басмаларыннан аның шигырьләрен укыганымны хәтерлим...

Боларның авылда әтиләре тарафыннан туган тиешле байлар булса да, бу фәкыйрь кардәшләрен танырга теләмиләр!

Сәгыйть шушылай бер шагыйрь буларак, тегендә-монда гизгәндә, Сталин белән очраша, таныша. Бер тарафтан фәкыйрьлек, бер тарафтан бу танышу нәтиҗәсе – Сәгыйть большевик булып чыга!

Менә шушы шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй миңа юллаган хатында үзе яшәгән авылда бай бер агайның кызларын укытырга мөгаллимә эзләгәнен яза. Һәм: «...Апа, бер төрмәгә охшаган Дарулмуаллиматтә буш ятканчы, тиз арада авылга кил. Биредә күпкә рәхәт һәм яхшырак яшәрсез», – ди.

Сәгыйтьнең бу хаты миңа мөшкел бер хәлдә яшәгәндә, Хозырның ярдәмгә ашыгуына тиң килде. Тагын да калыр идемме?! Тиз генә Гүзләведә вакытта алган бер тукыманы ерак бер мәхәлләдәге бай кешегә: «Миңа Истанбулдан килде. Әмма әлегә миңа кирәкми», – дип сатып, юлга акча юнәттем. Иң кирәкле әйберләремне бавылга бәйләп, үзем белән алдым, бүлмәмне бикләдем. Истанбулдан ияртеп килгән кече кардәшем белән бергә поездга утырып, юлга чыктык.

Киткән җирем Севастопольгә якын бер авыл иде. Мине авылда Сәгыйть каршылады. Сөйләштек, хәл-әхвәл белештек. Мине авыл бае белән таныштырды. Шулай итеп, аның балаларын укытырга керештем. Шул ук вакытта авыл мәктәбенә дә укытучы кирәк икәнлеге беленде. Мәктәпкә укытырга чакыргач:

– Укытырмын, әмма өч айлык хезмәт хакын алдан алам! – дип, гайрәтлек күрсәттем. Кабул иттеләр. Хезмәт хакым – ярым миллион врангель акчасы... Ярты миллион рубльне сумкама салдым!

## Төркиядән бер хат

...Төркиягә, Истанбулга хатлар язам, һич беренә җавап килми. Ниһаять, беркөн Бергама шәһәреннән Җәлал исемле бер дустымнан хат алдым. Бу дустымны Коммунистлар университетыннан Казанга сөргәннәр иде. Берара Казанда вокзалда эшләгән, соңрак Төркиягә киткән. Хатында башта минем үлгәнемне, аннары исән икәнемне ишетүе турында әйткән. Казанда булуым хакында хәбәр алуга хат язган. «Апа, Казанда икәнсең, сиңа бер киңәш бирәм. Анда Казанның иң зур галимнәреннән Һади Максуди әфәнде бар. Аның янына бар, сөйләш. Ул сиңа рухи да, матди дә ярдәм итәр. Мөхтәрәм бер заттыр. Казанда горбәт җәфасын чиккәндә, иң зур ярдәмне миңа ул күрсәтте».

Хатны укыганнан соң, ай башы булганга күрә – һәр айдагы кебек ГПУга теркәлергә киттем.

– Сезне Сәетов иптәш эзли,– диделәр.

Югары чыгып, Сәетовның бүлмәсенә кердем.

– Мине күрергә теләгәнсез, – дидем.

– Әйе. Эшлисеңме? Эш урыны ошыймы?

– Рәхмәт. Эшлим. Бик ошый.

– Төркиядән хат аласызмы?

Шунда ук эш нәрсәдә икәнне аңладым. Төркиядән, Җәлалдан хат килде бит, ә... Хатны ГПУдан яшерергә телимме, юкмы, шуңа төшенергә тырыша, димәк. ГПУ Төркиядән килгән бер хатны ачып укымыйча, миңа бирер идеме? Укыганнары көн кебек ачык. Саклавым, инкарь итүем бу хәлдә бер көлке булыр иде. Сәетов иптәш миңа никадәр бер «инсанлык» күрсәтсә дә, ул ГПУ кешесе иде. Аңар ышанып булмас иде.

– Әйе, – дидем. – Төркиядән бер хат алдым. Бер дустымнан.

Һәм хатның эчтәлеген ничек бар, шулай аңлатып бирдем.

– Һади Максудига бардыгызмы?

– Юк. Китмәдем әле.

– Адресын беләсезме?

– Белмим.

– Мин сезгә бирим...

Һади әфәнденең адресын язып бирде. Әле ничек барасын аңлатты. Аннары майлагандай татлы тел белән:

– Барыгыз, күрешегез, – диде. – Соңыннанниләр сөйләштегез, мөһим нокталар турында миңа килеп, мәгълүмат бирегез. Ни дияргә теләгәнемне, әлбәттә, аңладыгыз?

Монда аңламаслык ни бар?! Янә бер шымчылык тәкъдиме каршында калдым.

– Әйе, аңлыйм, – дип мыгырдандым.

## Һади Максуди янында

Икенче көнне китапханәдә дежур идем, сәгать сигездә чыктым. Өйгә китмичә, туры Һади Максуди әфәндене күрергә киттем. Хөкүмәт Һади Максуди мөлкәте булган зур бинаны аның кулыннан тартып алган, хуҗа кешегә бер фатир калдырган. Баскычтан күтәрелеп, шул фатир ишеген шакыдым, бер хатын чыкты.

– Һади Максуди бәй монда яшиме?

Хатын җавап биргәнче, үзе ишек төбенә килде. Берничә сүз белән генә аңар үземне таныттым. Мине эчкә уздырып, ишекне япты. Китапханәсендә кара-каршы утыргач:

– Сөйләшә башлаганчы ук Төркиядән килгәнегезне аңладым, – диде һәм: – Ничек, кайчан килдегез? – дип сорады.

Россиягә ничек килгәнемне, башымнан кичкәннәрне аңлаттым. Бу арада, әлбәттә, Бергамалы Җәлалдан килгән хат турында әйттем, сәлам сөйләдем.

Һади әфәнде күзләрен бер ноктага төбәп, уйга калды. «Бик мәрхәмәтле калебле, саф чиста бер яшь кеше...» – диде. Бераздан сүзен дәвам итте: – Төркиядә бер кардәшем бар. Һәрхәлдә аны беләсеңдер... 1905тә монда иде. Депутат иде. Хәзер Төркиядә депутат дип ишеттем. Әмма аның белән элемтәбез юк. Сез – төркияле, әлбәттә, беркөн Төркиягә китәрсез. Сүзләремне аңа җиткерүегезне үтенәм. Күрдегезме, өемне, мал-мөлкәтемне – бар нәрсәне алдылар. Мин моңар борчылмадым. Карамы, акмы – ипи кисәге булса, шуңа шөкер итеп, көн уздырам. Чөнки шуңа сөенәм ки, большевиклар бу туфракларда яшәгән кырык миллион төрек яшен, татар димим, чөнки без дә төрек, укытып, белем биреп җитештерәләр. Әмма, коммунизм идеясе белән җитештерәләр кебек. Ярый, җитештерсәләр, җитештерсеннәр. Акыл утырткан, фикри алгарыш эчендәге бу яшьләрнең йөрәкләрендәге «миллият» тойгысын һәм милләтне яратуны һичбер идея йолкып ала алмас. Һәм бу тойгы аларны беркөн алга чыгарыр. Менә шул минем өметем!

Бер мизгел сүзсез торды. Тирән бер сулыш алгач, сүзен дәвам итте:

– Мин фәлсәфә белән бик кызыксынам. Аллаһыны инкарь иткәннәргә каршы Аллаһының барлыгын исбат иткән бер китап язам. Әмма һаман тәмамлый алмадым. Мине дә сезнең кебек ГПУ тикшерә. Биш ай төрмәдә яттым. Ул арада яза торган китабымны да алдылар. Хәзер яңадан башладым.

– Китабыгызны кайтармадылармы?

– Кайтардылар.

– Караламаларны үзгәрткәннәрме, бозганнармы?

– Юк, нигәдер, бөтенләй кагылмаганнар. Хәзер калган җиреннән дәвам итәм.

Һади Максуди өендә берсе 16, икенчесе 14 яшьләрдәге ике энҗе кебек кыз бар иде. Чәй өстәле әзерләделәр.

Остаз:

– Бу кызлар – минем оныкларым, – диде. – Кызларымның кызлары. Ике улым да бар. Берсе – доктор, берсе – инженер. Мәскәүдә эшлиләр.

– Мәскәүдә эшләүләре әйбәт, остаз, – дидем. – Монда булсалар, күптән Себер буйларлар иде.

Моңсу бер караш белән башын селкеп:

– Әйе, әйе... Дөрес, – дип сөйләнде һәм болай дәвам итте: – Кызганыч, бер милләт инсаннары бер-берләрен батырырга тырышалар. Әгәр мондый хәл булмаса, без хәзер рус боерыгы астында бер милләти тоткын буларак түгел, зур бер милләти хаким буларак яшәр идек. Аллаһ соң терәгебез булган Төркияне безнең гакыйбәттән – ахырдан корысын, сакласын, даими пайдар – даими бар булсын. Яңадан сүзсез калып торды. Сулышын эченә аларак тирән итеп сулады. – Төркиягә гашыйкмын, ватандашым... Аллаһы минем дә Төркияне күргәнче җанымны алмасын, кичә-көндез дога итәм...

Сөхбәтебез шактый озакка сузылды, кичке сәгать 12 тулды. Остазның рөхсәтен алып, урынымнан калыктым. Миңа үзе язганнардан өч сүзлек бүләк итте. Рәхмәт әйтеп аерылышканда, шулай диде:

– Сезгә бер сүз әйтәм, зинһар, мине гафу итегез, миңа үпкәләмәгез. Бу безнең беренче һәм соңгы күрешүебез булсын. Чөнки, мәгълүм ки, икебез дә ГПУ тарафыннан тамгалы...

## Казан төрмәсе

...Икенче көнне төн уртасында йокымнан уяттылар, Казанга китәчәк тоткыннар бар икән, мине дә алар белән бергә җибәрәчәкләр, имеш...

Куыштагыларның берләре йоклый, берләре уянган иде. Уянганнар белән хушлаштым, ашыгып, юлга чыктык. Бер гаскәри мине ялгызымны гына станциягә, вагонга кадәр озатты. Башка тоткыннар белән вагон тулган иде, бер җир калмаган. Өсте-башы җыйнак бер адәм калыкты, миңа утырырга җир ачты. Поезд кузгалып киткәч сөйләшә башладык. Бик яхшы сөйләшә торган кеше булып чыкты. Чуваш милләтеннән бер укытучы икән. Минем дә элеккеге бер мөгаллим икәнемне белгәч, бик шатланды.

Тәмәкем юк иде. Чуваш укытучы бер дустын уятып, аңардан минем өчен бер сигара алды. Юлыбызны иртәнгә кадәр сөйләшә-сөйләшә уздырдык.

Таң атканда, Казанга барып җиттек. Туры карантинга дип, мунчага яптылар. Чөнки бетләр инде киемнәр өстендә үк базар коралар иде.

Мунчага кергәндә, бары тик бер хатынны күрдем. Ялгыз башына юына иде. Аның белән сөйләшеп киттек.

– Сез дә безнең кебек поезд белән килдегезме?

– Юк, мине төн уртасында өемнән тотып китерделәр. Монда берүзем юынганга курыккан идем, ярый, сез килдегез.

– Нигә тоттылар?

– Белмим! Мин «иттифак»та машинист. Кич эштән чыккач, киногa киттем. Соңрак өйгә кайтып яттым. Төн уртасында бирегә алып килделәр!

Мунчадан чыккач, безне хатын-кызлар куышына китерделәр. Биредә ятар өчен биек такта караватлар тезгәннәр. Әмма алар өстендә бер генә буш урын да калмаган! Мунчада танышкан хатын бер карават астына өеннән китергән җәймәсен җәйде, мендәрен куйды. Мине дә янына яткырды.

Төн кунган башкалар иртәннән тордылар, безне дә уяттылар. Монда да бер кисәк ипи белән чәй эчәр өчен кайнар су тараттылар.

Куыш шактый зур, тәрәзәләре биек, якты бер бүлмә иде. Ике якта такта караватлар. Өстләре, астлары кешеләр белән тулы. 50-60 хатын бар иде... Күбесе татар хатыннары. Араларында берән-сәрән чуваш, чирмеш күренде.

Монда да каршыма бер укытучы хатын чыкты. Бер татар хатыны. Минем белән дусларча сөйләшә башлады. Шагыйрь дә икән... Ирен өч ел элек Себергә сөргәннәр. Үзен тотып китергәннәре өчен борчылмады кебек.

– Ирем янына китәргә телим. Әмма «болардан» курка идем. Хәзер тотып китерүләре әйбәт булды, бәлки мине дә ирем янына сөрерләр...

Башка бер хатын да үзенең борчуларын уртага салды:

– Якташымның ирен боз утравына сөрделәр. Якташым бер яшьлек һәм алты айлык балалары белән калды. Аларны караячак, ярдәм итәчәк беркем юк... Хөкүмәт тарафыннан шул балаларга бирелгән шикәрле бисквитны, икмәк алыр өчен акча табу ниятеннән сата идем. «Спекулянт» дип тоттылар. Алты елга Пермьгә сөрәчәкләр. Русча бер сүз дә белмим. Мин – анда, якташым ике бала белән монда нишләр, белмим...

## Төрмәдән газап кочагына

Мине поезд белән Казанга килеп җитүгә иреккә җибәрергә тиешләр иде. Чөнки мин бирегә сөргенгә хөкем ителгән тоткын. Әмма төрмәгә китереп тыктылар. Анда өч көн узды, тавыш-тын чыкмады. Мин үзем дә чыгарып җибәргәннәрен теләмәдем. Чөнки моннан чыксам, кая барыйм? Ни ашыйм?

Нишлим, ни теләсәм, шуның киресе була иде. Беркөн:

– Әйдә, чык! Нәрсәң бар, ал! – дип кычкырдылар.


Чарасыз, апар-тупар тупланып чыктым. Урамда минус 28-30 дәрәҗә суыклык. Китәр, барыр бер җирем юк! Өстемдә иске бер костюм, аягымда юка оек һәм иске сандалилар! Юлдан барам, үзем җелекләремә кадәр үткән суыктан дер-дер килеп калтыранам. Шул кадәр суык ки, төкерек җиргә төшкәнче ката. Берара көчем калмады, үземә кул салу турында уйлый башладым. Үзем дерелдим, көч-хәл атлыйм, үзем: «Шәһәрнең читенә кадәр чыгыйм. Анда карны ишеп, бер чокыр казырмын, эченә кереп ятармын», – дип уйлыйм. Суыкта туңганнар сөйләвенә караганда, туңып үлү – иң кулае, иң рәхәте, имеш. Инсан акрын-акрын туңганда, җылы бүлмәләр турында хыялланыр, ул җылы, рәхәт бүлмәләрне уйлаганда, үзен дә югалтыр...

Зур бер урамда арган, бетәшкән хәлдә йөрдем. Ниһаять, бу урамны таныган кебек булдым. Уңда бриллиант тешле Мәхмәтнең ипи пешерә торган җире – пекарнясы булачак. Менә шул! Әмма бераз якынлашкач, Мәхмәт әфәнденең түгел, башка кешенең язуын күрдем. «Осман вә Дурсун Рәйхан» дигән язу эленгән иде. Элек Казанда булганда танышкан Мәхмәт әфәнде пекарнясын ташлаганмы? Башка берсе урнашканмы? Әллә мин урамнарны бутадыммы? Шулай аптырап бер мизгел икеләнеп тордым...

# «ҺИЧБЕР ВАКЫТ БЕЗДӘН «ТАТАР» ДИГӘН СҮЗ АЛЫНА АЛМАС»

***(Г.Ибраһимовның «Без – татарбыз» китабы чыгуы мөнәсәбәте белән)***

Быел апрельдә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнгән Галимҗан Ибраһимовның «Без – татарбыз» исемле китабы нәшер ителде. Әлеге китапка әдипнең төрле елларда язылган туган тел, татар әдәбияты, милли тарих һәм сәнгать мәсьәләләренә багышланган хезмәтләре тупланган. Китап – татар һәм рус телләрендә әзерләнгән: рус телендәге хезмәтләр укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителә.




Г.Ибраһимовның XX гасыр башында милләт темасына бәйле күп мәкаләләр язганы билгеле. Алар, шул чор вакытлы матбугатында («Шура», «Аң» журналлары, «Вакыт», «Йолдыз» газеталары) басылып, зур бәхәсләр уятканнар. Матбугаттагы чыгышларында әдип һәм публицист үзен татарлык тарафдары итеп күрсәтә: гомумтөрки тел һәм әдәбият идеясен яклаучыларга (И.Гаспралы, Р.Фәхреддин) каршы чыга. Шунысы да игътибарга лаек: 1913 елны «Аң» журналында (21 нче сан) «Милләтне ничек аңлыйсыз?» дигән анкета бастырыла. Шул вакытта Г.Ибраһимовның журналда сәркатип булып торуын исәпкә алсак, әлеге анкетадагы җитди сорауларны формалаштыруда («Миллиятнең фәнни тәгърифе, фәнни мәгънәсе нидән гыйбарәт?»; «Миллиятнең тарихында вә хәзерге хәяттә тоткан әһәмияте ни мәртәбәдә?»; «Миллиятнең нигезләрениләр – ул ни белән тора, ни белән күтәрелә?»; «Халкымызның үткәндә миллияте вә милли куәте ни мәртәбәдә иде дә хәзер ни хәлдә?»; «Милли вөҗдан нидән гыйбарәт?» һ.б.) әдипнең ролен инкяр итү мөмкин түгел. «Аң»ның 1913-1914 елгы саннарында әлеге анкетаның сорауларына аерым татар интеллектуалларының җаваплары басылган (Г.Гобәйдуллин, Г.Шәрәф һ.б.). Бу җаваплар шул чор татар зыялыларының миллият мәсьәләләренә карата югары теоретик дәрәҗәдә фикер йөрткәннәрен ачыктан-ачык күрсәтә. Мисал өчен, Г.Гобәйдуллинның анкетадагы беренче сорауга («Миллиятнең фәнни тәгърифе, фәнни мәгънәсе нидән гыйбарәт?») җавабын китерик: *«Миллиятнең асылы тарихи ганганәләргә (сүзнең кешедән-кешегә күчүе), хатирәләргә теркәлгән була: ягъни бер милләттән булган кешеләр бер-берсенең якынлыгын хис итәләр; һәркайсының бабасының бабалары вә нәселләре бер дошманга – дошман, бер дуска – дус; бер җирдә торганны яисә бергә күчеп йөргәнне халык тарихи җырлары кыяфәтендә күңелдә саклыйлар. Шулай итеп, без миллияткә хәзер рухи бер тәгъриф бирәбез: миллият – тарихи ганганәләре бер булып, берлек хис иткән адәмнәрнең җыеныдыр»*. Биредә танылган тарихчы миллият тойгысы турында яза, аны милләтнең нигезе итеп карый. Соңрак бу фикер С.Максудиның мөһаҗирлектә язылган «Миллият тойгысы һәм аның нигезләре» хезмәтендә чагылачак.

Г.Ибраһимовның яңа дөнья күргән

җыентыкка кергән хезмәтләре хәзер дә үз актуальлеген югалтмаган. Без, мәсәлән, төрле мөнбәрләрдән телебезнең чисталыгын саклау турында чаң сугабыз. Кайвакыт бу көрәш телдәге ясалмалылыкка китерә. Биредә сүз компьютерны «санак», принтерны «басак» яки «язак» дип атау турында бармый (бу, билгеле, ясалмалылыкның ахыр чиге). Ә менә киң кулланышка кергән «редактор» сүзе урынына «мөхәррир»не куллану – бу күренешкә бер мисал булып тора ала. «Татар теле һәм татарча язу хакында бер-ике сүз» мәкаләсендә татарчалаштыруның уңышсыз мисалларын китереп (мәсәлән, «мөтәрҗим» (тәрҗемәче) сүзе урынына «татарчага әйләндерүче» сүзтезмәсен куллану), Г.Ибраһимов татарча язуны чит телләрдән сүзләр кертмәү дип аңлаучыларга каршы чыга. Шулай итеп, ул телне ачык система буларак кабул итә, татар теленең башка телләр белән аралашмыйча үсеш алмаячагы турында кисәтә.

Шул ук вакытта галим телебезнең потенциалы гаять зур булуын һәм аны төрле өлкәләрдә куллану мөмкинлекләрен шик астына алмый. Киресенчә, Г.Ибраһимов татар теленең үсешен әдәбият өлкәсе белән генә чикләми, аны фән теле итеп үстерү максатын куя. *«Бер төркем халыкның аерым бер милләт мәртәбәсенә күтәрелүе өчен ана телендә әдәбияты булу гына җитми, аның үз телендә фәне дә булырга тиеш»*, дип яза ул «Фәнни истыйляхлар (терминнар)» мәкаләсендә. XX йөз башында әйтелгән бу фикер әле дә үз әһәмиятен югалтмаган. Милли телдә фәнни терминологияне тудыру өчен, билгеле, аның фән теле буларак актив кулланылуы зарур. Яшерен түгел: хәзерге шартларда мондый мөмкинлекләр чикләнгән. Ләкин терминология өлкәсендә эзләнүләрне беркем дә тыймый бит? Бу өлкәдә перспектив бер юнәлеш – аерым фәннәргә мөнәсәбәтле сүзлекләр төзү.

Җыентыкка кертелгән һәм тел мәсьәләсенә караган тагын бер хезмәтне игътибарсыз калдырып булмый. Сүз Г.Ибраһимовның 1918 елда нәшер ителгән «Татар телен ничек укытырга?» китабы турында бара. Әлеге хезмәттә әдип телне укыту методикасы турында җитди фикер йөртә. Г.Ибраһимовның фикеренчә, телне укыту нигезендә ике принцип булырга тиеш: телнең кешенең уйлавы белән бәйләнешы; ана теле дәресләренең милли тәрбиягә хезмәт итүе.

XX йөз башында Америка галимнәре Эдвард Сепир һәм Бенджамин Уорф тел структурасының кешенең дөньяны кабул итүенә йогынты ясавы турында язалар (тел белемендә алар эшләгән теория «Гипотеза лингвистической относительности» исеме астында мәгълүм). Г.Ибраһимов бу теория турында хәбәрдар булмаса да, аның фикерләре көнбатыш галимнәре идеяләре белән аваздаш. *«Адәм уйлау вә мөхакәмә (логик фикерләү) өчен кирәк булган материалларны табигатьтән, хәяттан, китаптан ала. Уйны асыл тудыручы шул өч нәрсә. Ләкин шулар тәэсире белән туган уйны мантыйкый мөхакәмә рәвешендә ачык вә билгеле бер сурәттә алып баруында, һәр уйның тышкы калыпка сугылуында телгә – сүз вә җөмләгә – хаҗәт төшә»*, дип яза ул.

Икенче принципка мөнәсәбәтле Г.Ибраһимов болай ди: *««Тел» дигән нәрсә сүз белән җөмлә генә түгел, тел дәресе димәктә имля вә сарыфның кагыйдәләрен ятлату гына түгел, болар тышкы як кына. Телнең эчендә халыкның рухы, моңы, уй вә тойгысы яшеренгән. Бу – бер хәзинә. Телнең камил алынуы нәтиҗәсендә бала ихтыярсыз шул хәзинәне сөя, шул рух белән сугарыла. Бала үзен халыкның углы итеп хис кыла»*. Бу фикер соңгы еллардагы телне укыту методикасында булган борылышка туры килә.

Җыентыкның аерым бүлегендә Г.Ибраһимовның милли тарих мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре тупланган. Төрле жанрда язылган (мәсәлән, «Яңа әсәр» һәм «Гани бай» китабы» исемле хезмәтләре рецензия жанрында язылганнар) бу мәкаләләрдәге аерым фикерләр игътибарны җәлеп итә. Аерым алганда, Фатих Кәриминең мәктәп-мәдрәсәләр өчен язылган дәреслегенә мөнәсәбәтле «Вакыт» газетасында (1911 ел, 18 ноябрь саны) басылган рецензиясендә Г.Ибраһимов дәреслек авторын татар һәм төрек кавеменнән чыккан даһиларны (Атилла,

Чыңгыз, Аксак Тимер) гел кара, ямьсез яклары белән күрсәтүдә гаепли: *«Безнең ул даһиларымызда бөтен дөнья тарафыннан тасдыйк кылынган (расланган) әллә ничаклы яхшы сыйфатлар да бар. Без иң элек күренә торган урынга шуларны куеп, начар якларын сөкүт итәргә (телгә алмаска), ул да мөмкин булмаса, буярга, төзәтергә тиешлемез»*. Г.Ибраһимовның фикеренчә, тарих дәреслекләре мәктәп-мәдрәсәләрдә укыган шәкертләрдә милләт каһарманнарына карата горурлык хисе тудырырга тиеш. «Рус милләтенең тарихи каһарманнарыннан берсе булган мәшһүр Иван Грозный кем? Ул ниләр кылган? Ә шул затны мәктәп вә мәдрәсәләр өчен язылган рус тарихларында нинди кеше итеп күрсәтәләр? Без дә шундый хәлләрдән гыйбрәт алырга тиешлемез дип беләм», дип тәмамлый әдип үз мәкаләсен. Кызганыч, әле дә тарих дәреслекләрендә аерым бер шәхесләргә бәйле стереотиплашкан карашлар хөкем сөрә.

Җыентыкның соңгы бүлегендә Г.Ибраһимовның аерым танылган шәхесләргә (М.Вахитов, К.Насыйри, Г.Ибраһимов) багышланган мәкаләләре тупланган. Шунысы кызык: революциядән соң язылган булсалар да, бу хезмәтләрдә әлеге шәхесләр сыйныфчылык ягыннан түгел – татар милләтенә хезмәт итү критерийларыннан чыгып бәяләнә. Мәсәлән, Габдерәшид Ибраһимовка багышланган «Тарихи кыңгыравык өзелде» мәкаләсендә Г.Ибраһимов аның эшчәнлеген тарихи контекстта карый: Рәшид казый һәм аның аерым замандашларының иҗатын күчеш дәвере (кадимнән җәдидкә) күренеше буларак бәяли: *«Ләкин шулай булса да, ул «Бәдәвам»нар, «Кызыл алма»лар, «Шәкерт абый»лар, «Мулла бабай»лар, «Мәгыйшәт»ләр тарихи бер дәвернең тарихи җимешләре булып сакланалар... Хрестоматияләргә кертеп, балага, шәкерткә өйрәтеләләр. Шулай үткән эшләрне таныштыралар. Менә шуның кебек Рәшид бабай мәгълүм бер тарихи дәвернең, үткән баскычның бер көрәшчесе – кадимнән җәдидкә чыгуда алга өстерәүче буларак урын алачак»*. Үткән заманнар мәдәниятен инкяр итәргә чакырган радикаль лозунглар хөкем сөргән бер вакытта (мәкалә 1922 елда басылган) аларны саклап калу идеясен яклаган Г.Ибраһимов, һичшиксез, зур хөрмәткә лаек.

Ә инде әдипнең 1927 елда басылган «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» брошюрасы аның чын мәгънәсендә милләтпәрвәр булганын күрсәтә. Ана теленә битараф булган яңа совет түрәләренә каршы язылган бу хезмәтендә, Г.Ибраһимов татар мәдәниятенең үсешен татар теленең рус теле белән беррәттән төрле дәрәҗәдәге рәсми учреждениеләрдә, мәгариф, фән системасында актив кулланышы белән бәйли. Шунысы да мөһим: әдип татар мәдәниятенең «милли мәдәниятләр кәрванында аерым бер отряд булып» яшәвен яклый, ягъни башка мәдәниятләр арасында үз төсен югалтмыйча, алгарыш итүен ассызыклый. Әлбәттә, 1920 нче елларның азагында мондый фикерләр милли телләрне һәм мәдәниятләрне тигезләү тенденциясенә туры килмәгән, шуңа күрә Г.Ибраһимовның хезмәте каты тәнкыйть уты астына эләгә. ВКП(б) ҮК политбюросы әгъзасы Михаил Калинин аңа мөнәсәбәтле: *«Бу тезисларның башка бер куркыныч ягы да бар: татар теле Көнчыгышның барлык халыклары өчен дә аңлаешлы. Шуңа күрә бу тезислар алардагы партактивлар арасында фикер төрлелеге тудырырга, «рус мәдәниятеме яки милли мәдәниятме» дигән сорауны калкуландырырга мөмкин»,* дип яза.

Г.Ибраһимовның миллият мәсьәләләренә (милли тел, милли үзаң, милли әдәбият һәм сәнгать) багышланган хезмәтләрен туплаган җыентык әдипне яңа яктан ача, күрсәтә. Китапка кергән мәкаләләреннән чыгып, укучы аларның авторын фидакарь татарлык тарафдары, татар теле, мәдәнияте турында тирән фикер йөртүче, аларның киләчәге турында кайгыртучы милләтпәрвәр буларак күз алдына китерә.

Китапның электрон вариантын Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты сайтыннан укырга була.

**Марсель ИБРАҺИМОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

# XVI ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ – XVIII ЙӨЗНЕҢ УРТАСЫНДА ИДЕЛ-УРАЛ ТӨБӘГЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕ

## 2. Мәхәлләләр – авыл мөселман җәмгыятьләре

Һәр авыл җәмгыяте үзенең мәнфәгатьләрен кайгыртып яши. Халыкның руханилар әзерләүче уку йортын тоту өчен матди мөмкинлеге дә, теләге дә булмый. Ханлык чорында моны дәүләт, руханилар, сәүдәгәрләр һәм аксөякләр кайгырткан була. Соңгыларының исә, инде әйтеп үтелгәнчә, саннары һәм матди мөмкинлекләре нык кими.

1552–1557 еллардагы «Казан сугышы», рус колонизациясе тәэсирендә халыкның яшәү урынын алыштыруы, ул да түгел, Чулман елгасының аргы ягына чыгып, Көньяк Урал якларына юнәлү ханлык заманы мәхәлләләре структурасын җимереп бетерә. 1565–1568 елгы статистика кәгазьләрендә авылларда берничә гаилә генә теркәлгән *(Писцовое описание Казани и Казанского уезда 1565–1568 годов: публикация текста / сост. Д.А. Мустафина. Казань, 2006)*. Иван Болтинның 1602 елгы Казан өязе писцовый кенәгәсендә дә халык саны нык артканы күренми *(Писцовая книга Казанского уезда 1602-1603 годов. Публикация текста / сост. Р.Н. Степанов. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978)*. Күрәсең, эчке миграция даими барган, яңа авыллар барлыкка килү һәм татарларның яшәү тирәлеге киңәю торак пунктларда халык саны ныклап артуга комачаулаган.

Вәгазьләү кимү, авылларның кечкенә булуы һ.б. югарыда аталган сәбәпләр тәэсирендә халык арасында моңарчы да нык булмаган ислам тәгълиматы тагын да йомшап, мөселманнарның рухи тормышында мәҗүсилек элементлары көчәя. Тарихи әдәбиятта мондый күренешне «халык исламы» дип атыйлар.

Шул ук вакытта дәүләтчелекне югалту, чит телле һәм динле яңа хакимият вәкилләре белән очрашу-аралашу, чукындыру турында сүзләр таралу мөселманнарны дин һәм руханилар тирәсендә берләштерә. Ягъни дини тәгълимат йомшару шартларында авыл җәмгыятьләре эчендә чит идеологиядән саклану хисе көчәя. Шушы иҗтимагый халәт, акрынлап, дини активлыкка нигез була. Әйтик, 1602 һәм 1647–1656 елгы Казан өязе ясаклы һәм йомышлы татар авылларын исәпкә алган җанисәп кенәгәләрендә теркәлгән антропонимик мәгълүматларда абызларның яңа туган балаларга исем кушкандагы дини активлыгы беркадәр чагылыш тапкан. XVI гасыр ахыры белән чагыштырганда, XVII гасыр уртасына таба гарәп һәм фарсы исемнәренең антропонимик системада кулланылышы 10 процентка арткан *(Хазиева-Демирбаш Г.С. Татарские личные имена в этнокультурном пространстве языка. Казань, 2017. С. 241)*.

XVIII гасырның беренче яртысында Көньяк Уралга күченү массачыл төс алган, ул

*Дәвамы. Башы алдагы санда.*

авыллап яки кайбер авыл җәмгыятьләреннән берничә гаилә китү рәвешендә барган. Шулай да халык саны арту авылларның эреләнүенә китергән.

1742 елгы «Экстракт в Сенат из Казанской губернии о татарских мечетях» исемле документта Казан өязенең мәчетле авылларында хуҗалык һәм ир-атлар саны теркәлгән. Шундагы саннарны анализлаганда, иң күп хуҗалыклар һәм халкы булган авыллар Галич даругасында (32 йорт һәм 129 ир-ат) булуы ачыклана. Нугай даругасында бу күрсәткечләр – 31 йорт һәм 122 ир-ат, Алат даругасында – 30 йорт һәм 119 ир-ат. Кечкенә авыллар күбесенчә Җөри (23 йорт һәм 91 ир-ат) һәм Арча (26 йорт һәм 105 ир-ат) даругаларында тупланган булып чыга.

Рәсми исемлеккә кергән 517 торак пункт арасында ике яки өч мәчете булганнары бармак белән генә санарлык. Ике мәчетлеләр исемлегенә Алат даругасына караган Олы Әтнә (120 хуҗалык), Кошар (100 хуҗалык), Сая (60 хуҗалык), Җөри даругасында Тәберде Чаллысы (35 хуҗалык), Арча даругасында Казанбаш (55 хуҗалык), Нугай даругасындагы Чаллы (30 хуҗалык) һәм Урай (60 хуҗалык) авыллары керә. Өч мәчет хәзерге Балтач районына кергән Сасна авылында (90 хуҗалык) гына булган. Күрәбез, ике мәчет, нигездә, зур авылларда эшләгән. Шул ук вакытта Нугай даругасындагы Олы Тигәнәле (200 хуҗалык), Иске Шәйморза (75 хуҗалык), Иске Рәҗәп (100), Олы Елга (90), Арча даругасындагы Ямаширмә (70 хуҗалык) һәм Банзилә (80 хуҗалык) кебек зур авылларда бер генә мәчет күренә. Безнең уебызча, бу авылларда тирә-якта абруйлы имамнар яшәгән, шуңа да җирле халык тагын бер яңа мәчет төзү мәсьәләсен күтәрмәгән.

Мәчетле авылларда, нигездә, мөселманнар үзләре генә яшәгәннәр. Кайбер авылларда, берничә православие вәкиле булуга карамастан, мәчет эшләгән. Әйтик, Нугай даругасындагы Селенгуш авылында 8 йортта керәшеннәр һәм руслар көн күргән. Биредә мәчет 50 ел элек төзелгән. 30 ел элек мәчетле булган Такталы авылында 10 йортта руслар яшәгән, Кибри авылында 10 йортта яшәгән мөселманнарның 100 ел элек төзегән мәчетләре булган. Мондый очраклар күп булмау, чукынганнарның аерым авылларда көн күрүләрен һәм әле мөселманнар арасында чукындыру башланмаганын раслап тора.

«Экстрактта...»гы «Мәчетегез кайчан төзелгән?» дигән сорауга авыл халкының өч төрле җавабы теркәлгән: 1) «хәтерләмибез» бик борынгы дигәнне аңлата; 2) «Казан ханлыгы алынганчыга кадәр», ягъни 1552 елга кадәр; 3) мәчетнең якынча төзелү вакыты (3, 8, 15, 20 еллар элек һ.б.).

Шунысы игътибарга лаек, Арча һәм Галич даругалары авыллары халкы бердәм рәвештә мәчетебез бик борынгы – кайчан төзелгәнен хәтерләмибез дип җавап биргән. Алат даругасында урнашкан 88 авылның 14ендә яшәүчеләр мәчетләренең 180 елдан башлап 15 елга кадәр элек төзелгәнен әйткәннәр, калганнар исә төзү вакытын ачыклый алмаганнар. Җөри даругасына караган авыл кешеләре югарыда китерелгән өч төрле җавапны да кулланган. Нугай даругасында урнашкан авылларда яшәүчеләр мәчет төзелгән вакытны төгәл яздырганнар (3 ел элек һ.б.).

«Экстракт...»тан күренгәнчә, Җөри даругасында мөселман авыллары 12 керәшен авылы янында урнашкан, Нугай даругасында – 32, Арча даругасында 9 шундый авыл булган. Яңа керәшен авыллары Алат һәм Галич даругаларында бөтенләй юк. Җөри даругасында 88 авылның 66сы янында рус һәм керәшен торак пунктлары булмау теркәлгән *(Загидуллин И.К. Махалли Казанского уезда в середине XVIII в. // Арская земля: актуальные проблемы изучения историко-культурного наследия. Казань, 2010. С. 82-86).*

Яңа чукынганнарны күчерү аларга яңа урында имана җире бирү белән бәйле булганлыктан, XVIII гасырда алар мөселманнар арасында яшәп кала.

Яңа мәчет төзү нормативы Урта Идел төбәгендә мәхәлләләр структурасына беркадәр үзгәрешләр кертә. Беренче чиратта, берничә авыл халкы берләшеп, иң күп

кеше яшәгән торак пунктында мәчет салу тәртибе урнаша. XVIII гасыр уртасында Көньяк Урал төбәгенә күченү хәрәкәте сүнүгә бара. Халык саны арту мәчетләр күбәюгә уңай тәэсир итә.

Казан өязендә хәрби кораблар төзү өчен урман кисү буенча дәүләт йөкләмәсен үтәүче авылларның 1768 елгы исемлегенә барлык торак пунктларында да берәр мәчет булганлыгы күренә. 300 ир-ат яшәгән авылларда икешәр мәчет тә очрый. Мәсәлән, хәзерге Балтач районына кергән авылларда 1742 елдан соң сакланып калган мәчетләр Ор авылында (1762 елгы Өченче ревизиядә теркәлгән 227 ир-ат), Саснада (180), Смәилдә (286), Кариледә (203), Салавычта (155) эшләүләрен дәвам иткән. 1768 елга зур авыллар рәтенә кергән Түнтәр (136), Яңа Салавыч (184), Яңгул (245), Борнак (254) кешеләре яңа мәчетләр төзегәннәр. Күрәсең, бу авылларда яшәүчеләр мәчет төзергә рөхсәт сорап биргән гаризаларында мәхәллә составына сан өчен күрше кечкенә авылларны керткәннәр. Ягъни мәчетләр төзүдә авылларда яшәгән халык саны зур роль уйный башлаган. Кечкенә авыллар да үз дини тормышларын көйләргә тырышканнар. Әйтик, югарыда телгә алынган Казан Адмиралтействосы идарәсендә булган авыллар исемлегендә Алат даругасында урнашкан Әтнә (Өченче ревизиядә теркәлгән 3 ир-ат), Солабаш (6), Арча даругасында Яңа Мәсәгут (3), Нугай даругасындагы Кече Енали (5) һ.б. кечкенә авылларда «молитвенный дом» дип аталган җәмәгать биналары күрсәтелгән *(Загидуллин И.К. Махалли Казанского уезда в середине XVIII в. С. 91-92)*. Мөгаен, мәчет төзергә хокукы булмаган яки башка сәбәпләр белән төзи алмаган авылларда үзләренең абызлары дини ритуалларны үтәүләрен дәвам иткәннәр. 1789 елда Мәхкәмәи шәргыя ачылгач, мәчет төзү, мәхәллә теркәү нормативы ревизиядә исәпләнгән 200 ир-ат санына калдырылган. Ул заманда бу сан әле канун буенча һәр авылда мәчет төзү мөмкинлеген бирмәгән, ләкин кануннар үтәлмәү сәбәпле, мөселманнар аларны «урап үтү» җаен табарга тырышканнар.

## 3. Дини әдәбият

Инде искә алынганча, 1552–1557 елларда булган «Казан сугышы», китапханәләрнең янгында юкка чыгуы, руханилар әзерли торган система җимерелү һәм башка сәбәпләр рус хакимияте чорында дин әһелләренең белем дәрәҗәләре төшүгә сәбәп була. Безнең уебызча, күпмедер санда имамнарны әзерләү дин әһелләре гаиләләрендә дәвам иткән, белем алу һәм рухани вазифасы нәселдән-нәселгә тапшырыла башлаган.

Дини китапларга кытлык шартларында дин гыйлеменең Урта Идел төбәгенә читтән кайтуы мөһим роль уйный башлый. Бу өлкәдә берничә юлны атап китү сорала.

Р.Фәхреддин фикеренчә, Казан алынгач, туган якларыннан качып китәргә мәҗбүр булган мөселманнар, асыл ватаннарына кайтканда, юл капчыгына дини китаплар салганнар. Урта Идел төбәгендә киң таралган «Шарт ас-салат» (Намаз шартлары), «Тәгаллүм әс-салат» (Намазга өйрәнү) кебек кульязма китаплар Дагыстан галәмәләре тарафыннан язылган, димәк, шул яктан килгән. Төрле сәбәпләр белән туган якларыннан читкә киткәннәр дә илгә кайту юлына Госманлы дәүләтеннән, Төньяк Кавказдан «Устуани», «Мөхәммәдия», «Әнвәр әл-гашикыйн», «Алты бармак», «Мәгърифәтнамә», «Һәдиятес-Соглук», «Нисабел-әхбар», «әт-Тарика-и әл-Мөхәммәдия» (Мөхәммәд юлы) һ.б. китапларны сатып яки күчереп алганнар *(Фәхреддин Р. Казан вә Болгар төрекләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 238-239 б.)*.

Мондый китаплар Идел-Урал төбәгендәге дин әһелләренә үзләрен мөселман дөньясының аерылгысыз өлеше итеп сизәргә, ислам фәлсәфәсен һәм диндәшләренең башка җирләрдә нинди мәсьәләләрне үзәккә алып яшәгәнлеген аңларга ярдәм иткән.

Алар укучыга Мөхәммәд пәйгамбәрне үрнәк итеп куеп, дини кагыйдәләрне һәм ритуалларны төгәл үтәргә, исламны йөрәк белән кабул кылырга өндәгән.

Әйтик, шундый юллар белән Истанбулдан Мөхәммәд Биргәвинең (1573 елда вафат булган) гарәп телендә язылган «әт-Тарика-и әл-Мөхәммәдия» китабы кайта. Җ.Зәйнуллин бу хезмәтнең әдәп-әхлак тупланмасы булуын, Коръән һәм хәдис китапларындагы фарыз гамәлләрне күрсәтү, бәян итү белән бергә гыйлемнең, белемнең никадәрле кирәкле икәнен ассызыклаганын билгеләп үтә *(Зәйнуллин Җ.Г. XVIII йөз – XX йөз башында татар рухани әдәбияты. (Коръән тәфсирләре, хәдисләр һ.б. чыганаклар. Тәрҗемә принциплары һәм тел үзенчәлекләре). Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 1998. 9 б.)*.

Чыннан да, бу китап мөселманнарны тел-теш тидермәслек тормыш алып барырга өйрәтә. Китапның беренче бүлегендә шуңа «нигезләмә» бирелә. Гамәлләр кылганда, Коръәнгә таяну кирәклеге турында 12 аять, ни өчен шулай эшләргә кирәклеген дәлилләүче 7 хәдис, гамәлләр кылганда, сөннәткә таяну кирәклеген дәлилләүче 17 аять, аларны раслаучы 20 хәдис санала. Мөхәммәд пәйгамбәр гамәлләрен үрнәк итеп, шул заманда мөселманнар тормышында пәйда булган төрле яңалыклардан, бидгатьләрдән ваз кичәргә кирәклеге ассызыклана. Биргәви, бер үк вакытта, исламны көчәйтүгә хезмәт итә торган: мәчетләргә манара кую, китап бастыру, мәдрәсәләр ачу кебек яңалыкларны урынлы дип таба *(Тарика Мөхәммәдия. Әһле Сөннәт вәл-җәмәгать игътикады һәм әхлагы. Казан: «Иман» нәшр., 2002/1423. 20 б.)*. Автор, «гамәлдә уртача булу» турында 7 дәлил, моның шулай икәнен шәрехләүче 10 хәдис һәм күренекле фикъһе галимнәренең сүзләрен китерә.

Китапның икенче бүлегендә ислам динендә әһәмиятле булган эшләр хакында бәян ителә. Аллаһы Тәгалә, иман, хәсән, беренче дүрт хәлиф, кайбер сәхабәләр, мөселманнарга имам билгеләнергә тиешлеге, руханиның сыйфатлары һ.б. турында сөйләнә. Өч төрле әһәмиятле гамәлләр атала (әмер кылынган, тыелган, мөстәхәб булган), гыйлемнең һәм гыйлем иясенең яхшырак һәм артыграк булуы Коръән аятьләренә һәм хәдисләргә нигезләп дәлилләнә.

Тәкъвалык турында да аятьләргә нигезләнеп сөйләнә. Биргәви дини кагыйдәләрне белү – иң яхшы гыйбадәт кылуга тиң, ә Аллаһтан куркып, гөнаһлардан саклану һәм тәкъвалык – дингә ышану билгесе дип яза. Тәкъвалык – йөрәк эше, ул кануннар белән билгеләнми, кеше кагыйдәләргә игътибар биреп, тыелуны (аскетизм) һәм хикмәтне күздән ычкындырса, аның йөрәге катылана, ул Аллаһтан ерагая дигән фикер әйтә.

Биргәви мөселманнарда булмаска тиешле 60 начар сыйфат («60 явыз холык») дип, түбәндәгеләрне атый: иманның юклыгы, наданлык, көферлек, мактаганны сөю, бидгатьне игътикад итү, үз нәфесеңә иярү, дәлилсез кешегә иярү, комсызлык, тәкәбберлек, үз-үзеңне кимсетү, хөсетлек, күңелдә дошманлык саклау, дошманыңның бәлагә ирешүенә шатлану, аннан көлү, куркаклык, ачуның чиктәш тыш артык булуы, вәгъдәне бозу, хыянәт, Аллаһы Тәгалә һәм мөэминнәр турында начар уйлау, саранлык, исраф (шәригать кушканнан артыграк сарыф итү), малны сөю, ялкаулык һәм эшсезлек, әдәпсезлек, сабырсызлык һәм шикаять кылу, дөнья эшендә курку, наданлык һ.б. *(Шунда ук, 55–103 б.)*. Хезмәттә, шулай ук, 78 мактаулы холык санап үтелә, әдәп-әхлак кагыйдәләре «тел афәтләре», «колак афәтләре», «күз афәтләре», «кул афәтләре», «корсак афәтләре» кебек бүлекләргә аерып тасвирлана *(Шунда ук, 105–156 б.)*.

Китапның өченче бүлегендә мөселманнар тормышында еш очрый торган мисаллар тикшерелеп, бидгать белән тәкъвалык аерып күрсәтелә.

Биргәви, пәйгамбәрнең мөселманнар 73 төркемгә бүленәчәк, шуларның берсе генә тәмуг газапларын күрмәячәк дигән сүзләрен искә төшереп, һәр мөселманны, башкаларга карамыйча, Аллаһка якынайта торган изге гамәлләр кылырга өнди, өстәмә

намазлар укуга караганда, пәйгамбәр кебек башкаларга ярдәм итүче, файда китерүче кеше булу яхшырак дигән фикер уздыра.

Биргәвинең аскетизмы тормыштан ваз кичүне түгел, ә җәмгыять эчендә актив булуны ассызыклый. Якын кешеләренә хөрмәт һәм ярату хисләре булган һәм гомере буе изге гамәлләр кылган кеше яхшы мөселман була дип, ул пәйгамбәр сүзләрен мисалга китерә. Аныңча, милек кешегә бу дөньяда матди кыенлыкларга тармыйча яшәү өчен кирәк, ә акча – Аллаһ биргән игелек, аны дөрес тоту һәр мөселманның ахирәттәге тормышына турыдан-туры йогынты ясый. Шуңа күрә акчаны башкалар мәнфәгате өчен сарыф итү – мәдрәсә, мәчет, күпер салу – мөһим дигән фикер уздыра. *(Кемпер М. Суфии и учёные в Татарстане и Башкортостане (1789–1889). Исламский дискурс под русским господством. Казань: РИУ, 2008. С. 217–229).*

«әт-Тарика-и әл-Мөхәммәдия» хезмәте XIX гасырда Казанда берничә тапкыр басыла, 1902 елны аның татарча тәрҗемәсе дөнья күрә.

Күпчелек абызлар, руханилар исә Мөхәммәд Биргәвинең «Пиргули васыяте» китабындагы материалларны 1640 нчы елларда төрек шагыйре Руми Синан госманлы теле белән сөйләп биргән һәм Идел-Урал төбәгендә халык арасында «Пиргули китабы» дип атала башлаган хезмәтеннән киң файдаланган *(Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 2 нче том. Казан: Татар. кит. нәшрияты, 1985. Т.2. 44 б.).* Ислам дине һәм аның йолалары турында сөйләүче «Пиргули китабы» Казанда тәүге тапкыр «Азия типографиясе»ндә, беренче мөфти М.Хөсәенев фәтвасы белән 1802 елда басыла. Гомумән, бу хезмәт XIX йөздә берничә тапкыр нәшер ителә, шәкертләрнең һәм гади халыкның иҗтимагый аңы формалашуга зур йогынты ясый.

Мөфти М.Хөсәенев фатихасы белән 1802 елда типографиядә дөнья күргән тагын бер хезмәт – «Устуани китабы» (хезмәтне Хәнәфи мәзһәбенә күчкән Дәмәшекъ галиме Мөхәммәд Устуаниның (1662 елда вафат була) шәкерте госманлы телендә яза). Шулай ук Истанбулдан кайткан бу кульязма XVII гасыр ахырында – XVIII йөздә мәхәллә имамнарының өстәл китабына әверелә. Хезмәттә бик тәфсилләп һәм шәрехләп, дини ритуалларны башкару кагыйдәләре аңлатыла, исламның «алтын баганалары», мәет күмү, мәчеткә йөрү, тәһарәт алу, бишвакыт намаз, җәмәгать, бәйрәм һәм җомга намазлары тәртибе, сәяхәт вакытында үтәлергә тиешле гамәлләр һ.б.лар ваклап аңлатыла *(Устувани М.Устувани китабы. М.: «Алтын Мирас», 2019).*

Шулай ук 1802 елда Казанда бастырылган «Сөбат әл-гаҗизин» («Гаҗизләр ныклыгы)» китабы XVIII гасырдан башлап Идел-Урал төбәгендә халык арасында иң киң таралган хезмәтләрнең берсе санала. Аның авторы – Урта Азиягә күченгән Суфи Аллаһияр Идел буе татарлары нәселеннән, ул Сәмәрканд янындагы бер авылда туа, 12 яшеннән Бохарада укый башлый, 25 яшендә әмир аны таможня җитәкчесе итеп билгели, әмма егет шәех Хәбибуллага мөрид булып барып, остазыннан 12 ел дәвамында белем ала, тәсаувыфта югары дәрәҗәләргә ирешеп, «Суфи Аллаһияр» булып китә. Хаҗ кылу сәфәренә чыгып, Казанда туктала, бирездә күренекле суфи Идрис Хафиз белән очраша. Юлда, Искәндәрия каласында 90 яшендә вафат була.

Суфи Аллаһияр, дуслары теләген үтәп, үзенең фарсы телендә 12 мең бәеттән торган әсәрен төрки телгә кыскартып тәрҗемә итә. «Сөбат әл-гаҗизин» 77 бүлеккә тупланган 1718 шигъри ике юллыклардан – бәетләрдән – тора. Авторның максаты – Мөхәммәд пәйгамбәрне үрнәк итеп куеп, сүз сәнгате белән укучыларында югары әхлак тәрбияләү. Суфи әдәбият үрнәге булган бу әсәрнең бүлек исемнәрендә дә әлеге максат чыгылыш тапкан: «Аллаһы Тәгаләнең сигез сыйфаты», «Мөхәммәд рәсуллаһ бәяны», «Үгет-нәсихәт», «Фәрештәләр бәяны», «Гомернең вакытлы гына булу хәбәре», «Җәннәт белән тәмуг бәяны», «Комсызлык хикәяте», «Яхшы юлдашның бәяны» һ.б.лар. Шагыйрь тормыштагы һәрбер кыенлыкны, авырлыкны олы сабырлык белән каршы алырга һәм зарланмый чыдарга өнди *(Маханова Р.Р. Творчество суфи*

*Аллаяра и его традиции в татарской литературе: Автореф. дисс.... канд. филол. наук. Казань, 2008. С. 14–16).*

Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» (1449) китабы XVI гасырдан башлап Кырым ханлыгында киң тарала, аның Урта Идел төбәгендә Казан ханлыгы чорында ук билгеле булуын фаразларга мөмкин, яисә ул Әстерхан аркылы Истанбулдан хаҗи-сәүдәгәрләр тарафыннан XVII гасырда алып кайтылган. Г.Гобәйдуллин, «Мөхәммәдия» суфичылык әсәре булып та, андагы суфичылыкның шәригать кысаларыннан бер карыш та читкә чыкмавын ассызыклый. И.Р. Мөхәммәтов фикеренчә, «китапта дөньяның барлыкка килүеннән һәрнәрсәнең бетүенә кадәр дини мәгълүматларның урын алуы да «Мөхәммәдия»не тиңдәшсез уку китабына әйләндергән. Һәркем үзенә кирәкле дини белемне аннан таба алган. Күрәсең, шуңа күрә дә аның таралыш һәм кулланыш киңлеге дә башка китаплар белән чагыштырганда зуррак» *(Мөхәммәтов И.Р. Күрс. хезмәт. 77 б.).* Китапның кереш өлешендә автор һәм мәшһүр ислам галимнәре турында, шулай ук тәмуг һәм җәннәт хакында әйтелә. Китапның беренче өлешендә җиһанда акыл яралудан башлап тарих бәян ителә, Адәм һәм Һавага мактау сүзләре яудырыла. Икенче өлештә барлык пәйгамбәрләр хакында сүз әйткәннән соң, автор Мөхәммәд пәйгамбәрне олылый, Мөхәммәднең гүзәл пәйгамбәрлек сыйфатлары, аның тормыш юлы, Коръән китабы турында мәгълүмат бирә, беренче дүрт хәлиф турында сөйли. Өченче өлештә, кыямәт галәмәтләрен тасвирлаганнан соң, җәннәткә эләгү шартлары һәм тәртибе хакында сөйләнелә һ.б. *(Мөхәммәтов И.Р. Күрс. хезмәт. 42–45, 73–75, 77, б.).*

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: гарәп телен өйрәнү әсбапларыннан тыш, чит илләрдән кергән китапларның күп өлешен аерым галимнәрнең хезмәтләренә таянып язылган дини хезмәтләр һәм суфи әдәбият тәшкил иткән. Беренче вакытта бу хезмәтләр абызларның уку китаплары булсалар, соңрак мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту әсбаплары буларак кулланылганнар.

Имамнар кулында тупланган шул берничә китап гарәп телен үзләштерүдә, дин әһелләренең мөселман җәмгыятендә тоткан урыннарын билгеләүдә, ислам ритуалларын үтәү нечкәлекләренә төшенүдә, мәктәп-мәдрәсәләрдә укытуда, мөселманнарга ислам дине нигезләрен аңлатуда һәм аларны вәгазьләүдә бик зур роль уйнаган. Бу китаплар, дини белем бирүдән тыш, руханилар тарафыннан авыл җәмгыятьләре турында кайгыртуны һәм дин кардәшләре өчен җаваплылыкны, дини дәвамчанлыкны тәэмин итүгә, үзләрен Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәзерге заманда дәвамчылары һәм ислам дөньясының аерылгысыз бер өлеше итеп тоюга, Рус дәүләтендә яшәү шартларында дини һәм социаль эшчәнлекне активлаштыруга зур йогынты ясаганнар.

Күренекле алман галиме М.Кемпер фикеренчә, Идел һәм Урал төбәкләрендә яшәгән мөселманнарның игелеклелеккә һәм яхшылык кылырга омтылуы дәрвишләрнең вәгазьләренә генә бәйле булмыйча, Госманлы дәүләтеннән алып кайтылган кайбер популяр дини китаплар йогынтысында формалашкан *(Кемпер М. Күрс. хезмәт. 245 б.).*

Никах, Коръән мәҗлесләрендә, әрвахларны 7, 40 көннәрендә искә алганда, шулай көндәлек тормышта сөйләшү, аралашу аша бу китаплардагы фикерләр, кагыйдәләр гади мөселманнарга да барып ирешкән.

Акрынлап, дини китаплар күчермәләрен алып кайтуның берничә каналы формалаша. Шуларны карап үтик.

1) Хаҗ кылу. Идел-Урал төбәгендә яшәгән мөселманнар XVII-XVIII гасырларда Мәккә, Мәдинә шәһәрләренә баруны ике төп маршрут буенча тормышка ашырган: 1. Урта Азия (Сәмарканд, Бохара) – Әфганстан (Мазари Шәриф, Кабул, Пәшәвар) һәм Һиндстан (Бомбей), аннары диңгез юлы белән Мәккә һәм Мәдинәгә алып баручы Җиддә яки Янбуга; 2. Кара диңгез буе портларыннан Истанбулга, аннан Җиддәгә *(Сибгатуллина А.Т. Контакты тюрок-мусульман Российской и Османской империй на рубеже XIX-XX вв. М.: Институт востоковедения РАН, 2010. С. 22-23).* Ул заман

өчен сирәк күренеш булган ерак, зур матди чыгымнар сораган һәм күп авырлыклар белән бәйле хаҗ сәфәреннән дин әһелләре һәм сәүдәгәрләр юл сандыкларында дини кулъязмалар алып кайтканнар. Урта Идел төбәгеннән беренче хаҗ кылучылардан Мәүла Колыйның остазы Казан имамы Мамай, муллалар Юныс бине Иванай һәм Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети исемнәре билгеле (Кемпер М. Күрс. хезмәт. С. 53). 1698-1699 елларда язылган Симети хаҗнамәсеннән сәфәр маршрутын һәм ул зиярәт иткән изге пәйгамбәрләр һәм бөек шәехләр каберлекләре исемлеген Р.Фәхреддин үзенең «Асар»ында китерә *(Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 1 том. Казан, 2006. 38-39 б.).*

Г.Рәхим: «Госманлы телендәге әсәрләрне безнең илгә алып кайтучылар исә күбрәк Истанбул аркылы хаҗга барган татар хаҗилары иде. Шул сәбәпле булырга кирәк, безгә Төркиядән мәктәп өчен кирәкле китаплар түгел, бәлки халис (саф) әдәбия китаплар кайтты. [...] Классик госманлы шагыйрьләренә, аларның җен теле белән «гали» сюжетларга язылган шигырьләренә безнең садә вә надан татарның теше батмады. Ул бары тик мәддахлар вә кыйссаханнар тарафыннан мәйданга китерелеп, төрек гаммәсенең яратып укый торган китапларын гына үзенә кабул итеп алды», дип яза *(Мөхәммәтов И.Р. Күрс. хезмәт. 72 б.).*

2) Дагыстан. XVII–XVIII гасырның беренче яртысында бу төбәккә Россиянең Көнчыгыш илләр белән сәүдә итүдә үзәге булган Әстерхан каласы һәм Кизләр шәһәре аша барганнар. Аларны, бигрәк тә, Дагыстанда мәшһүр шәех һәм мөдәррис Мөхәммәд әл-Кандәкыйның гыйлеме (1652–1717) җәлеп иткән. Р.Фәхреддин мәгълүматларына караганда, Мөхәммәд әл-Кандәкый Урта Идел төбәгеннән килгән шәкертләргә үзенең силсиләсен биреп, аларны шәех иткән *(Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 1 том. 35 б.).*

3) Дини кулъязмалар Урта Азиягә, Әфганстанга барып укыган шәкертләргә дә «ияреп» кайта. Күрәсең, бу кадерле кулъязмаларның күбесе шәкертләр тарафыннан күчерелгән текстлар булып, аларның шәхси китапханәләрендә уку еллары истәлеге буларак сакланган, аларга киләчәктә мәдрәсәдә укытканда, бик кирәкле әсбап булып хезмәт иткән.

Идел-Урал төбәгендә мөселман интеллектуаллары катламы оеша башлауның ачык чагылышы булып, чит илләрдә укып кайткан голәмәләрнең дини китаплар һәм дәреслекләр яза башлавын атарга кирәк.

Ш.Мәрҗанигә билгеле чыганакларга караганда, XVII гасырда Урта Азиягә, Мәвараэннәһергә дини белем эстәргә беренче булып Юныс бине Иванай исемле егет киткән. Юнысның (1689 яки 1690 елны вафат була) 1649 елда 18 яшендә күчергән Коръән нөсхәсе әле XIX гасырда исән була. Юныс ахунның остазы Тубылда яшәгән мелла Сәсәр әт-Тәркыйд дип күрсәтелгән *(Мәрҗани Ш.Күрс. хезмәт. 233-234 б.; Фәхреддин Ризаэддин. Күрс. хезмәт. 40-41 б.).*

XVII гасыр ахырында Арча ягындагы Кәче авылы ахуны Иванай «бераз кытыршылыклары белән» күчереп язган Коръән кулъязмасы нәселдән-нәселгә кадерле ядкарь буларак тапшырылып килгән *(Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 234 б.).*

XVII йөзнең икенче яртысында Мәвараэннәһердә хаҗи, суфи-мулла Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети (1723 елны вафат була) укыганлыгы мәгълүм. Аның тарафыннан 1703 елда күчереп язылган дини китап сакланып калган.

Шулай итеп, Юныс бине Иванай һәм Симети Урта Идел голәмәләреннән беренчеләрдән булып фикъһе буенча язылган хезмәтләргә шәрехнамәләр, шулай ук шәригать буенча беренче хезмәтләр һәм фәтвалар язганнар һәм алда сүз булачак «Болгар» гыйлеменең нигез ташларын салганнар *(Кемпер М. Күрс. хезмәт. С.53-54)*

Симетинең укучысы, Казан губернасы Зөя өязе Борындык авылыннан чыккан, Оренбургның булачак беренче мөфтие М.Хөсәеневнең бабасы Мансур, шулай ук, XVII йөз ахырында Бохарада белем ала, илгә кайтып, мәдрәсә ача, белем бирү тәртибенә яңалыклар кертә. Ул заманда башлангыч сыйныфларда гарәп теле морфологиясен – «Зәнҗани», синтаксисын «Мисбах» һәм «Ифтитах» китаплары белән укытканнар.

Мансур әл-Борындыкый сарыфтан «Бидан» һәм «Шәрхе Габдулла», ә нәхүдән «Кавагыйдә» һәм «Гавамил» китаплары буенча дәрес бирү тәртибен кертә. Мансур әл-Борындыкый 1727 елда Габдулла әл-Болгарый тәхәллүсе белән «Әл-гавамил әл-мийә» китабына аңлатма рәвешендә фарсы телендә «Тәракыйбе Мансурия» («Чәчелгәннәрне җыйнау») дигән, Ш.Мәрҗани «мәшһүр» дип, югары бәяләгән хезмәтен яза. Р.Фәхреддин әлеге хезмәтнең XX гасыр башында да киң таралган булуын шәрехләп, бу күренешне мөдәрриснең шәкертләре күп һәм гыйлемле булулары белән аңлата *(Фәхреддин Ризаэддин. Күрс. хезмәт. 36, 39 б.)*. Мөдәрриснең гыйлеме һәм абруе империя хакимиятен дә җәлеп иткән. Ул 1734–1744 елларда Оренбург экспедициясендә ахун булып хезмәт итә. 1738 елны Орск шәһәрендә агачтан беренче җәмигъ мәчете төзетә һәм аның беренче имамы була *(Зиннәтуллина А.Ә. Кайбыч төбәгенең күренекле шәхесе // Фәнни Татарстан. 2020. №3. 96-100 б.)*.

## 4. Дини укыту системасы оешу

XVI гасырның икенче яртысы – XVIII йөз башында Урта Идел буе дини белем бирү системасының торгынлыктан чыгуы һәм яңарышы Дагыстан, Бохара, Сәмәрканд һәм Кабул мөдәррисләре эшчәнлеге белән бәйле.

Мәгълүм ки, татарлар яшәгән төбәкләргә XVII-XVIII гасырлар чигендә Дагыстан белем бирү тәртибе үтеп керә. Ул барыннан да элек нәхү (гарәп теле синтаксисы), сарыф (гарәп теле морфологиясе), фикъһе, Коръән һәм Сөннәт, әхлак, игътикад кебек предметларны тирәнтен һәм сыйфатлы укыту; мәдрәсәләрдә җыелып утыру; бергәләп җырлау традицияләре белән аерылып торган. Дагыстанда белем алган мөдәррисләр мантыйк (логика) һәм кәлям фәннәрен укытмаганнар, чөнки бу предметлар соңрак кертелгән һәм элек яшәгән голәмәләр күзлегеннән бидгать (Коръәндә һәм Сөннәттә булмаган яңалык) дип саналган.

Соңрак бу укыту тәртибе Бохарада белем алган голәмәләр тарафыннан үзгәртелә: тарих фәне төшеп кала, Коръән һәм Сөннәт гыйлемнәренең исемнәре генә саклана; мантыйк һәм кәлямгә бик киң урын бирелә; предметлар яңа дәреслекләр буенча укытыла башлый. Шул рәвешле, укыту ысулы һәм дәреслекләр алмашына. Эш шунда ки, Дагыстан мәдрәсәләрендә борынгырак, ягъни ислам динендә хөрлек заманында һәм кәлямга каршы мөкаддимнәр тарафыннан язылган китаплардан укытканнар. «Бу китапларның кереш сүзләренә үзенә тиешле кадәр генә әһәмият биреп, шәрехләр вә хашийәләр белән авырайтмый, каршылыклы сораулар белән чуалтмый, китапларның максатын мөмкин кадәр аңлатып, укытып чыгарырга тырышканнар», – дип яза Хәсәнгата Габәши *(Габәши Х. Мәрҗани хәзрәтләрен искә төшерү // Мәрҗани. Фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2010. 612–614 б.)*. Урта Азия мәдрәсәләрендә кулланылган дәреслекләр исә схоластик китаплар була.

Дагыстанда казый булган һәм ниндидер сәбәпләр белән туган иленнән сөрелеп, Россиягә күченгән, Оренбург янында 1744 елда нигез салынган Сәгыйть бистәсендә мәдрәсә тоткан Мөхәммәд бине әд-Дагыстанидан бер төркем татар шәкертләре дәрес алган. Дагыстани (1795 елда вафат була) Е.Пугачёв житәкчелегендә баш күтәрүне яклап чыга һәм 1775 елда Казакъ даласына качып, җәйләүләрдә дәрес бирүен дәвам итә. Ш.Мәрҗани аның шәкертләре дип беренче мөфти М.Хөсәеневне, Сәгыйть бистәсенең мәшһүр мөдәррисе Габдрахман бине Шәриф әл-Каргалыйны, Нигъмәтулла Тәүзихыйны атый *(Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 243-244 б.)*.

Тумышы белән Ашыт авылыннан булган Мөхәммәдрәхим бине Йосыф (1818 елда вафат) Ибраһим исемле яшьтәше белән Дагыстанга сәфәр кылган. Анда ун ел яшәп кайткач, Мәчкәрә авылында мәдрәсә ачып, аның данын еракларга тараткан, төбәкнең ахуны булган *(Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 263–264 б.)*.

Оренбург төбәгендә ислам мәгарифе алгарышы Каргалы бистәсе оешып, бирсдә

яшәүче татарлар Урта Азия белән сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга салгач башлана. Бистә ахуннары Россия белән Казакъ җөзләре ханнары, солтаннары арасында яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыра, хакимиятнең төрле җаваплы йөкләмәләрен үти. Бистәдә зур мәдрәсәләр ачыла.

Татарларның Бохара белән сәүдә итүе дини элемтәләрнең ныгуына һәм көчәюенә уңай йогынты ясый. XVIII гасыр ахыры – XIX гасырның беренче яртысында Бохара мәдрәсәләре татарларны күпләп үзенә җәлеп итә башлый. Белем алу үзәгенең Дагыстаннан Урта Азиягә күчүенә, шулай ук, Төньяк Кавказда шәфигый мәзһәбе һәм әшири гакыйдәсе өстенлек итү, ә Урта Азиядә, Идел-Урал төбәгендәге кебек, хәнәфи мәзһәбе һәм Матуриди гакыйдәсе актив булу да тәэсир итә.

Дагыстанда Гали әш-Ширвәнидә ун ел укып, 1781 елда асыл ватанына кайткан Ибраһим бине Хуҗашиның 1796 елны Казанда ачкан мәдрәсәсендә әлифба, иман шарты, гарәп теле синтаксисы һәм этимологиясе, мантыйк, Коръән тәфсире, хәдис шәрифе, гыйльме фараиз (милек бүлү), астрономия кебек фәннәр укытуы билгеле *(Хабутдинов А.Ю. Движение абызов и некоторые аспекты функционирования ислама // Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье: история и современность. Очерки. Казань, 2002. 106 б.)*. Күрәбез, XVIII гасыр ахырында Урта Азиядән кайткан имамнар йогынтысында Дагыстанда укыган мөдәррисләр мәдрәсәсендә мантыйк укытыла башлый.

XVIII гасыр дәвамында Идел-Урал төбәгендә бер-бер артлы мәдрәсәләр ачыла. Әйтик, Көньяк Уралда 1709 елда Сөендектә, якынча 1720 елда Эстәрлебаш авылында эшли башлый *(Фархшатов М.Н. Народное образование в Башкирии в пореформенный период. 60-90-е годы XIX в. /Отв. ред . Х.Ф.Усманов. Уфа: «Наука», 1994. С. 16)*. Казан губернасында мәдрәсәләр Кариле (1768), Бай Оланнар (1757), Орнашбаш (XVIII йөз ахыры), Ашыт (XVIII йөз ахыры), Мәчкәрә (XVIII йөз ахыры), Казаклар (1779) һ.б. авылларда эшли. Казанда 1771 елны – Апанай һәм Ахун, 1780 елны Әмирхан мәдрәсәләре корыла *(Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 238, 282, 283, 284, 285, 287 б.)*.

Гыйлемле мөдәрристән тыш, мәдрәсә ачуның мөһим шарты – уку йортына ярдәм итеп торырлык мөселман бае булу. Урта Азия һәм Казакъ даласында сәүдә эшләре киңәю татарлар арасында буржуазия формалаша башлауга китерә, андый шәхесләр табыла.

Укытучылар-мөгаллимнәр җитешмәгәнгә күрә, аларны башка төбәкләрдән чакыру тәҗрибәсе киң тарала. Күрәсең, сезонлы мөгаллимлек, бер яктан, табышлы эш булган, икенче яктан, саваплы гамәл саналган. Әйтик, 1773 елның октябрендә Е.Пугачёв гаскәре белән Каргалыда һәм күрше торак пунктларда тукталгач, шушы төбәк авылларына балалар укытырга Арча даругасыннан килгән укый-яза белүче бер төркем крестьяннар, дәресләрен һәм шәкертләрен калдырып, баш күтәрүчеләр сафына баса *(Алишев С.Х. Татары Среднего Поволжья в пугачевском восстании. Казань, 1973. С. 81).* 1774 елны дәүләт органнары Урал артыннан (Күбәл, Катай, Тамьян волостьлары) балалар укытып кайтып килүче Казан губернасыннан – 13, Уфа тирәсеннән – 2, Ставрополь өязеннән 1 укытучыны тоткарлый. Аларда дини һәм дөньяви эчтәлекле 50 кулъязма китап табыла *(Гвоздикова И.М. Башкортостан накануне и в годы Крестьянской войны под предводительством Е.И.Пугачёва. Уфа, 1999. С.187).*

Дин әһелләренең тырышлыгы белән чукындыру куркынычына каршы тору өчен абызлар ачкан мәктәпләрдә кечкенә балаларны намаз укырга өйрәткәннәр, догалар ятлатканнар һәм башка беренчел дини бурычларны аңлатканнар. Мәктәпләрдә үзләштергән белем һәм практика аларның чит мохиткә эләккәндә дә, мөселман булып саклануына юнәлтелгән. Авыллар зурайган саен, аларда мәчет һәм мәктәп ачу матди яктан җиңелрәк хәл ителгән, абызлар яшәгән игенче җәмгыятьләрендә исламлашу көчлерәк барган. Бигрәк тә XVIII гасыр башында авылларда халык саны сизелерлек

арткач, мәктәпләр саны да күбәя башлаган дип уйлыйбыз. Кечкенә авылларда вәгазьләү белән суфилар да актив шөгыльләнгән. Әлбәттә, аларга ияреп, игенчеләр суфи булып китмәгән, халыкка суфиларның ислам нигезләре һәм югары дини әхлак турында сөйләүләре кадерле булган. Күрәсең, күпчелек абызлар һәм, бигрәк тә, чит илләрдә укып кайткан яшьләр, Нәкышбәндия тарикате әгъзалары сыйфатында, имам һәм мөгаллим вазифаларын башкарганнар.

Казан егылудан соң исән калган берән-сәрән гыйлем ияләре шулай ук укыту белән шөгыльләнгән дип уйларга кирәк. Р.Фәхреддин сүзләренә ияреп, XVII гасырда азсанлы мәдрәсәләр, нигездә, Дагыстанда укып кайткан шәхесләр тарафыннан ачылган дип саныйбыз. Күрәсең, ул елларда чит илләргә белем алырга чын мәгънәсендә исламга һәм туган халкына хезмәт итүне максат итеп куйган югары әхлаклы шәхесләр барганнар. Шуңа да кайткач, мәдрәсәләр ачып, дини кадрлар әзерләүгә зур игътибар биргәннәр. Аларга XVIII гасыр башында Урта Азиядә укып кайтканнар да кушылган. Гадәттә, гыйлемле мөдәррисләр ахун итеп сайланган һәм алар күп булмаган.


Дагыстан укыту системасы Урта Азиянеке белән алмашыну мөдәррисләр арасында каршылыклар китереп чыгарган дигән дәлилләр сакланмаган. Дини белемнең йомык авыл җәмгыятьләрендә туплануы һәм һәр данлыклы мәдрәсә авыл халкының горурлыгы булуы, шулай ук мөдәррисләрнең мөстәкыйльлеге авыл җирлегендә һәр ике укыту системасының да янәшә, параллель эшләвенә мөмкинлек биргән. Халыкара сәүдә мөнәсәбәтләре йогынтысында Бохарада укыган голәмәләр саны арту һәм Урта Азиядәге ислам институтларын күреп кайткан сәүдәгәрләрнең акчаларын шундагы сыман мәдрәсәләр ачарга бирүләре татарларда укыту өлкәсендә тирән үзгәрешләргә китергән.

Дагыстанда укыган Казан ахуны Ибраһим Хуҗаши мәдрәсәсе мисалында карап кителгәнчә, XVIII гасыр ахырында укытуга, гарәп телен тирәнтен өйрәнү сакланган хәлдә, яңалык рәвешендә Урта Азия мәдрәсәләренә хас фәннәр кергән, шулай итеп укыту эчтәлеге үзгәрә башлаган дип уйларга нигез бар. Шулай да Дагыстан дини белем бирү системасы буенча эшләүче авыл мәдрәсәләренең күпчелеге, нигездә, мөдәррисләре вафатыннан соң эшләүдән туктаган, шул ук вакытта остазларының укыту тәҗрибәсен үз авылларында гыйлемле укучылары да дәвам иткән.


Шулай итеп, дини белем бирү системасын булдыруга һәм читтә белем алган мөгаллимнәр үстереп җиткерүгә акча тотарлык бай катлам барлыкка килүгә, татар җәмгыятендә ислам дине көчәя башлый. XVIII гасыр ахырында артык үзгәрешләрсез яшәп киләчәк һәм мәгърифәтчелек хәрәкәтенә нигез булачак белем бирү тәртибе оеша.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*


*(Дәвамы киләсе санда.)*



*Сулдан уңга: Ә.Мәҗит, Ә.Уразаев, Г.Нигъмәтуллина, Г.Булатова, Һ.Такташ. Узган гасырның 20 нче еллар ахыры.*



*Татар әдәбиятын дөньяга танытуда зур өлеш керткән тәнкыйтьчеләр, әдәбият галимнәре. Сулдан: Рафаэль Мостафин, Роберт Бикмөхәммәтов. 1989 ел.*



*Нури Арслан, күренекле шагыйрь, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Ул озак еллар «Казан утлары» журналында поэзия бүлеген җитәкләде. Бу айда аның тууына 110 ел.*



*Чорыбызның бөек шәхесләре – СССРның Социалистик Хезмәт Геройлары: әдип Мостай Кәрим (сулда) һәм композитор Нәҗип Җиһанов. 1986 ел.*



*Рафаэль Хәкимов – сәясәтче галим. Ул озак еллар (1991-2008) Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең киңәшчесе булып эшләде. Соңрак Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтын җитәкләде. Быел аңа 75 яшь тулды.*



*Шагыйрә, прозаик Асия Юнысова. Бу айда ул үзенең юбилеен билгеләп үтә. Котлыйбыз!*



*«Казан утлары» журналы хезмәткәрләре Рәдиф Гаташ, Альбина Әхмәтова, Асия Рәхимова, Лилия Гатауллина, Эльвира Камалова. 2002 ел.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# ОЛЫ ЮЛНЫҢ... УЗЫЛГАНЫ



Тормышта кеше һәрдаим, кайчак үзе дә аңламастан, ике юл чатында – сайлау алдында кала. Андый чакларда дөрес юнәлеш алу өчен үз тәҗрибәң, белемең, сизгерлегең белән беррәттән, читтән килгән киңәш тә бик ярдәм итә. «Юлга чыксаң, юлдашың үзеңнән яхшы булсын», ди бит халык. Гомеренең күп өлешен төзелеш тармагына багышлаган Илгиз Шакир улы Хәлимовның тормыш юлында да яхшы, киң күңелле кешеләр шактый.

Тумышы белән Чүпрәле районы Иске Чокалы авылыннан ул. Сугыштан имгәнеп кайткан әтисенә, колхоз эше белән йорт мәшәкатеннән бушамаган әнисенә булышу өчен 13 яше тулар-тулмас ул да кул арасына керә. Һөнәрләрнең төрлесен үзләштерә. Ындыр табагында йөк машиналарын бушата, элеваторга ашлык ташырга да туры килә аңа. Сигезенчедә укыган Илгизгә мәктәпнең комсомол оешмасын җитәкләү йөкләнә. «Кышкы бер көнне авылдан 85 чакрым ераклыкта урнашкан Буага район конференциясенә барырга туры килде. Пөхтә киенгән, төрле темаларга аралашкан шулкадәр кешене тәүге тапкыр шунда күрдем, алар кебек эшлекле буласы килү теләге уянды», – дип искә ала ул чакларны героебыз. Тик юл газабы гына гүр газабына әйләнә яза. Кире кайтканда утырган тракторлары ватылып, кышкы төндә җәяүлегә күчкән комсомол вәкилләре аздан гына юлда туңып калмыйлар. Мең бәла белән күрше авылга кайтып кунган сәяхәтчеләрнең иң яше – ундүрт яшьлек Илгиз иртәгәсе көнне дәресләрдән соң мәктәп җыелышында конференциядә катнашуы хакында хисап тота. Мишәр үҗәтлегенә кушып, алынган эшен җиренә җиткереп башкарырга кирәк дигән уй аның күңелендә шулай кечкенәдән тәрбияләнә.

Шул ук үҗәтлеге, тырышлыгы аңа, җил-яңгырга карамыйча, күрше Аксу авылына йөреп укуын дәвам итәргә булыша. Ә менә мәктәпне тәмамлаганнан соң егетнең югары белем алу теләге уяна. Монда да бәхетле очрак ярдәмгә килә. Хайван авыруы таралмасын дип, карантинга ябылган авыл капкасын армиядән кайткан күрше егете Вазыйх «ача»: икеләнеп йөргән Илгизгә үзе белән башкалага китәргә тәкъдим итә. Казанга илтә торган юллар җиңел генә булмый, әлбәттә. Әнисенең хәер-фатихасын алган егетләр төн уртасында җәяүләп Ульян ягына чыгып китә. «Туган авылымнан 40 чакрым ераклыкта урнашкан Нагаткино авылына барып җиткәндә, кояш шактый югары күтәрелгән иде инде», – дип искә төшерә Илгиз әфәнде. Бераз ял итеп алганнан соң, егетләр автобус белән Ульянга, аннан поездга утырып, Казанга юл ала.

Һәр кешенең үз язмышы, үз бәхете кулларында, диләр. Илгиз Шакир улы да нәкъ шул сүзләрне кабатлый. Язмышны Аллаһы Тәгалә язса да, кайсы юлны сайлау – кешенең үз эше. Башкала урамнарында хозурланып йөргән егетләр, үзләре дә сизмәстән, трамвай тукталышына килеп чыга, һәм бераздан аның ишекләре Казан инженер-төзелеш институты янында ачыла. Тик гариза тапшыру вакыты тәмамланган була инде. «Иртәгә беренче имтихан», – дип каршы ала аларны кабул итү комиссиясе әгъзалары. «Шактый киеренке сөйләшкән чакта яныбызга олы яшьтәге бер абзый туктап, ни булганын сорады. Укырга керер өчен 40 чакрым җәяү килдем, ә мине

кире боралар, дидем. Әллә жәлләде, әллә үҗәтлегемә исе китте, Аллаһының рәхмәте белән, хезмәттәшләренә иң аз гариза кергән автомобиль юллары факультетына документларымны кабул итәргә, шулай ук тулай торактан урын бирергә кушты».

Ә икенче көнне математикадан язма эшен «бишле»гә тапшырган Илгиз берничә көннән «Беренче курска кабул ителде» дигән язу белән авылга кайтып төшә. Шулай да чын студент булыр өчен паспортлы булырга, моның өчен өметле, эшчән яшьләрне колхозда калдырырга омтылган рәис белән шактый тарткалашырга туры килә. Бу мәсьәлә дә үзен аңлаучы, бер уйда булучы укытучысы ярдәме белән чишелә.

Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый, диләр. Авыл кешесе дә, кайда гына яшәвенә карамастан, эшсез тора алмый. Илгиз дә укудан бушаган арада спорт белән шөгыльләнә (тимераякта шуу буенча 3 нче разряд ала), каравылда тора, сөт ташучы булып эшли. Җәйге елларда, имтиханнарны иртәрәк тапшырып, авылга әнисенә булышырга ашыга, стройотрядта хезмәт итә. Әнисенә, аның янында калган энесе белән сеңлесенә ярдәм итә алганына Илгиз әфәнде үзе дә сөенә.

Кулына югары белемле белгеч дипломын алган Илгизне исә КамАЗ төзелешенә җибәрәләр. Чаллының гөрләп үскән чоры, эшләргә, үзеңне күрсәтергә менә дигән мөмкинлекләр бар. Шулай килеп чыга да: хезмәт юлын гади мастердан башлаган Илгиз Шакир улы Хәлимов ике завод, биш төзелеш идарәсен берләштергән трестның техник директоры дәрәҗәсенә ирешә. Кама Аланы атом станциясен төзүдә, Әрмәнстанның Ленинакан шәһәрен торгызуда катнаша. Һәр җирдә дә үз тирәсенә фикердәшләрен, уртак эш өчен көчен кызганмаучыларны туплый. Хезмәтенә күрә бөтенсоюз, федераль дәрәҗәдәге рәхмәт хатларына, мактау кәгазьләренә лаек була. «Бу юлны сайлаганыма бер дә үкенмим. Нинди генә авырлыклар килгәндә дә, янымда ныклы терәгем булган Алсуыма да рәхмәт», – ди ул.

Илгиз әфәнде үз тормышындагы юлларны төрлечә уза: җәяүләп тә, поезд, автобус белән дә, самолётка утырып та. Шулай да юллардан битәр, шунда очраткан кешеләрне якын күрә ул. «Алар йә гыйбрәт, йә үрнәк, йә яңалык. Рәхмәт әйтеп кабул итәргә кирәк», – ди героебыз. Шуңа күрә дә Казанга чакыру алган Илгиз Шакир улы икеләнеп тормый, Алсуы белән киңәшләшә дә башкалага кайтырга ният кыла. Башта Казначылык департаментында, соңрак «Главтатдортранс» оешмасында эшли. Аңа кадәр туплаган тәҗрибәсен яшьләр белән уртаклаша, кулланылышка кертелә торган объектларны кабул итүдә башлап йөрүчеләрдән була. Илгиз ага бүген дә хезмәттәшләре белән элемтәне өзми. Аның зирәк фикере, төпле киңәшләре гел кирәк.

– Шунысы сөенечле: коллектив ышанычлы кулларда. Директор Эдуард Юрьевич Данилов оешманың инде лаеклы ялда булган ветераннарын онытмый, һәрдаим кайгыртучанлык күрсәтеп яши, республикабыз юлларының төзеклеге сагында торган бүгенге белгечләрне дә яхшы эш шартлары белән тәэмин итә, хезмәтләренә хөрмәт күрсәтә.

Лаеклы ялга чыккач та тик утырмый ул: Алсу ханым белән бакчада мәш килә, кыз-улларына оныклар тәрбияләшергә булыша. Гомере буе туплаган китапханәсенә, 3-4 дистә ел элек дөнья күргән басмаларга карап исең китәр. Әле менә бишенчедә укыганда мавыккан иҗат өлкәсенә әйләнеп кайткан: кулына кабаттан каләм алган. «Яшьрәк чакта эштән бушаган чакта, уй-фикерләремне, күргәннәремне кәгазь битенә терткәли бара идем, хәзер шуларны барлыйм», – ди ул, елмаеп. «Тормыш юлы» («Дорога длиною в жизнь») автобиографик китабын бастырып чыгарган. Оныклары белән бергәләшеп, балачак хатирәләренә нигезләнеп язылган «Бүре хәтере» («Волчья память») җыентыгын басмага әзерләп яткан чаклары.

Улы Айрат әтисе һөнәрен сайлаган, кызы Земфира банкта эшли. Шул рәвешле, Хәлимовларның язмышына әйләнгән юл йомгагы үз җаена тәгәрәвен дәвам итә...

**Ландыш НӘСЫЙХОВА.**

*Кәрим Тинчуринның тууына – 135 ел*

# УЛ КАБЫЗГАН УТЛАР СҮНМӘС АЛАР...



Татар драматургиясенең классигы, күренекле артист һәм режиссёр Кәрим Гали улы Тинчуринның тууына 135 ел тулды. Республикабыз театрларында, сәнгать коллективларында шушы олы вакыйга уңаеннан зур чаралар үткәрелә. Татарстан радиосы да «Казан утлары» журналы белән берлектә әлеге эшкә кушылып китте.

Бөек драматургның иҗатына һәм тормыш юлына багышланган яңа тапшырулар белән беррәттән, фонд материаллары да хәрәкәткә китерелде. Алар арасында уникаль, хәтта тарихи дип бәяләрлек, театр фәне белән шөгыльләнүчеләр өчен бай чыганак булырлык язмалар саклана.

Күзәтүне музыкаль материалдан башлыйк. Фонд белән танышканда Кәрим Тинчурин спектакльләрендәге җырларга мөрәҗәгать итмәгән җырчы була алмый кебек тоела. Үз вакытында алар Галия Кайбицкая, Азат Аббасов, Фәхри Насретдинов, Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичев, Рәйсә Билалова, Әлфия Галимова, Хәнәви Шәйдуллин, Рафаэль Сәхәбиев, Наил Әюпов, Генрих Дәминов, Наҗия Теркулова кебек олпат җырчыларыбыз тарафыннан башкарылган. Татарстан дәүләт симфоник оркестры, Җыр һәм бию ансамбле, «Идел егетләре» эстрада-фольклор ансамбле тарафыннан спектакльләрне бизәгән инструменталь әсәрләр яздырылган. Бу җырлар әле бүген дә Клара Хәйретдинова, Мәсгут Имашев, Георгий Ибушев, Венера Ганиева, Илсур Сафин, Идрис Газиев, Зөлфия Зарипова, Вил Усманов, Гөлшат Имамиева, Резеда Галимова кебек җырчыларыбызның репертуарында.

Радиобыз фондында Кәрим Тинчурин спектакльләренең язмалары аерым бер киштә тәшкил итә. Г.Камал исемендәге ТДАТ артистлары башкаруында «Җилкәнсезләр» (1967), «Американ» (1971), «Сүнгән йолдызлар» (1974) спектакльләренең радио версияләре саклана. Биредә татар театры тарихын өйрәнүчеләр өчен аеруча кызыклы бер нәрсә бар: безнең фондта «Зәңгәр шәл» спектакленең ике вариантын – 1957 һәм 1976 елгы куелышларын тыңларга мөмкин.

Минзәлә татар дәүләт драма театрының «Ил» (1976), К.Тинчурин исемендәге ТДДһК театрының «Хәйләсез дөнья файдасыз» (1995) спектакльләренең дә архивта тузан җыеп ятканы юк, тыңлаучыларыбызның теләгең искә алып, эфирда әледән-әле яңгырап торалар.

Юбилей көннәрендә үз вакытында Азат Әхмәдуллин тарафыннан эшләнгән «Кәрим Тинчурин һәм татар театры» дигән тапшырудан да фрагментлар яңгырады.

Аеруча кадерле язмаларга килеп җиткәнбездер. Болар – замандашларының, иҗатташларының Кәрим Тинчуринга кагылышлы истәлекләре. Алар арасында Заһидә Тинчурина һәм Хәким Сәлимҗанов язмалары аерым бер игътибарга лаек. Гәрчә бу чыгышларда сүз башлыча татар халкының сөекле композиторы Салих Сәйдәшев турында барса да, аның янәшәсендә Кәрим Тинчурин шәхесе дә булуы сизелеп тора.

«Сәйдәш Тинчурин пьесалары буенча иҗат итте, – дип сөйли Заһидә Тинчурина. – Аларның үзара сөйләшүләре, киңәш итүләре булмый калмаган инде. Ләкин Тинчуринның күп вакыты театрда узганга күрә, ә Сәйдәш әсәрләрен искиткеч тиз язганга күрә, аларның бөтен фикер алышулары, әйтик инде, иҗади процесслары шул театр эчендә уза барган.

Сәйдәш тарафыннан язылган беренче музыкаль драма – «Зәңгәр шәл». Шул чакта Сәйдәшнең безгә кергәләгәне дә булды. Башта алар бик нығытып, озаклап кына

пьесаның эчтәлеген тикшерделәр, аерым урыннарына да тукталдылар, кешеләренә. Тинчурин хәтта мезансценаларны да телгә алды, булачак музыканың характеры турында да сүз барды. Ара-тирә Тинчурин аерым җырларны көйләп тә алгалады. Җырлый да, менә шулайрак булса иде, дип куя торган иде. Сәйдәш аны төзәтмәде дә, көлмәде дә. Әйтик менә, «Зәңгәр шәл»дә, урман пәрдәсендәге «Качкыннар җыры»нда, беренче пәрдәдәге Булат җырында, башка пьесаларда, мәсәлән, «Сүнгән йолдызлар»да үзе көйләп күрсәтеп, менә шулайрак булса иде, дип әйтеп куя иде. Сәйдәш дәшмәсә дә, ул музыка язганда, авторның теләкләрен, хисләрен читкә какмыйча, үзенчә, Сәйдәш моңына гына хас рәвештә, шул нигезгә – Тинчуринның теләгенә таянып, искиткеч матур әсәрләр яза торган иде.



*Заһидә һәм Кәрим Тинчуриннар.*

Тинчуринның Сәйдәш музыкаль пьесаларыннан бишенчесе «Кандыр буе» була. Колхоз турында музыкаль пьеса язарга дигән фикер туды. Болар икәүләп, велосипедларга утырып, Татарстан авылларын, колхозларын әйләнеп кайтырга булдылар. Анда алар колхозчылар белән очрашып, аларның эшләрен күреп, теләкләрен ишетеп, бөтен колхозның зур өметләре, киләчәк планнары белән танышып, шуларның барысын да өйрәнеп, үзләштереп «Кандыр буе» пьесасы барлыкка килде.

Пьесаны кабул итәләр, соңрак репетицияләргә дә керешәләр. Ләкин музыка юк әле. Премьера якынлаша, музыка һаман юк. Пошына башлыйлар. «Була, – ди Сәйдәш. – Языла, күп калмады», – дип тынычландыра. Ул арада матбугатта музыкаль спектакль әзерләнүе турында хәбәр тарала. Менә шунда инде Тинчурин нык борчыла башлый. Буламы, юкмы, дип, Сәйдәшкә катгый таләп куя. «Кәрим абый, язылып бетте ул, мин аны ноталар күчерә торган кешегә биргән идем, нишләптер китерми», – ди Сәйдәш. Икәүләп шул кешенең өенә баралар. Ә ул «Андый ноталарны күчерергә бирүче булмады», – ди. Икенчесенә, өченчесенә барып карыйлар – файдасыз. Шулай итеп композитор драматургны шәһәр буйлап йөртә.

Театр кешеләре, бер фикергә килеп, театрдагы рояль тора торган бүлмәдә Сәйдәшне калдыралар. Сәйдәш каршы килми, шунда кала. Бер тәүлек уза микән, артыгракмы, ләкин берзаман, бөтен кешене шаккатырып, әлеге бүлмәдән Сәйдәшнең яңа җырлары яңгырый.

Журнал укучылары игътибарына тәкъдим ителә торган аудиоязмада Заһидә Тинчуринаның нәкъ менә шушы чыгышы урын алган. Ә Татарстан радиосы эфирына килсәк, бөек драматургның юбилее уңаеннан әзерләнгән тапшырулар, аның пьесалары буенча куелган спектакльләрнең радио вариантлары, музыкаль драмаларындагы җырлардан төзелгән концертлар ай дәвамында яңгырап торачак. Тыңлаучыларыбызны дөнья күләмендәге рухи хәзинә дип исәпләнерлек әсәрләр белән яңа очрашулар көтә.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу – безнең сәхифә!

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ РИМАН

### Бишек җыры

«Үз-үземне әле телем ачылмаган чаклардан ук беләм», – дигәнгә дуслар ышанмый. Алар ышанмагач, мин дә икеләнә башлыйм, әмма булган хәл бит бу.

Әтием Солтан – укытучы, әнием Дания Субаш-Аты балалар йортында тәрбияче иде. Икесе дә көне буе эштә булгач, безне әби тәрбияләп үстерде. Кайчагында көйсезләнеп елаганымны хәтерлим. Ничә яшьләрдә булуым онытылган, әмма сөйләшә белми идем әле. Әби мәрхүмә мине юатып карый: «Ни булды икән соң бу балага, нәрсә кирәк икән соң моңа?» – дип сөйләнә. «Әни кирәк, кайда соң ул, ник кайтмый?» – дип, бик әйтәсе килә дә, ну, тел ачылмаган бит, әйтеп булмый.

Аның каравы мин бик иртә җырлый башлаганмын. Монысы да әбидән үк килмәде микән, дип шикләнәм. Чөнки бишек тирбәткәндә, гел җырлый иде ул. Бер куплеты истә дә калган:

– Деңнең деңнең деңе күп,
Деңнең байның кызы күп.
Борыннары шалкан күк,
Йомарлаган талкан күк.

Бу дүртьюллыкның мәгънәсен бүгенгә кадәр аңлап та бетермим. Хәер, анда әллә ни мәгънә салынмагандыр да. Колакны торгыза торган мәгънә салынган булса, Риман оныгы уйланып ятар да тиз генә йоклап китә алмас дип курыккандыр, бәлки. Мин әлеге җырның көен дә хәтерлим әле. Төннең кайсы вакытында уятып сорасагыз да, көйләп бирә алам. Ышанмыйсызмы? Алайса, тыңлагыз: «Деңнең, деңнең, деңе күп...» И, дәлше шулай дәвам итә.

### Суда, суда...

Бишектә чакта әллә ни җырланмагандыр инде. Әмма, биш яшем тулганда, әти Казаннан Саручи базарыннан (Сорочья ярмарка) тальян гармун алып кайткач, көннәр буе сыздыра идем. Иң беренче өйрәнгән җырым «Суда йөзәләсеңме» булды. Башта бер бармак белән уйнадым, аннан соң икенче, өченче бармакларны эшкә җигә башладым. Инде шактый шомаргач, әлеге үнәремне халыкка күрсәтәсе килә генә бит! Гармунны күтәреп, капка



төбенә чыга башладым. Ул чакта авылда эскәмиясез капка төбе юк иде һәм эскәмия күрше-тирәнең бөтен хатыннары сыярлык озын була торган иде. Күпме кыз-кыркынны, күпме яшь киленнәрне җырлатканымны инде хәтерләмим. Кайчак авыл егетләре дә безнең капка төбен үз иткәлиләр иде. Шушы бер көйгә күпме вакыт, күпме кеше җырлагандыр, әйтүе кыен. Кайчак: «Бу җырың нәрсә турында соң?» – дип тә сорыйлар иде. Андыйларга бераз үпкәләгән чаклар да булмады түгел, шул яшьләренә җитеп, суда йөзү турында җырлаганымны да аңламыйлар бит! Юк инде, юк... Мин бүген дә җырлыйм, җырлыйм дип түгел, күңелдән үзеннән-үзе чыга. Җырлаган тавышымнан эшкә килгәнне беләләр. Кайберәүләр: «Маладис», – ди. Кайберәүләр: «Акырып йөрмә!» – ди.

Ә беркөнне... Беркөнне редакциягә штаттан тыш авторыбызның берсе килгән. Фойеда безнең Габделбәр Ризванов белән нидер гәпләшеп утыра болар. Һәрвакыттагыча: «Суда, суда...»ны җырлап, яннарыннан узып киттем дә бүлмәмә юнәлдем. Бераздан ишектән Габделбәрнең башы күренде: «Карале, теге автор синнән зарланды бит!» – ди.

– Ни өчен?

– Монда инде ничә мәртәбә киләм, бу абзый гел исереп җырлап йөри, нигә тотасыз сез аны? – дип әйтә.

Габделбәр – шук егет, булган хәлгә үзеннән өстәп, әллә ниләр сөйләргә ярата. «Борчылма, теге авторны тынычландырдым мин. Риман – әйбәт егет ул. Бераз сәеррәк, кәнишне, ну буйный түгел ул. Ә гомумән алганда, журналистлар арасында нормаль кеше сирәк», – дидем, дип көлеп җибәрде. Һәм ни сәбәп, икебезгә дә рәхәт иде.

### Намыслы караклар

Очучы булырга хыялланмаган малай-шалай юктыр ул. Булса да бик аздыр. Самолётта очулар төшләргә кереп йөдәтә иде. Ә инде Гагарин галәмгә очкач, безгә – 13 яшьлек малайларга зәңгәр күк тә тәбәнәк тоела башлады. Космонавтларны кайда әзерләгәннәрен белми идек. Авылның башлырак егетләре космонавт булу өчен иң элек лётчик булырга кирәклеге турында аңлаттылар. Кайбер ачы теллесе: «Хәзер лётчиклыкка да алмыйлар, бөтен кеше лётчик булса, илдә самолёт җитмәячәк икән. Мәскәү радиосыннан үзем тыңладым», – дип, күңелне төшерергә тырышты. Алай гына төшерерсең, бар!

Бер елны Кишет басуына яман биек каланча куйдылар. Без, булачак очучылар, сәпитләргә утырып, шунда киттек. 10 чакрым чамасы араны «әх!» дигәнче үттек. Бүрәнәләр ялгап-ялгап эшләнгән каланчаның иң өстендә кечкенә генә мәйданчык бар. Әй, шунда басып, тирә-якны күзәтәсе килә бит! Берничәбез каланчаның яртысын менгәч, кире төште. Баскычлары да бик ышанычлы түгел, аннан соң бик чайкала икән, диделәр. Баш әйләнәме, юкмы икәнен белү өчен шул кирәк тә бит инде, әллә самолёт чайкалмыймы? Иң йөрәклеләребез тәки менде каланча башына, «йөрәклеләр» арасында мин дә бар идем.

Галәмәт зур каланчаның ни-нәрсә өчен куелуын төгәл әйтмәделәр. Берәүләр җир өслеге картасын эшләү өчен, диде. Чөнки бөтен тирә-як колхоз басулары матур-матур шакмаклар кебек әллә каян күренеп тора иде. Икенчеләр, бу – янгын каланчасы, диделәр. Монысы да дөреслеккә туры килә кебек, чөнки каланча башыннан 10-15 чакрымдагы авылларны күреп була иде. Безнең өчен исә каланча тренажёрга әйләнде. Көн саен барып, биеклектә кемнең башы әйләнү-әйләнмәвен тикшердек. Авыл малайларының шактые «комиссия» узгач, каланчаның биеклеген тикшерергә булдык, әмма мондый озын бау каян аласың? Берничә малай җыелып сөйләштек тә, үзләренә әйтмичә генә әниләрнең кер элә торган бауларын алырга булдык, ярты көн эчендә генә кер юмаслар әле, янәсе. Тик ялгышканбыз, Фердинантларда, Тәбрисләрдә, бездә, Ленарларда кер юганнар. Ә киптерергә эләргә бау юк. Ярый әле әнинең запас бавы булган, керләрне элгән. Әмма күршеләр: «Авылда кер бауларын урлый башлаганнар!» – дип, кара тавыш чыгарганнар.

Без каланчаның биеклеге 45 метр ярым икәнен ачыклап, шаулашып-гөрләшеп кайтып килгәндә, әниләр капка төбендә утыралар иде. Кыска гына мондыйрак сөйләшү булды:

– Кайда йөрдегез?

– Кишет каланчасына барган идек.

– Анда нишләдегез?

– Биеклеген үлчәдек.

– Ничә метр инде?

– Кырык алты... Юк, кырык биш ярым. Әни тәрбияче бит инде: «Ярый, бауларыгызны башка кешенеке белән бутамыйча гына үз урыннарына бәйләгез. Бүтән сорамыйча алмагыз, яме!» – диде. Бернинди тавыш-гауга купмады.

Моннан соң кая кеше әйберенә кагылу, сорамыйча алу, әни җаным! Шушы сүзең безнең өчен зур тәрбия булды. Ә авылда: «Намыслы (бездә өлкәннәр «намуслы» дигән сүзне шулай әйтәләр иде) караклар туры килгән, бауларны кире кайтарганнар», – дигән сүзләр таралды. Бу сүзләрне безнең өстән гаепне төшерү өчен әниләребез таратмады микән, дим әле мин.

**Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

## Чәйнең төрлесе була

Әдипләр талымы төрлечә. Берәүләр иҗат иткән чакта каһвә уртлап куя, кемдер тәнәфес вакытында чәй эчеп алырга ярата. Ә менә шагыйрь Сибгат Хәким сөтле чәйгә өстенлек бирә иде. Сөтле чәй... Ошбу сүз тезмәсен ул бер шигыренә дә кертә.

*Аерма мине*
*Туган илемнән,*
*Кара икмәгем,*
*Сөтле чәемнән...*

«Әй, язмыш, язмыш» исемле әлеге әсәрне композитор Сара Садыйкова матбугаттан күреп ала. Көннәрнең берендә ул Сибгат агага телефоннан шалтырата, яңа җыр язуы турында кыскача гына сүз әйтеп, яшелле-зәңгәрле тавышы белән аны көйләп тә күрсәтә. Гаять моңлы яңгыраш шагыйрьне әсир итә. Уртак казанышка ихлас куанган аксакал, үзенчә ләззәткә бирелеп, берничә чынаяк сөтле чәй эчә. Аннары дачага җыена.

Аккош күле янындагы иҗат йортына килеп җиткәч, Сибгат Хәким янә тансык чәен чөмерә башлый. Аңа теге җыры һаман тынгы бирми. Көне дә бик эссе. «Син инде агып китәсең бугай, – дип шаярта Мөршидә ханым, ире бушаткан чокырларны санап. – Бераз күл һавасын сулап кайт».

Үзәк аллея буйлап салмак кына барган мәлдә шагыйрь каршына каләмдәше Абдулла Әхмәт килеп чыга. «Туксан тугыз үләннән чәй әзерләдем, – ди ул, кул сузып. – Бергә-бергә шул сыемнан авыз итик!» Сибгат Таҗиевич пошаманга кала. Берәр уңайлы сәбәп уйлап табарга кирәк. Әле моңарчы эчкән чәе дә тын алу юлын томалап тора. Үңәче туп-тулы. Аптырагач, тере классик үләннәрнең исемен җентекләп сорашырга ният кыла. Шуны гына көткән әдип бер-бер артлы тезеп китә: «Бөтнек, мәтрүшкә, күкебаш, андыз, нәркиз, сәрдә, сарут, нәүрүз...» Яудаш дусты, туктарга кушкандай, ым кага. Әмма тегесе һәмишә саный. Тәмләткеч үләннәр исемлегенә тузганак, меңьяфрак, аксыргак, кипрәй, рәйхан, мелисса, шалфей, кычыткан, ярабай кебек үсемлекләр өстәлә. Чамасын белеп кулланысаң, янәсе, болары да бик файдалы.

Сөйләшү барышында ботаника белгеченә охшап калган Абдулла Әхмәт чәйгә өстәлгән тәмләткечләр хисабын тәки туксан тугызга җиткерә. Сибгат Хәким исә тәмам тәкатьтән яза. «Миңа кирәкле йөзенче үлән синең чәеңә салынмаган икән». Шушындый нәтиҗә чыгарган шагыйрь, кыстаудан котылуына сөенеп, Кече тирән күлгә юнәлә. Авыз эченнән генә яңа җыруын шыңшый: «Аерма мине... Сөтле чәемнән...»

## Батулла алымы

Рус телендә иҗат итүче танылган язучы Әхәт Мушинский «ТАТМЕДИА» бинасындагы «Әдәби кафе»да яңа китабын тәкъдим кылды. «Запах анисовых яблок»... Шулай аталган саллы мәҗмуга уңаеннан авторның талантына тулаем бәя бирелде.

Сөйләшү ахырында сүз алган Рабит Батулла үзенең чыгышында тел-өслүп мәсьәләсенә игътибар юнәлтте. Стиль серләрен өйрәнүче галимгә охшап киткән әдип Рөстәм Кутуй әсәрләрен тиз-тиз шәрехләп узды, аның «өлкән брат» теле нечкәлекләрен ошбу кавем вәкилләреннән дә әйбәтрәк белүе хакында искәртеп үтте. Аннары күренекле рус шагыйре булып исәпләнгән Михаил Львовны, ягъни үзебезнең милләт углы Рәфкать Габитовны искә төшерде. «Аларның телбизәкләргә гаять бай югары слогына сокланып туймаслык, – дип белдерде ул. – Лирика осталарының язганнарыннан әнис алмасының исе килгәндәй тоела...»

– Сезнең дә русча язылган әсәрләрегез бар лабаса, – диде тамашачы арасыннан берәү. – Пушкин теленең хикмәтләрен шактый тирәнтен аңлыйсыз бугай.

Җәһәт әңгәмә башланып китте. Рабит Батулла күпчелек сорауларга уены-чыны белән җавап бирде.

– Русчага яхшырак өйрәнү өчен берчак марҗага өйләнеп яшәдем, – диде каләм остасы, яшьлеген искә төшереп.

– Безнең Габдулла Тукай да немец теле буенча дәресләргә йөргән, әмма аңарда фрау Мария Карловага өйләнү теләге тумаган бит.

– Шунлыктан әлеге телне юньләп үзләштерә алмаган.

– Шагыйрь Шәрәф Мөдәррис рус, чуваш, немец, француз, инглиз телләрен белгән, шушы телләрдә язган байтак әдипләрнең әсәрләрен турыдан-туры татарчага тәрҗемә иткән. Вәләкин ул рус, чуваш, немец, француз, инглиз кызлары белән гаилә кормаган. Насыйп никахына тугрылыклы калган.

– Һәммә өйләнү дә – бик чыгымлы гамәл. Башлы-күзле булу иллә мәшәкатьле. Фаразлап карагыз: фани дөньяда нибары кырык өч ел яшәгән адәм заты, тел үзләштерәм дип, ничек инде бер-бер артлы алты милләт кызын хатынлыкка алсын?! Тасылын белсәң, ташны кисәрсең. Куелган максатына үҗәтләрчә омтылган Шәрәф абзый берничә телне хәләл җефете Ләбибә Ихсанова канаты астында үзлегеннән өйрәнә.

– Рус телен тагы да мөкәммәлрәк дәрәҗәдә белү өчен янә берәр марҗа белән яшәп карарга уйламадыгызмы соң?

– Чамадан чыкмау хәерле. Ярый әле, ашкын җанымны кисәтеп куйдым: әгәренки син шушы юлдан барсаң, рус телле язучыга әйләнеп китәчәксең. Мондый очракта инде шәхсән үземә тапшырылган сәмави йөкләмәмне – Коръән тәфсиренең татарча басмаларын да әзерли алмас идем...

Блиц-әңгәмә тәмамланды. Хәзер башка телләрне өйрәнгәндә, әйе, төрле-төрле ысулларны кулланырга мөмкин. Әмма татар баласының хәтеренә сеңдерәсе килә: иҗтиһат сорый торган әлеге җаваплы эштә Рабит Батулла үрнәген кабатлау киңәш ителми.

## Миңеште

Сәфәргә чыккан каләм әһелләре, тәгаен тема билгеләп, экспромт бәйгеләре үткәрергә ярата. Башкортстанның Дүртөйле районыннан кайтканда да бу кызыклы традициягә тугрылык күрсәтелде. Әүвәл язучылар әлеге төбәктә Уфадан килгән коллегалары белән очрашты, аннары күренекле шагыйрь Нажар Нәҗминең каберенә чәчәк бәйләме китерде, соңыннан аның туган авылы Миңештедә урнашкан музей-йортында кунак булды.

– Миңеште атамасында нindидер серлелек бар, – диде Рәдиф Гаташ, кайтыр юлга чыккач. – Ул күңелне кытыклап торгандай тоела.

Мондый әйтешүне күпләп оештырган шагыйрь кыска вакытлы ярыш игълан итте: дүртьюллыкта авылның исеме рифмалашсын...

– Һи, аңар аваздаш сүзне ничек табасың инде?!

Рәдиф Кәшфуллович, каләмдәшләрен тынычландырып, үзенекен сөрде:

– Киресенчә, ошбу үзенчәлекле кәлимә фикер очкыннары чәчә, хәтта югары категорияләр хакында уйлауга этәрә. Әйдәгез, рифмоплётлар, җиңебезне сызганыйк!

Күпмедер вакыт үткәч, йомгак ясау башланды. Һәркем үзенең дүртьюллыгын чиратлашып укырга тиеш. Бәйге кызды. «Афәрин» сүзе кат-кат әйтелде. Чират Зиннур Мансуровның экспромтына килеп җитте. Аз-маз гына йокымсырап утырган шагыйрь, кисәк аягына басып, мәктәп баласыдай чәтер-чәтер сөйләп китте: «Миңеште» исемле операдан Яшь шагыйрә ариясе!»

– Әйттем бит, Миңеште безнең күңелдә югары хисләр уята, – дип гөрелдәде Рәдиф Гаташ үтә ихлас канәгатьләнү белән.

Зурдан кубып белдерелгән ария сүзләрен, ниһаять, автор анык рәвештә ярып салды:

*Кунакларны мунча ягып*
*Каршы алды Миңеште.*
*Берәү чапкач, гаурәтемне*
*Бизәп торган миң пеште...*

Яшь шагыйрә ариясенең эчтәлеген ишеткәч, автобуста көлешү дулкыннары йөгереп узды. Көчәя барган тавыш егәрлеге, ихтимал, югарыгы децибел бүлеменә җиткәндер. Менә сиңа рифма, менә сиңа ярыш!.. Шаркылдаудан тәрәзәләр зыңгылдады. Героиняның арттарак утырган прототибы, кашларын җыерып, сәфәрдәшләре халәтенә керергә азапланды. Аның каршылыклы хисләрне чагылдырган йөзе серле Мона Лизаны хәтерләтә иде.

## Ахирәтләр сөйләшүе

Ишәй белән Кушай дисәм, күренекле әдәбият-сәнгать әһелләре Разил Вәлиев һәм Рафаэль Сәхәбиев күз алдында гәүдәләнә. Аларны әле якташлык та берләштерә – авыллары бер-берсенә терәлеп үк урнашкан. Аерылмас мөнәсәбәттә яшәүче дуслар арасыннан бервакытта да кара мәче узмагандыр.

Җәйге көннәрнең берендә Рафаэль Разилгә шалтыратып алмакчы була. «Син кайда әле?» Уңайлы кесә телефоннары заманында, гадәттә, сөйләшүләр шушындый сораудан башлана.

– Лапаста йөрим, – дип җаваплый тегесе, төп-төгәл мәгълүмат биреп. Тавышы беркадәр сүлпәнрәк – ерактан килгәндәй тоела.

Әһә, беренче нотадан ук бар картина ачыла: аның якын кордашы авылга китеп барган. Җырчы шулай гөман кыла. Нигәдер Рафаэльгә белгертмәгән. Бусы аңлашылып бетми.

– Нәрсәңне югалттың лапаста?

Яхшы дикция югарылыгында яңгыраган ошбу сөальгә шагыйрь басынкы тамагын киеребрәк җавап бирә:

– Мин тик кенә йөрмим бит инде. Эшләрем бугазга терәлгән. Әллә йомышың бармы? Кыскарак тот сүзеңне!..

– Бар иде шул, – дип дәвам итә Рафаэль, гаебен таныган бала кук. – Йөк автомобиле табарга булышлык күрсәтсәңче син!

«Авыл качкыны» төпченә башлый:

– Нәрсә, хатыныңны тагын аердыңмы? Мал-мөлкәтең «КамАЗ»га сыярлыкмы?

– Юк ла, аерылышмадык. Кичә антиквар рояль юнәттем, кичекмәстән алып кайтырга кирәк...

– Лапаста йөрим – ничек булышыйм?

Янәдән «лапас» кәлимәсен ишетү Доцентны тәмам ярсытып җибәрә. (Театр

солисты Рафаэль Сәхәбиев Казан дәүләт консерваториясендә дәресләр биргәләде; дус-ишләре аңа кайвакыт «Доцент» тәхәллүсе белән дә эндәшәләр иде). Шулчак сөйләшү ирексездән монологка әверелеп китә: «Чык инде шул лапасыңнан, яшәешнең ямен күбрәк күр, кызыктырган илгә барып кайт. Байтак татар әдибе Европаны да сугыш вакытында гына иңли алды. Кояшны да күрмичә, интекмә түбә астында...»

Шушы урында элемтә өзелә. Бераз гына кызып китүен Рафаэль үзе дә аңлый. Юкса Разил Вәлиевнең чит илләргә йөрү буенча язучылар арасында рекордчы булуын, гомумән, аның яшьтән үк төрле сәфәрләргә бик теләп чыгуын ул яхшы белә. Төрттереп кенә әйтүе. Әмма Рафаэль Сәхәбиев шунысын аңышмыйча кала: кесә телефоны аша йөк машинасы табуга бәйле гозерен җиткергән чакта Разил Исмәгыйлевич Көньяк Америкадагы Боливия Республикасы башкаласы Ла-Паста йөри иде.

## Мунча исеме

Адәм баласының шәхси исеме искиткеч зур әһәмияткә ия. Үсеш чорында ул кешегә шулкадәр йогынты ясый, аның нәтиҗәләреннән инде беркем дә арына алмый. Кушылган атның холык-фигыль белән бәйләнешен тулысынча аңлату мөмкин дә түгелдер. Халкыбыз тикмәгә генә шулай кистереп әйтмәгән: яхшы исем малдан артык.

Сабыйларга исем бирүдә төрле хәлләр күзәтелә. Әйтик, язучы булып танылган Ркаил Зәйдулла да бу җәһәттән элгәрләр йоласы кысасына кертелгән. Дөньяга тәүге тапкыр варисларча аваз салгачтын, акушер ханым бала атасына киңәшен җиткерә: «Күз генә тимәсен, улыгыз томрап тора. Нарасыйны өйгә алып кайткач, мунча исеме кушып юындырыгыз. Нәфесен сузучы бичура ише зат аны үз баласына алмаштырып куймасын. Барча мут җен-пәрине куркытырдай ат кирәк. Биш-алты ай үткәч, башка нам табарсыз...»

Мондый ырым-шырымга ышанмаган Рафаил абзый кулын гына селти, әмма аның күңелендә барыбер борчылдыргыч шик-шом утырып кала. «Кат-кат исем кушмыйлар инде, – дип уйлана ул. – Һәммә очракка ярашлысы хаҗәт». Колачлы рәвештә фикер йөртүче мөгаллим үзенчә нәтиҗәгә килә, әлбәттә, соңгы карарын кабул иткәндә беркадәр арттырып та җибәрә: малайга Ркаил исемен бирергә! Һәртөрле җен-пәриләр гаскәренә каршы торырлык, аларның котын алырлык атама булачак, янәсе. Шифрын ачып әйтсәк, РКАИЛ «Рабоче-крестьянская армия имени Ленина» дигәнне аңлата.

Шулай беренче юындыруда кушылган мунча исеме Ркаил Зәйдуллинга гомер буенача тагылып кала. Ошбу сәер атны йөртүче чырыс малайдан мифик затлар гына түгел, кайчак авыл урамында бергәләп тырай типкән яшьтәшләре дә шүрләп куя. Аның бәгъзе гамәлләре дә бик шаккатмалы килеп чыга: йә ул менү-җигүгә бөтенләй өйрәтелмәгән асау айгырга атланып җилдертә, яисә Актырнак кушаматлы көчеген кызу мунчада себерке белән чаба. Оланкай үзенчә кыланып, бүре токымының усаллануын тели. «Ркаил исеме аклана бит», – дип, ихластан сөенә этисе.

Казан университетына белем алырга килгән яшьләр арасында да бу үзенчәлекле исем күпләрнең колагын әледән-әле торгызгалап тора. Бунтарь холыклы егетнең кыю-кыю шигырьләре әдәбият аксакалларын да сискәндереп куя. Шулай әсәрләнү аларга тансык. Ркаил өлкәннәргә якынаеп китә. Берчак Сибгат Хәким аңа тәкъдим кыла. «Ташла әле шул мунча атамасын, – ди ул. – Натураңа ятыш шәп исем кушыйк». Яшь шагыйрь әлеге кәттә кушаматны түземсезлек белән җәһәт ишетергә тели. Вәләкин остазы сабырлык күрсәтә. Үзенчә озаграк тукталыш ясаганнан соң ул тәкатьсез студентка иҗекләп пышылдый: «Рка-ци-те-ли...» Сибгат ага кайбер мәҗлесләрдә чынлап кыстасалар, шушындый грузин шәрабен якын күрә иде. «Монысы да мунча

исеменнән ерак китмәгән ич», – дип күрсенгәндәй итә көләргә азапланган Ркаил Зәйдулла. Ркацители, имеш.

Шушы җәһәттән дус-ишләрнең төрлечә оскытуы тора-бара ниндидер «комплекс»ка әйләнеп китә. Ркаил үз-үзен яклау әмәлен, аклану юлларын эзли башлый. Әнә, миллилек үрнәге булырлык Актаныш тумаларының байтагы сәп-сәер мунча исемнәре белән яши ләбаса. Азнакайда да күп андыйлар... Эченнән генә сабыйларча үртәлеп йөри биргән шагыйрь, берчак җаен табып, XIX гасырда ук чыккан иске китап күрсәтте. Анда ап-ачык итеп шулай язылган иде: «Аркаил – күкнең икенче катындагы фәрештәләр башлыгы». Монысына инде һичкем ышанмады – фәрештәләр кайда да, габед Ркаил кайда...

Шактый сәер яңгыраган ошбу исемгә мәдәни кавем акрынлап ияләште инде. Пәри кызларын бот чабарга мәҗбүр иткән намне йөртүче әдипнең төрле шәкелдәге әсәрләре газиз халкы тарафыннан тәэсирләнеп укыла, шайтаннар өерен шыр җибәрергә ирексезләгән шәхси атаманы танытучы җәмәгать эшлеклесенең катгый мәкалә-чыгышлары милләт хакын һәрьяклап дауларга булыша. Кыскасы, каләм рыцаре Ркаил Зәйдулла үзенең атын тулаем аклый. Шулай барса, әдәбият тарихына аның «Ф.И.О.»сы да, иншалла, зур хәрефләр белән язып куелачак.

Менә сиңа мунча иseме!..

## Төртмешләр

• Безнең баш миебез тулы куәтенә эшләсә, бәлки, ахмаклыклар тагын да күбрәк кылыныр иде.

• Монафикъ сәясәтчеләрнең «Сөекле халкым!» дип лаф оруы яңгыраулы зал мөнбәреннән «...электоратым!» кебегрәк ишетелә.

• Иртән оекбашының уңын сул аякка бутап кигәнгә күрә, бездә дәүләт ирләренең еш кына очракта эше уңмый.

• Бер тамчы никотиннан үлүче атларны саклап калырга омтылу татар баласының фидаиларча тәмәке тарта башлавын аклый алмый.

• Бездә ишек күбрәк ясалган саен, керер тишек табу кыенлаша бара.

• Без еш кына юкә майлау белән шөгыльләнәбез, шул рәвешле һәйбәт каеш ясаган булып кыланабыз.

• Хәшәрәт микробларны да эчәргә өйрәтсәк, спиртның тыйб эшендә кирәге калмас.

• Безнең динебез адәм балаларын чисталык-пакьлеккә өнди, әмма «акча юучылар»ны тәмуг белән кисәтә.

• Бездә чистартуга бәйле күпчелек гамәлләр пычракны тигезләп таратуга кайтып кала.

• Инсаннар катнашында үткәрелә торган реформаларга караганда тычканнар белән уздырылган тәҗрибәләр уңышлырак төгәлләнә.

**Зиннур МАНСУРОВ**

## ШАГЫЙРЬ

### ЮМОРИСТИК ХИКӘЯЛӘР

Кичен подъездга чүп түгәргә чыккач, каршыма дәфтәр тоткан күршем килеп басты: «Көлмисеңме, мәхәббәт турында шигырь яздым, – дип, ул күзләрен идәнгә текәде. – Подъездда синнән башка татарча юньләп белүче кеше юк. Тыңлап карыйсыңмы, ничегрәк икән? Хатыныма укып чыккач, бот чабып көлде генә, ул шигърияттә берни аңламый. Мәктәптә укыганда да, исемдә калмый дип, укытучы кушканны да ятламыйча котылган», – дип, минем җиңемә ябышты. Лифт ишеге каршында күршемне зур игътибар белән тыңлап тордым. Химия фәнен укытсам да: «Шәп язылган, колакка ятышлы, бер сулышта укып чыктың», – дип, аны канатландырып җибәрдем.

Иртән торуга бу шигырь көне буе колагымда яңгырап йөрде. Бу таныш юлларны кайдадыр ишеткән дә кебек, ләкин күпме тырышсам да, хәтеремә төшерә алмадым. Дәресләр арасында вакыт табып, китапханәдә шагыйрьләребезнең җыентыкларын караштырып чыктым. И-и, менә бит ул таныш китапчык, аны үземнең дә ничә тапкыр укып чыкканым булды. Кайсыдыр битендә күршемнең өч куплетлы шигыре акка кара белән ярылып ятканы күзгә чалынды.

Кич белән кабат чүп түккәндә, әлеге җыентыкны кыстырып чыктым. Аны күрсәтүгә күршем: «Бу шагыйрьнең кай арада мине уздырырга өлгергәнен сизми дә калганмын, болай булгач миңа гонорар тәтемәячәк. Нишлим, күрше, аның белән судлашып йөреп булмас бит, эх, нинди шәп шигырем әрәм китте» – дип, ул көрсенеп куйды. «Юк, сиңа гонорар булмаячак, судка да бирә алмыйсың, чөнки бу узган гасырда иҗат иткән күренекле шагыйрь, күптән түгел мәктәпләрдә аның олы юбилеен билгеләп үттеләр», – дидем. Күршенең кәефе кырылды.

Икенче көнне лифт төбендә ул тагын очрады. «Менә, тыңла әле, табигать турында өр-яңа шигырьләр, иманым камил, боларны миңа хәтле язган кеше юк, төне буе керфек какмыйча утырдым», – дип, ул кулындагы дәфтәрен ачып җибәрде. Сабырлыгым бер куплеттан да артык тыңларга җитмәде. «Син сөйләгән юлларны мин мәктәп елларыннан ук яттан беләм», – дип, аны туктатып калдым. «Хәзер бөтенесе яза башлады, чынлап торып иҗат итәргә ирек бирмиләр. Гонорар өчен түгел, күңелемә җыелганны башкаларга да җиткерәсем килә», – дип, күршем ни өчен тынычлана алмавын аңлатырга тырышты.

Хәзер кичләрен чүп түгәргә чыкмый башладым. Артык хисле күршемнең берәр танылган шагыйребезнең озын поэмасын укып чыканын тыңлап торасым килми әле. Безнең гаиләдә чүп түгү хәзер хәләл җефетемә йөкләнде Аңа теге мәхлук үзенең шигырьләрен укыр дип, һич кенә дә борчылмыйм. Хатыным белеме буенча бухгалтер, поэзиягә бөтенләй битараф карый, аңа күпме укысаң да, барыбер. Хәләлем саннар дөньясында гизә, аңа шуннан да кадерлерәк нәрсә юк!

Тик беркөнне сөеклем чүп түгәргә чыккан җиреннән күршемнең дәфтәрен тотып керде. «Янибызда гына нинди зур шагыйрь яшәгәнен белми йөргәнбез», – дип, ул дәфтәрне ачып җибәрде һәм миңа таныш шигырьләр укый башлады. Әй укый бу, әй укый, һич кенә дә туктатып булмый! Шул көннән алып, кичләрен ул: «Шигырь язарга булышам», – дип, күршемдә югала башлады. Белмим, нәрсә язалардыр, әлегә укып күрсәткәннәре юк! Шигъри юлларның аерым көчкә ия булганын ишетеп белә идем, нишлисең, хәзер моны үз җилкәмдә татырга туры килде. Шулай итеп, безнең фатирда

ашарга пешерү, өй җыештыру кебек эшләр бөтенләй онытылды. Көннәрдән беркөнне хәләлем: «Күрше белән төнлә шундый шәп шигырьләр яздык, мавыгып китеп, синең янына йокларга чыгарга вакыт әрәм итеп тормадым», – дип белдерсә, нишләрсең?! Менә ничек үзгәртә поэзия кешене! Шигырь язу уен эш түгел, аны һәркем булдыра алмый...

## КОМАНДИРОВКА

Көннәр буе компьютерга березеп утырган бухгалтер ярдәмчесе Сәлмәнияне югарыдан җәй уртасында салкын якларга командировкага җибәрергә дигән фәрман килде. Һәрхәлдә кич эштән кайтуга бу яңалыкны ул иренә шулай дип ирештерде. «Бармаска теш-тырнагым белән каршы килдем, колак салмадылар, алай озакка иремне калдырып китә алмыйм дигәч, сайла, йә командировкага, йә премиясез каласың, диделәр. Шулай дип бугазыңа баскач, тыңламый кая барасың? Ичмасам андый чакта безнең хатыннарны ирләре килеп яклый», – дип, Сәлмәния балавыз сыга башлауга, Мәгъсумҗанның ачуыннан: «Кая барыйм, кемгә нәрсә әйтим», – дип, йодрыклары төйнәлә башлады. Иренең үзен шулай үлеп яратуын күреп торган хатынның күңеле нечкәреп китте, күзләренә чынлап торып яшьләр килде.

Икенче көнне сөеклесенең: «Хатыным еракта булганда, берүзем генә кала алмыйм, мине дә салкын якларга командировкага җибәрегез дип сорадым», – дигән сүзләрен ишетүгә, Сәлмәниянең дә эченә җылы йөгерде. Аэропортта алар бик авырдан аерылыштылар. Икесе ике самолетта очсалар да, юнәлешләре берүк булды.

Җылы диңгез буенда беренче өч көн бик тиз узып китте. Көндезләрен Мәгъсумҗан пляжда кояш астында назланды, кичләрен адым саен очрап торган кафе-барларда тамак чылатып, күңел ачып йөрде. Сәфәренең соңгы көнендә ул пляжда үзе белән рәттән кызынып яткан яшь кенә хатынны кафега чакырды. Бераз кызып алгач, алар дөньяларын онытып биеделәр, ир тора-бара янында бөтерелгән чибәркәйнең биленнән тоткаларга да тарсынмый башлады. Хәлләре бетеп, кире урыннарына утыргач, ул сулыш алып, хәл җыям, дигән сылтау белән як-ягына каранып куйды. Бу минутта аның күзенә ике өстәл аша гына таныш гәүдә чалынды, дулкынланудан Мәгъсумҗанның йөрәге лепелдәп тибә башлады. Кит, сөйләсәң кеше ышанмас, бер атнага салкын якларга командировкага киткән Сәлмәниясе аның белән рәттән генә утырган булып чыкты бит! Әйе шул, өстендәге күлмәге дә таныш, муенындагы алтын чылбырны Мәгъсумҗан кайчандыр аның туган көненә үзе бүләк итте. Тик менә тамаша, ни эшләп йөри ул монда? Нәкъ шул чакны Сәлмәния ялт итеп алар ягына борылды һәм ире янында утыручы хатынга эреләнеп кенә карап куйды. Бу минутта Мәгъсумҗан сикереп торып, тавыш куптару теләге белән янды. Әмма хәләле янында таныш булмаган таза гәүдәле ирне күреп алуга ул тыелып калды һәм берни булмагандай кафедан чыгып китте. Кеше арасында тавышлану килешми, өйгә кайткач та аңлашырга була дип, ул үзен-үзе тынычландыргандай итте. Шулчакны Мәгъсумҗан үзенең дә суык якта командировкада чутлануын исенә төшерде. Ничек акланырга тиешле сүзләрне каян табарга?! Бу минутта аның башында мең төрле уй чуалды. Баштагы план буенча авылга кайтып, мунчалык утын әзерләгән булса, бүген мондый кыен хәлдә калмаган булыр иде. Ир шунда ук нинди зур ялгышлык кылганын аңлады һәм аэропортка йөгерде.

Өенең бусагасын атлап керүгә аның борыны фатирга таралган яңа пешкән мантый исен сизеп алды. Мәгъсумҗан да буш кул белән кайтмады, кулындагы купшы чәчәк бәйләмен Сәлмәниянең кулына тоттырды. «Бик ялынгач, командировкадан бер көнгә алдан җибәрделәр», – диде ул, хатынының күзләренә карамаска тырышып. «Әйе, иремне бик сагындым диюгә үземне дә тотмадылар», – дип, тегесе дә карашын тизрәк плитәгә текәде.

Җәнҗал чыкмаганга ике як та җиңелчә сулап куйды. Менә бит кешечә аңлаша белгәндә, уртак тел табуы әллә ни авыр түгел икән. Монда гаҗәпләнәсе юк, хилафлыкка һичнинди урын калмасын. Бер уйласаң, баш ватарлык берни кылмадылар, алар икесе дә командировкада булдылар...

**Илдар ХӘЙРУЛЛИН**

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫ

«Казан Экспо» Халыкара күргәзмәләр үзәгендә Бөтендөнья татар конгрессының VIII съезды булып узды. Ул Бөтендөнья татар конгрессы оешуга 30 ел тулуга багышланды. Анда дөньяның төрле почмакларыннан җыелган 1000гә якын делегат, 500ләп шәрәфле кунак катнашты.

Беренче көнне Казанның Иске Татар бистәсендә «Печән базары» заманча татар дизайны һәм татар шәһәр мәдәнияте фестивале үткәрелде. Икенче көнне съезд делегатлары һәм кунаклар өчен Изге Болгар тарихи-архитектура музей-тыюлыгына экскурсия оештырылды.

Өченче көнне «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәгендә «Идел Болгарстанында ислам динен кабул итүгә 1100 ел. Татар дөньясы һәм ислам дине», «Милли мирас. Татар мәдәнияте: бүгенгесе һәм киләчәге», «Милли үзаңны тәрбияләүдә шәҗәрәнең әһәмияте. Гаиләнең, балалар бакчасы һәм мәгариф системасының роле», «Татар эшмәкәрләре һәм иганәчелек», «Тарихи шәхесләр һәм хәзерге заман татар дәүләт эшлеклеләре: милли горурлык тәрбияләү мәсьәләләре», «Татар төбәк тарихын һәм татар тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү мәсьәләләре», «Татар мәгълүмат кыры: алда торган бурычлар» дигән темаларга дискуссия мәйданчыклары эшләде. Шул ук көнне И.Шакиров исемендәге концерт залында съездны ачу тантанасы булды. Аны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев ачты.

Съездның пленар утырышында Россия Федерациясе Президенты Владимир Путинның котлавы яңгырады. Съезд делегатларына һәм кунакларга РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин котлавы да ирештерелде. Пленар утырышта Васил Шәйхразиев (төп чыгыш), Татарстан Язучылар берлеге рәисе, ТР Дәүләт Советы депутаты Ркаил Зәйдуллин (Ркаил Зәйдулла), Үзбәкстан Республикасы татар һәм башкорт Аксакаллар шурасы рәисе Рим Гыйниятуллин, Казакъстан Татарлары һәм башкортлары конгрессы рәисе урынбасары, Казакъстан Республикасы «Туран» университеты профессоры Гриф Хәйруллин, Мордовия Республикасының «Татар эшкуарлары клубы» иҗтимагый оешмасы әгъзасы Рафыйк Фәтхуллов, Луганск Халык Республикасы Алчевск шәһәренең «Таң» татар мәдәният үзәге иҗтимагый берләшмәсе рәисе Флюр Карачурин, Бөтендөнья Татар конгрессының Башкортстан Республикасындагы вәкиле Альфред Дәүләтшин, «Татарстан – Яңа гасыр» (ТНВ-Планета) телеканалының «Халкым минем» тапшыруының авторы һәм алып баручысы Ләйсәнә Садретдинова һ.б. чыгыш ясадылар.

Съезд делегатлары Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасының яңа составын, рәисен сайлады. Рәис итеп яңадан Васил Шәйхразиев сайланды. Аның беренче урынбасары – Данис Шакиров (ул Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе дә), урынбасарлары – Федераль татар милли-мәдәни мохтарияте советы рәисе, РФ Дәүләт Думасының Милләтләр эшләре комитеты рәисенең беренче урынбасары Илдар Гыйльметдинов, ТР Фәннәр академиясе вице-президенты Дания Заһидуллина, Сарытау өлкәсе Төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Камил Әбләзов, Казакъстан Республикасы татар һәм башкорт конгрессы рәисе Тәүфыйк Кәримов.

Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасының яңа составын раслаганнан соң, сүз ТР Дәүләт Киңәшчесе, ТРның беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә бирелде.

Съездда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул шулай ук бер төркем милләттәшләребезгә дәүләт бүләкләрен тапшырды. Съездда резолюция кабул ителде.

### АВГУСТ КИҢӘШМӘСЕ

Быел мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең август киңәшмәсе «Цифрлаштыру чорында тәрбия һәм белем бирү: традицияләрне саклап, киләчәккә барабыз!» шигаре белән Яшел Үзән районында узды. Ул М.Ломоносов исемендәге 18 нче күп профильле лицейны ачу тантанасы белән башланып китте. Киңәшмәдә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул ата-аналар белән эшләү, яшь буында патриотизм һәм гражданлык хисе тәрбияләү кирәклеген,

сыйныф җитәкчеләренең тәрбия эшендә роле зур булуын, «Адымнар» күп телле белем бирү комплексларына, «Сәләт» хәрәкәтенә зур өметләр баглавын, соңгы дүрт елда мәгариф инфраструктурасын үстерүгә 40 миллиард сум акча бирелгәнен әйтте. Әлеге чарада чыгыш ясаган ТР мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин сүзләренә караганда, быелның 1 сентябреннән уку-укыту планнарына «ТР дәүләт теле – татар теле» предметы кертеләчәк.

### ТУКАЙГА ҺӘЙКӘЛ

Тукай районында Габдулла Тукайга һәйкәл ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов катнашты.

### ИСКӘ АЛУ

Казандагы 1 Май мәйданында фашист төрмәсендә җәзалап үтерелгән Муса Җәлил һәм җәлилчеләр Гайнан Кормаш, Абдулла Алиш, Фоат Сәйфелмөлеков, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаровларны искә алу мәрәсиме булды.

### «КАЗАН УТЛАРЫ» – «БӘЛЛҮР КАЛӘМ – 2022»ДӘ ҖИҢҮЧЕ!

Казандагы «Пирамида» концертлар залында XXV «Бәллүр каләм – 2022» республика бәйгесе лауреатларын бүләкләү тантанасы үткәрелде. Анда чыгыш ясаган Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев сүзләренә караганда, ел журналистлар өчен уңышлы булган. Конкурска эшләрнең күп килүе дә шул хакта сөйли. Тантанада катнашучыларны Татарстан Журналистлар берлеге рәисе, «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов сәламләде.

Быел «Ел медиа-шәхесе» исеменә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин лаек булды.

Бәйгенең җиңүчеләре 10 номинациядә (тагын 4 өстәмә номинация) ачыкланды. «Иң яхшы район (шәһәр) редакциясе» номинациясендә җиңүчеләр – «Казан утлары» журналы белән Балтач районының «Хезмәт» газетасы! Безгә тәгаенләнгән Дипом белән Бәллүр каләмне басмабызның баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин кабул итеп алды.

Бәйгенең иң зур бүләге – Гран-прига («Lada Granta» автомобиле) КФУның милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире Васил Гарифуллин лаек булды. Бүләкне аңа ТР Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева тапшырды.

### ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ХИКӘЯЛӘРЕ ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ

Төркиянең данлыклы «Һәҗә» нәшриятында (Анкара) «Хәзерге заман татар хикәяләре антологиясе – XXI гасыр» җыентыгы басылып чыкты. 376 биттән торган бу җыентыкка бүгенге көндә иҗат итүче утыз исән-сау язучыбызның яңа гасырда иҗат иткән берәр хикәясе кергән. Антологиягә кереш сүзне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла язган. Хикәяләрне төрек теленә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Фатиһ Кутлу тәрҗемә иткән. Китап Төркиядә сатуга чыкты. Тиздән бу антология Татарстан Язучылар берлегенең Әдәби тәрҗемә үзәге проекты буларак, Мәскәүдә рус телендә дә дөнья күрәчәк.

### «ФӘЙЗУЛЛИН ЙӨЗҮЛӘРЕ – 2022»

«Фәйзуллин йөзүләре»нең 44 нчесе Лаеш районында булып узды. Анда катнашучылар башта Атабай авылында әдәбият сөючеләр белән очрашты. Йөзү Ташкирмән авылы янында үткәрелде. Аксакал йөзүче, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин быел анда ике улы, оныгы белән катнашты. Алар һәммәсе, шулай ук «Татарстан – Яңа гасыр» телевидениесенең баш мөхәррире Данил Гыйниятов финишка беренчеләрдән булып килделәр.

2022 елның 4 августында 88 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова, Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби премияләр лауреаты **Әсгать Салах (Әсгать Сәхап улы Салахов)** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Иске Әлмәт зиратында җирләнде.

2022 елның 19 августында 63 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, С.Сөләйманова, Ш.Маннур исемендәге әдәби премияләр лауреаты **Илдар Шәмсулла улы Хәйруллин** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Түбән Камада җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Р.САБЫРА «Чисто татарское убийство»,
роман-фарс А.ХАМЗИНА «Примете?»; поэма Ф.ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ;
стихи Р.РАХМАН, Ф.СУЛТАН.
Литературный конкурс «Майдан - для батыров»: рассказ Л.АБУДАРОВОЙ «Черный ягуар», документальный рассказ А.ГАФИЯТОВА «Чугунный медведь».
«Новые имена»: стихи Л.Равиловой.
«Литература родственных народов»: рассказ В.ИСХАКОВА «Друзья».
«Свет далёких огней»: статья Р.КУРБАНА; стихи: Р.РАМАЗАНОВА,
Х.БАДРЕТДИНОВА в переводе Р.КУРБАНА.
«Юбилеи»: статья Г.ГАЙНУЛЛИНОЙ.
«Соплеменники»: статья Э.ШАРИФУЛЛИНОЙ.
«Тюркские литературы и современность»: статьи Ш.КУНТАЯ,
А.ГАРАЕВОЙ-АКЧУРА; отрывки из романа Р.САНАЯ «Турчанка из Красной России».
«Обзор книги»: статья М.ИБРАГИМОВА.
«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.
«Современник»: статья Л.НАСИХОВОЙ.
«Бесценные голоса»: статья к 135 -летию К.ТИНЧУРИНА. Рубрику ведет Н.АКМАЛ.
«Белый парус»: Р.ГИЛЕМХАНОВ «Маленький Риман».
«Страница сатиры и юмора»: рассказы-миниатюры З.МАНСУРОВА.
«Сенной базар»: юмористические рассказы И.ХАЙРУЛЛИНА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: памятник татарскому поэту Х.Такташу. Фото И.АБРАМОВОЙ;
писатель Айгуль АБДРАХМАНОВА.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by R.SABYR «Pure Tatar Murder»,
farce novel by A.KHAMZIN «Will you accept?»; poem by F.GIZZATULLINA;
poems by R.RAHMAN, F.SULTAN.
Literary competition «Maidan is for Batyrs»: story by L.ABUDAROVA «Black Jaguar»,
documentary story by A.GAFIYATOV «Cast-iron Bear».
«New Names»: poems by L.RAVILOVA.
«Literature of kindred peoples»: story by V.ISKHAKOV «Friends».
«Light of distant fires»: article by R.KURBAN; poems by R.RAMAZANOV, H.BADRETDINOV
translated by R.KURBAN.
«Anniversaries»: article by G.GAINULLINA.
«Tribesmen»: article by E.SHARIFULLINA.
«Turkic Literatures and Contemporary Times»: articles by Sh.KUNTAY, A.GARAEVA-AKCHUR;
excerpts from the novel by R.SANAY «Turkish Woman from Red Russia».
«Review of the book»: article by M.IBRAGIMOV.
«1100 years since the adoption of Islam in the Volga region»: article by I.ZAGIDULLIN.
«Contemporary»: article by L.NASIKHOVA.
«Priceless Voices»: article dedicated to the 135th anniversary of K.TINCHURIN. The rubric is led by N.AKMAL.
«White Sail»: R.GILEMKHANOV «Little Rieman».
«Page of satire and humor»: miniature stories by Z.MANSUROV.
«Hay Bazaar»: humorous stories by I.KHAYRULLIN.
Diary of social and cultural life.
On our covers: monument to the Tatar poet H.Taktash. Photo by I.ABRAMOVA;
writer Aigul ABDRAKHMANOVA.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Һади Такташ һәйкәле. *И.Абрамова фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы Айгөл Абдрахманова.